ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# Казан утлары

10.2006





**Сажидә Сөләйманова**
**(1926 –1980)**

# Казан утлары
# Qazan utları

2006

**10**

**(1008)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами, Рәдиф Сәгъди.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎: Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, фән һәм сәнгать бүлеге—541-38-77.
Шигърият һәм публицистика бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Компьютер үзәге һәм гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.
**Факс**—(843) 541-38-77.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Айдар ХӘЛИМ. Татарлар, берләшегез! *Шигырь.* ..... 5
Рауль МИРХӘЙДӘРОВ. Үзем хөкем итәм. *Роман.* ..... 6
Марсель ГАЛИЕВ. Шигърият рухы.*Эссе;* Балбал түшендәге тустаганнан. *Шигырьләр.* ..... 42
Фоат САДРИЕВ. Бәхетсезләр бәхете. Роман. ..... 51
Мөдәррис ӘГЪЛӘМОВ. Ил җанына — шигырь какты. *Шигырьләр.* ..... 89
Рәфкать КӘРАМИ. Олы юл да сикәлтәле. *Роман.* ..... 95
Айрат СУФИЯНОВ. Тоташыйм якты таңнарга. *Шигырьләр.* ..... 116
Наилә МИҢНЕХАНОВА. «Кызлар тавы»н йөгерепләр кичтем... *Шигырьләр.* ..... 120
Гайсә ГАТАУЛЛИН. Бездән сәлам булыр... *Шигырьләр.* ..... 123

**ДУСЛАР СҮЗЕ**

Равил БИКБАЕВ. Мәхәббәт дәфтәре. ..... 126

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Рафаэль ХӘКИМ. Татар рухы. ..... 128

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Илшат ВӘЛИУЛЛА. «Кай йөрәктән килә бу моң?» ..... 137

**СӘНГАТЬ**

Юныс САФИУЛЛИН. Сәхнәбезнең өч йолдызы. ..... 147
Земфира СӘЙДӘШЕВА. Чын татарча милли көй... ..... 155

**ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ**

Надир ДӘҮЛӘТ. Чит илләрдәге татарлар һәм Тукай. ..... 157

**ФӘН**

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. ..... 164
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ..... 166
«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ..... 168

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ. Бу нинди... сугышлы балачак? ..... 169

**САҖИДӘ СӨЛӘЙМАНОВАНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ**

Гөлзадә БӘЙРӘМОВА. Җырланмаган җырлар ни сөйлиләр? ..... 176

**ЮБИЛЯРЛАР**

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Барасы юллар озын. ..... 179
Марсель Зариповка 75 яшь ..... 182

**АК ҖИЛКӘН**

Лилия ЗАКИРОВА. Шаян хикәяләр. ..... 183
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ..... 188

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: романы Р. МИР-ХАЙДАРОВА «Судить буду я» (начало), Р. КАРАМИ «Тернистый путь» (продолжение), Ф. САДРИЕВА «Счастье несчастных» (окончание); рассказы Л. ЗАКИРОВОЙ, стихи А. ХАЛИМА, М. ГАЛИЕВА, М. АГЛЯМА, А. СУФИЯНОВА, Н. МИННЕХАНОВОЙ, Г. ГАТАУЛЛИНА.
«Слово друзей»: статья Р. БИКБАЕВА о М. Джалиле.
«Публицистика»: Р. ХАКИМ. «Метаморфозы духа» (продолжение).
«Литературная критика»: статья И. ВАЛИУЛЛИНА о поэзии М. Аглямa.
«Искусство»: Ю. САФИУЛЛИН. «Три звезды нашей сцены»; статья З. САЙДАШЕВА о композиторе Ш. Тимербулатове.
«К 120-летию Г. Тукая»: Н. ДАВЛЕТ. «Тукай и татары зарубежья».
«Наука»: А. ТИМЕРГАЛИН. «Словарь нации» (продолжение); Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень» (продолжение).
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Книжное обозрение»: рецензии Р. ШАРАФИЕВА на книгу Р. Башарова «Открытые ворота».
В номере отмечаются юбилеи Д. ФАТХИ; М. ЗАРИПОВА, С. СУЛЕЙМАНОВОЙ, Н. ГИМАТДИНОВОЙ.
Новые члены Союза писателей.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Казанский флот»—картина художника Н. ХАЗИАХМЕТОВА; писатель А. Гимадеев.

## IN THIS ISSUE:

«Prose and poetry» novels by MIR-HAYDAROV «I shall judge» (beginning), R. KARAMI «Thorny path» (continuation), F. SADRIEV «Happiness of unhappy people» (ending); stories by L. ZAKIROVA, verses by A. HALIM, M. GALIEV, M. AGLYAM, A. SUFIANOV, N. MINNEHANOVA, G. GATAULLIN.
«Friends' word»: article by R. BIKBAEV about M. Jalil.
«Publicism»: R. HAKIM. «Metamorphosises of spirit» (continuation).
«Literary critics»: article by I. VALIULLIN about poetry by M. Aglyam.
«Art»: Yu. SAFIULLIN. «Three stars of our scene»; article by Z. SAYDASHEV about composer Sh. Timerbulatov.
«To 120th anniversary of F. Tukay»: N. DAVLET. «Tukay and tartars of foreign countries».
«Science»: A. TIMERGALIN. «Dictionary of nation» (continuation); F. Garipova. «History our villages» (continuation).
Pages from «Tatar encyclopedia».
«Book review»: reviews by R. SHARAFIEV on book by R.Basharov «Open gates»;
In this isue are celebrated anniversaries of D. Fathi; M. Zaripov, S. Suleymanova, N. Gimatdinova.
New members of Union of writers.
From photoarchive of magazine.
Diary of sicial-cultural life.
On our covers: «Kazan fleet» - picture by artist N. HAZIAHMETOV; Writer A. Gimadeev.

*The magazine edits monthly*

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 20.09.2006 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^1/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ 3–821. Тираж 6032.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2006 ел.

Айдар Хәлим

## Татарлар, берләшегез!

Җавап тотар заман килде—
Байтакка тыңлашегез.
Иман нуры булып тамсын
Коръәнгә күз яшебез.
Азатлык өчен жанны да
Кызганмый көрәшегез.
Таңнарда серләшегез—
Татарлар, берләшегез!

Арабыздагы имансыз
Карагруһ көяләрен,
Милләтен сатып, мал җыйган
Бар эшем ияләрен,
Тамырлары белән йолкып,
Кояшка күрсәтегез.
Бер телдә сөйләшегез—
Татарлар, берләшегез!

Без—илен сөйгән илдәшләр,
Җегәрле, сәләтлеләр;
Ватаннан ватансызлыкны
Куарга сәбәплеләр.
Кайтып туган нигезләргә,
Ил өчен көрәшегез!
Бер моңда гөрләшегез—
Татарлар, берләшегез!



Рауль Мирхәйдәров

# ҮЗЕМ ХӨКЕМ ИТӘМ

РОМАН *

## I

Маңгаенда яңа яра эзе ярылып яткан кешенең сул аягына аксый төшеп, Яңа елга бизәлгән «Лидо» ресторанының иркен залына үтеп барганын күреп алган Миршабның шундук тамагы кибегеп китте, аның сулышы кыса, һава җитми башлады шикелле. Ул, дулкынлануын басарга тырышып, буфетчыга эндәште:

—Тиз генә берәр нәрсә салып бир әле...

Ләкин сүзләре тыныч кына чыкмады, аның яңаклары тартышты, шуңа күрәдерме, тавышы борчулы, үтенечлерәк килеп чыкты—аның гадәттәге боеручан ныклыгы кая киткән икән, диярсең? Борчылуы шул мизгелдә үк суырылып, агарынып калган йөзенә дә бәреп чыккан иде. Юкса, Сәлим Хәсәнович үзен тота белә, буфетчы да моны яхшы шәйли иде.

Теге сәер аксак кеше бер-бер артлы ике йөз граммны каплап куйгач, бокал-шешәләр белән бик оста уйнаучы буфетчыны да югалтып калдырды, буфетчы шунда ук ялгышты: гадәттәгечә әрмән коньягы саласы урында, тирләп торган шешәдән аракы салып, аны Сәлим Хәсәнович авызына китергәч кенә, үзенең ялгышлыгын сизенеп алды. Әмма ләкин иң гаҗәбе шул булды: үз теләгән генә үтәтә торган бик төгәл, «Лидо» рестораны хуҗабикәсенең сөяркәсе булган Сәлим Хәсәнович, ишектән чыгып баручы аксак кешедән күзен алмыйча гына, аракыны каплап куйды да кулы белән ишарәләп тагын салып бирергә сорады. Хашимовның аракы эчмәгәнен буфетчы белә иде юкса...

Буфетчы, ул сузган рюмкага аракы салгач,үзе дә ирексездән ишеккә таба карап алды. Ул Кареннның кыланып иелә-бөгелә, теге аксакка ишек ачканын күрде. Карен, тегене чыгарып җибәрүгә, Миршабның чакырулы күз карашын сизгәндәй, йөгереп диярлек буфет янына килде. Бер минут элек Миршаб кушаматлы Сәлим Хәсәнович шикелле үк, комсызланып:

Рауль МИРХӘЙДӘРОВ (1941) — *язучы; рус һәм татар телләрендә чыккан өч дистәгә якын китап авторы. Мәскәүдә яши.*

—Тизрәк бирәр нәрсә салып бир әле...—диде. Буфетчының кулындагы шешәне күргәч, өстәп куйды:—Күбрәк сал, бер стаканны тутырып...

Буфетчы көттереп тормады, күзе белән кабымлык эзләде...

Карен аракыны берьюлы йотып җибәрде, үзенә сузылган уылдыклы бутербродка игътибар итмичә, үзе һәрвакыт «шеф» дип йөртә торган кешегә эндәште:

—Ул бирегә очраклы гына сугылдымы икән, әллә Яна елыбызны тәмсезләү өченме икән?

Хашимов усал гына уйлап куйды: «Син минә кушканны үтәп, прокурорның «Жигули»ен сытып үтсән, хәзер безнең борчылуыбыз да булмас, бәйрәмебез дә матур гына үтәр иде». Әмма ул кычкырып башка сүзләр әйтте:

—Юк, очраклы түгел. Ул минә исәп-хисап ачканын белдерде, Сухроб белән икебезнең ана шактый бурычлы булганыбызны да искә төшерде. Аңладыңмы?

Миршаб үзенең хисләрен авызлыклап өлгергән иде, Карен алдында да үзен тыныч, ышанычлы итеп тотасы килде, тегесенең үзенә салкын канлылыгы, түземлелеге өчен гашыйк булганлыгын да белә иде ул. Кареннын абыйсы Ашот Артур Александрович Шубаринда озак кына тән сакчысы булып хезмәт итте, үзе дә «нервларсыз кеше» саналса да, шефының искиткеч тыныч холыклы булуына һәрвакыт соклана, аны үрнәк булырлык кеше дип саный иде. Каренны куркытырга, борчуга салырга ярамый иде. Һәрвакыт сак-сизгер Миршаб, буфетчы барын да онытып, сөйли башлады, буфетчы үзенә кирәкмәгән мәгълүматлардан ераграк булырга тиешлеген тоеп, сиздермичә генә кырын-кырын чыгып китәргә ашыкты. Маңгаенда тирән яра эзе булган теге кеше аның да күңеленә шөбһә салган иде. Ул кеше бит: «Хатыным өчен, улым өчен...»—дигән сүзләр ташлады. Нәрсә әйтергә теләде икән ул?

Буфетчы шәһәрдәге «эшлекле» һәм «эре» дип йөртелгән кешеләрнең күбесен белә—«Лидо» буфеты үзенең яхшы эчемлекләре күп булуы белән андыйларны үзенә тартып тора, ә инде бик тә кыйммәтчелеге белән очраклы кешеләрне бирегә кереп йөрүдән тыелырга да мәҗбүр итә иде. Әмма буфетчы күпме генә тырышмасын, тышкы кыяфәтенә караганда шушы шәһәрнекенә охшаган бу аксакны тәки хәтерли алмады. Карен исә хуҗасының һәр нәрсәгә көче җитәрлегенә күптәннән ышана. Югары суд кешесе булган Миршабның үзенә дә, әле җитмәсә Яна ел алдыннан борчу салырлык тагын кемнендер булуына һич ышанасы килми иде. Ләкин андый кеше бар икән шул, ул «Лидо»га үзе килеп керде—моны буфет янында сөйләшеп торучыларның йөзләреннән дә укып була иде.

Сәлим Хәсәнович, Кареннын күңелендәге борчылуны сизенеп, сүзне җинаятьчеләр дөньясындагы хәлләргә күчерергә тырышты:

—Прокурорның кыланышы бик ясалма, әллә нервылары түзмәдеме икән? Хәтерлисеңме,Стивенсонның «Хәзинәләр атавы» романындагы бер аяклы пират үзенең корбанына кара тамга китерә. Шулай килеп чыкты бугай, бу «мәскәүледән» бүген без дә кара тамга алдык шикелле.

—Ничек кенә булмасын, аның тарафыннан намуслы эшләнгән гамәл бу—ул ачыктан-ачык эш итә...—диде коры гына итеп Карен.

—Намуслылык—кыйммәтле гамәл, һәркемнең дә буе җитәрлек түгел...—дип сүзне томанлы гына йомгаклап куйды Хашимов һәм, Каренга Яна елны күңелле үткәрергә теләк теләп, ресторан хуҗабикәсенең бүлмәсенә юнәлде.

Нәргиз әкче селектордан кухняга йомышларын үтәргә кушып тора иде, Сәлим Хәсәнович исә кызыл телефон трубкасын алды да, Республика прокуроры дәваланып яткан травматология институтының этаж дежурные номерын җыйды—ул аны яттан белә иде.

—Рәхим итеп әйтегезче, бер-ике сәгатьтән прокурор Камаловка бәйрәм

табыны әзерләп илтсәк, соң булмасмы?—дип сорады ул итагатьле генә итеп, шул ук вакытта дежурныйны Яңа ел бәйрәме белән котларга да онытмады.

—Кем сорый әле моны?—дип шәфкать туташы кызыксынып сорады, прокуратура кешеләре аны тиешенчә кисәтеп куйганнардыр, күрәсең.

—Югары судтан Сәлим Хәсәнович Хашимов,—диде, үзенең хәйләкәрлегеннән канәгать калган Миршаб.

—Игътибарыгыз һәм борчылуыгыз өчен рәхмәт, Сәлим Хәсәнович, ләкин теләгегезне кире кагарга туры килә: прокурор Яңа елны безнең хастаханәдә каршыламый.

—Ул терелеп чыктымыни инде?—дип ясалма гаҗәпләнгән булды Миршаб.

—Юк әле, профессорыбыздан бер тәүлеккә сорап кайтып китте. Аңа әле бездә озак ятарга туры киләчәк...

Шәфкать туташының җавабыннан канәгать калган Миршаб, тынычланып, трубканы элеп куйды. Сөйләшүне ишетеп торган Нәргиз гаҗәпләнеп сорады:

—Син әллә Камаловны Яңа ел белән тәбрикләргә теләгән идеңме?

—Ә нигә тәбрикләмәскә, ди? Ни әйтсәң дә, коллегалар бит, бер үк эш белән шөгыльләнәбез. Аллабыз да бер—гадел хөкем итү. Андый һәлакәткә юлыгудан Ходай үзе сакласын, мин дә бит көн-төн машинада йөрим.—Ул, сөяркәсен бу эш-гамәлләргә бутамаска тели иде, шул ук вакытта, шәфкать туташы белән сөйләшеп, үзенә гаять кыйммәтле алиби—гаепсезлеген дә тәэмин итте бит, кирәк булса, шәфкать туташы аның белән телефоннан сөйләшүен дә раслар иде, мөгаен.

Урамда эңгер-меңгер төшеп килә иде, ишек алдындагы фонарьлар берьюлы кабынып китте. Иркен холлның зур тәрәзәләре аша лампалардан сирпелгән яктылыкта кар бигрәк тә матур төшә, әйтерсең лә, әкренәйтелгән кинофильмдагы кебек, һәм ул бәйрәм алды кәефен тагын да күтәрә иде. Койма буенда карга күмелеп утырган ике чинар агачы да кечке алдавыч яктылыкта чыршыларга охшап тора иделәр. «Аларны юкка гына төсле утлар белән бизәп куймаганнар?»—дип уйлап алды Сәлим Хәсәнович һәм Нәргизгә бүләк алмаганын да исенә төшерде. «Каһәр суккан «мәскәүле»!—дип эченнән генә карганып куйды ул. Шуның аркасында Яңа ел бүләге турында оныту ярыймы соң? Андый көндә мәгъшукаңны үпкәләтү—гафу ителмәслек хата булыр иде, андый чакта гафу үтенүләр кабул ителми.

Әмма «мәскәүле» һич кенә уеннан чыкмый. «Әгәр хәзер үк Нәргизгә берәр бүләк бирмәсәм, бу турыда янадан онытачакмын бит»,—дип уйлап алды ул. Ләкин уйлары һаман да прокурор тирәсендә бөтерелә, анда бәйрәмгә дә, үзе яраткан Нәргизгә дә урын юк иде шул.

Нәргиз килде дә, йомшак кына иркәләп башыннан сыйпады. Сәлимнең инде чал керә башлаган чәчләре әз генә көдрәләнеп тора, парикмахер кулы тимәсә дә, сөйкемле-күркәм кыяфәт бирә иде. Шулай да, Хашимовның үзен-үзе тотышында, тышкы кыяфәтендә ясалмалылык сыйфатлары сизелә, аның гел үзен генә кайгыртуы шәйләнә иде. Нәргизнең иркәләүләре Миршабны һәрвакыт тынычландыра, әмма бу юлы ул бүләген тапшырырга җай чыкканына гына куанды. Куе-зәңгәр «өчле» костюмының эчке кесәсеннән биш рәтләп тезелгән авыр ал муенсалы энҗе салынган тар гына тартманы тартып чыгарды. Кичә аңа рәхмәтле кешеләр хезмәтләре өчен бер «дипломат» тулы матур-нәфис әйберләр китергән иде, шулар арасында гаҗәеп зиннәтле алсу замшадан эшләнгән тартмада шушы искиткеч бизәнү әйберсе дә булып чыкты. Муенса шунысы белән аерылып тора: аның биш рәт тезелгән энҗеләре кыл уртадан бик тә матур зур зәбәрҗәткә тупланган иделәр. Миршаб кибеттә, дөньяларын онытып, бер сәгать буена шул гүзәл сәнгать әсәренә сокланып карап торды, төсе, күләме, формасы белән бер-берсеннән аерылып

торырдайларын эзләп табарга тырышты, әмма кытай Гонконгыннан килгән энҗеләрдә бер генә хилафлык та күрмәде. «Дипломат»ында башка бизәнү әйберләре дә бар иде, әмма прокуратураны талап чыккан көнне Бармаксызның Нәргизгә энҗе муенса бүләк итәргә биргән вәгъдәсен исенә төшереп, Яңа ел кичендә сөйгәненә нәкъ менә шушы матурдан-матур, күз явын алырлык бүләккә тукталды.

—Күзенне йом,—диде Миршаб, күтәрелә төшеп сөеклесенең аккоштай озын ак муенына муенсаны каптырып куйды, бер мизгелгә генә шунда Нәргизнең кап-кара чәчләренең авырлыгын да тоеп алды.

Соңгы елларда Ташкентка энҗе-мәрҗәннәрне Кытайдан кире әйләнеп кайткан әрмәннәр китереп тутыра иде, бу хакта Бармаксыз кушаматлы Арсен Парсегян да кайчандыр сөйләнгән иде, ә хәзер, Кытайга кереп-чыгып йөрү иреклегә әйләнгәч, Үзбәкстан белән Казакъстанда яшәүче уйгырлар һәм дунганнар шул кәсеп белән шөгыльләнә башладылар. Биш рәт тезелгән алсу энҗеле, зур зәбәрҗәтле муенсага Нәргиз шунда ук исе китеп карап торды, юкса, үзенең бер тартма муенсалары да бар иде: борынгы мөселман гаиләләрендә энҗе элек-электән үк бриллиант-алмазлардан кыйммәтлерәк саналган ич.

—Рәхмәт!—дип ихластан соклануын белдерде Нәргиз, сөеклесенең муенына кайнар куллары белән сарылып, ул Сәлимнең үзен чын-чынлап яратканына һич шикләнми иде.—Бу бит таң калырлык!

Бүләк аны шатландырды да, шул ук вакытта бераз күңелсезлеккә дә салды: ул, ашыгып бүләк биргәч, Миршаб кайтып китәр дип уйлаган иде, юкса Миршаб алай ашыкмый да иде әле.

Көзге каршысына килеп, әлеге бүләкне карап туйгач, Нәргиз күрше бүлмәгә күз салды, анда ике кешелек шәп табын корылган иде инде. Урамда бөтенләй караңгы төште, ә Нәргизнең үз бүлмә тәрәзәләре тоташ ишегалдына чыга, шуңлыктан анда һәрвакыт караңгы була иде. Ләкин Нәргиз ут яндырып тормады, ә дүрт мөгезле шәмдәлләрдәге хуш исле шәмнәргә генә ут алды, алар өстәл уртасында тора иде, утлар, юка фарфор чынаякларда һәм өстәл өстендәге көмеш савыт-сабаларда биешеп, күләгәләре биек диварларда уйный башлады. Бераз уйланып торгач, ул, зур булмаса да, бик юмарт-матур бизәлеп куелган почмактагы чыршының утларын кабызды, бары тик шуннан соң гына Миршабны залга чакырды. Йомшак кына лирик музыка,—атаклы Паппеттиның саксафоны,—бүлмә почмакларына куелган зур динамиклардан агыла, эреп килә торган шәмнәрнең ылысның исләре, бизәлгән чыршының ялт-йолт балкып торган утлары, ике кешелек итеп матур корылган табынлы өстәлнең шул утлар яктылыгында биешеп торган күләгәсе—болар барысы да Миршабка югалып барган бәйрәм тойгысын кире кайтардылар. Ул, Нәргизен кочаклап алды да, дулкынланып аның колагына пышылдады:

—Туып килүче Яңа ел котлы булсын, сөеклем...

Нәргиз аңа җинелчә үбү белән генә җавап кайтарды да, официантларга табынны әзерләп бетерергә кушмакчы булып, китеп барышлый ризасызлык белән әйтеп куйды:

—Кызганыч, без Яңа елны Ерак Көнчыгыштагыча гына каршылыйбыз...

Ул аның Яңа ел бәйрәмнәрен гел генә гаиләсе белән үткәргәнен дә белә иде, ләкин бүген үзенең үпкәләвен тыеп кала алмады. Ләкин Хашимов аның төртмәле сүзләрен колагына да элмәде, ул аны ишетми иде инде: уйлары янадан прокурор Камаловка әйләнеп кайтты.

Әгәр дә ул бүгенгә кадәр үзенә куркыныч янамавына инанып, «мәскәүленең» капкынына шефы һәм фикердәше Сухроб Әкрәмхуҗаев кына эләккән дип йөрсә,—ул аны уйларында да «Сенатор» дип кенә атый иде,—

хәзер инде иминлеге, бөтенләй үк җимерелеп төшмәсә дә, бик нык какшаган— үз тормышы да куркыныч астында калган иде.

Димәк, бер генә юл кала—кичекмәстән нәрсәдер эшләргә кирәк!

Качарга... Чибәр Нәргизне һәм Аксай ханы Акмалның үзенә биргән биш миллионын алып качарга кирәк. Хан аңа акчаны әллә ислам диненең яшел байрагы тантанасы өчен дип, әллә үзен КГБ кулыннан коткарган өчен биргән иде—анысының әһәмияте юк... Аның беренче уе шундый булды.

Әмма эчке бер тавыш аңа: «Аннары гомереңбуе төнлә килеп ишек шакуларыннан куркып яшәргәме?»—дип пышылдый иде. Шуна күрә, Миршаб бу акыллы фикерне шундук кызганусыз-нисез өзеп ташлады—хакимлексез тормыш итүне ул инде уена да китерә алмый иде.

Бер генә ышанычлы юл бар—прокурор Камаловны да, Бармаксыз кушаматлы Арсен Парсегянны да юк итәргә кирәк. Соңгысын республиканың җинаятьләр эзләү бүлегендәге хәйләкәр начальник Жураев КГБ изоляторына кертеп яшергән иде. Бармаксыз аңа гына түгел, фикердәше Миршаб тормышына да куркыныч яный торган күп нәрсәләрне белә иде.

Яңа ел якынлашып килүгә дә карамастан, менә хәзер шушы минутта ук нәрсәдер эшләргә, карар кылырга кирәк, сүз бит аның тормышы-язмышы хакында бара. Шулай булса да, акчалардан, хакимлектән, абруй-дәрәҗәдән баш тарту бик тә кызганыч иде. «Юк, син мине, Сенаторны эләктергән шикелле, тиз генә эләктерә алмассың!»—дип күңеленнән генә прокурор Камаловка янап куйды ул. Миршаб ачуы кайнап, башын тинтерәтә, миен бораулый башлаганын сизенде һәм үз-үзенә боерык бирде: «Тукта! Үзеңне кулга ал. «Мәскәүлегә» каршы бик нык уйлап, сак эш итәргә, чит куллар белән эш итәргә кирәк. Мөгаен, ул «Лидо» ресторанына да аны котырту һәм турыдан-туры һөҗүм иттерү өчен килгәндер дә әле, шулай капкынга каптырырга оста ул. Сигез пулялы «Франчи» пистолетлы снайпер Арифның үлемен онытма. Ул да бит үзе оештырган капкынга үзе килеп капты һәм һәлак булды. Ә Камалов аркасында Мәскәү милициясендәге югары урындагы күпме түрәләр төрмәгә эләкте. Органнардагы «убырлар»ны аулаучының ул икәнен исәпләп чыгарып кына котыла алдылар бит... Мәскәүдә дә, Ташкентта да бик күп кешеләрнең тамагына кадалган сөяк ул килешмәүчән прокурор, тормыш аны тәки бер нәрсәгә дә өйрәтмәгән икән...»

Ресторанның зур залындагы оркестр уен коралларын көйли башлады. Вакыт-вакыт, легендар Фаусто Паппеттиның саксафон тавышын басып, трубаның кинәт чинап җибәрүе ишетелеп куя. Көчәеп янып киткән шәмнәр якындагы почмакны яктырта, чыршының утлары балкып тора, ылыс исеннән җылы, уңайлы, күңелдә бәйрәмчә тойгылар күтәрелә—ләкин Сәлим берсен дә күрми, берсен дә ишетми, берсен дә тоймый иде. Ул һаман да прокурорның «Лидо»га көтелмәгәндә килеп керүе турында уйланып утыра.

Нәргиз аны шулай уйга батып утырганда килеп тапты. Ике официант артыннан кайнар һәм салкын кабымлыклар, үлән-сәлән, җиләк-җимеш, брынза ишеләрне тезгән кечкенә өстәлне тәгәрәтеп китерделәр. Нәргизнең кулында матур-матур эре мандариннар салынган ваза иде. Ерак Абхазиядән кайтарылган мандариннарның хуш исе Миршабның аңын уятып җибәрде, ул, көчәнеп кенә булса да, прокурор турындагы уйларыннан арынып, Нәргизне басып каршы алды һәм ихластан сокланып:

—Нинди гүзәл мандариннар, нинди хуш исләләр!—диде.

Нәргизнең гаҗәпләнүенә каршы, ул шактый озак утырды, моның үз сәбәпләре бар иде—ул уйлаган ниятен озын-озакка сузмаска карар кылды. Чибәр Нәргиз белән тәмләп ашап утырганда, Камалов турындагы уйлары бөтенләй онытылды дигәндә генә, кинәт Коста исенә төште... Миршаб бу юлы аның ярдәменнән башка эш барып чыкмасына төшенде. Егетнең Яңа

елны «Лидо»да каршылавын белгәнгә күрә, ул биредә тоткарланган да иде, шунын белән Нәргизне дә чиксез шатландырды.

Коста ресторанга килеп керүгә, ана Хашимовның «Лидо»да икәнен әйттеләр, ул үзенең шефы Шубаринның компаньонын Яна ел белән котларга керде. Бер-берсе белән итагатьле генә фикер алышкач, Миршаб аны Яна елдан соң ук үзенә кунакка килергә чакырды. Югары суд кешесенең бәйрәм көннәрендә үз өенә чакыруыннан Коста аңлап алды: димәк, нәрсәдер булган. Костаның ризалыгын алгач, Сәлим Хәсәнович гаиләсе янына кайтырга ашыкты, аның өчен бәйрәм беткән иде инде—бурычлары өчен исәп-хисапны аңа бик житди кеше ачкан иде шул.

II

Ресторанда көтмәгәндә генә Хашимов белән очрашканнан соң, машинасы янына чыгып барган Камалов үзенең тыелып кала алмавына үкенә иде инде. Үен кәртләрен ачмаска—гаиләсен кем үтерткәнен, үзенә Коканд-Ленинабад юлында кем һөҗүм оештырганын белгәнлеген сиздермәскә кирәк иде бит. Хәзер Хашимовның нинди гамәл кылачагын белеп булмаячак: ул Акмалханның элекке биләмәләренә качып китәргә яки аның кешеләре ярдәмендә җинел генә Әфганстанга ук чыгып сызарга да мөмкин. Әфганстандагы сугыш вакытында контрабандистлар ышанычлы кереп-чыгып йөрү юллары булдырдылар, ә Югары суд кешесенең элемтәләре дә җитәрлек, акчалары да аздан түгел. Әгәр дә Сенатор Акмалханның ышанычлысына әйләнгән икән, бүген Сәлим Хәсәнович аның миллионнарын рәхәтләнеп туздыра алыр иде.

Ләкин нәтиҗәле булырлык тагын бер юл бар, анысы ике мәртәбә өзелде инде—тегене тәки юк итә алмадылар ул чакта, тагын тырышып карарга кирәктер инде. Монысы Миршабның күнеленә ятышлырак иде: уңышлы барып чыкса, очын югалтасын да, Сенатор иреккә чыгу юлын күрәчәк: Бармаксыз саф-намуслы кешегә, демократия һәм гаделлек өчен көрәшүчегә прокурор Камалов коткысы белән яла яккан, диячәкләр.

«Ничек кенә әйтсән дә, ялгыштым шикелле»,—дип үзен шелтәләде прокурор, машиналар туктала торган иркен мәйданнан Нортухта машинасын эзләштереп. Алар бит Фирганә вакыйгаларыннан соң Арифнын капкынына бергә эләккән иделәр. Әмма күнеле бу вакыйгаларга катгый бер генә бәя бирергә карыша иде: «Әйе, мантыйк буенча ялгыштым да шикелле. Ләкин бит тормышта һәммәсе дә, математикадагы шикелле, «плюс» яки «минус» белән генә бәяләнми»,—дип үзен ышандырырга тырышты ул, кинәт кенә аңлап та алды: бу бәя белән салкын канлы прокурор түгел, ә яраткан хатынын һәм улын үтергәннән соң кайгыга баткан ир кеше килешә алмый иде. Шул яктан караганда, ул уй-ниятләрен ачып дөрес эшләде, тегеләргә рәхим-шәфкать булмаячак, көтмәсеннәр дә, җәзасы иң югары дәрәҗәдә булачак: үлемгә—үлем, канга—кан. Ул үзен ирләрчә тотты, күзләренә карап туп-туры әйтте, бу гамәле белән горурланырга да мөмкин булыр иде, ә инде бәйрәм хисен бозган икән—анысы очраклы гына килеп чыкты, ул һич тә андый максат куймаган иде. Бүген, мөгаен, Яна ел Миршабка да куаныч китермәстер, аның куркуы йөзенә үк чыккан иде бит. Бу уе прокурорны тынычландырып кына калмады, ә көтелмәгән нәтиҗәгә китерде: әгәр ул, «Лидо»га килеп кереп, ачыктан-ачык үзенә һөҗүм итүчеләрне кем котырткан лыгын белгәнен әйткән икән, Хашимов үзе өстеннән җитәрлек дәлилләр җыелганын һәм аны кулга алырга ордер да әзер икәнлеге турында да уйларга мөмкин ич. Прокурор кадәр прокурор нигезсез генә янамас иде. Югары суд кешесенең башына шундый уй килмәс идеме? «Бик килер иде»,—дип үз-үзенә җавап

бирде прокурор һәм елмаеп та куйды. Монардан бер генә нәтиҗә ясарга була—Миршаб хәзер үк нәрсәләрдер эшләргә тотынып, аның икеле-микеле уйланыр вакыты калмады...

Нортухтаның аксыл-көрән казна «Волга»сы Ташкент номерлары булган зиннәтле ике «Мерседес» арасына куелган икән, ә ул үзе каршыда торган чия төсендәге «Вольво»ны күзәтеп тора иде. Затлы «Вольво»га күз төшереп алуга, Камалов Совминдагы эре кап-йотның киявен—ОБХСС майорын исенә төшерде. Кодрәтовны ниндидер Варлам исемле рэкетер белән бергәләп Бармаксыз талаган иде түгелме соң? Алар ОБХСС майорының ике йөз егерме биш меңгә нәкъ менә чия төсендәге «Вольво» сатып алырга җыенганын белгәннәр бугай. «Кодрәтов машинасы түгелме соң бу»—дип уйлап алды прокурор һәм машина номерын, кирәге чыга-нитә калса, дип язып та алды. «Яна елны «Лидо»да каршы алырга бик кәттә кешеләр җыела шикелле»,— диде ул үз-үзенә, бу тантаналы мәҗлесне видеотасмага төшереп алсаң—кызыклы гына кино килеп чыгар иде.

Нортухта прокурорны күрүгә, машинасы янына ашыкты. Чыгып барышлый, ул хәйләкәр генә сорап куйды:

—Миңа сез «Вольво» хуҗасын беләсездер кебек тоелды, юкса, бу машинаның әле шәһәрдә күренә башлавына ике-өч ай гынадыр, сез ул вакытта хастаханәдә идегез ич...

—Әйе, син хаклы. Машинаның хуҗасы, минемчә, милиция хезмәткәре Кодрәтов. Шулай да, минем гөманымны тикшереп кара әле, мин бит ярты ел инде эштән аерылган, барысын да белеп бетермәвем дә мөмкин.

—Әле базарга барып та кермәдек, ә Ташкентта күпме шәп чит ил машиналары үрчеде, ә алар янында безнең «Волга»быз бер калтырча шикелле генә,—дип тавышына рәнҗү-үпкә чыгарып әйтеп куйды шофер.

—Әйе. Республикада беренче «Мазерати» кайчан күренер икән дә, аның хуҗасы кем булыр икән?—дип прокурор аның сүзләренә куәт өстәде. Аның тизрәк «Лидо»да булган вакыйгалар турындагы уйларыннан котыласы килә иде.

—Ә минем аны ишеткәнем дә юк,—диде шоферы.—Бик шәп машинамыни?

—Әйе. Экстра-класс, супер-люкс! Италиядә аерым кешеләр соравы буенча гына эшләнә, хуҗаның бөтен теләкләрен үтәргә тырышалар икән. Мин Парижда да аларның бер өч-дүртен генә күреп калдым. . .

Дархандагы йорт янына тиз килеп җиттеләр, Камалов, сәгатенә карап алгач:

—Димәк, мин сине иртәгә сәгать дүртләрдә көтәм,—диде.—Мин хастаханәгә кичке карауга кадәр кайтып җитәргә вәгъдә биргән идем. Сине һәм барлык туганнарың-якыннарыңны Яңа ел белән котлыйм!—Аннары ишек тоткасына тотынгач кына, дулкынланып өстәде.—Дөресен әйткәндә, теге һөҗүмнән соң син миннән башка машинага күчерүне сорарсың, дип уйлаган идем. Миндә эшләү куркынычлыктан башка бернәрсә дә вәгъдә итми бит. Менә хәзер мин сиңа бәхет, имин-тыныч тормыш теләр идем дә, әмма без астыөскә килгән дөньяда яшибез, биредәге уенда тигезлек була алмый. Гадәттәге шома сүз-теләкләргә телем әйләнмәсә дә, барыбер сиңа ак бәхетләр, иминлектынычлык телим! Яхшы кеше син!—Ул сулышын кыса төшеп туп-туры әйтеп бетерергә карар кылды.—Ярты сәгать элек кенә мин Фирганә вакыйгалары вакытында безгә капкын коручыларның берсен күрдем. Мин сиңа тагын бер тапкыр уйларга киңәш итәм—минем белән эшләргә кирәкме икән сиңа? Әгәр башкача уйласаң, сиңа үпкәләмәм...

Озак кына уйланып утыргач, Нортухта телгә килде:

—Юк, Хөршид Азизович. Ресторанда сезгә нәрсәдер булганын тойдым. Мин

алар артыннан барырга бик теләгән идем дә... Сез ярты еллап дәваланып ятканда бу жылы урын бик күпләрнең телендә булды. Бу елан оясына бик зур кешеләр игътибар итә, диләр. Сезнең килеп чыгуыгыз күпләрнең тамагына калалган сөяктәй булгандыр...—Ул муенына сызып күрсәтте.—Ә минем эшемә килгәндә... Гадәти ирләр эше бит, үзем сайлап алган эш. Беләсезме, Әфганда йөргәндә безнең бер әйтем бар иде: «Су кичкәндә атларны алыштырмыйлар»... Шулай булгач, Яна елны каршы алгач, көрешкәнгә кадәр... Димәк, иртәгәгә кадәр...

... Инде ярты ел булмаган өенә кайтып кергәч, прокурор сәер хисләр кичерде, ул моның күп вакыт үтүдән түгеллеген дә анлый иде. Ул үзенең Мәскәүдәге фатирына Парижда унөч ай торып кайтып кергән иде, ә Вашингтоннан бервакыт хәтта ике елдан соң гына кайтты, әмма алар башка шартларда булган иде. Бүген исә ул, әйтерсең лә, яшәү белән үлемнең теге ягыннан кайтып керде, хәзер ул үзенең, егерме сигез көн үлем белән тартышканнан соң гына, могҗиза белән генә исән калганлыгын анлый—аны, гадәттәгечә, хатыны белән улы да каршы алмады...

Әле өйдә аларның куллары тоткан әйберләр аларның жылысын-исен саклыйлардыр кебек иде... Тәрәзә төбендә онытылып калган китап, ванна бүлмәсендәге крем, караватт янындагы башмаклар, тартма төбендәге теннис ракеткасы, язу өстәлендәге музыка тыңлый торган колакчын—болар һәммәсе дә хуҗаларын көтеп тора шикелле. Әмма алар юк, юк шул инде...

Әле ике генә сәгать элек аларның каберләре янында булып кайтса да, Камалов күнеленнән якыннарының һәлак булуларына ышана алмый, кешедә һәрвакыт ниндидер могҗизага ышану яши бит. Аның көчсезлектән, нәрсәнедер үзгәртә алмавыннан кычкырып елап җибәрәсе килде, и-их, калерле кешеләрен кайтарасы иде дә бит... Әле кичә генә улы һәм хатыны белән утырган кебек, диванга ыңгырашып авып төште ул.

Каралып беткән борынгы кызыл агачтан эшләнгән зур идән сәгате. Яна елга бары тик алты гына сәгать калганын искәртеп, чыңлый-чыңлый сугып куйды. Бу сәгатьне дә хатыны очраклы гына комиссия кибетеннән сатып алып кайткан иде. Ул шунда кинәт кенә үз тормышында да Яна вакыт башланганын тойды.

Шушы тойгыдан соң, ул тирә-юнендәге әйберләргә дә башкача карый башлады—күнегелгән, якын әйберләр аларны тәрбияләп-карап торган хуҗабикәнең ягымлы кулларыннан башка аптырашып калганнар шикелле тоелды. Шунда улы һәм хатыны белән бергә һәлак булган булса, бу өйдә бөтенләй ят кеше хуҗа булып йөрер, аларның әйберләрен тотар-файдаланыр, сәгатьнең сугу тавышларын тыңлар шикелле тоелды... Әле мона кадәр аның яшәү шул кадәрле кыска, бары тик бер җептә генә эләгеп торганын тойганы юк иде. Ә бит юкса яшьлегеннән үк, кем әйтмешли, гомере кыл өстендә булгалады.

Ул үзе дә сизмәстән:

—Өлгерергә кирәк бит!—дип ыңгырашып куйды. Юкса бу сүзләрне Миршаб белән ресторанда очрашуга һич тә бәйләми иде шикелле.

«Өлгерү»—аның өчен уй-ниятләренең бер өлешен булса да тормышка ашыру иде. Ул гомеренең, уйланган ниятләренең комга сеңгән су кебек юкка чыкканнарын тойгандай булды. Ә бит аның ул эшләре «Үтә яшерен» тамгасы белән әле һаман да, җәмәгатьчелек таләп итмәгәч, сейфларда ята, һәм безгә ничә елга соңга калганлыгыбызны искәртә кебек... Ул Юрий Владимирович Андроповның искәрмәстән бик иртә үлеп китүен кызганды, түрә кеше аны кайчандыр үлемнән йолып калган иде бит.

Озак кына вакытлар хатынының булмавына карамастан, өй ташландык хәлдә түгел, ул туган-тумачаның бирегә гел генә булып торуларын белә иде, шуна күрә йә телефон шылтырар, йә ишек кыңгыравы тавыш бирмәсме дип

тә көтте. Ул якыннарының берсен дә: «Яңа елда өйдә булам»—дип кисәтмәде. Бик матур кар ява иде, бу нияте дә шуның тәэсирендә килеп чыккан иде бит. Туган-тумачалары, аның кайтуын белүгә үк, үзләренә кунакка чакыра башлаячаклар. Әмма аның Яңа ел төнен ялгыз гына каршы аласы килә, хәтерендә гаиләсе белән үткәргән бәхетле көннәрен яңартмакчы, үзенең эше-тормышы, бу заман турында ялгызы гына уйланып утырасы килә иде. Ә бит туганнары, аның кайтканын белеп алгач, бер минутка да тыныч калдырмаячаклар. Аларның үзе турында ихластан кайгыртуларын белсә дә, бу бәйрәм кичендә кәефләрен бозасы килми иде. Камалов өчен, ничәмә-ничә еллардан бирле туган иленнән еракта, чит-ят җирләрдә яшәгәнлеге, әлбәттә, эзсез үтмәгән иде, ул хәзер, шәрекь гореф-гадәтләреннән битәр, күбесенчә европача яши, әмма тегесенә яки монысына да өстенлек бирми иде. Шулай килеп чыкты инде, аның хезмәте һәрвакыт тулы иркенлек һәм бәйсезлек сорый, ә туган-тумача арасында кеше эреп бетә, меңләгән шартлылыклар белән бәйләнгән була. Шуңа күрә ул үзен күпсанлы туган-тумачалары арасында ничектер уңайсызрак сизә, туганнары да моны беләләр һәм аны бик аптыратмаска тырышалар, әмма шулай да... Бүген аның бигрәк тә ялгыз каласы килә, үзенең мөмкинлекләренә һәм югалтуларына бәя бирергә кирәк иде, ул бит Миршабка турыдан-туры әйтте: сезгә һөҗүмгә кучәм, диде.

Караңгы төште, борынгы сәгать моңлы гына итеп ике тапкыр сугып куйды, ул Яңа елның якынлашып килүен белдерә иде, ә Камалов әле һаман өскә күтәрелеп ут яндыра алмый азаплана, квартирын бер әйләнеп, йокы бүлмәсенә дә сугылырга, улы бүлмәсенә, кухняга да күз салырга тели иде ул. Янә аягы биленнән үк авырта башлады. Ул үзенең бүген дә йоклый алмаячагын төшенде. Кинәт телефон шылтырады. Камалов, аягының авыртуын басарга теләп урыныннан күтәрелде, кулын телефон трубкасына суза да башлаган иде, әмма тукталып калды: ул бит Яңа елны ялгызы гына каршы алырга җыенган иде—шулай итсә, барысына да яхшырак булыр төсле.

Почмактагы сәгать янә сугып, Яңа елга бер генә сәгать калганлыгын белдерде, Камалов, стеналарга тотына-тотына, утны кабызырга барды. Аягы тагын да ныграк сызларга тотынды, ул ишек яңагына сөялеп шактый озак басып торды, вакыт инде уникегә якынлашып килә иде, Яңа елны каршы алырга әзерләнәсе бар бит, һич югы символик рәвештә генә булса да, дип, Камалов янә әле өстәлгә, әле урындыкка тотынып буфет-бар ишеге төбенә килеп җитте. Ул барда, әлбәттә, нәрсәдер булганлыгын белә, Вашингтоннан кайтыр алдыннан хатыны, бер бизәк булыр дип, зиннәтле виски белән джин сатып алган иде, соңгы чиктә шуларның берәрсен ачарга була ич! Ләкин барда аракы да, коньяк та табылды, дөрес, «Столичная» ярты гына шешә калган булып чыкты, ул аны бер читкәрәк этеп куйды да җирле «Үзбәкстан» коньягын алды, ни әйтсәң дә, бәйрәм бит, ә бу коньяк дөньядагы башка коньяклардан да калышмаслык иде.

Ул инде барның эчке көзгеләрен каплап торган ишеген ябарга җыенган гына иде, күз карашы ялтыр-йолтыр килгән күпсанлы болтларның берсенә төште: әйе, барның яшерен серле бүлеме дә бар иде. Камаловның аны ачып карамаганына да күптән инде, юкса эчендә нәрсә сакланганын белә бит. Ул теге болтка бармагы белән басты, көзгеле бүлем тавышсыз гына, әкрен генә эчкә батып китте. Бүлемнән тынчу һава бәреп чыкты. Камалов караңгыдан кулы белән капмалап бер төргәк тартып чыгарды да, көзгеле бүлемне ябып куйды. Аннары коньяк шешәсе белән серванттан бер чәркә алды, теге төргәге дә кулында иде, шуннан ул өстәле янына килде.

Төргәкне сүтеп, прокурор коралның әле үзенә Мәскәүдә яшь чагында ук яхшы таныш булган рәхәт авырлыгын тойды, пистолет, әлбәттә, әйбәт иде. Ул Мәскәүнең университет аспирантурасында укыганда ук, Ташкентка китеп, андагы

прокуратурада эшләп алды, үзенең фәнни хезмәтенә ул елларда сирәк булган теманы—«Гадел хөкемгә каршы җинаятьчеләр» дигәнен сайлап алды. Бу тема хокук саклау органнарының үз эчендәге җинаятьләре турында иде. Үзен кызыксындырган бер сорау белән ул КГБга мөрәҗәгать итте, ул алган мәгълүмат аның киләчәк бөтен тормышы өчен ачкыч булды. Ана, әлбәттә, барысын да чыгарып салмадылар, шулай да Камалов шактый нәрсәләр белән танышты, инде өченче тапкыр да әрсезләнеп һәм үҗәтләнебрәк барып кергәч, КГБ хезмәткәре, шаярткандай итеп, төрттереп әйтеп куйды: «Һе, бик елгыр икәнсең, әзергә бәзерне генә алмакчы буласың, үзең безгә килеп эшләсәң, тәмлерәк булыр иде»,—диде. Бу сүзләр Камаловның бәгыренә барып кадалды, бер атнадан соң, ул аспирантурада укуын калдырып, җинаятьләрне ачу бүлегенә эшкә килде—аның яшерен максаты милициядәге «убырлар» һәм хыянәтчеләрне аулау иде.

Аның эше алмаш-тилмәш кизү тору белән генә чикләнми, эш сәгате беткәч, ул да, башка офицерлар шикелле үк, коралын тапшырып китә, аның яшерен миссиясе бик куркыныч булганлыктан, аңа бер елдан соң шушы пистолетны бирергә мәҗбүр булдылар: үзе өчен үлем куркынычы яный торган эштә иде шул капитан.

Җиде елдан соң, Камалов инде подполковник дәрәҗәсе алгач, бер кораллы банданы юк итү операциясе үткәргәндә, аңа хезмәттәше терәп үк диярлек атты. Хыянәтчеләр үзләрен кем аулаганын инде белеп алган иделәр. Менә шунда Камалов, үзендәге пистолеты белән атып, тете бәдбәхетне юк итте. КГБның бер ябык уку йортында диссертация яклагач, аңа исемле пистолет бүләк иттеләр, пистолетны аңа Андропов үзе тапшырган иде.

... Төн уртасы җитәргә чирек сәгатьтән дә азрак вакыт калган иде, ул, җинаятьләрне ачу бүлегендә хезмәт иткән еллары турындагы истәлекләреннән арынып, каршында торган зур көзгегә күтәрелеп карады. Көзгедән Сальвадор Дали пумаласына лаек булырлык сурәт күренә иде: Яңа ел якынлашып килә, өстәл янында утыручы авыру кыяфәтле кешенең маңгаенда тирән яра эзе, алдында—бер шешә яхшы коньяк белән юан корсаклы тәбәнәк кенә чәркә һәм тагын авыр, әмма һәрвакыт ышанычлы Макаров пистолеты, аны чит илләрдә еш кына «рус пистолеты» дип йөртәләр. Шул вакыт телефон янадан шылтырады, хәзер инде аның ялгызлыгын бозарлык ара калмаган иде, ул трубканы күтәрде.

—Хәерле кич, Хөршид Азизович,—дигән ягымлы хатын-кыз тавышы ишетелде.—Яңа елыгыз котлы булсын, саулык-сәламәтлек, бәхет-шатлык, иминлек телим сезгә!—таныш түгел хатын-кызның теләге ихластан иде, Камалов аның кем икәнлеген хәтерләргә тырышты. Телефондагы кеше моны сизенде булса кирәк.—Сез, мөгаен, мине танымыйсыздыр, мин бит сезгә беренче тапкыр шылтыратам. Ике атна элек мин сезнең янга хастаханәгә кереп чыккан идем. Татьяна Георгиевна, Таня булам мин, хәтерләдегезме?

—Хәтерлим, Танечка, әлбәттә, хәтерлим. Сезнең дә Яңа елыгыз котлы булсын. Елкы елы уңышлар, бәхет китерсен үзегезгә...

—Рәхмәт! Сезне ишетүемә бик шатмын. Котларга дип, хастаханәгә сугылган идем дә, сез инде чыгып киткәнсез икән. Әмма бер ярты сәгать элек мин кинәт кенә сезнең өегездә ялгыз гына утырганыгызны сизендем, юкса Ташкентта туган-тумачаларыгыз күплеген дә беләм, сизенүем алдамаган икән, үзегез белән сөйләшә алуымнан икеләтә канәгатьмен...

Шунда сәгать уникене суга башлады, Камалов исенә килеп:

—Таня, Яңа ел котлы булсын! Ишетәсезме, сәгать суга? Сез хәзер бокал күтәрә аласызмы?

—Әйе, өстәлемдә—шәраб, борынгы сәгатегезнең сукканын да ишетәм.

—Хәзер, бер генә секунд,—прокурор кабалана-кабалана бокалына гадәттәгедән артыграк итеп коньяк салды.—Менә хәзер минем дә кулымда

бокал. Инде шулай килеп чыккан икән, әйдәгез, бер-беребезгә уңыш телик тә, эчеп куйыйк, без бит бер Аллага—Гаделлеккә генә хезмәт итәбез.

Алар, Ташкентның төрле почмакларында торсалар да, бокалларын берьюлы бушатып куйдылар.

Камалов үзе дә көтмәстән:

—Сез хәзер кайда эшлисез?—дип сорады.

—Мирзо-Олугбәк районы прокуратурасында..

Камаловның уе өлгереп җиткән иде, ул шуны әйтеп калырга ашыкты:

—Элек сөйләшкәндә сез минем белән бергә эшләргә теләк белдергән идегез. Кире уйламадыгызмы?

—Юк. Сез чын эш белән шөгыльләнәсез, минем сезгә файдалы буласым килә.

—Бәйрәмнәр уткәч, прокуратураның яңа бүлегенә—оешкан җинаятьләр белән көрәшү бүлегенә кирәгез әле. Анда күп кенә яшерен документлар бар, мин аларның ышанычлы кулларда булуын телим. Курыкмыйсызмы? Шәрекътә шундый әйтем бар: чит кеше серләре гомерне кыскарта.

—Курыкмыйм. Мин сезнең белән очрашканчы да курыкмый идем, тәкъдимегезне Яңа ел бүләге итеп кабул итәм...—Таня кызларча бер шаянлык белән өстәп тә куйды.—Сезнең Яңа ел теләкләрегез инде тормышка да аша башлады, мин хәзер үк бәхетле...

Бер-берсенә Яңа ел төнен күңелле үткәрүне теләп, алар саубуллаштылар.

«Хастаханәдән чыгу белән күпме әһәмиятле вакыйгалар булып узды»,—дип уйлады прокурор, иске елның соңгы сәгатьләрен исенә төшереп, ә шулай да «Лидо» ресторанында аңа гаҗизлектән кызып китмәскә кирәк иде, ул моны хәзер бөтен тирәнлеге белән аңлады. Ул үзен яхшы оештырылган мафия алдында бер ялгызы калган кебек тойган иде, кая карама, аларның кешеләре шикелле булды. Ялгышкан икән, ул ялгызы түгел, шофер Нортухта да ташлап китмәде, юкса Фирганә вакыйгалары вакытында кеше үтерүчеләрнең үзләрен ауларга ничек тырышып йөргәннәрен дә күргән иде бит; Татьяна Георгиевна, республика прокуратурасындагы хыянәтчене ачып салган Таня да, үз тормышын куркыныч астына куйса да, аның белән хезмәттәшлек итәргә әзер. Ә республиканың җинаятьчеләрне эзләү бүлеге начальнигы полковник Жураев, ә үзенең оешкан җинаятьчеләр белән көрәшү бүлегендәге егетләр—һәммәсе дә Аксай ханы Акмалны кулга алганда үзләрен күрсәтеп өлгерделәр бит. Озын көн буена уйчан-җитди йөргән Камаловның йөзенә беренче мәртәбә елмаю кунды, ул әле исенә төшергән иптәшләренең һәрберсен күңеленнән генә Яңа ел белән котлады, аларга уңышлар теләде—алар өчен дә гади булмаган Яңа ел килеп җиткән иде инде.

«Менә минем өчен бәйрәм дә бетте...»—дип уйлап алды ул, өстәл янынннан кузгалып. Карашы пистолетка төште... «Аны яңадан яшереп куярга кирәк,—дигән карарга килгәч, Камалов сервантка таба атлады, ләкин аны коралдан аерылудан нindidер эчке хис тыеп тора иде. «Нәрсә инде бу? Хастаханәгә пистолет белән бар, имеш»,—ул үз-үзе белән бәхәсләшә иде шикелле. Кинәт ул үзенең милициядә эшләгән вакытын исенә төшерде, аны эчке сизенүе бер вакытта да алдамый иде, шуңа күрә коралны үзе белән алырга булды.

### III

Артур Александрович Шубарин инде сигезенче аен Германиянең Мюнхен шәһәрендә заманча банк хезмәтен өйрәнә иде. Аның Германияне сайлап алуы очраклы түгел. Мәктәптә ул немец телен, ә институтта инглиз телен өйрәнгән, һәр ике телдә дә әйбәт кенә сөйләшә, ләкин болар төп сәбәп түгел иде. Кайчандыр ул, прокурор һәлак булганга кадәр,

Азларханов белән икътисади хәлләр турында сөйләшеп утыргач, алар безнен илгә теләсә нинди финанс һәм кредит системасы ярамас, хәтта алга киткән илләрдәге алым-ысуллар да нәтиҗә бирмәскә мөмкин, Россия белән элек-электән географик, тарихи, икътисади, сәяси, мәдәни бәйләнешләры, үзара аралашып үрелгән гореф-гадәтләре булган илләрнең тәҗрибәләрен алырга кирәк, дигән фикергә килгәннәр иде. Шубарин карашынча, бу җәһәттән иң унай илләр Европада, шул ук вакытта ул Америка, гаҗәеп Япониясе Азия илләрен дә исәптән бөтенләй сызып ташламый, ләкин банк хезмәте, валюта эшләре нигезенә бары тик Европага хас система гына салынырга тиеш дип саный.

Европада Россиянең күп кенә илләр белән меңләгән бәйләнешләры бар, әйтик, иң әүвәл Франция белән. Әмма Шубарин Германиягә барырга карар кылды, чөнки ул анлый: немецләрнең ике ягы бергә кушылгач, Европада гаять зур мөмкинлекләре булган яна дәүләт барлыкка килде. Якын елларда әнә шул яңа Германиянең икътисади көч-куәте Япониясен дә, Америкасын да дөнья базарыннан кысрыклап чыгаруы бик мөмкин. Европада моны иң беренче булып инглизләр үз җилкәләрендә татый башлады, анысы инде исәпкә алынырга тиешле тарихи чынбарлык. Америкага һәм бөтен Европа илләренә шулкадәр озак каршы тора алган безнен дәүләтебезнең дә, күпләрнең гаҗәпләнүенә каршы, кояшы бик тиз баеды бит.

Тевтон рыцарьлары заманыннан бирле Россия белән Германия күп тапкырлар сугышкан булсалар да, аларны шактый нәрсә берләштерә, хәтта хакимиятне үз кулларында тоткан Габсбурглар һәм Романовлар династияләре дә берничә гасыр буена үзара туганлашып яшәгәннәр, ә Екатерина II (әби патша) заманыннан башлап немецләрне Россиягә төпләнеп яшәргә чакыра торган булганнар, хәзер дә әле илдә алар ике миллионнан артык. Соңгы елларда үзләренең тарихи ватаннарына кайтып китү бик көчәйсә дә, алар әле Россиядә күзгә күренерлек милләт. Германиягә банк хезмәтен өйрәнергә киткәндә Шубарин монысын да искә алган иде. «Туганлыкны белмәгән Иван» әйтеме бары тик русларда гына, башка телләрдә ана охшаш әйтемне һич эзләп табып булмастыр. Ә Германиядә исә Россиядә яшәүче милләттәшләрен беркайчан да онытмаганнар һәм онытмыйлар.

Үзенең шәхси банкын ачарга ниятләгән Шубарин башта ук аның Германия белән нык элемтәдә булуына йөз тотты. Казакъстан, Кыргызстан, Үзбәкстан җирләрендә укмашып яшәгән немецләр арасында да үз банкының бүлекчәләре-филиаллары булыр дип өметләнә иде ул. Аннары алар аша немец эшмәкәрләрен һәм банкирларын турыдан-туры җәлеп итеп, үз ватандашларына шушында ук төрле предприятиеләр, зур булмаган, әмма бик файдалы заводлар төзергә ярдәм итсәләр, Россиядән Германиягә күчеп китү дә тукталыр иде. Бу мәсьәлә бит һәр ике ил өчен дә четерекле булып кала бирә әле. Шубарин Германиядә бу җәһәттән үзенә фикердәшләр тапты.

Әле теге «торгынлык» дип яманаты чыккан елларда ук Шубарин Көнбатышта еш була иде, аның дус-ишләреннән кемнеңдер бер сүз әйтүе дә җитә—барлык ишекләр дә ачыла иде. Шуна күрә дә ул һәрвакыт кайтып-китеп йөри алды. Ул заманда бит бер генә нәрсәдән куркалар—теге кемсә, чыгып китеп, кайтмый калмагае тагын, янәсе. Ә Артур Александрович Шубарин өчен курыкмаска була, аны Көнбатышта бернәрсә белән дә кызыктырып калдыра алмыйсың. Барып, күреп, өйрәнеп кайту—монысы ярый торган эш, ә шунда калып яшәү—урыс җанлы Шубарин өчен берничек тә була торган гамәл түгел иде.

Үзгәртеп коруның беренче, буталчык елларында ул, теләсә, башкалардан күп алда үзенең байлыгын чит илгә күчереп өлгергән булыр иде, әмма ул моны да эшләмәде. Аның компаньоннарыннан күпләр әле җитмешенче елларда ук Көнбатышка китеп бардылар, әмма, баесалар да, үзләре янында финанс

даһие Шубарин булмауны юксына иделәр. Аларга аның эчке сиземе, тимердәй ныклы кулы, искитәрлек инженерлык белеме житмәде. Алар аңа уртак эшләр тәкъдим итеп карадылар, янәсе, Японец (аны үзара шулай атап йөртә иделәр), байлыгын саклап һәм ишәйтеп алар ягына чыга алыр иде. Хәзер Көнбатышта гөрләшеп яшәп ятучыларның байтагы Шубаринга бурычлы иделәр: кемнәрдер аның тирәсендә «ипигә май ягып» яшәде, икенчеләренә ул йә акча белән, йә киңәшләре белән, ешрак һәр икесе белән дә ярдәм итеп килде. Ә кемнәрнедер, үзенең дус-ишләре ярдәмендә, үлемнән дә йолып калды—шуны онытырга мөмкинме соң? Аның Германиядә икәнлеген ишетеп-белеп алгач, әле үзләренең рус гореф-гадәтләрен югалтып бетермәгән бу кемсәләр аның янына Мюнхенга да еш килеп йөри башладылар. Ял көннәренең бик сирәген генә Мюнхенда үткәрә башлады ул: дуслары киләләр, йә Германиягә, йә Швейцариягә, йә Австриягә утыртып алып та китәләр.

Ана банк курсларында укуны оештырган фирма Шубаринга укырга йөри торган җиреннән ерак та түгел бер әйбәт районнан җиһазландырылган квартир да алып бирде, ул шуннан чиста-пөхтә бакча-парк аша гына укырга йөри иде. Ләкин бүген ул дәрәҗәле Кайзерштрассе урамындагы биш йолдызлы «Рица» отеленә өч кенә көнгә күченеп торды. Мюнхенның «Бавария» футбол командасы уенын карарга һәм аның белән күрешергә дип, күптәнге дусты, инде унөч ел АКШта яшәүче Мәскәү грузины Гвидо Лежава (хәзер-мистер Лежава) киләсе иде. Дөрес, Лежава Америкадан түгел, ә Португалиядән килә, анда аның үз шөгыле бар, Лиссабон тирәсендә диңгез буендагы атаклы Эшториаль комлыгына якын гына, бер шәп йорт сатып алган. Лиссабонны да ул сәер генә итеп Лизбон дип атый. Көнбатышта да Гвидоның күптәнге мавыгуы үлмәгән—ул һаман футбол ярата, үзе Тбилиси «Динамо»сы белән Мюнхен «Бавария»се өчен яна-көя икән. Бу юлы да ул «Бавария» белән Португалиянең «Бенфика» клублары арасында Европа чемпионнары кубогына финал уенын карарга килгән, ә яраткан клубы уенчылары янына үз өенә кайтып кергән кебек кереп йөри икән. Гвидо «Рица» отелендәге шәп ике номер өчен дә, футбол уенын карау өчен иң шәп урыннар кулдан меңәр доллар торса да, аларын да үзе түләп алган.

Мюнхенда элекке танышлары булгач, Артур Александрович акчага аптырамый, курсташлары һәм банк житәкчеләре карашынча, бик иркен-мул яши иде. Ул, өстәмә түләп, ике бүлмәле квартирын өч бүлмәлегә алмаштыручы бердәнбер кеше булды—иркенлекне ярата торган күптәнге гадәте җинде. Килеп бер атна үтүгә, актан-ак, «Мерседес» сатып алды, еш кына Франкфуртка опералар, Штутгартка балетлар карарга йөри башлады. Аны инде Мюнхен эшмәкәрләре ябык клубларга да бер генә чакырмадылар, үзләре атаклы Бавария банкына тәҗрибә тупларга килгән бу урыс баен игътибар белән күзәтә-өйрәнә иделәр.

Көнбатыш эшмәкәрләре гадәтле бу рус бае, чит илдә дә бик тиз үзләшеп, ышаныч һәм хөрмәт казана башлады. Аңа соңгы вакытларда киңәш сорап бик дәрәҗәле кешеләр килә, андый кешеләр белән танышу жаен башкалар еллар буе көтә, ә болар аны үзләре кунактан-кунакка дәшеп кенә тора—бирегә сәяхәтнең иң зур уңышы да шунда, ә бит ул үзе бирегә килергә кыенсынып кына жыенган иде. Кайвакытларда Шубарин: «Көнбатыш эшмәкәрләре өчен Россия базары буенча киңәшләр бирүче генә булсам да, күптән баеп беткән булыр идем инде»,—дип уйлый. Әмма Россия өчен дә кояшлы көннәр килер әле, анда да үзенең тәҗрибәсе һәм белеме кирәк булыр, дип ышана.

Ул «Рица» отеленә, Гвидо килеп житәргә берничә сәгать калганда ук, үз «Мерседесе»нда жилдереп килеп туктаган иде инде. Биредә менә дигән бассейн һәм массаж бүлмәләре барын белә, инде икенче атна теннис кортына да бара

алмый, рәхәтләнеп йөзәргә дә жай юк—көннәре бик тыгыз булды шул. Үз исемен әйтеп, сигезенче каттагы бүлмә ачкычларын алгач, хезмәтче ана тагын бер жетон калай тоттырды да:

—Сезнең өчен отельдә һәр жиргә юл ачык, моны мистер Лежава эшләде, шушыны гына күрсәтегез. «Рица»да ял өчен һәммәсе дә бар, вакытыгызны күңелле үткәрегез,—диде.

Йөзеп туйгач, бераз саунада да утырып чыгып, массажчыда һәм чәчтараштта булганнан соң, ул үз бүлмәләренә кайтты. Ташкент һәм Мәскәү белән сөйләшеп алмакчы булган иде дә, өлгермәде—телефон шылтырады, трубкада Гвидо Лежава тавышы иде.

—Исәнме, Артур. Мин Германиядә инде, аэропорттан шылтыратам. Биредән «Рица»га кадәр бер сәгатьлек юл, әмма бүген барлык юллар да дыңгычланган, мин моны һавадан ук күреп килдем. Немецләр стадионга, мөселманнар кәгъбәгә ашыккандай, ашыгалар. Әйе, «Бенфика»га бүген авырга киләчәк.

—Ярар, егетләр сынатмаслар дип ышанам,—диде Шубарин.

—Аска төшеп, итальян ресторанын эзләп тап, ул ун канатта булыр. Русча итеп яхшы кабымлыклар, туклыклы ашлар белән өстәл әзерләт, ә андагы эчемлекләр безнең грузиннарныкы кебек, син аларны аера беләсең, хәтерлим әле... Сине бик сагындым, төнге сөйләшеп утыруларны, мәжлесләрне... Биредә бөтенләй башкача яшиләр, өч мәртәбә миллионер булсаң да, аларга күнегә алмыйсың...—дип сүзен сүрән генә бетерде ул.

Атаклы «Бавария» футбол клубы стадионына алар гадәттәгедән озаграк бардылар, юкса Шубарин шәһәрне дә яхшы белә иде. Мюнхен урамнарында тоташ машиналар агымы, монда кайлардан гына, нинди генә машиналар юк: итальян, француз, грек, төрек... Бары тик безнең ил машиналары гына күренми, бездә хәзер футбол кайгысы түгел шул. Болар, машиналарын шактый еракта калдырып, халык ташкыны арасында җәяү генә әле тагын ярты сәгатьләп бардылар һәм уен башлануга гына килеп өлгерделәр.

Уен бик киеренке, каты булды, беренче унбиш минутта ук арбитр һәр ике яктан да берәр уенчыны куып чыгарды, ләкин уенның кызуы сүрелмәде, мәйдан хужаларының өстенлеге сизелсә дә, беренче таймның исәбе тигез—1:1 булды.

Сызгырып утыру белән кайнарланган Гвидо тәнәфестә сикереп торды:

—Артур, утырып тор, мин «Бенфика» егетләре янына төшеп менәм, вәгъдә биргән идем. Алар бүген төнлә кайтып китәләр, ике көннән Лизбонда мөһим календарь уены.—Ул малайларча йөгереп кенә, аска төшеп китте, аларның урыннары ике команданың да чишенү-киенү бүлмәләре өстендә генә иде.

Шул чагында Шубаринны борчуга салган сәер бер очрашу булды. «Рица»да шәпләп ашап-эчкәннән соң, аның тамагы кипкән иде, ул чыгу юлында йөрүче сатучыдан бер шешә минераль су алып бирүләрен сорады. Француз суы «Перрье»не аңа таба килгән бер ир кеше китереп бирде. Суны биргәч, ул рөхсәтсез-нисез генә, аның янәшәсенә, Гвидо урынына утырды һәм кинәт кенә саф үзбәкчә:

—Хәерле көн, Артур Александрович! Мюнхенда ничек яшәлә соң? Андыймондый борчуларыгыз юкмы?—дип сорады.

Гадәттәге үз-үзен тота белүе ярады, Шубарин, сүзсез-нисез генә суын эчеп бетерде дә, үзбәкчә сөйләшә торган сәер кешегә борылып карады. Тегесе кырык яшьләрдәге ир, модалы булса да, капчыксыманрак эленеп торган костюмнан, кыйммәтле һәм бик тә кычкырып торган галстук та таккан, күрәсең, анысы Кайзерштрасседагы берәр француз кибетеннән алынгандыр, сөйләшүе һәм тышкы төс-кыяфәте белән Ташкент кешесенә бик тә охшаган үзе. Мәскәү яки Ленинградта ышанып шулай дип әйтеп булыр иде, әмма Мюнхенда, житмәсә әле стадионның иң кыйммәтле урыннарында якташыңны очрату.

Артур Александровичның күзе кинәт кенә әнгәмәдәшенең кулына төште: тегенең бармакларындагы эре бриллиантлары,—аларны бездә гади генә «болванкалар» дип тә йөртәләр,—үзен башы-аягы белән «безнең кеше» икәнен, беләзегеннән, бетерергә тырышып та бетерә алмаган татуировкасы утырып чыкканлыгын дәлилли иделәр.

Шубаринның үзе каршысында утыручы бу кеше безнең илчелек яки консуллыктан, йә булмаса башка оешмадан, яки футбол буенча кубок уены финалы турында язучы берәр журналисттыр дигән уйлары шундук юкка чыкты. Шубарин бу ябык йөзле, нечкә генә итеп калдырылган мыеклы, йөгерек күзле кешене, күпме генә тырышса да, исенә төшерә алмады. Ә бит теге, никадәр затлы-шәп киенсә дә, үзенең күптәнге җинаятьче, берничә кат утырып чыкканлыгын яшерә алмый иде.

Шубарин җинаятьчеләр дөньясын яхшы белә-таный һәм беркайчан да ялгышмый иде. Шуңа күрә:

—Рәхмәт. Минем бер мәшәкатьләрем дә юк. Дөрес, Ташкентымны сагынам,—дип, сүзне тәмамларга ашыкты ул. Чөнки хәзер Гвидо килеп чыкса, бу көтелмәгән якташның кем икәнлеген абайларга мөмкин иде бит. Ә банк эшләре белән танышырга теләгән кеше мондый җинаятьчеләр белән аралашырга тиеш түгеллеге көн кебек ачык—үзенә ниндидер тап төшергән банк ул инде—нонсенс, ягьни булмастай хәл.

—Әйе, без сезнең Германиядә эшләрегез әйбәт барганын белеп торабыз, сезнең белән бик абруй-дәрәҗәле кешеләр кызыксына, сез, немецләрдән башка да, шактый атаклы эшмәкәрләрнең ышанычын казангансыз. Мистер Лежава да сезнең банкка акча салырга әзер шикелле.

—Без әле ул хакта сөйләшеп өлгермәдек,—дип сүзне кисәргә ашыкты Шубарин. Аның бу кешедән тизрәк котыласы килә иде.

Тегесе, вакыт икесе өчен дә бик кысан икәнен чамалап, дәвам итте:

—Сез мөстәкыйль рәвештә һәм уңышлы гына итеп Европа банк системасына тамыр җәеп киләсез, сезнең немецләргә һәр ике яктан йөз тотуыгыз, гади һәм шул ук вакытта бөек тә. Сезнең шикелле бу очракта кем дә булыр микән, ай-һай!. Беренчелек сезнеке! Шуның өстәвенә, сезнең, Лежава кебек, көнбатыш бизнесында шактый дәрәҗә тоткан дус-танышларыгыз да юк түгел. Боларның һәммәсе дә биредә уңыш казанган очракта искә алынмый калмастыр.

Артур Александрович, теге адәмнең алдан өйрәтелгән сүзләр сөйләвен аңлап алгач, бүлдермәскә булды—вакыйгаларны аңлап бетерергә кирәк иде.

Тегесенең артык тырышуданмы, маңгай-муеннары тирләп чыкты, әйтәсе сүзләре онытылып бетмәгәе дип, ул аларны тезәргә ашыкты.

—Сез аңлыйсыздыр, хәзерге интеграция вакытында Европада зур акчаларны «юу-чистарту» һаман да кыенлаша бара, моның өчен шактый зур бәяләр дә түләргә туры килә. Шуның өстенә, Англия һәм Американың эре банкларында булып узган скандал-шау-шулардан соң, сезне минем немец дусларым белән хезмәттәшлек итәргә үзе үк этәрә шикелле. Банк эшләре безнең өчен яна әле, шуңа күрә, тикшереп-нитеп тормастан, әле кем тикшерсен, диген, акчасы килә икән—хуш! Үзебез дә һәр тикшерүчене танып беләбез, дөресрәге, кайсысына күпме түләргә кирәклеген белә идек, ә инде килешергә теләмәгәннәрне хәл итү—безнең кайгы-хәсрәт... Безгә абруй-дәрәҗәле банк кирәк, немец дусларым аңа сез сөйләшкән кешеләрнең барысыннан да күп мәртәбәләр артык капитал салырга әзерләр. Сез мине аңлыйсыздыр дип уйлыйм?—дип сорады таныш түгел кеше, озак дәшми торган Артур Александровичның сынаулы карашыннан югала төшеп.

—Бик аңлыйм,—дип кыска гына җавап бирде Шубарин. Безнең илдә фахишәлек белән җинаятьчелек кенә халыкара дәрәҗәдә, дигән раславына

тагын бер мәртәбә исбатлау алды ул. Менә алар халыкара мәйданда да беренчеләрдән пәйда булдылар: башкалар суверенитет дип, аның чыны да, ялганы турында да лаф органда, болар инде үзләренең «агач» акчаларын шунда ук валютага әйләндереп куячак, үзләренең чит илдәге коллегаларыннан аны «юып» биргән өчен башка җирләрдәгедән бер дә ким сыдырмаслар, юкка гына алар Россиядәге аз процентларга исәп тотмыйлар...

—Немец коллегаларым сезгә һәркайсы йөз мен маркалык биш чек язды, аларны үзегезнең эшегез өчен файдаланыгыз...

—Мин сезне тулысынча аңладым,—дип тегеләмне бүлдерде Шубарин.— Миңа акча кирәкми, мин аны дусларымнан да алып тора алам, әйтик, мистер Лежавадан. Ә инде банкка килгәндә, без атылмаган аю тиресен бүлеп маташабыз шикелле. Бу хакта соңрак, Ташкентка кайткач сөйләшербез...

Эчендәге нәфрәте кайнап торса да, ул тыныч сөйли. Бу көтелмәгән кешене бик тә модалы галстугыннан тотып алып, гырылдый башлаганчы, умырткалары шытырдаганчы буасы килә иде. Ләкин мондый әдәмчекне алай гына эләктерә алмассың—артында кемнәр тора икән, шуны тәгаен генә белергә кирәк.

Кунак, күрәсең, мондый сөйләшүгә дә әзер иде, аның икенче запас варианты да бар икән.

—Юкка гына сез чеклардан баш тартасыз, алар ихластан иде, ярты миллион марка—акча ул. Ә Ташкентта, сезне хафага салып булса да, әйтим инде, анда зур үзгәрешләр... Үзәк Комитеттагы дустыгыз Сухроб Ходжаев хәзер «Матросская тишина» төрмәсендә.

Прокурор Камалов сезнең Югары судтагы икенче таянычыгыз Хашимовның да койрыгына баскан шикелле. Сезгә дустанә булган Аксай ханы Акмал төрмәдә; Заркент өлкә комитеты секретаре сезнең беренче ышанычлы кешегез Әнвәр Абидович Тилләходжаев унбиш елга хөкем ителгән. Ә без үзгәртеп кору дип йөртә торган хәзерге заманда, Артур Александрович, сез яңа дуслар таба алмадыгыз. Сез тирә-якка җирәнеп карадыгыз, сезгә һәммәсе дә нувориш байлар, бер сәгатьлек кенә хәлифләр булып тоелды, ә юкка гына... Хәзер сез Ташкентта беркемгә дә таяна алмыйсыз... Без, бары тик без генә сезнең талантыгызны тиешенчә бәяли алабыз. Сез банкир булырга хыялланган идегез, булыгыз соң, ярдәм итәрбез, булышырбыз, якларбыз...

Кунак кинәт кенә урыныннан күтәрелде, ашыгып саубуллашты да, җир астына төшеп киткәндәй, юкка чыкты. Баскычтан, үз урынын эзли-эзли, мистер Лежава менеп килә иде.

... Хан Акмалны кулга алганнан соң Аксай тынып, катып калды, үз кабыгына бикләнде. Акмал Ариповтан тыш, төбәктә котырынган аның якыннарыннан тагын берничә кешене дә алдылар. Аксай халкы, ниһаять, бу үзгәртеп кору белән безгә дә көн килер дип, шатланып бетә алмады. Әмма ай арты айлар үтә торды, ә яхшырак мул-имин тормыш Аксайда күренмәде. Киресенчә, начарланганнан-начарлана гына барды.

Әгәр баштарак халык урамнарда, чәйханәләрдә, туй мәҗлесләрендә Акмал хан кул астында озак еллар яшәгәндә күнелләрендә җыелган ризасызлыкны чыгарып түксәләр, хәзер хәл бөтенләй үзгәрде. Гади халык янадан җиргә генә карап йөри башлады: Акмалның хан кайтып төшүе чынбарлыкка әйләнде, бу бигрәк тә аңа тәлинкә тотучыларның кыяфәтендә үк чагыла иде. Алар башларын горур чөеп, янадан яный башладылар: туктагыз әле, менә Хуҗа кайтыр, ул сезгә хәбәрдарлыкны да үзгәртеп коруны да, фикерләр төрлелеген дә, демократияне дә күрсәтер, диделәр...

Аксай халкы Фирганә вакыйгаларында мәсхәт төрекләренә каршы оештырылган һөҗүмнәрдән соң бигрәк тә пошаманга төшеп калды.

Гел актан киенеп, тын гына йөри торган намаз карты, Акмал Ариповның

остазы Сабир-бобоның яңадан күнеле күтәрелеп китте. Россиядә христиан диненең меңъеллыгын бәйрәм итү уңаеннан хөкүмәт дингә башта христианнарга, аннары мөселманнарга да түземлерәк карый башлады. Күп еллардан соң Мәккәгә хаҗ кылырга баручыларны мөселман диния нәзарәте сайлап алды. Кәгъбәдәге изге ташка табынып кайтыр өчен Сабир-бобо да хаҗга җыенды. Ул хәтта күнеленнән генә уйлап та куйды: әгәр дә аны изге Мәккә белән Мәдинә калаларына кертсәләр, анда берәр кара бәрәнне корбан чалырга рөхсәт итсәләр, димәк Аллаһы Тәгалә ихтыяры белән Сабир-бобо үзе үтергән бертуганының улы—хыянәтче Мәхмүт өчен Ходай аны ярлыкаган дигән сүз булачак.

Сабир-бобо Сөгуд Гарәбстанына хаҗ кылырга хәтта ике тапкыр барып кайтты, хәзер инде ул бертуганының улы оҗмахка керәчәк дип чын күнеленнән ышана. Хаҗдан беренче кайтуга ук ул якташларына Аксайда мәчет салдыру өчен зур сумма акча бирәчәген дә белдерде.

Надан дехканнарны иң гаҗәпләндергәне Сабир-бобоның мәчет салырга сайлаган урыны булды. Мәчетне Аксайның Кызыл мәйданында Ленинга куелган мәһабәт һәйкәл каршында ук сала башладылар, Даһи юлбашчының алга сузган кулы беркая да күрсәтми икән. Сабир-бобо, күрәсең, алдан күрә белгән: зур мөселман бәйрәмнәрендә бер генә мәчет тә бу кадәр диндарларны сыйдырып бетерә алмас иде, ә бу мәчет алдындагы Зур мәйданда барысына да урын җитәчәк. Ә инде намазга җыелган халыкны Ленин карап тора икән— зур бәла түгел, заманында аңа да җитмеш елдан артык табынганнар бит, нәтиҗәсе һәркемгә билгеле. Ахыр чиктә, Аллаһы Тәгалә дә һәр кешегә бәхет һәм тигезлек вәгъдә итмәгән. Аннары Ленин биредә бик озак тора да алмас: Россиядә, Украинада, Молдавиядә көн саен диярлек пелләш юлбашчыга куелган һәйкәлләрне җимереп торалар бит. Мәкальдәгечә: «Ни чәчсән— шуны урырсын». Үз вакытында юлбашчы фәрманы белән чиркәү-мәчетләрне җимереп бетергәннәр, руханиларны атып үтереп, чиркәү чаңнарыннан унитазлар һәм юлбашчыларга һәйкәлләр койганнар, ә хәзер менә аның меңләгән бронза скульптураларын яңадан чаңнар коярга тотарлар—чиркәү-мәчетләр дә хәзер көн саен үсеп чыгып кына торалар, ә илдә бакырга кытлык...

Мөселманнарның изге җирләргә хаҗга барып кайтулары безнең өчен әле гадәти булмаган күренеш, шуңа күрә хаҗиларны пәйгамбәрләргә тиңлиләр диярлек. Ә Сабир-бобо ике барып кайтты бит, әле тагын Аксайда үз акчасына мәчет тә салдырмакчы була, шуңа күрә аның абруй-дәрәҗәсе бик нык үсте.

Ил-дәүләттә вакыйгаларның тиз алышынып торуы Сабир-бобоны әле куандыра, әле куркыта да иде. Зур илнең таралып төшүе, республиканың бик күптәннән көтелгән бәйсезлекне алуы, бер караганда, яхшылыклар гына вәгъдә итә. Чит ил прокуратурасының гаепләүләре Үзбәкстанда үз көчен югалтыр, Акмал Арипов үзеннән-үзе иреккә чыгар иде. Ә инде өенә кайткач, Аксай хуҗасы нишләргә кирәген белер, КГБ подвалларында утырганлыктан, сәяси абруе да артыр иде.

Икенче бер нәрсә куркыта... Бәйсез республикада хакимияткә кем килер? Элек һәммәсе дә ачык иде: хөкүмәт, андагы түрәләр Аксайда хәл ителә, хан Акмал хуплавыннан башка беркем дә министр була алмый, алар барысы да танылган, яхшы гаиләдән чыккан, хөрмәткә лаек, җитәкчелек тәҗрибәсе туплаган партия әгъзалары, ниндидер урын биләмәгәннәре турында сөйләшеп тә тормый иделәр. Әмма хәзер әлегә кадәр тын яткан Үзбәкстанда да халык кайный башлады, кайдандыр яңа әйдәп баручылар пәйда булды—шагыйрьләр һәм әдипләр, галимнәр һәм журналистлар, инженерлар һәм агрономнар... Халык шуларның сайрауларын тыңлый, шуларга ышана, яңа партия һәм төрле агымнарга дәррәү кушыла. Алар республиканы кая алып чыгарлар, алып чыга алырлармы, яки, сүз боткасы пешереп, буш куык кына булып калырлармы? Шәхес хокукларының, милләт-дәүләт мәнфәгатьләре алдында

гражданнарның беренчеллеге—монысы нәрсә икән? Совет кешесе бит кечкенәдән үк дәүләт мәнфәгатьләре—иң мөһиме, дигән уй-фикер белән тәрбияләнеп үсә иде. Димәк, барысы да киресенчә булып чыгамы? Ташкенттагы яңа демократлар белән аларның өлкәләрдәге дуслары республиканы кая илтеп кертерләр? Ә дин, ислам дине нишләп бетәр? Ул дәүләткә йогынты ясый алырмы, яки үзбашка яшәргә хөкем ителерме?

«Юк, бер дингә генә ышанып яшәргә иртә әле,—дип уйлый Сабир-бобо.—Аңысы төбәктәге карт-корылар өчен генә, алар дәүләт тормышында төп көч тә түгел, һәммәсен дә элеккечә партия номенклатурасы, урыннардагы житәкчеләр хәл итә».

Урта Азия республикаларында, бөтен илдәге кебек үк, үзгәртеп кору елларында бер нәрсә дә үзгәрмәде диярлек. Килеп туган вәзгыятьтән файдаланып, бер ыругныкылар икенчеләрен куып тарата, биредә бер-берсен батыру һәрчак дәүләт исеменнән башкарыла, халык моны законлылыкның тантана итүе дип уйлый, үзәк тә шул ук фикердә—коммунистлар, житмеш ел ил белән идарә итеп, Шәрекъне, аның асылын аңлауда бер адым да алга китә алмадылар. Юк, дәү..әт белән идарә итәрлек, аңык программасы булган кешеләрне эзләргә кирәк. Сабир-бобо ‹әрәкәт итәргә, Ташкент белән элемтәләр урнаштырырга кирәклегенә көннән-көн ышана төшә иде. Шәхсән үзе барып очрашырга тиешле беренче кеше итеп ул Югары суд хезмәткәре Сухроб Әкрәмходжаевның иске дусты һәм күптәнге хезмәттәше Сәлим Хашимовны сайлады.

## IV

Прокурор Камалов алдан чамалаганча, Миршаб Яңа елны куркып каршы алды, әмма гаиләсенә һәм якыннарына сиздермәде, бер дә булмаганча күңел ачты. «Лидо»дан өенә кайтып кергәндә, аларда энесе белән сеңелесе утыра иде инде. Һәр икесе гаиләләре белән килгән икән. Бераздан хатынының туганнары да килеп житте. Сәлим хезмәтендә бик тиз югарыга үрмәләгәннән соң, зур бәйрәмнәрне гел аларда гына үткәрә башладылар. Урта Азиядә шул рәвешле ырудан иң зур уңыш казанган туганга хөрмәт күрсәтәләр.

Һәркемнең язмышында туган-тумачаның нинди урын тотканын белү өчен Шәрекътә яшәргә кирәк. Ырусыз, туган-тумачасыз кеше, жирле күзлектән караганда—беркем түгел. Биредә кем турында булса да белешергә кирәк булса, иң әүвәл аның кайдан, чыгышы белән кайсы жирләрдән икәнлеген, кемнәр белән туганлашканлыгын сорашалар—тегe яки бу кешенең ни өчен хөрмәтле булганлыгы, ниндидер урын биләгәнлеге шунда ук ачыклана.

Хашимов үз ыруы арасыннан беренче булып югары үрләгән, танылган кеше иде. Мөмкинлек туу белән ул тырышып-тырышып күпсанлы туганнарына булыша башлады, күрәсең, үзенең нинди кыенлыклар аша күтәрелгәнен хәтерләгәндер.

Кунакларга булган мөнәсәбәтләрне аңлау өчен дә Шәрекътә яшәү кирәк. Биредә аларны чынлап та ихластан шатланып каршы алалар—кунак килмәгән йорт, мул тормышлы, бай йорт булса да, аңа хөрмәт юк. Бу гореф-гадәтләр күп гасырлык тарихка ия, европалы кешегә, мәсәлән, аңлавы бик кыен: әйтик, ни өчен ярлы-ябагай да автомобиль алырга хыялланмый, ә үз тормышында бер генә мәртәбә булса да бай табын янында өй тулы кунаклар кабул итеп утырырга тели. Бу милли сыйфат рәхимсез өткән кояш астында мамык кырларында бил бөккән дехканның да, Сәлим кебек яхшы тәрбия һәм белем алган кешенең дә канына сеңгән.

Көтмәгәндә-уйламаганда гына «Лидо» ресторанында прокурор Камаловны

очраткач, ул гүзәле Нәргизгә Яңа ел бүләге алырга да, бүген үз өендә гадәттәгечә күпсанлы туган-тумача җыелачагын да онытты. Ләкин йорт хуҗасы булу аны үзенә янаган куркынычны вакыт-вакыт онытып торырга мәҗбүр итә иде. Хәтта андый мизгелләрдә дә кунак кунак инде ул. Үзенең туган-тумачаларына алган бүләкләрен дә хәтерли—аларның һәрберсен Миршабның өендә куандырырлык бүләк көтә. Андый яхшылыклар онытылмый, бу юлы ул аеруча юмарт кыланды, чөнки белә—үзе белән ул-бу була калса, туганнары аның хатынын да, балаларын да кайгы-хәсрәттә ялгыз калдырмаячаклар.

Гадәттә, Мәскәү вакыты белән Яңа елны каршылагач, кунаклар таралыша башлый торган иде, әмма бу юлы, көлкеле төрле уеннар уйлап чыгарып, йорт хуҗасы аларны таңга кадәр җибәрмәде. Ул бу зур йорт эчендә ялгызы гына калудан курыкты, аның уйлары әле һаман да прокурор Камаловның янаулы сүзләренә әйләнеп кайткалый иде.

Бу кадәр озак мул табын янында һәм чыршы тирәсендә утырырга күнекмәгән кунаклар иртәнге якта аяктан егылыр дәрәҗәдә иделәр инде, бераз тын алырга дип, тирән күн кәнәфигә бер генә минутка утырган Сәлим шунда залда ук йоклап та китте. Бары тик шуннан соң гына туган-тумачалары, якыннары хуҗабикәгә искиткеч күңелле бәйрәм өчен рәхмәтләр әйтеп, кунакчыл йорттан китә башладылар.

Миршаб көн уртасында гына уянды, әйтерсең лә, кичәге борчулы көн дә, шау-шулы Яңа ел төне дә булмаган—аның башы саф, гәүдәсе ял иткән иде инде.

Салкын суда коенып-юынып чыккач, ул, өйдә икәнлегенә бик ышанып бетмәсә дә, Костага шылтыратып алырга булды. Ләкин Джиоев шунда ук телефон трубкасын күтәрде, Хашимов моны яхшыга юрады. «Лидо»да Яңа елның ничек үтүен, андый-мондый хәлләр булу-булмавын сораштыргач, ул Костаның үзенә кереп чыгуын үтенде. Коста берәр сәгатьтән килергә вәгъдә бирде.

Коста инде Кареннан ресторанда прокурор Камаловның булганлыгын, бөтенесен куркуга салып чыгып киткәнлеген белә иде, ләкин ул Мирша янына бу сәбәп аркасында гына ашыкмады. Кичә, ул инде кәеф-сафа корырга чыгып китәм дигәндә генә, Мюнхеннан Шубарин шылтыратты.

Артур Александрович аны Яңа ел белән котлады, эшләренең ничек барышы белән кызыксынды, бары тик Джиоев кына аңлый торган читләтеп сөйләү алымы белән әйтте: бирелә аның койрыгына басып өлгергәннәр икән. Ул Мюнхенның «Бавария» стадионында үзе белән үзбәкчә сөйләшкән кешенең төс-кыяфәтен сурәтләп бирде. Аңа «кунакның» кем икәнлеген, иң мөһиме—аның артында кемнәр торганлыгын белергә кирәк иде. Костаның уйлавынча, Югары суд хезмәткәре Сәлим Хашимов йортында сүз нәкъ шул хакта барачак та.

Миршабның чакыруы ни өчен булуына карамастан, Коста аннан баш тарта алмас иде: ул Сәлим белән аның дусты сенаторның, үзен травматология институтыннан урлап алып китеп, төрмәдән коткарып калганлыкларын һәрвакыт исендә тота, ул аларга гомере буе бурычлы. Костаның хуҗасы Шубарин да алар булышлыгы белән генә сакланып кала алды: үтерелгән прокурор Азлархановның республикадагы һәм Мәскәүдәге, хәтта Кремльдәге бик зур түрәләр өстеннән җыелган үтә яшерен гаепләү материаллары-компромат салынган кейсын да Миршаб белән сенатор урлаган иде бит.

Коста Миршаб янына Шубаринның тыйнак кына ак «Волга»сы белән килде, әмма машинада «Вольво»ның дизель двигателе, Рәшидовның элекке машинасыннан алынган караңгы яшькелт, пуля тишә алмаслык пыялалары, ә дүрт ишеге автоматтан атуга да түзәрлек икәнлеген бик азлар гына беләдер.

Шефының машинасы белән Джиоев күптән түгел генә файдалана башлады, хуҗасы Германиягә китәр алдыннан нинди дә булса шәп автомобиль алып кайтачагын әйткән иде—Ташкентта, көнләп түгел, дигәндәй, зиннәтле кәттә машиналар арта тора, ә сәүдә банкы хуҗасына башкалардан калышу һич килешми.

Коста машиналарны яхшы белә иде, шуңа күрә ул берничә шарт куйды: пуля тишмәслек пыялалары, бер булса да броня ишек,—-илдә хәзер әнә ниләр генә булмый!—Һәм, әлбәттә, кондиционер, аннан башка машина җәй көннәрендә Урта Азиядә әҗәл тагарагына әйләнә.

Бүгенгә кадәр Костаның әле Миршаб өендә булганы юк иде. Ул көмеш төсенә буялган авыр капка янында машинасын кычкыртуга, өйдә автоматика төймәсенә бастылар, авыр капка йомшак кына ике якка ачылып китте, бу ишегалдына шактый еш килеп йөргән машина эчкә үтте. Сәлим ишек төбендә көтеп тора иде инде, Коста житди сөйләшү генә түгел, кичектергесез эшләр дә булачагына тагын бер кат ышанды. Хуҗа аны бизәлгән чыршылы зур зал аша туп-туры үз кабинетына алып кереп китте, анда ике кәнәфи арасындагы кечкенә өстәлдә кайнар чәй утыра, янәшәсендәге вазаларда—бераз каралашинә төшкәнрәк йөзем, кипкән җиләк-җимешләр, чикләвек, печенье—бик тыйнак һәм зәвыклы күренеш иде бу.

Кабинетка килеп кергәч, Коста күңеленнән генә Сенатор белән Миршабка да үзенең хуҗасы Щубаринның нинди унай йогынты ясаганлыгын уйлап алды. Бик һәйбәтләп яңартылган узган гасырның зиннәтле җиһазы; дивар буена тезелгән биек китап шкафларының пыялалары аша борынгы фолиантлар янәшәсендә Кытай һәм Бениннын борынгы бронзалары, аларның бик рәтен белеп җыелганлыклары күренеп тора; төрле уенчыклар һәм немец фарфорына ясалган рәсем-күренешләр, Кузнецов һәм Гарднер заводларында эшләнгән, ватылырга гына торган рус фарфоры сыннары. Ә каршы яктагы яшел бильярд поставы белән тышланган диварга гаҗәеп матур алтынсу рамнарда биш-алты рәсем-картина эленгән—болар һәммәсе ирексездән Шубаринның эш кабинетын хәтерләтә иде. Күрәсең, җирле таможня хезмәткәрләре Миршаб өчен чит илләргә китүчеләрне җитәрлек җилгәргәндер, мондый малларны комиссион сатудан да таба алмыйсың.

Костаның хәл-әхвәлен, сәламәтлеген, кәефен сораштыргач,—ә шәрекъта, нинди генә ашыгыч һәм мөһим сөйләшү булса да, шунсыз сүз башламыйлар,—Миршаб аңа «Лидо» ресторанында прокурор Камалов белән очрашканын, «матур-матур» сүзләр алышканнарын тәфсилләп сөйләп бирде. Коста үзе өчен көтелмәгән нәтиҗә ясады: Хашимов Мюнхен стадионында Артур Александровичның ниндидер бер якташ кеше белән сәер очрашуы турында бер нәрсә дә белми икән...

Хашимов кинәт туп-туры бәрдереп сорады: бер атна эчендә прокурор Камаловны җитди генә пычратып буламы? Коста уйлап та тормастан җавап бирде—юк. Коста фикеренчә, бер генә юл кала—тегене, җәмәгатьчелекне кузгатмаслык итеп, тавыш-тынсыз гына юк итәргә кирәк—Камалов республикада танылган шәхес.

Сәлимгә ризалашырга гына калды, чынлап та прокурорны пычратыпбуяп торырлык вакыт юк, бары шул бер чара гына... Ул, сүз уңаеннан гына, КГБ изоляторында утыручы Бармаксыз турында телгә алды. Прокурор Камалов кулындагы бу мөһим шаһиттан Сәлимгә дә, Артур Александровичка да, Костаның үзенә дә җеп сузылырга мөмкин...

Джиоев аның сүзләренә күңеленнән генә көлемсерәде. Ул Парсегянны яхшы белә: алар икесе дә законлы караклар, димәк, тегесе моны беркайчан да сатмаячак. Коста ни өчен Арсенның Сенаторны гына тоттыруын да аңлап алды: утыртып куйгач, Сенатор туганнары һәм дуслары аша Миршабны

өркетүне оештырачак, тегенә исә ирексездән ярдәм итәргә туры киләчәк— Югары судта эшләгәндә моны башкару катлаулы түгел. Бармаксыз дөрес юл сайлаган шикелле, әмма... Үзенең башында кайнаган уйларын ул чыгарып түкмәде. Джиоев тагын шунысын да төшенде: Парсегянның язмышы хәл ителгән, үзенең дә сайланып торыр чагы түгел—җавап тотар сәгать суккан. Кичә анын үзен коткарып калган булсалар, бүген Сенатор белән Миршабны ул коткарырга тиеш.

Коста дөрес уйлаган булып чыкты: Миршаб чынлап та Парсегянны юк итәргә кирәклеге турында сөйли башлады. Ләкин эш КГБга барып терәлә—аннан Бармаксызны әләктерү мөмкин түгел шикелле. Алар өч сәгатьтән артык төрле юллар эзләп утырдылар, әмма берсе дә барып чыкмас төсле иде... Инде китәргә генә җыенганда, Костаның башына кинәт бер фикер килде:

—Без башта ук дөрес уйланмаганбыз,—диде ул.—Юкка гына КГБдан сөйләшер-кинәшер кеше эзлибез. Хәтта шундый кешене тапсак та, ә бу бик катлаулы эш, ул, никадәр тырышса да, Парсегян янына үтеп керә алмаска мөмкин... Димәк, безгә Бармаксыз янына керердәй кешене КГБдан түгел, башка җирдән эзләргә кирәк... Әйтик, табиб яки мунчачы...

Үзенең әйбәт фикергә юлыкканын аңлагач, Джиоев яңадан кәнәфигә килеп утырды һәм бер өч минут дәшми торды. Миршаб бу тынлыкны бозарга берничек тә базмады. Коста кинәт кенә сүрән тавыш белән: «Амин»—дип мыгырдап куйды, кулы белән мәгънәле генә хәрәкәт ясап алды: мөселманнар мәетне соңгы юлына шулай озаталар.

—Бетте, Парсегян килеп терәлде. Мин аннан ничек котылу юлын хәзер беләм инде, ләкин бер-ике атна бик яхшылап әзерләнәсе булыр...

—Яле, яле, аңлатып бир...—дип җанланды Миршаб.

—КГБның үз хезмәткәрләре өчен бик шәп медсанчасте бар, ул шәһәр үзәгендә, үзләренең төп биналарына терәлеп тора, тимер Феликс һәйкәле каршысында. Минем белүемчә, бөерләр авыруын тикшерү өчен кирәкле бердәнбер япон аппаратурасы бары тик шунда гына, шәһәрдә башка юк. Анда күпләр танышлык белән генә керәләр. Сездән шул таләп ителә: иртәгә үк медсанчастьнең баш табибына шылтыратасыз да бөерләрегезне тикшерүләрен үтенәсез. Башка авыру-фәлән дисәгез—ышанмаслар. Сез бит шул аппараттан башка һәммәсе дә булган хөкүмәт поликлиникасында исәптә торасыз. Башымны кисәргә бирәм—нәкъ шулай. Сез медсанчастька ике барып кайтырга тырышыгыз. Башта барып сөйләшкәч, анализларсыз гына барасыз, өйдә онытып калдырганмын, дисез—кыскасы, анда никадәр озаграк торсагыз, шулкадәр яхшы булыр.

Баруыгызның максаты—күбрәк табибларның фамилияләрен белешү, әйтик, ун-унике кешенекен. Бу миңа алар арасыннан кайсысының изоляторга керү мөмкинлеге барлыгын исәпләп чыгару өчен кирәк. Мин беләм, Парсегянның кышларын аяклары бик сызлый, радикулиты да көчле, төрмәдә ул төннәрен акырыпмы-акыра иде, аны камерадан конвойсыз гына чыгаралар. Ә калганын мин сез биргән исемлектән берәрсен сайлап алгач кына сөйләрмен.—Сүзе беткәнгә санап, Коста урыныннан кузгалды. Миршабның күзләреннән аңарга да өмет уты үрләгән иде. Хуҗа аны озата чыкты. Машинасын кабызганда, Джиоев әйтеп куйды:

—Ә «мәскәүле» белән эш җинел булачак—ул бит һаман да өченче катта ята, тәрәзәсе дә караңгы ишегалды ягына карый.

Яңа елның беренче эш көнендә үк Сәлим, иртән республика КГБсының медсанчасте баш табибына шылтыратып, үзен тикшерү турында сөйләшеп килеште. Сөйләшүдән ул шуны аңлап алды, Костаның мәгълүматлары дөрес

икән, поликлиникага барып кайтуы шик тудырмаска тиеш, хәтта сау-таза булсалар да, ул бөерләрен тикшертеп карарга хаклыдыр ич.

Медсанчастька барырга җыенгач, Хашимов пинжәгенең эчке кесәсен капшап карады, анда һәрвакыт йөртә торган, шырпы кабы кадәр генә диктофоны бар аның, еш кына файдасы да тиеп куя. Бу юлы да көтмәгәндә генә диктофонның файдасы чыкты.

Медсанчасть ишек төбендә аңа инде әзерләп куелган пропуск тоттырдылар, вахтер баш табибның кабинеты дүртенче катта икәнен әйтте. Хашимов, үзен беркем дә озатып тормаячагын белүгә, нишләргә кирәклеген төшенеп алды. Бу очракта аңа икенче кабат килеп йөрисе дә булмаячак, башка әгъзалары шикелле үк, аның бөерләре дә сәламәт иде.

Ул лифтка утырып өченче катка менде дә, кирәкле ишекне эзләгәндәй кыланып, озын коридор буйлап китте. Кабинетларның ишекләрендә табибларның нинди белгеч булуы, исем-фамилиясе, атасының исеме язылган иде. Хашимов пышылдап кына диктофонына, Коста сораганча, ун гына түгел, ә унсигез фамилия язып алды, дүртенче катта аларга тагын унике өстәлде. Хәзер инде баш табиб янына кереп йөрисе дә калмаган иде, әмма күңеле күтәрелеп киткән Миршаб, бераз уйлагач, шулай да кереп чыгарга булды. Соныннан ул үзенә көтмәгәндә килеп туган уңышы турында кат-кат уйланды. Кабул итү бүлмәсендә озын чират тезелгәнен күргәч, ул борылып китәргә дә уйлаган иде, әмма аны нәрсәдер тыеп калды, түземлеге уңыш та китерде. Кыска гына әңгәмәләшеп, гадәттәге шәрекъчә бер-берсенә матур-матур сүзләр әйтешкәннән соң, баш табиб бу дәрәҗәле кунакны экспресс-анализга үзе озатып куярга булды. Миршаб бер ун минут кына элек буеннан-буена йөргән озын коридорга килеп кенә чыкканнар иде, аларны, гафу үтенеп, чик сакчысы формасындагы бер итагатьле офицер туктатты һәм ике генә минут көтеп торырга кушты.

Сәлим кайсыдыр табибның кабинетыннан ике ир кешенең бергәләп чыкканнарын күреп алды, аларның берсе хәрби киемнән иде, алар коридорның аргы башындагы лифтка таба тиз-тиз атлап киттеләр, анда да погонлы бер кеше көтеп тора иде. Миршабның тәҗрибәле күзе бу ике кешенең берсе офицерга богауланганын абайлады—бик куркыныч җинаятьчеләрне шулай озатып йөриләр. Һәрвакыт салкын канлы булган Сәлим телдән калды: лифтка шундый сак белән алып барылган җинаятьче ул... Бармаксыз, ягъни Арсен Парсегян иде...

Бу хәл бер генә минут булгандыр, әлеге күренешкә игътибар итүче дә юк иде шикелле, әмма Сәлим аптырашта иде, аның үзен чемете килеп китте—юк, ул ялгышмады: чал бөдрә чәчле арестант, һичшиксез, ул аулап йөргән кеше иде. Парсегянны алып чыккан кабинет яныннан узганда Миршаб хәтта үзе фамилиясен язып алган теш табибын да күреп алды.

Бәлки, дәшми генә калырга кирәк булгандыр, ләкин Сәлим түзмәде, телчән баш табибтан:

—Сездә кулда булган кешеләрне дә дәвалыйлармыни?—дип сорады.

—Юк, монысы очраклы гына, пациент, дөресен әйткәндә, безнеке түгел. Республика прокуроры аны безгә ышерган, диләр, ниндидер бик мөһим шаһит икән, күз карасы кебек саклыйлар. Бүген беренче алып килүләре бугай...

Шул көнне кич белән теш табибы эңгер-меңгердә эштән кайтып барганда, аңа арттан, юл читендә торган машинадан эндәштеләр:

—Ильяс Әхмәтович, утырыгыз, илтеп куям...

Хезмәткәрләренең шәхси машиналарын куя торган урын КГБ ишегалдында булып, анда бары тик зур түрәләр генә керә ала, калганнар автомобильләрен, ни булса да булыр дип, урамда калдыра иделәр. Теш табибын еш кына шулай үз авырулары илткәли, бу һәрвакыт очраклы килеп чыга. Бүгенге чакыру да аның өчен көтелмәгән һәм күңелле хәл иде: хәзер дыңгычлап тутырылган

метрода кайту, аннары салкын урамда автобус көтеп тору бер дә шатлыклы эш түгел, әлбәттә. Шуңа ул салкыннан өстенә сыкылар кунган машинага ашыкты, аңа итәгатьле генә итеп арткы ишекне ачтылар. Ул «Волга»ның караңгы һәм җылы салонына рәхәтләнеп кереп чумды. Машина, бозлавыкта йөрү өчен арткы көпчәкләренә кигезелгән чылбырларын шылтыратып, җинел һәм тиз генә кузгалып та китте. Ильяс Әхмәтович гаҗәпләнмәде, чекистларның күп машиналарында көчле двигательләр яки куәтле иномаркалы машина моторлары торганын белә иде. «Волга» эчендә, шофердан тыш, тагын ике кеше бар икән, берсе алгы утыргычта, икенчесе табиб янәшәсендә булып чыкты. Алар аны дәррәү сәламләп каршы алдылар. Көчле музыка уйный, әмма теге икәве, табиб килеп кергәч тә, Горбачевның телевидениедән ясаган соңгы чыгышы турындагы кайнар бәхәсләрен туктатмадылар, бер-ике минуттан теш табибы үзе дә кайнарланып сүзгә кушылып китте.

Шулай бәхәсләшә-бәхәсләшә бара торгач, Ильяс Әхмәтович күпме юл үткәннәрен дә сизмәде, кинәт: «Килеп җиттек»—дигән тавыштан гына айнып китте. Машинадан дәррәү коелып төштеләр, теш табибы да төште. Машина утлары балкып торган зур йортның биек коймалы ишегалдына кереп туктаган икән, тимерләрен шалтыр-шолтыр китереп капканы бикләделәр.

Ильяс Әхмәтович, ни өчен бирегә килеп кергәнлекләрен аңышмыйча, беразга югалып калды. Машина хуҗасы аның беләгеннән сак кына тотып алды да елмаеп әйтеп куйды:

—Борчылмагыз, доктор, өегезгә гадәттәгедән соңламыйча кайтып җитәрсез, хатыннарыбызның көнчел икәнлеген беләбез. Менә егетләр берәр касә яхшы коньяк салып куймакчылар, Яңа елда үз запасларыбызны эчеп бетердек, диләр. Үзегез беләсез, хәзер бит эчемлекләр табуы кыенрак чак. Ә миндә бер шешә әрмән коньягы калган иде... Өйгә рәхим итегез!

Хуҗаның ягымлы гына елмаеп сөйләшүе табибны тынычландырды, аның борчылуы шундук юкка чыкты. Соңрак, булып үткән хәлләрне исенә төшергәч, табиб үзенең бу ягымлы, әмма боеручан кешенең йогынтысында булганлыгын чамалады. Җыелышып өйгә керделәр. Чынлап та, өстәл тирәсенә утырышып, машинада башланган сүзне дәвам иткән арада, хуҗа яхшы маркалы «Двин» коньягы белән кабымлыклар куелган поднос күтәреп керде. Машина эчендә караңгыда табиб әңгәмәчеләрнең йөзләрен күрә алмаган иде, хәзер якты бүлмәдә алар ана таныш та, түгел дә шикелле күренделәр. Хәер, барысын да хәтерләп тә бетерә алмассың, ул бит кайсыбер көннәрдә егермешәр кешене кабул итә.

Йорт хуҗасы да тимер Феликсның кыршылып беткән һәйкәле каршындагы йортның алтынчы катындагы энергияле яшь җитәкчеләрнең берсенә охшаган, бик әдәпле, шәп-пөхтә киемнән. Берәр касә коньяк уртлап куйгач, хуҗа сәгатенә карап алды да табибка сүз катты:

—Безнең сезгә, Ильяс Әхмәтович, бик зур гозеребез бар, төгәлрәге, без сезнең ярдәмгә мохтаҗ...—диде.

Әле һаман да шик-шөбһәгә төшмәгән табиб:

—Тыңлыйм сезне, ярдәм итә алсам, итәрмен,—диде.

—Сездә Арсен Парсегян дигән кеше дәваланып йөри, без шуның белән бик тә кызыксынабыз...

Шунда гына кунак үзенең күңелсез хәлгә тарганын аңлап алды: органнар аны нindидер Парсегянның эшенә катыштырмакчы булалар. Башыннан яшен тизлегендә уй йөгереп үтте: аны тикшерәләр, ул бит үзенең кайда һәм кем белән эшләгәнен белә. КГБ сүзеннән һәр совет кешесе шүрләгән шикелле, Ильяс Әхмәтович та шүрли иде. Бу курку үзе шуларның медсанчастендә эшли башлагач тагын да көчәйде. Юк, ул үзен куркыттылар, янадылар дип тә, шәһәрнең тулы бер кварталын биләп торган бинадагы ниндидер анык кына куркыныч хәлләрне белдем дип тә әйтә алмый. Юк, бары тик әйләнә-

тирәдәге аңлаешсызрак хәлләр генә күңелгә шом сала. Ана көн саен дистәләп килеп йөрүче бу кешеләр үзләрен ничектер табигый булмаганча тотулары белән аерылып торалар. Шуңа күрә табиб башта бу яңа танышларын да шул «зур йорттан» үзенә килеп йөрүче пациентлары дип уйлаган иде. Әмма хуҗа шундук ачыклык кертте.

—Доктор,—диде ул,—без сезнең пациентларыгыз түгел, безнең мәнфәгатьләребез КГБга кагылмый, алар очраклы гына кисештеләр. Сездә Парсегян дигән кешене яшереп торалар...

—Мин берниндиПарсегянны да белмим!—дип куркынып кычкырып җибәрде теш табибы.

Курку аның акылын алган, аның хәзер ниндидер Парсегянга да, КГБсына да, үз мәнфәгатьләрен күптән буйсындырган дәүләт мәнфәгатьләренә дә төкерәсе килә иде. Ул үзенең үлемгә тиң хәлгә тарганын аңлады, эшкә алганда ана шундыйрак хәлләр булырга мөмкинлеге турында сөйләгән иделәр. Үзе кызганыч, балалары кызганыч. Ләкин ул, дөрестән дә, Парсегян фамилияле беркемне дә белми, КГБда әрмәннәр эшли эшләвен, бу оешманың хуҗасы да әле күптән түгел генә Рәшидовның якыннарыннан саналган әрмән иде.

Йорт хуҗасы, әйтерсең, каядыр соңга калган кебек, тагын бер тапкыр үзенең «Картье» сәгатенә күз салып алды, аннары, шашыну хәленә җиткән Ильяс Әхмәтовичка игътибар белән карагач, аңлады: Парсегянны мөгаен табибка берниндидокументларсыз-нисез генә, ә бәлки бөтенләй башка фамилия белән алып керәләрдер. Шуңа ул табибка Бармаксызның төс-кыяфәтен җентекләп сөйли башлады, аны бүген иртән сак астында сезнең кабинетка алып та килделәр, диде.

—Әйе, шундый кеше миндә булды, ләкин аның фамилиясен сездән беренче ишетүем,—дип җиңел сулап җавап бирде табиб, ул кемнең дә булса авыру тешләре турында яшереп калдырырга җыенмый иде.

—Исегезгә төшерүегез яхшы,—диде йорт хуҗасы, аның тавышында боз салкынлыгы бар иде.—Сезне озаклап үгетләп торырга вакытыбыз юк, чөнки безнең тормышыбыз куркыныч астында,—ул инде күптән тынып калган юлдашларын күздән кичереп алды.—Югарыда утыручы күп кенә түрәләрнең дә тормышы куркыныч астында! Һәммәсе дә шул Парсегянга барып төртелә: аның теле бик озын булып чыкты, шуңа күрә аны үлемгә хөкем иттеләр—анысы тиз үтәлер. Аның яшәү-яшәмәве сездән тора...

Йорт-хуҗасы касәләргә янә коньяк салды да, үзенекен мәгънәле генә итеп күтәреп алды...

Ильяс Әхмәтович барысы белән бергәләп коньякны эчеп куйды, үзенә төбәлгән соры акай күзләрнең тәэсирен тоеп, үпкәләбрәк әйтте:

—Ни өчен миннән тора әле ул? Мина комачауламый ул, яшәсен...—Ул хәтта үзенчә кыю һәм үткен җавап биргәненә үзе дә гаҗәпләнде. Ләкин йорт хуҗасы шундук аңлатып бирде:

—Әгәр сезгә болай әйтү ошамаса, башкача әйтәм: сезнең тормышыгыз Парсегянның үлү-үлмәвенә бәйле.

—Мин аны үтерергә тиешлеме?—дип пышылдады агарынган теш табибы, аның куллары калтырый иде.

—Әллә нинди куркыныч сүзләр сөйлисез, доктор... Ул табигый үз үлеме белән үләчәк, бер экспертиза да аның башкача булганлыгын исбатлый алмаячак, монысы бер генә тикшерелмәгән инде. Шунысы бар бит, аны сез генә үзегездә күрә аласыз, юкса без сездән башка да хәл итәр идек аны. Әгәр сез фаталист булсагыз, моны үзегезнең язмышыгыз дип уйлагыз, аны әйләнеп узып булмый...

Хуҗа жилет кесәсеннән иснәп карарга хушбуй салына торган кечкенә генә пробиркага охшаш савыт чыгарды. Савытның төбендә борчакның өчтән

бере кадәрле генә кара шарчык тәгәрәп йөри иде.

—Менә шушы шарчыкны иртәгә сез аның теш пломбасы астына салып калдырырга тиешсез. Ул нәкъ биш көннән бу якты дөнья белән хушлашыр, безнең борчулы мәсьәләләребез үзеннән-үзе хәл ителер. Алай гына көтә алабыз... Әлбәттә, мондый хезмәтләргә мулдан түләнә, без дә вакланып тормабыз...

Өстәл янында утырган яшь егетләрнең Кавказ халыкларына охшаганы аңа кара пластик пакет сузды, йорт хуҗасы Ильяс Әхмәтович алдына биш төргәк йөз сумлыклар чыгарып салды.

—Биредә илле мең, инфляция заманында да әз акча түгел,—диде.

Доктор моңа берничек тә игътибар итмәде, ул әйтерсең катып калган иде. Озакка сузыла башлаган тынлыкны хуҗа бозды, усал гына итеп:

—Әгәр дә КГБ сезгә халык дошманы Парсегянга карата шушыны эшләргә кушса, сез аны берсүзсез һәм бер тиенсез үтәр идегез,—диде.

—Мин аны эшли алмыйм. «Сез бит ул үләчәк, дидегез...—Табибның бармаклары өстәл өстендә биешә иде, ул, әңгәмәдәшенә күтәрелеп карарга да куркып, күзләрен идәнгә текәгән.

—Әлбәттә, үләчәк, анысы ышанычлы,—дип кырыс-катгый раслады йорт хуҗасы.—Ләкин сез аңларга тиеш: чигенергә юл юк. Әгәр ризалашмасагыз, биредән исән-сау чыкмаячаксыз. Уйланырга сәгать ярым гына вакытыгыз бар, юкса хатыныгыз эшегезгә шылтыратыр да сезне эзли башларлар. Анда сезнең югалуыгыз нык саклап йөртелгән Парсегянның бүген килеп-китүенә бәйле икәнен төшенергә мөмкиннәр. Ләкин без андый фаразларга юл куймаячакбыз. Сез, исерек килеш кайтып барганда, кемдер урлап киткән самосвал машинасы астында калып һәлак булырсыз, ул инде сезнең юлыгыз өстендә автобус тукталышыннан йортыгызга кадәр булган арада көтеп тора. Без бер чылбырга бәйләнгәнбез, шулай булгач, уйлагыз, доктор...

—Юк, юк, мин кеше үтерә алмыйм!—дип кычкырып җибәрде табиб, ишеккә ташланырга теләде.

Әмма аны оста гына итеп аяк чалып ектылар, торгызып, кулларына богау салдылар, авызына дыңгычлап чүпрәк тыктылар да тәрәзәсез-нисез бер бүлмәгә кертеп бикләделәр.

—Гафу итегез, доктор, бер генә сәгать вакытыгыз калды, аңлагыз безне,—диде аңа хәзер инде бер дә ягымлы булмаган хуҗа.

Үзенең коточкыч хәлдә калуын, кемнәрнеңдер һич аңлашылмас мәнфәгатьләре аркасында һәлак булачагын аңлап алгач, бер кырык минутлардан теш табибы аягы белән ишеккә тибәргә тотынды.

Өстәлдәге кәртләр һәм акчаларга караганда, болар бик эредән уйный иделәр, ләкин Ильяс Әхмәтович моңа гаҗәпләнмәде. Өстәлдә будильник сәгать тә бар, аның телләре билгеләнгән вакытка җитеп килә иде инде. Шул гадәти кызыл будильник табибны хуҗаның барлык кырыс сүзләреннән дә артыграк шүрләтте, ул ихтыярсыз гаҗизлек белән:

—Мин риза, бирегез савытыгызны...—диде.

Ярты сәгатьтән ул өендә иде инде. Ишек янында пәлтәсен элгәндә эчке кесәсеннән бүлтәеп чыгып торган йөз сумлыкларны күреп алды...

## V

Хастаханә палатасына янадан килеп яткан прокурор Камалов, үзе ачыктан-ачык өркеткәннән соң, Миршабның нәрсәләрдер эшләгәнен көтә башлады. Яңа елның өченче атнасы бетеп килә, ә бернинди хәлләр дә булмады әле. Дөрес, Камалов, үзе «Лидо» ресторанында күренеп киткәч Миршабның травматология бүлегенә, янәсе, аны Яңа ел

белән котларга бәйрәм ашы алып килергә телим, дип шылтыратуын, шулай итеп Камаловның терелеп чыкканмы-юкмы икәнлеген ачыклаганын белә иде инде. Әлбәттә, Камалов биредә ятканда, Миршабның куллары чишүле, мөмкинлеге зур, хәзер ул ашыга-ашыга нәрсәдер корадыр-оештырадыр—әмма нәрсәләр майтарырга уйлый икән соң ул? Аның турында мәгълүматлар бөтенләй кермәде диярлек, хәер, шулай буласын көтәргә мөмкин иде. Сәлим Хәсәнович, һичшиксез, үзенең дусты Сенаторның хаталарын кабатламас, прокурор кулына алай тик торганда гына килеп капмас. Ул утлы күмерне башкалар кулы белән актара-көри торган кеше бит...

Караватында озын-озак сәгатьләр буе ятканда прокурор үзенә Коканд-Ленинабад юлында ясалган һөҗүм, хатыны һәм улының үлеме, үз кабинетында үткәрелгән яшерен кинәшмәне сөйләүчеләрнең иреннәреннән укып, магнитофонга яздырып торган Айдынның һәлак булуы турында кабат-кабат уйлангач, бер нәтиҗәгә килде, һәм әкренләп анык өчпочмак төзеде: Сенатор, Акмал хан һәм Миршаб. Әлбәттә, болар янына Артур Александрович Шубаринны да кертергә булыр иде, ләкин ул, Фирганә вакыйгаларыннан күп элек Германиягә китеп барганлыктан, тегеләрдән аерылыбрак тора иде. Прокурор полковник Жураевның әйткән сүзләрен хәтерли: «Шубаринга сезгә үлем теләүдән мәгънә юк. Ул акыллы: ни Сенаторга, ни Миршабка базар да, ирекле-иркен кәсәбәчелек тә кирәкми, ә ул үзе банкир буларак күрергә теләгән хокукый дәүләткә юл сезнең аша...»—дигән иде ул.

Палатада җентекле мәгълүматлар үзенең кул астында тупланган Шубарин турында уйланганда Камалов аның прокурор Азлархановны бик югары бәяләгәнен, аңа игътибар биргәнен, аның белән бергә кешеләргә күренеп йөрергә яратканнарын исенә төшерде. Полковник Жураев та Азлархановны белән дус, аның кешелек сыйфатлары турында мактап телгә ала иде. Хәзер аның булмавы кызганыч, дип уйлады Камалов. Акыллы кеше белән аралашу-сөйләшү теләге көчле иде, Азлархановны күп белүе өчен генә түгел, ә һәр икесенең бер каннан булганнары өчен, аларның Алласы бер генә иде бит—Закон. «Кабере янына барып килергә кирәк әле»,—дип уйлап куйды Камалов. Азлархановны җирләшкән полковник Жураев аның үлеменә бер ел тулгач, кабере янына барган икән, шунда өеп куелган кабер өстендә кызыл тамырлы яшькелт мәрмәрдән утыртылган бик матур истәлек ташы күргән, таштагы «прокурор» дигән язу астына «чын, асыл» дигән сүзләр дә чокып язылган икән. Полковник Жураев моны үзе сөйләгән иде. «Бу кабер ташын кем куйды икән?»—дип кызыксынды полковник. Аны да ачыкларга кирәк иде, хәер, төптән уйлаганда, аны Шубариннан башка кеше куйдырмас та иде.

Азлархановы, Шубарин, Жураев—бер-берләреннән бик нык аерылып торган бу шәхесләр дә ни өчендер бер чылбырга тезелә һәм Камаловның уеннан һич чыкмый, ул үзен газаплый торган бик күп серләрнең ачкычы аларда икәнлеген эчке сизенү белән сизенә. Әмма Азлархановы исән түгел, угрозыск начальнигы Жураев белгәннәрен сөйләп бетерде инде, бер Шубарин гына кала, ә ул еракта—Германиядә. Кинәт кенә Камаловның башында бер юләр уй балкып китте, уй да түгел, хыял—Шубаринны теләктәш-фикердәш итеп булса икән! Ул инде кем артында кемнәр торганын белә дә белә булыр—ана барлык көчләр дә билгеле, таныш. Кайчандыр үзе дә шул административ командалык системасын оештыру-туплауда катнашкан кеше бит. Ә хәзер ул системага һәртөрле үзгәрешләр кертү һәлакәт дигән сүз. Ә нигә әле бу хыял тормышка ашмаска тиеш, ди? Жураев дөрес исәпләгән бит: Шубаринның бүгенге омтылышлары-теләкләре өчен кичәге ялагай дуслары аякка салган тышау, муендагы камыт кебек ич. Уй-исәптә шулай килеп чыга, ә тормышта...

Ә шулай да бу уй-исәп мантыйкка туры килә. Камалов үз исеменә ниндидер

бер кәсәбәчедән килгән исемсез, аноним хатны исенә төшерде. Кәсәбәче, дәүләтне (ул «державаны» дип зурдан кубып яза) ачыктан-ачык талаучылар турында бәяләп бетергесез дәлилләр китерә, халыкка зыян салучы аерым фамилияләрне, оешмаларны атап күрсәтә. Ил һәм республика прокуратуралары кичекмәстән күргән чаралар искиткеч нәтиҗәләр бирде, миллионнарча байлыкларны урлаучы дистәләгән каналлар ябылды. Ә бит хатны каршы як лагерь кешесе, Шубаринга якын торган кемдер язган булырга тиеш...

Камаловка прокурор Азлархановның күптәнге сәер үлеме дә тынгы бирми, юкса бүгенге вакыйгаларга аның катнашы да юк шикелле. Бу табышмакны чишү өчен тотынып жирлек тә юк: үтерүчене шул төнне үк хастаханәдән урлап алып киткәннәр, прокуратурага прокурорның үлеме бәрабәренә китерелгән, бик кыйммәтле мәгълүматлар тупланган дипломат та югалган. Кинәт кенә Азлархановның үтерелүе белән анлаешсыз бәйләнештә Камалов хәтер янчыгыннан бер фамилия тартып чыгарды—Әкрәмходжаев.

Полковник Жураев, республика прокуратурасы холлында булып үткән фаҗига турында сөйләгәндә, Сухраб Әхмәтовичны да күргәнен әйткән иде. Камалов Сенаторга кул селтәргә дә уйлаган иде—Сенаторның Азлархановка бернинди мөнәсәбәте дә юк—аларның элек беркайчан да очратмаганнары төгәл билгеле, араларында каршылыклар да булмаган. Торгынлык елларында алар җәмгыятьтә икесе ике баскычта торган кешеләр, Мәскәүдә аспирантура тәмамлаган, республика юристлары «реформатор» дип йөрткән белемле өлкә прокуроры белән үзенә таба кулы кәкрерәк, дан сөючән кечкенә район прокуроры арасында бернинди уртаклык та булырга мөмкин түгел.

Шулаен шулай шикелле дә... Әмма бер елдан соң Әкрәмходжаевның йолдызы кабынды, аның закон һәм хокук, хакимият башындагыларның хокукны белмәве турындагы мәкаләләре үзен республикада иң популяр юрист итеп танытты. Ә бит хезмәте буенча аның белән аралашкан чакларында Камалов анардан бер генә яңа фикер дә ишетмәде, бары тик табигать биргән акылын һәм тотканын ычкындырмас кеше икәнлеген генә чамалады. Бу сәер үзгәреш ничек, нәрсәдән килеп чыкты соң әле?

Камалов Сенаторның докторлык диссертациясен җентекләп өйрәнеп чыкты—гаҗәп заманча, тирән эчтәлекле, дәлилле эш иде ул. Сенаторның матбугаттагы чыгышлары да халык күнеленә хуш килде, ул, әлбәттә, үзгәртеп кору елларындагы беренче халыкчан дулкында өскә үрләде. Ләкин Сенаторның кылган эш-гамәлләре белән фәнни трактаты арасында бернинди уртаклык та юклыгын Камалов һәрвакыт күреп торды шикелле. Шулай килеп чыкты да: Әкрәмходжаев бөтенләй андый кеше булмаган икән. Җинаятьче Арсен Парсегянны очраклы рәвештә кулга алганнан соң ачыкланды бу. Алар күптәннән дус булганнар икән, Республика прокурорына Бармаксыз шундый хикмәтләр сөйләде ки, Әкрәмходжаевны кичекмәстән кулга алырга туры килде. Ләкин Парсегян, үзен канаты астында тоткан Сенатор турында күп нәрсә белсә дә, аның фәнни эзләнүләре, шул өлкәдәге эшчәнлеге турында юньле-башлы бер сүз дә әйтә алмады.

Ничек эш итәргә кирәклек турында уйланулар, төрле юлларны капшап караулар тупикка килеп төртелә иде. Әмма Камалов сизенә: Шубаринга юл бары тик Азларханов аша гына бара—Азларханов аның өчен бик кирәкле булган, шуна күрә дә кабере өстенә мәрмәр таш куелган, таштагы язуга гадәти булмаган «чын, асыл» дигән сүзләр өстәлгән...

Камалов Парсегяннан сорау алып шуны белде: Азларханов үтерелгән көнне Әкрәмходжаевның прокуратураны талауда катнашы булган. Әгәр дә Сухроб Әхмәтович Азлархановның дипломатын кулга төшерергә йөргән икән, аны үтерүгә дә катнашы булмадымы икән? Прокуратура ишегалдында төнлә булган вакыйгадан соң ике мәет калган: каравылчы белән сейфлар вату остасы,

Ростовтан килгән Кащей кушаматлы жинаятьче мәетләре. Парсегян Кащейны милиционер атып үтерде, ә Сенатор дипломатны коткару ниятеннән каравылчыга атты, дип бара. Ләкин Камалов Кащейны да Сенатор дөмектергәндер дигән фикердә. Кащей тикшеренүләрне бутар өчен генә кирәк булгандыр: ул көннәрдә прокуратурада нәкъ менә Ростовтан килгән кансыз-шәфкатьсез берничә рэкитерлар бандасының тикшеренү эшләре бара иде. Әкрәмходжаевның мәкерле планына башыннан аягына кадәр татуировкалар белән чуарланган Кащей бигрәк тә яраклы булгандыр. Әмма әгәр дә Сенатор Япончика якын кешене үтерүгә катнашкан икән, ни өчен Шубарин аның белән дус булган, ана ярдәм иткәләп торган? Бу сорау әле яна калкып чыкты, Камалов аны кесә дәфтәренә теркәп тә куйды. Сорау очраклы түгел, бик тә законлы—ни өчен? Әлегә ана жавап та юк. Әгәр Әкрәмходжаевның, дөрестән дә, Азлархановны үтерүгә катнашы булса? Бәлки, ниһаять, Миршаб, Сенатор һәм Шубариннарның араларын бозарга бердәнбер мөмкинлек туадыр? Бу фикер Камаловны үсендереп жибәрде. Юк, әле барысы да алай ук өметсез түгел. Һич түгел...

Жомга көн, атна азагы, ул мафия белән көрәш бүлеге башлыгын көтеп утыра—алар бергәләп бер операция әзерлиләр, шуны күзгә-күз генә сөйләшеп алырга жыена иделәр. Прокурор үзе эшкә чакырган Татьяна Георгиевнаның үз хезмәтенә керешкәнме-юкмы икәнен дә тизрәк белергә тели иде. Камалов сәгатенә күз төшереп алды: элекке чекистның килеренә бер сәгать вакыт калган икән, ул чиста кәгазьгә үзен борчыган өчпочмакны янадан сызып куйды, аны шундук квадратка әйләндерде, һәммәсе өстеннән күләгә булып Сенатор калыкты.

Камаловның ярты сәгатьтән икенче каттагы процедура кабинетына төшәсе бар, шуңа күрә ул прокуратурага шалтыратырга булды. Ул әле диварның аргы башындагы телефон-автоматка аксый-туксый барып та житмәде, ишектә мафия белән көрәшү бүлеге начальнигы күренде. Аның йөзенә карагач, прокурор нәрсәдер булганын аңлап алды.

Палатага кергәч тә бүлек начальнигы мөһим хәбәр житкерде.

—Бүген төнлә КГБның тикшерү изоляторында Арсен Парсегян үлгән,—диде ул.

Вакыйганың начарлыгын аңлап алган прокурор каттый гына сорап куйды:

—Сез мәетне үзегез күрдегезме?

—Әйе. Шуңа күрә соңладым да, экспертиза нәтижәләрен көтеп тордым.

—Нәрсәдән үлгән Бармаксыз?

—Табиблар бернинди дә көч куллану һәм агулау билгеләрен тапмаганнар. Табигый үлем—инфаркт.

—Сорау алуны төшергән видеотасмалар сакланамы?

—Мин дә шул хакта борчылган идем, барысы да үз урынында иде. Мин аларны үземә алдым.

—Ул-бу булмасын өчен күчерелмәләрен ясатып алыгыз да, минем сейфка салыгыз. Әйе, күнелсез вакыйга...—диде Камалов тоньк кына тавыш белән. Сынган боты янадан сызларга тотынды, авырту энәләр кадагандай аягына күчте, бөтен тәнен биләп алды.

КГБда күп еллар эшләгән полковник табибларның тикшерү нәтижәләре дөреслегенә тамчы да шикләнми, моны шундук абайлап алган Камалов Парсегянның үлемендә башка фаразлар да булуы турында сүз озайтып тормады. Кичә сөйләшеп куйган операция турында фикер алышканнан соң, алар саубуллаштылар. Камалов полковникка яна бурыч та йөкләп өлгерде: кайчандыр үтерелгән Азлархановның, мөмкин булганча, барлык теоретик хезмәтләрен дә табып алырга кирәк иде.

Полковник чыгып китүгә, прокурор ирексездән ыңгырашып куйды:

—Менә нинди этлек эшләгәнсең икән син миңа, Миршаб...

Бернинди абруйлы тикшеренү нәтиҗәләре дә Камаловны Бармаксыз үз үлеме белән үлгәндер дип ышандырмый иде. Ул нокаутка тиң бу көчле сугуның Югары судтагы кеше кулы белән эшләнгәнлегенә дә шикләнми иде. Ул юкка гына ун ел гомерен әлеге убырларның чын йөзен ачуга багышламады. Аның «Үтә яшерен» дип билге салынган хезмәтләре Политбюро һәм КГБ житәкчеләре өстәлендә ятып калды. Ул әлеге хезмәтләрендә оештырылган җинаятьчелекнең кешеләре хакимиятнең дә һәм хәтта КГБның да иң югары түрәләре арасында да булганлыгын раслаган иде. Ул хезмәтләр, бәлки, шуның өчен дә ят калганнардыр?

Әлбәттә, ул, иртәгә үк үзенең элекке укучысы КГБ генералы Саматовка шылтыратып, аның тавышсыз гына иң яхшы белгечләрне җәлеп итеп, Парсегянның үлемен яңадан тикшертүне үтенер. Үзен өч надзиратель көчкә тыеп торган үгез кебек таза Бармаксыз бары тик вакыт-вакыт радикулит белән генә җәфалана иде, ә бу юлы кинәт инфаркт... Үтерергә кирәк булганга үлгән ул...

Аягы янә сызлый башлады, прокурор, бүген даруларсыз йоклап булмастыр дип, борчылып уйланды. Әмма Камалов, аягы авыртудан битәр, үзенең хәзер үк Миршаб белән көрәшкә тотына алмау гаҗизлегеннән җәфаланды. Палатаның уңып беткән обойлы шәрә диварларын, ишегалдына караган биек тәрәзәсен күздән кичереп, ул үзенең биредә әле озак ятачагын аңлап алды, ә Хашимов, күрәсең, вакытның кадерен белүче бәндә иде...

Төнгә Камаловның температурасы күтәрелде, көчле авыртынулар башланды, ул бер ягыннан икенче ягына әйләнгәләп, үзен кая куярга белми башлады, аңа көчле тәэсир итә торган реланиум уколы ясадылар. Әмма авырту шулкадәр көчәеп китә ки, ул, вакыт-вакыт уянып, бозланган пәрдәсез тәрәзәгә карап ала. Төн якты, айлы иде. Ул бәс сарган чикләвек агачының хастаханә түбәсенә кадәр күтәрелгән куәтле ботакларын күзәтеп ятты. Камалов, кинәт кенә авыртынып уянган шикелле үк, кыска гына борчылулы йокыга тала иде...

Өзек-төтек йокы аралаш Камалов урам яктан үз палатасына кемнеңдер керергә маташканын тоеп алды да, ирексездән күзләрен ачты. Әйе, биек тәрәзәсе төбендә билен монтаж каешы белән буган бер кеше басып тора, каешыннан бармак юанлыгы нейлон бау уннан да, сулдан да тышка сузыла иде. Теге адәмне, күрәсең, урам яктан да саклыйлар булса кирәк. Камалов төне буе саташып чыккан төшләре дәвам итә дип уйлады, ул елмаеп күзләрен яңадан йомды, әмма күнеленә үтеп кергән борчу аның янә күзләрен ачтырды. Теге бәндә, тәрәзәнең тышкы ягындагы төбенә ак йон оекчан гына баскан да, рамның сул ягындагы тоткасы тирәсенә алдан ук ябышкак тасма ябыштырып, пыяла кискеч белән пыяланы кисеп маташа иде—шулай иткәндә пыяла шартлап ватылмый... Төн якты, якында гына фонарь да яна, бәндәнең күкрәгендәге рация янында тавышсыз ата торган пистолеты да ачык күренә, анысы каешка тагылган иде. «Юраган юш килә»,—дип уйлап алды прокурор, артык хәрәкәтләр ясамаска тырышып, мендәре астыннан сак кына «Макаров» пистолетын капшап алды. Теге бәндә, пыяланы кискәч, аны уң як тәрәзә рамына сөяп куйды да, тәрәзәне ачмыйча гына келәсен күтәрде. Ул, күрәсең, салкын һаваның йоклаучыны кирәгеннән алда уятуыннан саклана иде. Келәне ачкач, ул рациясе аша пышылдап кына нәрсәдер әйтте дә, пистолетын уң кулына алды... «Мин аткач, ул палатага егылып төшәрлек булсын»,—дип уйлап алырга өлгерде Камалов һәм тәрәзә ачылуга ике тапкыр атып та җибәрде.

Үтерергә теләүченең пистолеты идәнгә тәгәрәде, шуның артыннан үзе дә палатага чумган кебек булды, әмма шул мизгелдә үк, күренмәс кран белән эләктереп күтәргәндәй, өскә чөелде. Аны саклап торучылар прокурорның үзләрен бу юлы да алдаганнарын сизенделәр...

Иртән вакыйга булган урыннан кулдан язылган картон плакат кына табып алдылар, анда төрекчә генә: «Канга-кан» дип язылган иде. Әмма Камалов үтерүчене дә шул ук Миршаб җибәргәнен яхшы аңлады...

## VI

Мюнхен стадионында якташы белән сәер очрашудан соң ике генә атна үткән иде, Артур Александрович белән тагын да кызыграк вакыйга булып алды. Әгәр дә халыкара мафия вәкиленең килеп чыгуы, бераз уйлангач, Шубаринга ул кадәр үк сәер тоелмаса,—чөнки ул бездәге җинаятьчел дөньяның торгынлык елларыннан ук, инде күптән чит илләрдә үзенә мәйдан әзерләвен белә иде,—икенче очрашу исә бары тик саташулы төштә генә күренерлек булды.

Ул көнне Шубарин, гадәтенчә, зал түрендәге колонна артындагы «үз» өстәле янына барып утырды, бирсдән керү ишеге яхшы күренә иде. Хәер, гел килеп йөри торгач, ул ресторанга кухня аша да, хезмәтчеләр ишегеннән дә кереп-чыгып йөрергә мөмкин булганлыгын белә, соңгы ишек исә нык саклана иде.

Ул алдында яткан зиннәтле шәраб һәм башка эчемлекләр язылган меню белән танышырга да өлгермәде, артында бик тә таныш тавыш ишетте, кемдер гел дә үзебезчә, русча сорап куйды:

—У вас здесь не занято?

Артур Александрович менюны бер читкә куйды да күтәрелеп карады һәм... катып калды. Аның өстәле янында Әнвәр Абидович Тилләхуҗаев, «мамык Наполеоны», партиянең Заркент өлкә комитеты беренче секретаре, хәзер Уралда унбиш ел төрмәдә утырырга тиешле кеше басып тора иде.

Әле бер атна гына элек Коста белән сөйләшкәндә, ул Тилләхуҗаевның хәл-әхвәлен сорашкан һәм ана: «Аның эшләре тәртиптә»,—дип җавап биргәннәр иде. Әнвәр Абидовичны утырткан беренче көннәрдән үк хезмәт лагерына Ашот белән Коста, җинаятьчел дөньяда «абруйлы кешеләр» барган иде. Алар әле тагын бер «хөрмәтле кеше»не дә иярткән, анысы Урал төрмәләрен күзәтеп торучы икән. Аларның максаты өлкә комитетының элекке беренче секретаре, Шубаринның шәхси дусты һәм яклаучысына тоткынлыкта да юньле тормыш булдырудан гыйбарәт булган. Беренчедән, җинаятьчеләр тарафыннан да, администрация тарафыннан да ана бернинди мәсхәрә-кимсетүләр булырга тиеш түгел—Әнвәр Абидович андый мөгамәләләргә күнекмәгән. Икенчедән, ана унайлы эш һәм яшәү шартлары булдырылырга, ана даими азык-төлек һәм башка кирәк-яраклар килеп торырга тиеш.

Әнвәр Абидовичның тоткынлыкта утырган елларында,—ә ул үзгәртеп кору заманында беренчеләрдән булып эләккән иде,—ике егет «мамык Наполеонына» даими рәвештә алмаш-тилмәш Ташкенттан Уралга «күчтәнәчләр» илтеп торган һәм менә ул хәзер балкып Артур Александрович каршысында басып тора. Ирексездән катып та калырсың... Алар, кочаклашып, шәрекьтәгечә аркаларына суккалап күрештеләр, зиннәтле залдагы халык моны күрми калмады, әлбәттә.

Әмма бу минутларда тирә-юньдәгеләрнең үзләрен ничек күзәткәннәренә игътибар итеп торырга буламы соң? Аларны бик күп нәрсәләр бәйләгән иде бит. Әнвәр Абидович үз гаиләсенең Шубаринга тормышлары белән бурычлы икәнлеген дә белә, аның йортына өч мәртәбә ут төртергә җыендылар, өчесендә дә ут төртүчеләрне снайпер Арифның тавышсыз төз атуы каршы ала иде. Болар онытыламы соң?

Шунысы сәер, төрмә Әнвәр Абидовичка файдага булган шикелле: артык симезлеге юкка чыккан, элек чал керә генә башлаган бөдрә чәчләре бүген инде бөтенләй чаларып беткән, бу ана күркәм бер мәһабәтлек биреп тора.

Йөз чалымнары да ачыграк, кырысрак төс алган, күзләре яктырып киткән, дәрвишләрчә бер кырыслык, ирләрчә матурлык хасил булган. Аны юлга ашыгыбрак киендергәннәр, күрәсең, юкса киемнәре дә шәп кенә, әмма ул инде галстук-костюмнардан бизгән, төрмәдә бит сырмадан йөрергә дә, гадәти тормыштан ваз кичәргә дә өйрәнәсең. Шубарин белә: тотлыклыкта берничә ел утырып чыкканнарга урындык-кәнәфиләргә янадан күнегү өчен күп еллар кирәк, алар гадәтләре буенча дивар буена чүмәшәләр.

Кайнар аш китергәннәрен ярты сәгатьләр көтеп торганда, Артур Александрович түземсезләнеп сорады:

—Шулай да әйт әле, ничек син бирегә килеп чыктың да, мине шунда ук эзләп таптың?

—Мин партия солдаты бит, шуңа күрә дә биредә, аның фәрманын үтәп йөрим,—дип күпертебрәк җавап бирде Әнвәр Абидович.

Ләкин Шубарин аңлап алды, кунагы шаяртмый, иң өстәге түрәләрнең хәер-фатихасыннан тыш ул иреккә дә чыга алмас, Көнбатышка да килә алмас иде. Төрмәдән шулай котылган бу кешене, һичшиксез, нинди дер югары көчләр, хәтта мәнфәгатьләре йөртә икән. Моны Шубарин сиземләде.

Кайнар аш китергәч, алар тагын берәр чәркә немецлар ясаган «Горбачев» аракысын эчеп куйдылар. Әнвәр Абидович кыска гына итеп әйтте:

—Әшәке нәрсә икән, безнең өлкәләрдәге «Русская» яки «Столичная»га җитә торган түгел бу,—диде.

«Барин барин булып кала инде,—дип уйлады Артур Александрович.—Алты ел төрмәдә утырып, аракының тәмен дә оныткандыр юкса, ә менә «Горбачевка»ны санга сукмый»...

Тилләхуҗаев үзен иркенрәк тота башлады, хәтердә Заркентта үткән матур-күнелле көннәр яңарды.

—Мин бик шат,—диде Әнвәр Абидович.—Синең эшмәкәр, бизнесмен булырыңны дөрес чамалаганмын. Безнең идеологиягә туры килеп бетмәсә дә, диюем. Чынлап та, искәрмә-чыгармаларсыз кагыйдәләр юк. Мин хәтта уйлап та куям: партия алдындагы бөтен гөнаһларым өчен хаклы җәза алсам да, бер гамәлем барысын да юып төшерәдер. Мин бит сине ачтым, хокук-хаклыкларга каршы булуына карамастан, өлкәдә сиңа үз эшләреңне майтарырга юл куйдым. Ә бүген син рәсми рәвештә миллионер! Хәзер синең хезмәтеңә ил-халык та мохтаҗ...—Шунда Әнвәр Абидович тавышын баса төшеп, тирә-ягына каранып алгач, әкрен генә, әмма тантаналы итеп, иҗекләп әйтте:—Пар-ти-я дә!—диде.

Шубарин-Японец кунагын исергән дип уйлаган иде, ләкин Әнвәр Абидовичка игътибар беләнрәк карагач, үзенең ялгышканын аңлады. Тегесе эш турында сөйләшергә җыена икән: аңа куелган бурыч уңышлы үтәлсә, үзенә ирек вәгъдә иткәннәрдер дә, шуңа күрә ул күпертеп, купшы сүзләр сиптерә, ахрысы.

Артур Александрович, ресторан залын да игътибар белән күзәтеп, Тилләхуҗаевны озата килгән булырга тиешле берничә кешене дә чамалап алды. Тагын, үзе уйлаганча, бер-ике шикле кеше дә бар иде бугай. Ул үзләрен тыңлап-язып алучылар булмагае дип, артык сүз озайтмаска булды. Әнвәр Абидовичның исә тизрәк эш турында сөйләшәсе килә иде.

Кунагы төп сүзгә күчә башлагач, ул аны кырт кына бүлдерде дә:

—Әйдә, кофе эчик әле, эш турында миңа кайткач сөйләшербез,—диде. Аннары бик тә кызыксынган кыяфәт белән үзләренең бүген кич белән шәһәр янындагы атаклы бер клубта бик матур итеп утырачакларын сөйләп китте. Ул анда чакырулы икән, имеш. Мюнхенның төнге тормышы турында сөйләгәндә, Артур Александрович теге кешеләрнең тын гына бер-бер артлы чыгып киткәннәрен күрде. Күрәсең, ул ялгышмаган, аларның

сәйләшкәннәрен язып барганнар икән. Хәзер инде, кызыгы калмагач, чыгып китү ягын караганнардыр.

Машинасын кузгатып җибәрүгә, аның ак «Мерседес»ы артыннан бер саргылт «Порше» да иярде. Артур Александрович ашыкмый гына бара, үзе кунагына Кайзерштрасседагы кибетләр, салоннар, театрлар турында сөйләнә иде. Ул, теге эзәрлекләп килүчеләрне буташтыру өчен, яшәгән йорты ягына юл тотты. Кайсыдыр светофор янында җаен туры китереп, «Порше»ның яшел утка өлгермәгәнен күргәч, тизлеген арттырды да, бер тыкрыкка кереп чумды. Тагын бер мәртәбә борылгач, алар янә кире яктан Кайзерштрассега килеп чыктылар. Бер биш минуттан Шубарин машинасын «Рица» отеле янындагы үзенә таныш урынга кертеп туктатты.

Җиденче каттагы унайлы номерга килеп кергәч, Артур Александрович телефоннан гына үзләренә яшел кытай чәе «лунь-цзинь» китерергә кушты. Кәнәфигә утырып, кунагына сүз катты:

—Менә хәзер, кадерле Әнвәр Абидович, без инде эш турында да тыныч кына сөйләшә алабыз. Тыңлыйм сезне...—диде.

Кунак турыдан-туры сөйли башлады:

—Кичә иртән минем өчен тыгыз көн булды. Дүртенче-бишенче бараклардагыларның киемнәрен алыштырдылар. Синең тырышлыгың белән мин андый көннәрдә складта гына йоклап калам. Беләсеңме, шундый җирдә эшләү нинди бәхет! Анда мине иң «абруйлылар» яклаcard да, ул кыргыйланып беткән җинаятьчеләрдән барысын да күтәргә мөмкин... Мин андагы иң «кәттә» егетләргә яхшы киемнәрне сайлап кына өлгергән идем, администрация кешеләреннән башка гына ике кеше килеп керде. Үзләрен тотышларына, сөйләшүләренә, киемнәренә караганда болар журналистлар да, прокуратура, МВД, юстиция-мазардан да түгел иделәр. Алар, исәнләшкәч, шәрекъкә хас булганча, сәламәтлек, тормыш-көнкүреш турында сораштылар да, үзләре белән әбәт ашарга чакырдылар, анда танышларың да булыр, диделәр. Төрмәдә артыгын сораштырып тормыйсың, аларга ияреп чыгып та киттем. Ишек төбендәге машиналары безне тиз генә шәһәргә таба алып чапты. Без ниндидер түрәләрнең дачаларына барып кердек булса кирәк. Залда бик бай табын әзерләнгән икән, шул тирәдә йөрүчеләр арасында мин, чынлап та, үземә электән таныш булган ике ир-атны күреп алдым. Хәер, исем-фамилияләре дә, эшләгән урыннары да исемә төшмәде. Ничек хәтерләп бетермәк кирәк, Заркентта меңләгән халыкны кабул итә идем бит. Политбюро әгъзаларын да, хәтта Брежневның кияве чибәр Юра Чурбановны да. Күрше лагерьда мин аны вакыт-вакыт очрата да идем, ул анда безгә урын-җир өчен җәймәләр тегеп тора...

Әмма ләкин бу килгән кешеләрнең КПСС Үзәк Комитетыннан икәнлекләренә шикләнмәдем. Бары тик әллә аларны үзем кабул иткән идемме, әллә эш белән аларда булдыммы икән, дип шикләндем. Соңрак мин берсенең КПСС Үзәк Комитеты Управляющие Кручининаның ярдәмчесе икәнен исемә төшердем, мин аңа кереп, өлкә комитеты хезмәткәрләренә яхшы йорт төзеп бирү мәсьәләсен хәл итәргә йөргән идем. Алар мине бик әйбәт кабул иттеләр, Заркентта булган чакларын искә төшереп алдылар. Әйе, без аларны бик кунакчыл каршылап, үзләре әйтмешли, ханнарча бүләкләр биреп озаткан идек. Минем биредә утырганымны командировкага килгәч ишеткәннәр, имеш тә, күрергә теләгәннәр, бер унайдан мине бик тә кирәк булган кешеләр белән дә очраштырырга ниятләгәннәр.

Миңа таныш булмаган бу өч ир-ат, мөгаен, үзләрен башка исемнәр белән таныштырып, кул биреп күрештеләр дә табынга чакырдылар. Әбәт озакка сузылды, элекке заманнарны, хәзер инде хакимияттән сөрелгән элекке хуҗаларны искә төшереп утырдык. Мин, партия буенча элекке көрәштәшләремә нәрсә кирәклеген аңламыйча, әңгәмәгә катнашкан сыман

кыланып кына утырдым. Аларның «дусларын» мина чыгарылган үлем карары бик яхшы хәтерләтә иде, мин аңардан могҗиза белән генә исән калдым бит.

Әбәттән соң чәйдер-фәләндер китергәч, телефон шылтырады, теге икәү, ашыгыч эшебез бар, дигән булып, тиз генә чыгып шылды, мин исә яңа танышларым белән күзгә-күз генә калдым. Аларның да эшләре тыгыз булды бугай, без, шундагы кунакханәгә күтәрелдек тә, әңгәмәбез башланып та китте. Хәер, сөйләшүебезнең беренче өлеше ыкы-мыкысыз гына сорау алуга охшаган иде. Мине биек аркалы күн кәнәфигә утырттылар да, үзләреннән озын гына тәбәнәк журнал өстәле белән бүлеп куйдылар, ә үзләренең берсе генә мина күренә, күбрәк сорау бирүче яннары белән утырган иде. Бу хәйлә мина таныш—ике яклап сорау алучылар, гадәттә, шулай эшли дә...

Тилләхуҗаев, бераз сулыш алырга дип, тынып калды. Шубарин, аны бүлдермичә, тик тынлап кына утыра бирде.

—Иң беренче сораулары, Артур, сиңа кагылышлы булды. Аннары икенче-өченче һәм әле бик күп сораулар да синең хакта иде. Алар мина уйланып торырга да бирмиләр, җавапларым төгәл һәм тиз булсын, мин анда үземне ялганны тота торган теге детектор алдындагы кебек хис иттем. Ул хәзер бездә дә бар икән бит. Мин аларга үземнән нәрсәләр кирәк икәнлеген һич аңламадым, бары тик шунысы гына ачыкланды: алар синең хакта бик тә җентекле күп мәгълүмат җыйган икән. Ара-тирә мин синең дәүләт эшенә кагылышлы берәр кыек эшең юк микән, дип тә уйлана башладым. Син бит вак-төяк эш йөртмисең, юкса шундый югары дәрәҗәдә кызыксынмаслар да иде. Ләкин мин бит синнән даими хәбәрләр алып тордым: син әле һаман да «ат өстендә», «чәчәк атасың», анда «эшлекле» кешеләр дә юк түгел, алардан да мәгълүматлар килә иде. Әмма, сорауларын ничек кенә буташтырырга тырышсалар да, мин, ниһаять, аңладым: алар сине батырырга тырышмый, син аларга кирәк икән бит! Мин тиздән төшендем аларның хәйләсенә—син немецләр белән бергәлектә Ташкентта банк ачарга җыенасың икән. «Банк» сүзе бер генә мәртәбә дә телдән әйтелмәсә дә, шуннан соң мин сөйләшүне үзем теләгәнчә алып бардым. Шунын дәлиле—минем бирегә килүем.

—Банкмы? Әле юк килешме?—дип гаҗәпкә калды Шубарин.—Син ялгышмыйсыңмы?

—Әйе, әйе, Артур, банк. Аларга шунын өчен арадашчы кирәк булган да. Беләләр: андый тайгак сөйләшүне син теләсә кем белән алып бармаячаксын. Шуның өстенә аларга ныклы ышаныч та кирәк, анысы—минем яшәү-яшәмәвем. Алар һәммәсен дә яхшы үлчәп, синең йомшак якларыңны да искә алганнар.

—Кабахәтләр икән!—дип, үзе дә сизмәстән ачу белән кычкырып куйды Шубарин.

—Илнен мондый хәлиткеч буталчык көннәрендә бер генә төрле бәя була алмый. Кайнарланма әле, Артур. Әгәр дә бу хәлемдә минем гомерем дә уенга салынган икән, мин һич тә үкенмим, димәк, мин партиямә кирәк икән әле. Мин шат кына мона,—кунак янә күпертеп сөйләүгә кучкән иде.

—Партиягә?—дип гаҗәпләнеп сорады Шубарин.

—Әйе, Артур, партиягә. Сүз партия акчалары, партия кассасы турында бара.

Шунда гына бу сәер әнгәмәнең төп асыл фикере Шубаринга аңлашыла башлады.

—Бүген, ил өчен генә түгел, партия өчен дә авыр көннәр килгәч, ул алдагы киләчәге турында да уйларга тиеш,—дип дәвам итте Тилләхуҗаев.—Хәзер, демократия чикмәне киеп, чит илләрдән юмарт акчалар алып реакция котырынган заманда, партия вакытлыча үзен-үзе таратыр, «идән астына» да кереп яшеренер. Әмма монысы соңгы чик булыр. Социализм, коммунизм

идеяләре, гаделлеккә-тигезлеккә омтылу җәмгыятьтә бетмәгәндә, ышан мина, коммунистларның сәяси мәйданга күтәрелүләре бик тә ихтимал, халык аларны үзе үк чакырып алыр әле. Җәмгыятьнең байлар һәм ярлыларга бүленүе хәзер көнләп түгел, сәгатьләп үсә бара... Әмма оешмасыз, финанс мөмкинлекләрсез кайту һәлакәткә тин. Партия үзенең җитмеш ел буе туплаган байлыгын саклап калырга тиеш. Ә ул байлык, ышан мина, һич тә аз түгел...

—Партиягә шулкадәр акчалар каян килсен, ди?! Гади коммунистларның әгъзалык взнослары партком түрәләренә һәм чит илдәге компартияләргә ярдәм итеп торырга да җитмәгәндер, мөгаен. Ә илдәге гаять зур милекләре: иң яхшы торак йортлар, райком, горком, обкомнарның мәһабәт бинаалары, поликлиникалары, нәшриятлары, хастаханәләре, санаторий-курортлары—болар бит гаять зур күпмиллиардлы чыгымнар сорый.—Шубаринның тавышы гаҗәпләнеп чыкты.

—Менә ичмасам чын банкир сүзләре!—диде канәгать калган кунак.

Үзе ишеккә якынрак утырганлыктан, шакуга ишекне ачарга китте. Официант өстәленә зур чәйнек һәм чәшкә-тәлинкәләр тезелгән арбачыкны тәгәрәтеп кертте. Барысы да ап-ак тастымал белән каплап куелган иде. Әнвәр Абидович чәйне үзе ясый башлады. Шубарин аның төрмәдән соң тормышның шушы вак-төякләрен дә яратып башкарганын карап торды: матур савыт-сабалар, күзгә рәхәт җиһазлар, яхшы чәйнен хуш исләре...

—Артур, партиягә шулкадәр акчалар каян килсен? Мин сиңа күп нәрсәләр турында сөйли алам, әмма боларын белмим. Әйтергә кирәк, хәзер партия акчаларын дәүләтнекеннән аерып алуы да кыен. Партия бит һәрнәрсәне: җир асты байлыкларын, урман-кырларны, диңгез-тауларны, халык һәм акчаларны һәрвакыт үзенеке дип кенә исәпли иде... Әмма бу банкирга бирә торган җавап түгел. Төрле рәсми һәм рәсми булмаган чыганаклар булып, аларны бары тик азлар гына—партиянең бик ышанычлы кешеләре генә белә иде. Шулар арасында... мин дә бар идем.

Шубаринның гаҗәпләнүенең чиге юк иде.

—Әйе, әйе,—диде Әнвәр Абидович.—Партия миңа бик тә ышана иде. Шул ышанычны акламаган өчен җәза да алдым. Исеңдәме, син миңе кулга алачакларын әйткәч, мин тиз генә дәүләткә—димәк, партиягә илле килограммнан артык алтын, алты миллионнан артык акча кайтарып бирдем. Ләкин алты ел элек мин үз серемне ачып бетермәгән идем, хәзер исә вакыты җитте, мин аны сиңа ачам...

Тилләхуҗаев, тәмләп йота-йота, хуш исле чәен эчеп куйды:

—Әйе, бу инде төрмә суы түгел,—дип тел шартлатты.—Менә шул, туган, әле өлкә комитеты секретаре чагымда ук мин ел саен партия кассасына зур-зур акчалар күчереп тордым. Кабатлап әйтәм, аны һәр кешедән сорамыйлар, бары тик ышанычлылардан гына алалар иде. Бервакыт өлкәдә алтын акчалар тутырылган ике чүлмәк табып алалар, җитмеш килограммга якын икән алар. Миңе шунда ук чакырып алдылар: белгеч, янәсе. Бер көннән соң мин СССР Югары Советы сессиясенә чыгып киттем һәм съезд алдыннан партиягә бүләк бирергә булдым. Беркайда да теркәлмәгән әлеге хәзинәне Мәскәүгә илтеп, КПСС Үзәк Комитетының Эшләр идарәсенә тапшырдым, тиздән үземнең беренче Ленин орденымны да алдым, монысы сүз уңаеннан гына әйтелде. Партиянең ышанычлы кешеләре ил эчендә генә түгел, алар чит илләрдә дә бар, разведкадан тыш икътисад өлкәсендә эшләүче «штирлицлар» да җитәрлек... Аларның төп эшчәнлеге—алга киткән илләрдәге аноним фирмаларда, дөньядагы иң эре банкларда сакланачы һәртөрле байлыклар белән эш йөртү. Сүзләремне раслап шуны әйтә алам, бервакыт мин, Грециягә делегация җитәкчесе булып барганда, Афинага матур гына кейста алты миллион доллар илттем...

Икенче юлы шуңа охшаш үтенеч белән Германиягә очтым, анда бер эшмәкәргә яшерен генә миллион ярым доллар тапшырдым—аның фирмасы катлаулы финанс шартларына төшкән иде.

Үзәк Комитетның Эшләр идарәсе базар әлифбасын яхшы үзләштергән һәм күптәннән инде буржуаз илләрдә зур процент исәбеннән бурычка күп миллиардлаган акча биреп тора, ягъни рибачылык итә, ул моны үзебездә дә, чит илләрдә дә эшли. Партиянең финанс эшчәнлеге үзгәртеп кору чорында бигрәк тә көчәйде. Ул акчаларын кече һәм арадашчы оешмаларга, ассоциацияләргә һәм концерннарга салды. Менә хәзер без Мюнхенда искиткеч кытай чәе эчеп утырган мәлдә йөзләрчә совет һәм чит ил фирмалары, дистәләрчә совет һәм чит ил банклары партия милкен кадерләп ишәйтәарттыра торалар. Кече һәм арадашчы предприятиеләрнең ил эчендәгеләренә, кагыйдә буларак, КГБ, МВД, МИДнын һәм партаппаратның элекке хезмәткәрләре хуҗа, хатыннары, кайнаналары һәм балалары хуҗа. Алар оештыручылар, теге яки бу эшне башлап җибәрүче булалар да, Үзәк Комитетның Эшләр идарәсенә мөрәҗәгать итеп, кредитка йөзләрчә миллион акча алалар.

Коммерция банкларына да зур өметләр баглана, аларга миллиардларча сумнар салынган инде. СССР Профсоюзлар банкы, Токобанкларның устав фондларында да дистәләгән миллионнар ята. Синнән, Артур Александрович, яшерен серләр сакламабыз, син, әлбәттә, партия акчалары салынган банкларның исемлеген алырсың. Аларның иң эресе «Автобанк», ул, процентлар түләү шарты белән, партиядән бер миллиард сум алды. Аның оешу тарихы бик гади: банк идарәсе рәисе Наталья Раевская—СССР финанс министрының беренче урынбасары Владимир Раевскийның хатыны. Бәлки, СССР тиздән таркалыр да, ә Раевскийлар банкы чәчәк атуын дәвам итәр.

Көнбатыш илләрендә тулысы белән КПСС акчасына төзелгән фирмалар да бар, алар гадәттә салымы түбән булган үсеп килүче илләрдә ачылды, ә совет базарында аларга башка чит ил фирмаларына караганда күп өстенлек бирелде. Мәсәлән, сәүдәгә билгеле бер күләмдә нефть яки корал, мех яки урман, алмаз яки алтын чыгарып салына. Алар Көнбатыштагы «үзебезнең» фирмаларга яки тугандаш партияләр фирмаларына арзан гына бәягә сатыла. Аннары ул фирма товарын гадәти дөнья бәяләре белән янадан сатып җибәрә дә өстәмә табышны банкка салып куя. Бу очракта партия турыдан-туры дәүләт «җилкәсен кимерә», шуның өчен дә мин партия акчаларын халыкныкыннан аерып алу кыен, дип сөйлим.

—Әле минем ачылмаган банкым нигә кирәк булды соң? Аңлавымча, партия кулы астында дистәләрчә коммерция банклары бар хәзер,—Тилләхуҗаевны бик кызыксынып һәм гаҗәпләнеп тынлап утырган Шубарин шундый сорау бирмичә булдыра алмады.

Иркенләп киткән Әнвәр Абидович, ефәк галстугының төенен бушатып җибәреп, елмайды гына:

—Мин шундый сорау бирәсеңне белдем. Сүзне ерактанрак башлыйм. Син үзеңә кайчандыр юрисконсульт итеп алырга теләгән мәрхүм прокурор Азларханов та сиңа: «Ни өчен нәкъ мин? Юристлар тулып ята бит»,—дигән иде. Ә син: «Миңа теләсә нинди юрист кирәкми, миңа син кирәк»,—дип җавап бирден. Хәтерлисеңме?

Шубарин ризалык белдереп баш какты: ул, әлбәттә, хәтерли иде.

—Әйе,—дип сүзен дәвам итте Тилләхуҗаев,—партиянең банклары бар, әмма алар ясалма оештырылган һәм дөнья мәйданына житди аяк басулары да икеле. Ә синең банк әле ачылып житмәс борын ук дөнья эшмәкәрләренең игътибарын җәлеп итте. Синең банкка, безгә билгеле булганча, бүген үк инде куәтле корпорацияләр акча салырга әзерләр, ә инде бездәге ике миллион ватандашлары-милләттәшләренә Германиянең дә ярдәм итү фикере даһи

фикер. Партиянең ышанычлы кешеләренең башына бу фикер килмәгән иде...

Әмма төп мәсьәлә анда түгел. Конверсияләнгән валюталарның көчле агым белән үзенә керүе булган банк кирәк, андый банкның үз илебездә булуы да шарт. Партия акчалары нигездә чит ил банкларында саклана. Алар башка кешеләр кулында бит. Илнең, бөтен дөньяның хәзерге үзгәреше чорында, хакимиятләр җимерелеп, кем нәрсәгә хуҗа икәнен дә аңламаган шартларда, партия нәкъ менә шуннан курка да инде. Синең банкка аккан доллалар ташкынында, бер-ике ел эчендә, без дә тавышсыз-нисез генә үз миллиардларыбызны күчерер идек. Безнең ул миллиардлар илгә кайтарылырга, партия кулы астында булырга тиеш, хәзер конверсияләнгән валютасыз аяк та атлый алмыйсың. Менә шуның өчен дә сиңа тукталырга булдык, шуның өчен дә мин биредә хәзер...

—Әгәр дә мин банкымның партия кассасына эшләвенә риза булмасам?—Артур Александрович әңгәмәдәшенә сынаулы караш ташлады.

Әнвәр Абидович шундук кечерәеп, җыерылып калган шикелле булды. Шубарин аны сырма кигән, үкчәләре тапталып беткән күнитектән итеп күз алдына китерде. Әмма кунак үзен җиңәрлек көч тапты һәм тиз генә җавап та бирде.

—Ә ни өчен риза булмассың икән? Беренчедән, монда бер җинаять тә юк. Ул акчалар каян алынган, аларны банкларга кем салган? Нигә сиңа аны белеп торырга? Алар бит һәрхәлдә наркобизнестан да кермәгән, мафия акчалары да түгел. Банк хуҗасы буларак, син ул акчаларның кемнеке икәнлеген дә белмәскә мөмкин. Икенчедән, бүген партиянең абруе-дәрәҗәсе төшеп барса да, аңа яхшылык эшләү игелекле һәм оттырышсыз эш. Аңлатам: сине белгәнгә күрә мин бер җитди шарт куйдым—беркайчан да, беркайда да, бер кәгазьдә дә синең фамилияң күрсәтелмәскә тиеш. Сиңа бер генә вәгъдә кәгазьләренә дә кул куярга туры килмәс, сүз белән әйтүең дә җитәчәк. Ә коммунистлар гомерлеккә сәхнәдән төште дип уйлау ялгыш булыр, дөрес, алар аптыраштарак әле, әмма тиздән аннарына килеп, үз араларындагы һәртөрле юлаучылар, карьеристлар һәм мөртәтләрдән арынырлар. Банкир буларак, миллиард сумнар белән эш йөртү зур уңыш ул. Тиздән ул акчалар үзебезнең илгә әйләнеп кайтачак, син моңа ышана аласың.

Өченчедән, кем безнең белән түгел, ул безгә каршы, дигән гыйбарә бар. Аны мин уйлап чыгармадым. Минем белән мәсьәлә ачык, мин сиңа ышаныч белдердем. Ә син... Син, партия серләренә кереп, үзеңне куркыныч астына куйдың... Зур уен зур уен инде ул—анда беркемне дә кызганып тормыйлар. Син моны яхшы беләсең...

Һәркайсы үз уйларына чумып, алар сүзсез генә бик озак утырдылар. Шубарин Әнвәр Абидовичның яңадан бөрешеп калганын күрде, күптәнге дусты кызганыч булып китте аңа, ул аның янына кәнәфигә килеп утырды да иңнәреннән кочып алды.

Күптән инде, ул әле эшмәкәр булып күтәрелеп кенә килгәндә, партия дә, җинаятьчел дөнья да аның һәр адымын күзәтеп торды—аларын да, боларын да «ашатырга» кирәк иде...

Хәзер һәммәсе яңадан кабатлана кебек... Ләкин хәзер Шубаринның зур тормыш тәҗрибәсе бар, ул хәзер, нинди генә хәлләрдә калса да, һич югалмый. Ул кинәт кенә, бервакыт көндәлегенә язып куйган сүзләрен исенә төшереп, елмаеп җибәрде: «Минем язмышым—һәрвакыт тәвәккәл булу. Мин үз тормышымны һәр көнне диярлек куркыныч астына куям, дөресрәге, ул һәрвакыт шунда...»

*Дәвамы киләсе саннарда*



Марсель
Галиев

## ШИГЪРИЯТ РУХЫ

Шагыйрьлек «җене», хыялый алдану бәхете күпләргә бирелгән. Әмма һәр милләтнең күз карасыдай чын шагыйрьләре гасырдан гасырга бөртекләп кенә туадыр. Ул халык бәгыреннән янартаудай бәреп чыга да, билгеле бер көйгә салынган аңзиһен галәмен җимереп, тирә-юньне күмеп китә. Бу гарасатлы көч тынгач кына аның никадәр олылык иясе икәнен тора-тора аңлыйсың.

Үсендереп кенә үстереп булмый чын шагыйрьне.

Ни хикмәт, һәр каләм иясенә мәңгелеккә табыну нәфесе, беренче буласы килү зәхмәте кагылган.

Бу—бик табигый фал.

Илаһи сүзне егәрле алу осталыгына ирешкән җанның йолдыз җиленә өметхисләрен таратып алырга да дәхеле бардыр.

Аллаһы шундый кысыр бәхет индереп, безне һич тә рәнҗетмәгән. Чөнки без, каләмле затлар, телне сугаручылар; сүзләрне куныкландырмыйча, алтынын—алтынга, мәрҗәнен—мәрҗәнгә аерып, йокымсыраргa ирек бирмичә, һәр күзәнәгенә тере сулыш өртеп, хәрәкәттә тотучы гадиләр.

Шагыйрьләр фәрештә булалмыйлар. Шуңа күрә алар да гөнаһтан хали түгел... Тарихка борылып карасаң да, бүгенгегә күз салсаң да, танылысы килү ләззәтенә үрелгәндә бер-берсен таптау һәм таптaлу галәмәтләре—үзе бер кыйсса.

Елан кабыгын елга бер сала. Шагыйрь исә үлгәч кенә...

Ни генә кыланма: илбашы иңенә кунып сарай сандугачы булып сайра, көч белән үзеңне мәҗбүри яраттыр, үз-үзенә һәйкәл куй... Тагын язмышны әйләнеп узарга теләп, әллә ниләр майтар!.. Бер көн килеп, шәхес йөзтүбән ава да, хакыйкать күзгесе каршында ялангач иҗат торып кала. Гомерең буе корган илаһи гөмбәз бер мизгелдә убылып төшә... Кәгазь көшелен җил җилгәрә, кибәк арасында ач бөртекләр генә шәйләнә.

Мирасына—мәрсия...

Чын шагыйрь Иман биеклегеннән торып, дәверләр аръягына сүз йомгагын чөя алган икән, аны дәвер ызаннарында кузы калган учак көле арасыннан Вакыт кайтып күтәреп ала да мәңгелек бишегенә сала.

* * *

Сабакка үсми икән шул тарих сабагы. Үле мисал булып тамырда томаланып кала. Акыл ияләре рәтендә каләм әһелләренең язмышын күздән кичерсәң, гыйбрәтле

Марсель ГАЛИЕВ (1946)—*шагыйрь, прозаик, публицист; күпсанлы китаплар («Апрель кызы», «Догалы еллар», «Рух» һ. б.) шул исәптән дүрт томлык «Сайланма әсәрләр» авторы. Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.*

мисаллар бихисап. Тәхет, көч-куәт каршында горур кала белгәннәр бит элгәргеләр!

Менә бер генә мисал: Шәрекъта Зөлкарнәйн дип йөртелгән Александр Македонскийны фарсыларга яу сәфәре алдыннан греклар үзләренең юлбашчысы итеп игълан итәләр. Җәмгыятьнең күз карасы саналган олуг шәхесләре җыелып җиһангирны котлыйлар. Арада бер акыл иясе, сүз остасы Диоген гына булмый. Моңа бик аптырап, яраннарын ияртеп атка менә дә җиһангир үзе философ янына китә. Коринф шәһәре читендә яшәгән Диоген исә бу вакытта кояшта кызынып, истирәхәт чигеп ята икән. Капылт кына килеп төшкән шундый югары катлау ирләрен күргәч, Диоген торып утыра да, гаҗәпләнеп, Александрга төбәлә.

—Берәр үтенечең юкмы миңа?—ди Александр Македонский.

Диогенның шул мәлдәге җавабы кызык. Әмма бу ләззәтне азга гына сузыйк әле. Бүгенгеләр ничек, бүгенгеләр?..

Кайчан гына әле... Мәскәү Кремленең алтын залларында тәхет тоткан картлар каршында күндәм баш иеп бүләк алган әдипләрне күрә идек. Аларның куштанлык тәэсиреннән таралып киткән йөз-кыяфәтен күреп, сарказм чишенеп ташлап, көлә-көлә биергә мөмкин иде.

Кем тора синең каршыңда? Нинди юллар белән тәхет яулаган ул?

Атка мендереп кара—менәламы?!

Кылыч тоттырып кара—тоталамы?!

Йөзмеңләгән яугирне бер тынга буйсындырырдай сүз әйттереп кара—әйтәламы?!

Шагыйрь ике мәлдә генә тезләнергә хаклы: гыйбадәт кылганда һәм чишмәдән су эчкәндә...

Сиңа—вөҗданлы иҗат юлы бирелгән! Инендә гасырлар буена утлар-сулар кичеп, рухи мирас калдырган мәшһүр сүз ияләре тора; алар рухын рәнҗетмә: кичермәсләр, гасыр катламнары аша: «Акларммы?» дип мөлдерәп караган сәнгать кыялары кичермәсләр сүз иясенең иелүен.

Бүген иелгәнне киләчәк иелеп алмый.

Тезләнгәннең рухы тездән кала.

Йә, каләм! Әйләнеп кайтыйк борынгы Эллалага. Ярты дөньяны яуларга дип, Һиндстанга, ак таҗлы Һималай кыяларына күз аткан җиһангир Зөлкарнәйн: «Берәр үтенечең бармы миңа?» дип сорау биргән иде бит.

—Әз генә кырыйгарак тартыл әле, кояшны каплыйсың!—акыл иясенең бу сүзе күпме илләрне тояк астында калдырачак җиһангирга шулкадәр нык тәэсир итә ки, ул аның горурлыгына, бөек җанлы булуына хәйран кала, кайтыр юлга чыккач, яраннарына болай ди:

—Әгәр мин Александр булмасам, һичшиксез Диоген булыр идем...

«Кояшны каплыйсың...» Нинди тирән мәгънә. Гыйбрәтле мисал.

Әмма... сабакка үсми шул тарих сабагы, тамырда томаланып кала...

* * *

Шигърият ул—йөрәк биеклегендә. Әгәр инде, кызыгып, күккә аша, салкын дөньялар кинлегендә, галәми җилләрдән таланып, сүз кадерен җуя икән, янадан йөрәк биеклегенә кайтып кунаклый алмый инде ул.

Шигърият ул—йөрәк биеклегендә.

Әгәр инде, кызыгып, Җиргә сикерә икән, бөгелеп, буразнадан бәхет эзли-эзли канатларын имгәтсә, янадан йөрәк биеклегенә менә алмый инде ул.

Җиргә якынайганда Күкләр тынып, Күккә якынайганда Җир сулышын тойган шигърият былбылы гына йөрәк биеклегендә оя үрә ала.

Шушы ике яссылыкның уртак ноктасын таба алу—шигъриятнең мөкатдәс хыялы; хыялы гына түгел—максаты; максаты гына түгел—илһамлы яшәү мәгънәсе...

Халыкның күңел мәккәсендә түр мендәргә утыртылган солтанатлы шәхесләре күпме? Рухи гөмбәзебезне тотып торган асыл уллар йөз елга унау туса, сайлана-сайлана мең елдан соң да унау гына калырга мөмкин.

Үзе шигърияткә әверелә барган ерак заманнардан килгән баһадирлар, абруйлы акыл ияләре, руханилар, сүз пәйгамбәрләре... Аз дисәң, күп алар, күп дисәң, аз

алар безнең халыкта, кадерле, барлый белү олылыгына ирешергә генә кирәк!

Төп тамырдан—татардан аерылып, бүтән милләт исеме алып яшәргә, үзбаш үсәргә омтылган кавемнәр бар. Бу кавемнәрне әйдәп баручы даирә төп тамырдан өзелгән милләтнен рухи үзәге имгәтелгәнен аңлап, түбән баскычтан башланган үсешнең кәрлә калачагын чамалап, ялган тарих җилкәсенә утыра да, үткән дәверләрдән олы баба эзли башлый. Татар күкрәгендә ябалдашланган мираска кул сузарга да тайчынмый, чарасызлыктан, үз кыйбласын эзләп бәргәләнә.

Бакый чорларга китмичә, бер гасырлык катламны гына ачып карыйк:

—үз вакытында Тукайны тудыра алмаган, ганимәтле сүз егәреннән мәхрүм калган кавемне ничек юатырга?

—үз вакытында Сәйдәшне тудыра алмаган, моңын раслап, гимн тантанасына ирешә алмаган кавемне ничек санларга?

—үз вакытында Урманчены тудыра алмаган, Күк астында яшәү рәвешенне төсләрдә мәңгеләштерә алмаган кавемне ничек бәяләргә?!

Татарның милли рухы әнә шушы Тукайлар тавыннан яңа биеклекләргә сикереш ясый, ә инде уртак исемнән ваз кичкән бүтән кардәш кавемнәр исә үз түмгәген тау дип атап, яңа киңлекләргә талпынып карый да... Нинди зур аерма! (Бу—сөенеч түгел, бердәм үсә алмау көенече...)

Төп тамырдан шифалы сут алган татар теленең шагыйранә бөеклеген бер «Идегәй» дастаны гына да бәхәссез раслап тора. Олы халыкларда шулай: дастаннарда сәргаскәр, илбашы, чәчән язмышлары җирдә барган аяусыз сугыш гөрелтеләре, кылыч-сөнге чыңнары аша сурәтләнә. Эллада акыны сукыр Гомердән башлап шулай килә... Әмма сугыш күренешләрен мондый да гаҗәп тел үрнәгендә сурәтләгән әсәр дөньяда бер генәдер!

Ул—«Идегәй» дастаны!

Ул—ана телебезнең җәүһәри казанышы!

*«Шан-шаң иткән шам кылыч—Идегәйнең кылычы. Төндә балкыр ут булган, көндә балкыр су булган, ут елдырым яшен таш—чын булаттан корычы, Аждаһадай сулаган ул кылычның сулышы..."*

Искиткеч шигърилек, дәһшәтле күренешнең сүз энҗеләреннән чигелгән сәнгати сурәте! Кайсы тел, кайсы эпос, нинди сүз шарлавыгы моның белән ярыша ала?!

Бу—халык күңеленнән убылган симфония.

Тел хасиятенә соклanудан күз яше чыгара торган бу бөек поэма—*«Арыслан хәлдән тайса да, бер сарыклык көче бар...»* дигән кебек, сүз төше мәрмәри мәкальгә әйләнгән хикмәтле юллары белән генә дә вакытны тез чүктерә ала. *«Күктә Чулпан булудан суда чуртан булу артык.» «Нинди юан булса да ялгыз агач өй булмас; нинди ятыш булса да ялгыз егет би булмас." «Ирнең күнеле ефәктәй—бер төйнәлсә чишелмәс.» «Ком җыелып таш булмас, кол җыелып баш булмас!»*

Аннары... мең еллар буена килгән көрәш, туганга туган, ыруга ыру кылыч күтәреп, нинди гаярь халыкның үз кодрәтен үзе җуюның бәхетсез соңы хакында дөнья шигърияте көнләшеп баш иярлек юллар... Дастанның тетрәндергеч кыллары, матәмле сүзләрнең аһылдавы...

*«Җир китәр дә ни калыр? Җиреннән тайган ил калыр; ил китәр дә ни калыр? Ил киткәндә йорт калыр, йорт китәр дә сөт калыр, күкрәктән сөт имгән сүзе татлы тел калыр. Тел китәр дә ни калыр? Язганнан язган хат калыр; Баш китәр дә ни калыр? Буында типкән кан калыр; Буыннан буын чабылса, ул чагында ни калыр? Йорт урынында яу калыр; Яу чапканда ни калыр? Ялгыз башы каңгырап, чүл далада тинтерәп, дуадактай хан калыр...»*

Җиһанга түбә булган җиде кыя, дәверләр учы булып җәелгән җиде дала шаһит: ярларын өч океан, җиде дингез юган кыйтгаларга ия булып та, әкияттәге дию кебек җиде башка аерылган төрек дөньясының атлы дәверләр симфониясендә кисәтүле мәрсия булып яңгырый бу аккордлар...

Әрнүле бәгырь догасы бу дастан...

* * *

Бу—синдәме, шигърият,
ак кәгазь аланында каләм аягүрә басуга, яшәү суты өртелгән сүзләрнен, кысан шәкелгә буйсынып, хәр фикер күгенә сибелүе?!

* * *

Бу—синдәме, шигърият,
сүз пәйгамбәре тарафыннан сайланган кандаш, аңдаш, моңдаш сүзләрнен илаһи бердәмлеге: думбра, кубыз, саз, гөслә кыллары чиртеп, тормыш-хәят хакында тәүлекләр буена кабатланмыйча жыру әйткән чәчәннәрнең тиңдәшсез тапкырлыгы?

* * *

Бу—синдәме, шигърият,
аксакал Шәрекънын дастани олпатлыгы; илләр язмышын сөңге очына алып биетә алу аяусызлыгы; тәхет откан илханның кылыч сабыннан арган кулына каләм алып, сүзгә сәҗдә кылу сәләте?

* * *

Бу—синдәме, шигърият,
утлы-гарасатлы гасырлардан чит-читләре янып, көеп, таланып чыккан китапның үзәгендә сүз баганалары булып, исән калу бәхете?

* * *

Бу—синдәме, шигърият,
баш очында кылга эленгән кылыч торганда да иманга тугры калу тәвәккәллеге?

* * *

Бу—синдәме, шигърият,
Тубай агачына ялгыш кунган чәүкәне дә, лачын кадере биреп, тирбәтә белү юмартлыгы?..

* * *

Бу—синдәме, шигърият,
еланнан елау көтмә, дигәндә дә, елдырымланып, еланны елата алу елдамлыгы?

* * *

Бу—синдәме, шигърият,
көчек сикертер көйгә кечек такмак язганны да, каләм иясенә тинләп, үсендерү ихтирамы?

* * *

Бу—синдәме шигърият,
халкыңның хасталы рухын, әрнетә-әрнетә уятып, асыл исеме биеклегенә күтәрә алу ихтыяры?

* * *

Бу—синдәме, шигърият,
ана теленә хыянәт иткәннәрне дә, өмет жиме калдырып, бәхилли белү олылыгы?

# БАЛБАЛ ТҮШЕНДӘГЕ ТУСТАГАННАН

ТӨРЛЕ ЕЛЛАРДАН ШИГЫРЬЛӘР

## Вакытны узган шагыйрь турында

Гади генә кыяфәтле иде,
Иске кәпәч иде башында.
Аның эзе меңнәр эзе белән
Буталгандыр урам ташында.

Сүзен әйтсә, тыңламыйлар иде,
Ишетмиләр иде табында—
Эре гәүдәлеләр эре сүзләр
Сайлап кына тезгән чагында.

Ул көннән-көн кечерәя барды,
Наполеон буйлы калгач та
Көрәште ул туры сүзе белән,
Нужа якасыннан алгач та.

Заманга ул сыя алмый иде,
Артык иде шаулы тормышта.
Ул бит бары шагыйрь, шагыйрь иде,
Тәңре улы иде тумыштан.

Вакытында үлә белеп үлде,
Шул мизгелдән һәрбер шигыре,
Һәрбер әйткән сүзе канатланып,
Бөек мәгънә алып өлгерде.

Вакыт аны куып җитәр өчен
Туктатты да мәрмәргә төрде.

*1980*

## Шәрекъ биюе

Җиләс залда тып-тын гына бии кызлар—
Бөек ханның сылу колыннары.
Иңнәреннән ага тау чишмәсе кебек
Кырык нурдан үргән толымнары.

Алтын пәрәвезле биек гөмбәзләрне
Назлы аһәң күккә якынайта.
Кагыла моң күңелләргә, агыла моң
Чиксезлектән урап кайта-кайта.

Фарсы келәмендә хан утыра карап
Каш астыннан кызлар тарафына.
Ни булган соң бүген, ни булган соң аңа—
Зәһәр уты сүнгән карашында?..

Хан утыра, майлы кымыз тәме килгән
Каты мыек очын тешләгән дә.
Ачты аңа назлы аһәң бер хакыйкать:
Ул иректә бары төшләрендә...

Хәнҗәр сабын кыскан көчле бармакларда
Затлы ташлы күпме йөзек кашы—
Ул көл иткән шәһәр, илләр-җирләр саны,
Тәгәрәгән күпме кеше башы!

Бөек хаким. Ул бит әмер генә бирсен,
Чумып тәхет көче ләззәтенә;
Буйсынуга мохтаҗ кырмыскадай җаннар
Аямыйча үзен утка керә.

Бүген менә ачты хакыйкатьнең күзен...
Меңнәрне ул әсир иткән иде.
Хакимлекнең, тәхет биргән мөмкинлекнең
Ул үзе дә колы икән инде.

Назлы аһәң уятты да куйды аның
Калын көл астында калган хисен.
Күз алдында—җәйрәп яткан япан дала,
Учак төтеннәре, кылган исе.

Тезелешеп бара дөя кәрваннары,
Ә ул уйный-көлә белгән малай.
Аның да бит әнисе бар сыенырга,
Күктән төшкән изге түгел алай.

Менә хәзер атланырга иде дирбиясез
Һәм иярсез генә чаптарына.
Һәм кайтырга иде гөнаһларга ярлы,
Шатлыкка бай сабый чакларына!

Җиргә ятып бер елыйсы иде хәзер,
Карамыйча күктә Тәңре барга.
Тән сакчысыз, җан сакчысыз, вәзирләрсез,
Чыгып китәр иде далаларга...

Көч-куәте үзен әсир иткән ханның
Бу тәнендә затлы кан елыймы?!
Буйсындырган да ирексез, буйсынган да...
Шушы—җирдә яшәү канунымы?!

Тамды шул чак, ханның күз яшьләре тамды
Алтын җепле чапан бәрхетенә.
Сискәнде дә кинәт...
Ерак малайчактан
Сикерде ул биек тәхетенә!

Кем искәреп калды?!
Бөркет караш әзли,
Үз ирәген тоеп әле генә
Хозурланган ханны чиксез ярсу били,
Сынап карый күндәм вәзиренә.

Менә кем искәргән ханның күз яшьләрен!
Корбан сорап зеңли йөзек кашы—
Әмер биргән ханның зәһәр шәүләсенә
Карбыз булып төшә вәзир башы.

Аһәң тына... Кара елан шуып чыга
Һәрбер кызның кырык толымыннан.
Хан, күзләрен каплап, ярдәм сорый шашып,
Үзен әсир иткән үз колыннан.

*1983*

## Дала каны

Таң бөркете иңрәп күтәрелә
Җилгә изү ачкан балбаллардан.
Чыңгыз ханның елгыр аргамагы
Кешнәп чапкан япан далалардан

Өне килә ерак дәверләрнең,
Кемгә аны тою язмагандыр;
Гомер агачыннан башкаена
Әремле бал, әрнеп, таммагандыр.

Ялган зурлык—яман хурлык булып
Кайта берчак тормыш уенында.
Балбал кебек изүеңне ачсаң,
Кысыр җилләр бары куенында.

Җанда дала җиле уйнамаса,
Карашыңнан учак кабынмаса,
Җәя тартыр бармакларың дәрте
Саз кылына назлы кагылмаса—

Сиңа иңмәс Күкләр ихтыяры,
Дәвер ябар хәтер капкаларын.
Язмас хәтта төшләреңдә күрү
Җир тетрәткән, атлы чапкыннарын.

Атлы дастаннарга иелерлек
Дәрман бармы хисси төннәреңдә,
Тиңсез бөек дала поэмасы
Кайсы курган-кабер төпләрендә?

Уяныр мы Турфан оазисы,
Алтай-Саян, Тургай далалары?
Балбал түшендәге тустаганнан
Чык-су эчә бөркет балалары,

Күзләрендә—кыя чаткылары,
Йөрәгендә яна дала каны.

*2006*

## «Кисекбаш»лы халкым юлы

Исертә дә куя заман
Халык дигән сарыкларны.
Илдә күпме шәһәр тулы
Һәйкәл һәм чүп савытлары.

Айну килә бик соңарып.
Заман узган. Туннар тузган.
«Кисекбаш»лы халкым юлы—
Тузанлы кан, канлы тузан.

Бүген иман яңартам дип,
Багып кара күк-гарешкә.
Ни бирдең дә, ни алдың син,
Салаватмы үткән эшкә?!

«Өлкән туган» һаман әйди,
Гасырларга җитәр көче:
Яулаган бер гөл савытын
Чүп савыты итәр өчен.

Үзе һаман: «Мин бөек!» —дип,
Яулап тора, янап тора;
Әгәр инде ышанмасаң,
Шундый итеп яраттыра...

Күпме галим эшли аңа—
Татар дигән фәнни дошман.
Шул дошмансыз бөек булып
Кара идең, Ходай кушкан...

Татар һаман футбол тубы,
Кем иренми—килә, тибә.
Кайсы капкага керсә дә—
Туп түгел шул, типкән җиңә.

*1996*

## Томанлы август таңы

И, иртәнге хозурлыклар яме!
Тугайларга томан тулышкан.
Иркәләнеп кенә калка Кояш,
Җир кинәнә сөтле сулыштан.

Җилгә әле уяныrга иртә,
Бисмиллалы таңның үз мәле,
Яшәү дигән галибанә мизгел:
Иреннәрдә—сабый көз тәме.

Гөмбәләрнең колагыннан тартып
Агып бара август томаны.
Тәһарәтле таңы табигатьнең,
Зеңләп куя көмеш комганы.

*2006*

## Мин көтүче булам,
## дигән идем

Карашымны күккә юнәлтәдер
Таныш сукмакларның азаюы,
Һаман шулай, авыл турысыннан
Агып бара Киек Казлар Юлы.

Чигенә сулар, агышларын борып,
Иске ярын хәзер белә кемнәр?
Казлар кебек бер аякта басып
Йокымсырап тора өянкеләр.

Мин хуҗасы идем бу төбәкнең,
Чикне белми иде хыялларым.
Менгән саен тормыш баскычыннан
Сагындыра артта калган ярым.

Мин көтүче булам, дигән идем,
Кичерегез, кырлар, тугайларым,
Китеп барсам да мин еракларга,
Тугры калдым сиңа, туган ягым.

Үткәннәрем инде—бүтән дөнья,
Яд итәдер хәзер үзгә көннәр.
Пәке белән уйган исемнәр юк—
Коймаларга кадәр үзгәрткәннәр.

Сөялгәнмен хәтер агачына,
Чиксез күктә—таҗын ачкан өмет.
Җәйрәп ята чыклы йолдыз юлы—
Таңда көтү киткән эзләр кебек.

*1982*

## Аэропортта хушлашу

*Дусларга*

Җирдә урын кысанырак бугай,
Бу гомернең уйлыйм соң мәлен:
Кайгы белән сезне мәшәкатьләп,
Мин, ахыры, җирдә үлмәмен.

Уйнап-көлеп кенә хушлашырбыз.
Бер алманы бишкә бүләргә
Вакыт булыр, самолетлар очмас...
Сез китәрсез кайтып өйләргә.

Мин калырмын, ялгыз гына көтеп,
Ачылыр да һава юллары,
Ак канатлар күтәрерләр мине,
Мең борчулы җирдән югары.

Болытлардан өстә кабул итеп
Көтелмәгән язмыш карарын;
Яшәү дигән бөек газапка мин
Менә шунда җавап табармын.

Җавап табармын да... Күкләр ялгар
Олы сергә—гомер азагын.
Тик кызганыч, соңгы ачышымны
Сезгә инде яза алмамын.

Сез калырсыз уртак хыял белән,
Тормыштан күп кызык табарсыз.
Бер сүз аша мин хәтергә төшсәм...
Йолдыз арасына карарсыз!

*1981*

*Бу айда журналыбызның даими авторы* ***Марсель Галиевкә*** *60 яшь тула. Күпсанлы укучыларыбыз исеменнән шагыйрьне кайнар котлап, аңа сәламәтлек, яңа иҗат уңышлары телибез!*

**Редакция**

Фоат Садриев

# БӘХЕТСЕЗЛӘР БӘХЕТЕ

РОМАН

## 15

Минзаһит ике сәгать буе, әле лабораториягә барып, әле өлкән шәфкать туташы янына кереп, әле соңгы уколларын алып, хәлдән тайганчы чабулап йөрде. Сәгать унберләрдә үзләре ята торган ун кешелек палатага кереп, караватына барып утырды. Бик тә ятып торасы килде, әмма курыкты. Ятуы була, күз алдына әллә нинди хәшәрәтләр хәрәкәткә килә. Бүген ул бигрәк тә курыкты. Кычкырып җибәрермен дә, тагын чыгармаслар, озаклап ятарга туры килер, дип коты очты. Рәшат бер генә мәртәбә дә больницага килмәде, Минзаһит аны күрергә дә теләмәде. Аның өчен ул, гомумән, кеше булудан туктаган иде.

Арыганлык җиңде, Минзаһит акрын гына мендәренә таянды һәм шундук күз алдына әллә нинди ямьсез, йөрәгенне ярырлык кеше башы пәйда булды. Аның бөтен җирен миң баскан, пеләш башында кечкенә кеше башлары миң кебек тырпаешып торалар. Ияге түп-түгәрәк, шулай ук кеше башы төсле ялтырап тора. Менә баш түбә чәркәсе ягына сузылырга тотынды, сузылган саен нечкәрде, нечкәрә-нечкәрә ике колагы кара-каршы килеп кушылды да, шул турыдан кызыл күз килеп чыкты. Ул зураеп бөрек кадәр булды. Аның уртасында авыз барлыкка килде, авыз киереп ачылган, тамак төбе туры тишек, шул тишектән артта үсеп утырган агачлар күренеп тора, авыз тулы сары черек тешләр, алар арасында үлеккә охшаган кие нәрсә сузылган; менә баш әйләнергә тотына, аның белән бергә Минзаһит үзе дә әйләнә, башларның саны ишәя, ниндидер балалар пәйда була, аннан соң сакаллы картлар күренә, бөтенесе ишелеп, әллә нинди ярсыз-нисез су өстендә ага башлыйлар, ул су ага да ага, үзе яшькелт, үзе кызгылт, үзе сары, үзе көмештәй ялтырап китә... Минзаһит саташканын аңлый, бу галлюцинациядән котылырга тели, тешләрен кысып, кулын кулга ышкый, үзен ияртеп барган ташкыннан ахырда сикереп төшеп кача. Күз алдында больницаның ак түшәме пәйда була. Ул тирән итеп сулыш алып торып утырды. Башы җиңелчә генә әйләнә һәм маңгай турыннан сызлый иде. Биредә ятканда аның инде күрмәгән әйберсе калмады. Ул хәтта үзенең балачагын да, үлгәнен дә, кабердә ятканын да, оҗмах-тәмугларны кичкәнен дә күрде. Әгәр бу дөньяда аңа ни дә булса күрсәтсәләр, ул һич тә гаҗәпләнмәс иде. Шул коточкыч саташулар аның чәчләрен ап-ак итте, ул калтыравыкка әйләнде, ашаган вакытта авызыннан әйбере коелды. Гомер буе бритва белән кырынган Минзаһит Хәяттан электр кырынгычы китертте. Аның белән янәшә физика фәннәре докторы ята иде. Минзаһит аңа үзенең саташуларын сөйләде. Галим бөтенесенә квалификация ясады: сезнең галлюцинацияләрегезнең төп характеры зурдан кечкенәгә, кечкенәдән зурга әверелү, бар якка да сузылу һәм өзелү, бер ноктадан әллә ничә төрле әйбер барлыкка килү һәм шуларның кушылып тагын бер бөтен әйбергә әверелүе, астан да, өстән дә, уңга-сулга да

*Ахыры. Башы алдагы саннарда.*

ташкын рәвешендә агу, бөтерелү һәм шуларның бөтенесе ниндидер шакшы, лайлалы әйберләр белән буталу, дип схеманы сызды ул. Боларны Миңзаһитның организмында бара торган процессларның чагылышы, дип аңлатты. Димәк, ул процесслар һич тә яхшыга илтә торган рәвештә бармыйлар. Аннары тагын, аның аңлатуынча, безнең организмдагы бу процесслар иҗтимагый тормыштагы таркалуның, черүнең, анда барлыкка килгән яман шешләрнең чагылышы булып тора. Профессорны тыңлый-тыңлый, Миңзаһитта кайчакларда фикер галлюцинациясе башланды. Аңысы инде бөтенләй акылдан язуга тиң. Шушы саташулар ташкыны әллә кайларда ыргытып йөрткәндә, бервакыт ул ап-ачык итеп үзенең әбисен күрде. Әбисе зәңгәр һавада утырып тора, ап-ак яулык бәйләгән, ап-ак күлмәк кигән, яулык астыннан көмеш чәчләре күренә. Миңзаһит аңа кычкыра, зинһар коткар, ди, бу ташкыннан тартып ал, әбием, ди. Әбисе дәшми, кулындагы көрән төстәге акча янчыгын ачып, акчаларын саный-саный да, карап тора. Миңзаһит аңа бик озак ялынды, әмма әбисе әллә күрмәде, әллә күреп ярдәм итмәде...

Өлкән шәфкать туташы кереп, аңа башының томографиядә яздырган кәгазьләрен, берничә рецепт бирде.

—Инде сезгә китәргә мөмкин,—диде.

Миңзаһитның күптән борчыган бер олы уе бар иде. Ул әллә ничә мәртәбә профессорның кабинет ишегенә барып килде, әмма анда гадәттәгечә кулына кәгазьләр, рентген рәсемнәре тоткан авырулар чират торалар, баш тыгарга җай юк иде. Көндезге ашка чакырган вакытта гына профессор янына керә алды ул.

—Тыңлыйм сезне,—диде врач.

Миңзаһит, бүлмәдә беркем югын белсә дә, як-ягына каранды, калтыранган куллары белән туктаусыз җиңнәрен тарткалады, аякларын урыныннан кучереп-кучереп куйды.

—Мин инде сезгә үземнең кем аркасында мондый хәлгә төшкәнемне сөйләгән идем,—диде ул карлыккан хәлсез тавыш белән.—Инде мин янадан больницага эләгә алмам... туп-туры зиратка гына алып китәчәкләр.

Ул шунда туктап калды, сүзен дәвам итәргә хәле җитмәде.

—Рецептларыгыз язылган, тыныч кына яшәгез, дәваланыгыз,—врач шулай диде дә урыныннан торды.

—Сез минем ник кергәнемне белмәдегез,—диде Миңзаһит кабаланып.—Әгәр минем теләгемне үтәсәгез, үлгәнче сезгә рәхмәт укыр идем.

—Нинди теләк?

—Бирегез берәр көчлерәк йоклата торган дару.—Миңзаһит, куркудан калтыраучы башын тыярга тырышып, куллары белән тотты, үзенең куркынган карашы врачта иде.—Сез бит минем хәлемне аңлыйсыз. Зинһар кызганыгыз...

Врачның йөзе бозылды:

—Сез, Арсланов агай, бик җебегән кеше булып чыктыгыз. Ир кешегә хас нәрсә түгел бу. Кешеләр яшәү өчен көрәшәләр, ә сез...

—Мин бит... мин дә...—дип мыгырданды Миңзаһит.

—Хәзер үк чыгып китегез!

Ул, аякларын лыштыр-лыштыр сөйрәп, коридорга чыкты, ачынып үзләренең палатасына керде һәм урынына утырды. Нияте барып чыкмады, димәк, бүтән әмәлен табарга кирәк иде.

Травмотология институтының баскычыннан төшкәч, Миңзаһит үзе яткан бинага озаклап карап торды, аның ишек янына беркетелгән алтактасын кат-кат укыды, аннары җәяүләп трамвай тукталышына юл тотты.

Аның бәхетенә, Рашат өйдә юк иде. Ул кайтып ишектән керү белән, Хәят, нишләп хәбәр итмәден, тагын егылып ул-бу булса, син бит ярты гына кеше, дип тиргәде дә тиргәде. Өйгә кайткач, җаны тынычлап киттеме, ул атна буе йокылы-уяулы халәт кичерде. Саташулары бөтенләй бетте диярлек. Әллә инде ми күзәнәкләре ял итәргә теләделәр, әз генә утырып торса, йөреп алса, барды да ятты, хырылдап йокыга да китте. Уянып өлгермәде, исерек

кеше кебек тагын ауды. Шулай итеп атнага якын вакыт узды. Ә теге уй ана һаман да тынгылык бирмәде. Бер-ике мәртәбә Хәят белән кибеткә дә чыгып керделәр. Әмма бу бәхетле көннәргә Рашатның кайтуы чик куйды. Аның элеккедән дә хәтәррәк исереп тузынулары, икесенә дә бәйләнүләре, акча сораулары башланды. Минзаһитның йокысы качты, галлюцинацияләр тагын да куркынычрак рәвештә бөтен барлыгын агуладылар. Ял көнне, түземе бетеп, ул базарга чыгып китте. Акчасы кесәсендә, букчасы кулында, нияте башында иде. Ул, анда-монда сугылмыйча, базарның үлән сатыла торган почмагына китте. Электән үк сөйләшеп йөргән таныш карты белән күреште. Көн салкынча иде, карт күгәреп-туңып беткән, туктаусыз тәмәке пыскыта һәм бер урында таптанып тора. Алдына төрле үлән тамырлары, үсемлек орлыклары тартма-тартма итеп таратып куелган.

—Мина йоклата торган үлән табып бир әле,—диде ул ана, пышылдап кына.

—Әнә бит, ал,—диде карт.—Сукыр кычыткан, бөтнек, валериан тамыры—беткәнмени шунда.

—Юк, мина көчлерәге кирәк.—Ул картның колагына үрелеп пышылдады:—Мәнгегә йоклата торганын табып бир...

Карт тирән итеп суырган тәмәке төтенен эченә йотты да чыгармыйча, тын алудан туктап, Минзаһитка төбәлде, шаяртып кына әйтмиме, дип сынап каравы иде ул аның, Минзаһит кесәсеннән бөкләнгән мең сумлыкны чыгарып күрсәтте. Картның күзләре майланып китте, борынныннан төтене дә чыкты, әллә ничә мәртәбә төкреген йотып куйды.

—Бар,—диде ул, шыпырт кына.—Иртәгә кагыл.

Минзаһит кайтырга кузгалды, ул үзенен дәртләнеп атлавына хәйран калды. Ул бу җир йөзендә башкарачак соңгы эшенә әзерләнә. Ул инде гомеренен күп калмаганлыгын аңлый, салкын кабернен хәтта исен дә тоя кебек. Бөтенесе гади, ачык һәм рәхимсез. Кире борылу юк, ишекләр бикләнгән, бер генә нәрсәне дә үзгәртеп булмый.

Балаларын житәкләгән бәхетле парларга карый-карый, ул менә шушы кара уен күтәреп атлады. Шугалакта чана шуучы балалар янына басып карап торды, тәгәрәп аунаганда аларның киемнәренә ябышкан карларын кагып төшерде. Ул үзеннән җирәнергә тиеш иде, ләкин шаккатып күңеленен тынычлыгына, битарафлыгына хәйран калды. Аның инде хәзер хәтта Рашатка да нәфрәте, ачуы беткән иде кебек. Бары тик теге уй гына яши, ул гына тизрәк тормышка ашыруны таләп итә...

## 16

Мамонтның бәрмә теше очыннан чатный башлаган кебек тоелды Ирекка. Ул, кулына, лупа алып, урындыкка басты да, сөякне жентекләп карарга кереште. Шул чак ишек ачылды һәм Әхнәф килеп керде.

—Син музейга кергән һәр кешене дә шушлай каршылыйсынмыни?—диде Әхнәф, йөзенә ясалма елмаю чыгарып.

Ирек аңа таба борылып та карамады, мамонт тешен тикшерә бирде.

—Ни бар?—диде ул тамак төбе тавышы белән.

—Төш инде, болай сөйләшеп буламыни?

—Ни бар, дим?

Әхнәф аңа таба атлый башлады:

—Әллә авырыйсын инде...

—Якын килмә! Ни бар?

—Ай-яй-яй! Өскә сикерергә җыенган җанвар кебек син.

Ирек кинәт йөзен аңа таба борды, ачулы күзләрен елтыратып:

—Оясын актарсаң, агусыз елан да тешли,—диде.—Ник килден?

—Сүз бар иде.

—Безнең сүз бетте. Бүлмәннән ничек озатканынны хәтерләмисенмени?

—Ярый, сөйләшергә теләмәсәң.—Әхнәф тирә-ягына карап уйланып торды.—Экспонатлар карарга мөмкиндер бит?

Ирек «ә» дә, «җә» дә димәде. Әхнәф, акрын гына экспонатларга күз салгалап, иң түргә барып житте. Почмактагы ап-ак сакаллы карт төшерелгән фотоны кулына алды.

—«Кудряшов Алексей Григорьевич»,—дип кычкырып укыды ул.—Хвощинский исемле бояр шушы крестьянны Себердән бер көчеккә алмаштырып алып кайткан. Фажига инде бу. Шулай да дуслыкны дошманлыкка алыштыру кебек үк түгел. Әле андый кешеләр дә бар бит арада...

Ирек кысылган тешләре арасыннан сыгып:

—Йә, йә, әйтеп бетер,—диде.

—Бетерәм: сине күпмегә сатып алдылар?

Ирек болай да гәүдәсеннән үтәли яшен уты уздыргандай киеренкелектә тора иде. Әхнәфнең бу сүзләре аны тәмам чыгырыннан чыгарды.

—Нәр-сә-ә?!—диде ул үз тавышына үзе буылып.

—Дуслыкны Саттаровларның нәрсәсенә алмаштырдың? Акчага сатылдыңмы, бүтән әйбергәме?

Ирек үзенең урындыктан ничек сикереп төшкәнен, ничек аның каршына атылып барып житкәнен сизми дә калды.

—Мин сатылдыммы?!

—Сатылмасаң, Саттаров исеменнән мәкалә язмас идең. Ичмасам үз фамилияңне куйсаң, ирләрчә булган булыр иде.

Әхнәфне бирегә күпме вакытлар тынгылык бирмәгән шиге алып килде. Теге мәкаләне шушлай үтергеч ирония салып Ирек кенә яза ала, димәк, ул гына язган, дип уйласа да, Фәһимә һәр көн, «бары шуның гына кулы», дип тукып торса да, күңел түрендә, «бәлкем ул түгелдер», дигән шиге бар иде. Берәр Казан журналисты язган булса? Моны ачыклау аның өчен тәкъдирен билгеләр дәрәҗәдә мөһим иде. Әгәр Ирек шушы эшне эшләгән булса, аларны үзара тоташтыручы соңгы җеп тә өзелде, дигән сүз. Әхнәф исә моны һич тә теләми, чөнки ул япа-ялгыз иде. Юк, юк, ул Иректән бернинди дә ярдәм өмет итми. Аның янәшәдә икәнлеген генә булса да тоярга кирәк хәзер. Ерактагы ата-ананның исәнлеген белеп тору җанына тынычлык биргән кебек, үзенә начар итеп карамаучы Ирекнең барлыгын булса да сизеп торасы килә иде аның.

—Кем әйтте?!—диде Ирек, аның җиңеннән эләктереп.

Әхнәф чигенеп куйды: Ирек менә-менә ана ташланыр төсле иде. Ул, җиңен ычкындырмакчы булып, кисәк кенә читкә тартылды, әмма Ирекнең кулы аны чытырдатып кыскан, бармак буыннары агарып тора, кул сыртындагы тамырлары зәңгәрләнеп бүртеп чыккан иде.

—Кем әйтте?!

Әхнәф тегенди-мондый сылтау белән котыла алмаячагын аңлады.

—Беркем дә әйтмәде,—диде ул.—Саттаров аны мәңге яза алмый. Синнән башка беркемнең дә кулыннан килмәгәнлеге билгеле бит.

Ирекнең бармаклары үзеннән-үзе йомшардылар, ул, авыр итеп көрсенеп, маңгаендагы тирен сөрткәннән соң:

—Их, Әхнәф!—дип куйды да хәлсезләнеп шундагы урындыкка утырды, башын түбән иде.

Бу сүзләр аның күкрәгеннән әрнү һәм рәнжеш ялкынындай бөркелеп чыктылар да, Әхнәфне башыннан аягына кадәр көйдереп алдылар. Ирекнең ике чигәсе сулык-сулык чәнчешергә тотынды. Ул, көч-хәл белән өстәл янына барып, графиннан стаканга су агызды, шуның белән даруын эчеп куйды. Бераз хәл кергәч, сагышлы тавыш белән:

—Син миннән ерагайганнан-ерагая барасың,—диде.—Шул кадәр тырышасың...

Әхнәф аның сүзләрендәге аяусыз хаклыкны эченнән коты очып икрар

итәргә мәҗбүр булды. Аның өчен инде хәзер Ирекнең Саттаров мәкаләсенә кул тыкмаганлыгы да бәхәссез иде. Әхнәф акрын гына аның янына килде.

—Кичер мине,—диде ул ишетелер-ишетелмәс тавыш белән.—Син дип уйлаган идем... Булдыра алсаң, зинһар кичер...

Ирек дәшмәде, Әхнәф кадаклагандай шул урынында басып тора бирде. Әхнәфкә үз гомерендә беркайчан да бу дәрәҗәдә таяныч кирәк булганы юк иде әле. Аның йөзенә ялвару билгеләре җәелде, иреннәренең дерелдәвен сиздермәс өчен, ул аскы иренен шактый вакыт тешләп торды. Аннары:

—Ирек, әйдә, бер ачыктан-ачык сөйләшик әле,—диде.—Йөрәкләрне учка салып...

Ирек урыныннан кузгалмады, башын күтәреп, аны тыңларга җыенганын белдерде:

—Әйдә соң...

—Бар иде бит яшь чаклар! Гел искә алам, сагынам!.. Син дә сагынасыңмы?

—Сагынам, билгеле,—дип куйды Ирек, уйчан кыяфәт белән.

—Кояшлы чаклар булган икән!—дип дәвам итте Әхнәф. -Авырлык чыккан саен, бер-береңә йөгереп барасың, эч серенне бушатасың, күңелләр яктырып китә! Шул чаклар искә төшкән саен, күңел сыкрый...—Әхнәф, Ирек берәр нәрсә әйтмәсме, дип көтеп торды, әмма ул иренен дә кыймылдатмады. Әхнәф уйларына баткан хәлдә мамонт тешләре янына китте, хәтсез генә аларга карап торды.—Менә бу тешләр күпме җан ияләрен кыйгандыр, он-талканга әйләндереп ашагандыр...—Ул кире борылып килде, як-ягына күз йөгертеп, сүзен дәвам итте:—Бүгенге тормыш тегермәне дә рәхимсез, үзенең ташлары арасында адәм баласын туйганчы тарта, хәтта бүтән затка әверелдерә.—Ул шунда башын капыл гына Ирекқә борып, аның күзләренә туп-туры төбәлде.—Әмма ул сине миңа каршы кеше итәргә тиеш түгел иде!

Ирек баш чайкап куйды:

—Әгәр киресенчә булса? Сине миңа каршы кеше ясады бугай ул...

Әхнәфнең йөзе бурлаттай кызарып чыкты, күз алмалары сикерешергә тотынды.

—Ярар, теләсә ни әйт!—ул кулларын селтәп куйды.—Яши алмыйм мин болай! Кулым эшкә бармый, дөньяның яме, яшәүнең тәме калмады.

—Кем гаепле соң?—диде Ирек.

—Менә, менә, син гадәттәгечә гаепли дә башладың! Тормыш дистиллированный су түгел, ул хәтта фильтрланмаган да, болганчык булып, бөтен ләме, чүп-чары белән ага.—Әхнәф, ярсуын баса алмыйча, музейның икенче башыннан әйләнеп килде.

—Тормышны гаепләү ансат. Син аның һич югы берәр шөребен булса да үзгәртергә, яңадан корырга тырышып карадыңмы соң?

—Минем гомер буе шуннан башка шөгылем булмады!

—Юк, Әхнәф,—диде Ирек кашларын җыерып.—Күңелеңә авыр алсаң алырсың, тымызык күлдә кармак салучы кеше җилдән курыккан шикелле яшисең син.

—Бөтенегез миңа каршы! Тирә-юнем тулы кеше мыжгып тора,—җанымны ачып салырлык беркем юк. Берүзем, япа-ялгыз!

—Ә син аласың килсә, үзең дә бир.

—Мин бирмиммени?! Җилкәмдә күтәрә алмаслык йөк. Дөнья күрәнми, менә хәзер гөрселдәп авам, дигән көннәрем күп!..

—Кол шулай булырга тиеш инде ул.

—Кол?!

—Әйе. Сары май эчендәге балавыз кебек син. Үзең кол.

—Менә, сөйләшкән саен синең уйларыңның миңа каршы икәне ачыла бара. Революция кирәк сезгә...

—Ә кемнәр соң сине заманында депутат итеп сайлату, райком секретаре итү өчен тырышты?—диде Ирек, аның сүзен бүлеп.—Мин түгелме? ТИҮ

егетләре түгелме? Син миңа бер соравыма җавап бир әле: без элек күмәк тормыш, уртакны тигезләп бүлү кебек изге нәрсәләр белән яшәдек. Чынлап та инанган идеңме син шушыларга?

—Ирек, син вакытны туктатырга азапланасың!—диде Әхнәф ачынып.—Тигезләп булмаганын күрдек бит инде. Тәрәзәдән үрелеп кара: тышта бөтенләй икенче климат! Әллә бу мамонт сөякләрең борынгы дәверләргә сөйриме сине?—Ул сәер генә җилпенеп алды.—Вакыт поезды алга чаба, кешелек икенче төрле дәвергә күчте, бүтән заман килде. Әгәр аны кабул итмәсәк, вакыт җиле безне кибәк урынына очырачак. Элекке төшенчәләрнең күбесе мәгънәсен үзгәртте. Ә син виртуаль дөньяда яшисең.

—Нык шомаргансың син, хәтта куркыныч!—диде Ирек гаҗәпләнеп.—Инанган булсаң, үзең әйткән теге поездга ансат кына сикереп утырмас идең. Шамбы балыгы кебек шомаргансың. Минем соравыма җавап бирәсе урында, әллә кайларга алып кереп батырдың. Әле үткәннәргә, әле киләчәккә, әле фәлсәфә чытырманлыкларына... Болай булгач, барып чыкмый безнең йөрәкне учка куеп сөйләшү.

Ирек урыныннан сикереп торды. Аларның карашлары очрашты.

—Ирек, үтенеп сорыйм...—Әхнәф җайлырак сүзләр эзләде.—Һич югы син миңа каршы чыкма... Башка берни дә сорамыйм. Сүз бирәсеңме?

—Бик җиңел хәл итәсең син, Әхнәф. Утын ярган кебек кенә. Шарт-шорт—шуның белән вәссәләм!

Әхнәфнең йөзе кара янып чыкты. Ул Иректән уңай җавап ала алмаячагын аңлаган иде инде.

—Синдә үткәннәрдән берни дә калмаган икән!—диде ул ачу белән.

—Чишмәгә нәҗес салсаң, аның суы агулана. Өстенә чүп-чар аударсаң, бөтенләй коруы да бар.

—Димәк, син Саттаровлар белән һаман миңа каршы казыначаксың?

—Аллам сакласын андый түбәнлектән!—Ирек үзалдына сәер генә көлеп куйгандай итте.—Минем нидер эшләвем-эшләмәвемнең әһәмияте юклыгын син берничек тә аңлый алмыйсың.

Әхнәф кабаланып калтыранган бармаклары белән галстугын бушайтып куйды—аңа һава җитми иде.

—Хәйләләмә, мин ахмак түгел!—дип кычкырды ул, инде ачуын яшерә алмыйча.

—Юк, юк, ахмак түгел!—диде Ирек, аның сүзен җөпләгәндәй.—Син акыллы да, хәйләкәр дә. Тик син бер нәрсәдә ялгышасың: тормыш аргамагына атландым да, гел шушылай чабып барырмын, дип уйлыйсың. Ә аргамагың гел упкын читенә каера...

—Ни әйтмәкче буласың син?—диде Әхнәф шомланып.

—Берүзем дип зарландың. Тимер койма белән сине беркем дә мәҗбүри аермады. Шуны алып атмасаң, олы бәла киләчәк сиңа!..

Әхнәф, әйтер сүз таба алмыйча, кара янып, аңа шактый вакыт туп-туры карап торды. Әмма Ирекнең керфеге дә селкенмәде.

—Синдә миңа карата бернинди игелек тә юк икәненә мин тәмам ышандым!—диде ул һәм, кискен борылып, музейдан чыгып китте.

Йөрәкләрне уч төбенә куеп сөйләшү барып чыкмады...

## ӨЧЕНЧЕ КИСӘК

### 1

Бу ял көнне Таһир беркая да чыкмыйча, семинарга әзерләнергә уйлаган иде. Иртүк торып, өч сәгать буе укыды, язды. Ләкин ручкасының карасы бетеп, ерак булмаган киоскка китте. Ручкасына паста алып кайтып килүенә, ишеккә язу кисәге кыстырып киткәннәр. Ул аны кабаланып

укып чыкты: «Таһир, кайда йөрисең? Урнашып беткәч, мин кабат кагылырмын әле. А.» Аның йөрәге туктап калгандай булды, аннары шатлыктан ашкынып тибәргә кереште. «Ул килгән! Ул килгән!»—дип кабатлады эченнән. Күңеле юкка үрсәләнмәгән, сизенгән бит ул Айгөлнең киләсен.Таһир, әйберләрен өстәлгә куеп, кабат имтиханга әзерләнергә утырды. Бер минут укыды, ике минут, ун минут укыды, тик башына берни дә кермәде. Конспектларын, китапларын ябып куйды. Ә бәлкем ул ярты сәгатьтән әйләнеп килер, дип уйлады Таһир. Димәк, аш салырга, өстәл әзерләргә кирәк. Ит юып, аш салды, суыткычта булган азык-төлеген алып, өстәлгә таратты. Үзе әйбер турады, үзе әледән-әле, зал ягына чыгып, Айгөлнең язуын күзеннән үткәрде, үзе туктаусыз елмайды, тамак төбе белән генә көнелле көйләр көйләде.

Аш та пеште, өстәл дә әзерләнде, Айгөлне көтә торгач, өйлә туры да узып китте. Вакыт үткән саен, Таһир ныграк борчыла барды, баштарак китапларына, конспектларына күз төшереп маташса да, соңга таба миен туктаусыз бер уй бораулады: .»Нишләп һаман килми, кайда йөри?!» Ул, әле бер, әле икенче тәрәзәгә барып, урамны, подъезд алдын күзәтте. Сәгать икенчеләр киткәч, ишек кыңгыравы шылтырады. Таһир, атылып-бәрелеп, кем икәнен дә карамыйча, ишекне ачып җибәрде—каршысында елмаеп Айгөл басып тора иде. Ул аны кочаклап күтәреп алды һәм шул хәлендә зал уртасына алып кереп, берничә мәртәбә әйләндерде дә киемнәре белән диванга салды. Аларның иреннәре ирengә тоташты. Айгөлдән кар исе, кояш исе килә, салкын битләре Таһирның янагын рәхәт итеп иркәли иде. Ниһаять, алар телгә килделәр.

—Мина туныымны, итекләремне салырга мөмкинме?

—Юк,—диде Таһир елмаеп.—Мин сине шушы көе күтәреп кенә йөрим.

—Тун белән мин пешәрмен ич.

—Пешсәң, ашармын.

Алар шулай сөйләнә-сөйләнә шифоньер янына килделәр, Таһир Айгөлнең өс киемнәрен элеп куйды. Аннары күзләренә туп-туры карап:

—Йә, исәнме,—диде дә ике бите очыннан үбеп алды.

—Исән булмасам, җирдә басып торыр идеммени?

—Ничек килеп чыгасы иттең?

—Олимпиадага алып килделәр. Химия буенча.

Таһир, борынын җыерып, мыскыллагандай көлеп куйды.

—Ничек яратып була шул химияне?

—Химиядән башка ничек яшәп була, диген син.

—Мин аны күралмыйм.

—Син бит юрист, ә мин булачак врач.

—Син, Айгөл, шуны әйт: химияне яратмаган егет белән химияне яратучы кызның бергә кушылуыннан нинди химик реакция туа?

—Шартлау,—диде Айгөл көлеп.

Өстәл янына утыргач, Айгөл Таһир әзерләгән ризыкларны мактап туймады. Бергәләп савыт-сабаны җыештырганнан соң, урамнан урап кермәкче булдылар. Айгөл залга чыгып китте, Таһир үзенең бүлмәсеннән күлмәген алып чыкты, залга күз ташлап, Айгөлнең нишләгәнен күзәтә-күзәтә, акрын гына киенде. Шул чак аңа нидер булды. Айгөл алтын нурлар белән өретелгән түр тәрәзә каршында яны белән басып тора иде. Бер кулы белән тәрәзә төбенә таянган, фоторәсемгә төшәргә әзерләнгәндәй, башын бераз гына югары күтәргән, өстендәге ап-ак свитеры тал песие төсле папайланып тора. Ул аны, үзем бәйләдем, дигән иде. Гәүдәсе җыйнак, кечкенә, биле нечкә, кара итәк матур булып тезләренә җитәр-җитмәс тартылып тора. Башы да зур түгел, чәче өскә үк кабартып куелган. Әйтерсең лә ул менә хәзер кинәт кенә күтәрелеп очып китәргә әзерләнә. Ияге, бөтен йөз чалымнары шуна ишарәли кебек. Кояш нурлары Айгөлне үтәли күрсәтәләр төсле. Таһир өчен ул бу җир кешесе түгел, алтын нурлар эчендә балкучы серле зат булып тоелды. Шушы мизгелдә

гаять зур, куанычлы нәрсәне тагын бер мәртәбә аңлады: ул Айгөлдән башка яши алмаячак! Бу—мәхәббәтме, түгелме, анысын Таһир анык кына әйтә алмый. Тик Айгөл инде күптән аның янәшәсендә, аның җанында, ул аны әле куанычлы утка сала, әле шатлык канатларында югары күтәрә. Аны янәшәсендә тойганда, Таһир барлык мәсьәләләрне дә җиңел хәл итә, аның шәүләсе югалса, күз алдын авыр болытлар каплый, сагыш-сагыну уты эчтән яндыра башлый...

Таһир, акрын гына атлап килеп, бармак очлары белән Айгөлнең иңбашы турындагы свитер йонына сак кына кагылды. Ул аңа ялт итеп карады. Шул ук мизгелдә Таһир аның яңакларының, муенының кызарып чыгуын күрде, ул аңардан бәрелгән кайнарлыкны да тойды кебек. Айгөлнең киерелеп ачылган күзләрендә гаҗәпләнү катыш сорау билгесе чагылды.

—Свитер бәйлим, дип язган идең,—диде ул пышылдап кына.—Шушымыни?

—Әйе.

—Бу бит свитер түгел.

—Тунмыни?—Айгөлнең иреннәренә сизелер-сизелмәс кенә көлемсерәү җәелде, күзләренә шаянлык билгеләре чыкты.

—Бу бит... язгы тал песие.—Таһир бармак очлары белән кагылыр-кагылмас кына свитерның тырпаен торган йоннарыннан үтте.—Бу свитер түгелдер, синең секундлардан торган гомереңнең бер кисәгедер. Әнә бит ул нинди тере, синдәй матур, йомшак.

Айгөл нидер әйтергә теләп иреннәрен ачты, әмма Таһир аның иреннәрен үз иреннәре белән каплады... Алар чыгып киттеләр, Казан урамнарын күпме ураганнардыр, әмма эчләренә салкын төшкәч кенә, кабат әйләнеп кайттылар. Чишенгәч, икесе дә ут яндырмыйча гына залга үттеләр һәм тәрәзә каршына килеп бастылар. Казан аларның күз алдында мең төрле утлары белән җем-җем итеп җәйрәп ята иде.

—Синең тәрәзәңә бөтен Казан сыйган, Таһир.

—Әллә безнең күзләргә микән?

—Миңа хәзер миңа Казан олы бер чәчәк бәйләме булып күренә. Ничек матур булып җемелди ул.

—Мин аны сиңа бүләк итәм. Ал үзеңә.

—Куркам. Бу кадәр зур чәчәк бәйләмен мин ялгызым гына саклый алмам.

—Үзем булышырмын.

—Юк инде, Таһир, имтиханнарымны әйбәт кенә тапшырсам, көзгә мин үзем шушы чәчәк бәйләменең эчендәге студент булып йөриячәкмен. Тик нишләптер икеләнәм.

—Шулай булачак, Айгөл, икеләнмә.

Аларның тагын иреннәре иренгә ялганды...

Сәгать төнге унынчы яртыда Айгөл китәргә җыена башлады.

—Бу вакыттамы?!—диде Таһир, аның каршына төшеп.—Мин сине беркая да җибәрмим!

—Ай-яй, ансат уйлыйсың син!—Айгөлнең йөзе җитдиләнде, күзләре түгәрәкләнде.—Азагын исәплисеңме соң?

—Синең биредә калуың ул бит әле...—Шулай диде дә Таһир, туктап калды.

—Әйтеп бетер.

—Аңладың ич инде... Без барыбер бергә булачакбыз.

—Шулай булгач, көтик без ул бәхетле көнебезне.—Айгөлнең карашы шундый җитди иде, Таһирга аны озатып куюдан башка чара калмады.

## 2

Рашат әледән-әле спидометрга күз төшерә. Күсәк йөз егермедән киметми. Арттагы утыргычта сакал-мыекка баткан Фишке йоклап бара. Болынкырга якынлашкан саен, Рашатның йөрәге күкрәгеннән чыгардай булып типте.

Юл буендагы яшь каеннарның яфрак исе борынына керде. Ул туктаусыз тәмәке тартты, еш-еш сулады, хыялы белән әллә нинди уйларга керде. Хәзер инде кичке караңгы төште. Әгәр мөмкин булса, ул Болынкырга, машинага сирена куйдырып, бөтен халыкны тараташ катарлык итеп, үкереп килеп керер иде. Биредә аның бер генә якын кешесе дә юк. Әгәр шундый мөмкинлек булса, бөтен халыкны үзәк урамга алып чыгып тезәр иде, җәзалар иде. Спартак восстаниесен бастыргандай, дар агачлары утыртып, берәм-берәм асып чыгар иде. Кызык өчен үзе белән Арслановны да алып килер иде. Ин соңыннан дар агачына аны эләр иде һәм бу гадел булыр иде. Егет чактан ук әтисен күралмады Рашат. Аның, үзеннән түбән булып та, шундый югары урында эшләп йөрүе, кешеләр белән командалык итүе котырып ачуын чыгарды. Үзеннән өстен булырга теләгән теләсә кем аның өчен дошман иде. Ә Арсланов Рашатны кол итәргә теләде. Бала чакта кыйнавы да, аның үтенечләрен кире кагулары да, мыскыллаулары да күп булды. Үсеп житкәч, Рашат баш бирмәде, аңа теш күрсәтте, йодрыгын төйнәде. Болынкыр аңа Арслановның туйганчы ләззәт алган, хатын-кызлар белән типтергән, аракы эчкән урыны буларак ачуын китерде. Менә хәзер бу егетләргә кушып, бер башына үзе барып, Болынкырга өч урыннан ут төртер иде. Тик моны эшләп булмый. Ул бүген бердәнбер бурыч белән килде, аны тиз генә үтәргә дә Казанга борылырга кирәк. Төн коточкыч караңгы иде, аралары аз гына урынны яктыртып бара, бер генә йолдыз әсәре дә күренми. Төннең шулай булуы аларга бик тә кулай. Болынкырның җем-җем килгән утлары аның ажгырган күңелен бераз баскан кебек булдылар, ул хәтереннән бала чактагы, егет чактагы ниндидер күңелле хатирәләрне барларга теләде, әмма берсе дә күз алдына килмәде, әйтерсең лә алар бөтенләй булмаганнар, яисә каядыр качышып беткәннәр иде.

—Сулга борыл да беренче тыкрыктан уңга кер,—дип боерды Рашат.

Кызыл «Жигули», тыкрыктан акрын гына үрмәләп барып, Ирекнең өе турына житте.

—Менә шушы йорт,—диде Рашат.—Машинаны читкә куябыз. Әйдә турыга.

Чирәм өстеннән барып, машинаны шактый ерактагы бакча артында үскән карт тал төбенә куйдылар, аннары өчәүләп, тавыш-тынсыз гына Ирекләрнең өенә киттеләр. Өйнең тәрәзәләрендә балкып ут яна, капка ачык иде. Ишегалдына кергәч бераз тынланып тордылар. Рашат болдырга күтәрелде дә, ишекне тартып карады—ул бикле иде; капшанып табып, ишек кыңгыравының төймәсенә басты. Шундук Ирекнең «Кем бар?» дигән тавышы ишетелде.

—Мин әле бу,—диде Рашат.—Бәлки иске танышына чәй эчереп чыгарырсың?

Ирек ишекне ачып җибәрде. Ул кара трикодан, ак күлмәктән, яланбаш иде. Рашат яшен тизлеге белән аның касыгына китереп төртте. Ирек бөгелеп төшүгә, чәченнән эләктерде дә башы белән борыска китереп бәрде, аның маңгаеннан чәптереп кан ага башлады, бөтен йөзе, күлмәкләре, идән канга манчылды.

—Утларны сүндереп чыгыгыз,—диде ул Күсәк белән Фишкегә, үзе Ирекне чәчләреннән сөйрәп аска алып төште.

Барлык утлар сүнде, өй тирәсе караңгылыкка чумды. Рашат Ирекнең пульсын капшап карады—ул исән иде.

—Түрдә мунча булырга тиеш,—диде Рашат, Фишкегә пышылдап.—Карап килегез әле. Ачык булса, шунда алып керәбез.—Бераздан тегеләр килеп житте.

—Мунча ачык.

—Тәрәзәгә берәр нәрсә куегыз да утын яндырыгыз.

—Булды, бар да тәртиптә,—диде Фишке килеп.

—Әйдә, тот култыгыннан.

Алар Ирекне сөйрәп алып киттеләр һәм мунча эченә алып керделәр. Ул

анында түгел иде. Рашат бактан бер чиләккә су агызды да Ирекнең өстенә сипте. Ул акрын гына күзләрен ачты, ыңгырашып кулы белән маңгаеның ярылган урынын тотты.

—Йә инде, йә, бала-чага булма,—диде Рашат, аның култык астыннан тотып торгыза-торгыза.—Кая утырасың: ләүкәгәме, әллә менә бу астагы киң тактагамы?

Ул аны стена буйлап сузылган утыргычка чүңкәйтте. Ирекнең маңгаеннан аккан кан күзләрен томалый иде. Ул, берни аңламыйча, кулы белән күзләрен уалады, авызына кергән канны төкерде.

—Хәзер, хәзер, якын кешегә беренче ярдәм күрсәтү кирәк,—диде Рашат дәртле тавыш белән. Ул стенада эленеп торган бер сөлгене алды да Ирекнең маңгаен кысып бәйләп куйды.—Менә булды.

Ирек канга баткан кулларына, күлмәгенә, трикосына аптырап карап торды, ул һаман да аңына килә алмый иде.

—Фишке, булмаса шешәне ач әле,—диде Рашат.—Зиһенен җыйдырырга кирәк бит.

Фишке кесәсендәге яртысыннан капрон стаканга аракы агызды:

—Әйдә, тот берәрне,—диде Рашат, Ирекка аракы сузып.

—Эчмим мин.

—Эчәрсең.—Ирек аңышканчы, Рашат аның чәченнән кинәт артка тартты да ачылып киткән авызына аракы салды. Ирек аның күпмесендер йотты, аннары тончыгып ютәлләргә кереште.

—Ярый, шул җитеп торыр,—диде Рашат.

Аннары алар, стаканга тутырып-тутырып салып, аракыны эчеп бетерделәр, өчесе дә тәмәке кабыздылар. Мунча эчен зәңгәр төтен каплады.

—Табигать тере затларны мәзәк яраткан: берәр нәрсә кыландырсаң, келт итәләр дә сүнәләр.

Аның күз читләрендә көлгәндәге төсле җыерчыклар пәйда булды, иреннәренә ләззәтле елмаю таралды.

—Ну, ничек, хәзер эшнең кая таба барганын аңладыңмы?—диде ул, Иреккә туп-туры карап.

—Син нишләргә уйлыйсың?—диде Ирек, авызындагы канлы төкерекне учы белән сыпырып алып.

—Менә бит телгә килдең,—диде Рашат көлеп.—Бу инде начар түгел. Минем сине нишләтүем үзеңнән тора. Безгә берничек тә исәп-хисап ясамый булмый,—Рашат кулы белән аның янагын җинелчә генә чәбәкләп алды.—Болынкырга килгәннән бирле син миңа яшәргә комачауладың. Аннары Мәскәүгә килеп буталдың. Тагын минем юлга аркылы төшәсең.

—Минем синең юлыңа аркылы төшкәнем юк.

—Ничек кенә төшәсең! Теге чакта мин кушкан тәрҗемәне эшләмәдең. Ачу кабарып калды—кул җитмәде. Ә хәзер син мине кабат чакырдың. Менә шушы мунчаңның матчасына асам да китәм.

—Ни кирәк сиңа?

—Аңлатсаң озак,—Рашат сигаретын ыргытты да шундук икенчесен кабызды, тирән итеп суырып, аның төтенен Ирекнең йөзенә өрде.—Нишләп син Шәрифуллинга каршы барасың?

Ирек чак кына сикереп тормады. Ул кулларына таянып күтәрелә башлады да урынына утырды. Аның башына мең төрле уй килде, тик ул Әхнәф белән Рашат арасына бернинди күпер сала алмады, моның нигезе дә, максаты да, мәгънәсе дә юк иде. Әтисен урыныннан очырып беренче секретарь булган кешене, аларның гаиләсен Болынкырдан китәргә мәҗбүр иткән кешене Рашат терелəй тотып ашарга тиеш кебек.

—Инде тыңла,—диде Рашат теш арасыннан.—Шәрифуллинга син комачауламa. Аңладыңмы?

—Аңладым,—диде Ирек.—Ул сиңа акча бирәдер...

Рашат аның янагына сугып җибәрде. Ирекнен борынынннан кан китте.

—Засранец-писака! Минем монда элемтәләрем җитәрлек. Атна саен дуслар белән сөйләшеп торам.—Ул сәгатенә карап алды.—Безнең вакыт тар. Туктарга сүз бир дә, без китәбез. Әгәр башкача булса...—ул мунчаның матчасына карап куйды.—Бер генә юл кала.

Рашаттан барысын да көтәргә мөмкин икәнлекне аңлаганга, Ирек ниндидер үзен коткарырдай җавап эзләде. Ул җавап бар иде, «ярар», дигән бер сүз җитә, ләкин кан исен сизгән ерткыч дошманына ташланган кебек, ул әлеге сүзне әйтә алмады, авыр сулап утыра бирде, башы торган саен аскарак иелде. Рашат бармак очы белән аның иягеннән тотып, башын күтәрде һәм, сүзләрен санагандай, берәм-берәм бастырып тезде:

—Син мине һаман да шаяртадыр, дип уйлыйсың. Акылына кил. Син бит үзенчә кемнәргәдер яхшылык эшләргә телисең. Шулаймы?

—Әйе.

—Яхшылык дигән нәрсә бетте. Яманлык та юк. Алар кушылдылар, җөен дә таба алмыйсың.

—Ә нәрсә генә бар соң?

—Эш белән түләү. Әгәр кемдер пистолетның тәтесенә баса икән, аңа тозәп интеккән, бармагын бөгеп көч сарыф иткән өчен акча түләнә.

—Син мине калдыр, Рашат. Икебезгә дә яхшы булыр...

—Ю-у-ук!—дип сузды Рашат, тирәкерегенә тончыга-тончыга.—Син юлыма аркылы төшмәсәң дә, мин моны эшләр идем. Ник син шушлай яшәргә тиеш? Ә мин? Минем хакым юкмыни? Миндә коточкыч көч! Кем аркылы төшә, барысы да тезләнәчәк, сытылып калачак! «Сез печән басуы», дигән сүзләрне хәтерлисеңме? Миңа чабучылар якынлашты, килеп җиттеләр, без күп, барыбер кол булачаксың син дә.

Фишке яңа шешәне ачты, алар өчесе дә эчеп куйгач, Рашат, тәмәкесен суыра-суыра, ләззәтләнеп сөйләргә керешле:

—Сез өстә нинди гыйфрит утырганны белмисез. Бөтен җир шарына ул хуҗа. Астарак,—ул башы белән Фишкегә һәм Күсәккә ымлап куйды.—Тагын бер кавем бар. Тик ул кавем, өстәгеләр белән чагыштырганда, күселәр өере генә. Шуларның икесеннән җирнең үлем шәүләсе барлыкка килә. Өстә безгә урын юк, астагысында чәбәләнергә туры килә. Йә, соңгы сүзеңне әйт.

—Синенчә булыр...

—Менә бусы егетләрчә! Кисәтеп куям: кемгә дә булса теш араннан бер сүз ычкындырсаң... кызың... хатының юк дип уйла... Тагын кадерле кешеләреңне барла, үзенә кадәр алар расходка китәчәк. Ә маңгай өчен үпкәләмә, ныграк чиертелеп китте, элеккеге исәп-хисап бар бит безнең. Мәскәү исәп-хисабы.

Алар дөбер-дөбер чыгып киттеләр. Ирек, бармагын да кымшатмыйча, урынында бик озак утырды. Кем эше? Мен мәртәбә үлчәүгә салып карагач, ул Әхнәфнең бу адымга баруына шикләнде. Әхнәф Рашатның кем икәнен бик яхшы белә, аның белән мондый уен уйнау үз башына үзен элмәк киюгә тиң икәнен чамалый. Кем кулы? Рашат Әхнәфтән нәрсә даулый? Күпме генә эзләсә дә, бу сорауга җавап табылмады. Ул чайкалып урынынннан торды, башы җиңелчә әйләнә, тәне тораташ сызлый иде. Иң элек, ничек кенә булса да, бу канлы эзләрне юарга, Зәнфирә берниләп дә шикләнмәслек хәлгә китерергә, аны борчымаска кирәк иде... Әмма ниятен тормышка ашыру ансат кына булып чыкмады. Җыештыруын җыештырды, әмма өйгә кереп идәнгә ауды. Иртән Зәнфирә эштән кайтканда, ул шул хәлдә ята иде. Больницага ашыгыч ярдәм машинасы алып киткәнне Ирек юньләп хәтерләмәде дә...

### 3

Ирек өч көн буе башы әйләнеп, укшып җәфаланды. Йокысы качты. Хәтта газета укырга да рөхсәт итмәделәр. Үзе белән бер палатада яткан биш

кеше аша дөнья хәлләреннән хәбәрдар булды. Ярый әле, аның кыйналуын ишетү белән, Зәнфирәнең малае Зирәк Казаннан кайтып житте. Ул, ГИДУВның иң яхшы врачлары белән киңәшеп, өч төрле дару юнәткән иде. Әлеге даруларны кабул иткәч, стенага тотынып кына атлаган Ирекнең баш әйләнүе дә, сызланулары да кимеде. Айгөлнең килеп йөрүе дә аның сызлануларын күпмедер оныттырды. Кызы белән алар шактый нәрсәләр сөйләштеләр, аңлаштылар. Прокуратура тикшерүчесе ул көнне булган хәлне, әллә ничә мәртәбә килеп, кат-кат сөйләтте, төпченде, һәрберсендә протоколга кул куйдырды.

Менә бүген Ирек беренче мәртәбә стенага тотынмыйча йөреп килде. Мангаен бәйләтеп чыкканда, дәвалаучы врачы аны бүлмәсенә чакырды, үзе каядыр китеп барды. Ул сәерсенеп кенә ишекне ачса, өстәле артында инбашына халат элгән Әхнәф утыра иде. «Болай гына килгән, сүз булмасын өчен», дип уйлады Ирек.

Әхнәф каршы килде дә, аны ярым кочаклап, иңбашыннан какты, аннары бер адым чигенеп, аңа карап торды. Гажәпләнүен белдереп, баш чайкады.

—Эләктерсеннәр генә, һичшиксез ачык суд ясатачакмын,—дип куйды ул ачулангандай.

Ирекка әллә ни булды, әйтерсең лә аның битләренә, чәчләренә йомшак кына кагылып, җылы талгын җил исеп китте. Моңа кадәр сиздермичә генә барлык яшәү тамырларында йөргән иң кадерле тойгылар, кайнар күз яшьләредәй, бер мизгел эчендә күңеленнән бәрделәр дә чыктылар...

—Хәлләрең ничек?

Әхнәфнең бу соравы Ирекне күпмедер айнытып җибәрде. Хәзер тереләм инде, сызлаулары бетә, димәкче булды, әмма тамак төбендәге кайнар тыгызлык тавышын томалады. Шуңа күрә барлык тырышлыгын туплап, көч-хәл белән:

—Аруга таба...—дип кенә куя алды.

Әхнәфнең кайгылы күз карашын, борчулы йөзен күргәч, аның хакында начар уйлаганы өчен Ирекка оят булып китте. Бу күзләргә, бу йөзгә нәкъ менә аны Мәскәүгә укырга җибәрмичә тилмерткән көннәрдәге хафалану билгеләре кунган иде...

Әхнәф аңа туп-туры карады да:

—Син минем килгәнгә ачуланмыйсыңмы?—дип сорады. Аның күзләрендә икеләнү билгеләре чагыла, кулларының җиңелчә калтыравыннан каушаганлыгы күренеп тора иде.

—Ни сөйлисең, Әхнәф?! Чын күңелемнән рәхмәт...

Әхнәф ул кичтә булган хәлне җентекләп сөйләтте, гаҗәпләнде, нәфрәтләнде. Ирек аңа дөресен сөйли алмаудан кыенлык кичерде, әмма ул, Зәнфирәгә дә, тикшерүчегә дә, башкаларга да ялганлап сөйли торгач, моңа күнегеп бара иде инде. Аны тыңлап бетергәч, Әхнәф:

—Без буталдык...—диде.—Безгә бүтәнчә яшәргә кирәк...—Аның сүзләре Ирекнең бәгырен көйдереп узды.

—Минә да бик кыен,—дип сүз башлады Ирек.—Соңгы вакытта төрлесе булды: үпкәләштек тә, тарткалаштык та...—дулкынланудан ул күңелендәген белдерергә сүзләр таба алмыйча туктап калды.—Мин сиңа бер әйберне әйтмичә кала алмыйм. Вакыт-вакыт бик ерагайдык та... бәрелештек тә... Мин, барыбер бергә булачакбыз, дигән өметне сүндермәдем.

Аның башы чәнчешергә тотынды һәм ул, үзе дә сизмәстән, ыңгырашып куйды. Әхнәф аңа кып-кызыл помидорлар, кара һәм яшел виноград, хөрмә, тагын нindидер җимешләр тутырылган пакет тоттырды:

—Тизрәк савыгуың өчен витаминнар...

Әхнәф, коридор башына җиткәч, икенче катка төшүче баскычның һәр киртен берәмләп санагандай, аска таба лап-лоп атлады. Әйтерсең лә аның иңбашларына күтәрә алмаслык авыр йөк салынган һәм шуны исән-имин алып төшеп җиткерергә кирәк иде. Ул бер тын туктап та алды, Ирек янында

узган ярты сәгать вакыт анын бөтен дөньясын актарып ташлаган һәм ул шул дөньяны һич кенә дә бер бөтен итеп жыя алмый иде... Ул больницага барасы кеше түгел иде. Башта ул Ирек белән булган хәлне игътибарсыз гына уздырырга карар кылды, әмма ул карар бернинди сәбәпсез кинәт юкка чыкты һәм ул бармыйча кала алмаганлыгын аңлады. Тик бу барыбер җаны теләп түгел, мәҗбүри генә бару иде. Ярар, дип уйлады ул, андый чакта кешенең күңеле нечкәреп китүчән, бәлкем янадан Әхнәфкә каршы эшләр оештырып йөрмәскә бер этәргеч булыр. Халык күзлегеннән караганда, бу Ирек каршында аның күпмедер дәрәҗәдә баш июе, хәтта куркуы дип тә бәяләнергә мөмкин. Күңелен шушылар тырмап торганлыктан, ул ихтыярый-мәҗбүрирәк килгән иде. Ирекнең күгәргән, сыдырылган йөзен күргәч, аның бөтен гәүдәсен көйдереп, кызгану тойгысы үтте, бер мәл ул, әллә каушап, әллә аны кызганудан, өнсез булып басып торды. Ә менә хәзер ул нәрсәдер урлаганда тотылган кеше кебек кайтып бара.

Машина хакимият бинасы баскычына терәлә язып туктады.

—Нишләп монда алып килдең?—дип кычкырды Әхнәф.

Шоферның күзләре шакмак булды, йөзенә аптырау билгеләре чыкты.

—Кая барасы иде соң, Әхнәф Хәсәнович?!

Сәгатенә карагач, Әхнәф әле унберенче ярты гына икәнен күрде.

—Өйгә,—диде ул акрын гына. Аннары нишләптер пышылдап тагын кабатлады:—Өйгә...

Хуҗасының бу вакытта, хәтта ял көнне дә өенә кайтканын күргәне булмаган шофер, машинасын чак кына арттагы газонга кертмичә, выжылдатып алып китте.

Әхнәф, өйгә кайту белән, теге авыр йөкне җилкәсеннән төшергәндәй, диванга барып ауды. Аңа бөтен дөньясыннан качып, ялгызы гына калырга кирәк иде. Ирекнең ихлас тойгыларын күрү аның күңелен кайнатып җибәрде. Ул кабат үзара якынаю өметен өзгән иде бит инде. Ә менә Ирек ул өметне саклаган булып чыкты. Әхнәф үзенең анардан күпкә түбән икәнлеген аңлады. Ирек элеккечә үк сабый җанлы, элеккечә үк усаллык тойгысыннан мәхрүм иде. Әхнәф инде ничә еллар буе үзенең тулысынча ышанырлык бер генә кешесе дә калмаганын белә. Язмыш чәчәгенең бу әче нектарын инде ничә еллар буе тавышсыз гына йота ул. Кеше, җәннәтнең түрендә утырса да, ялгызы гына бәхетле була алмый. Бәхетле булу өчен кимендә ике кеше кирәк. Ә бит җир йөзендә аның таянырлык бер кешесе бар икән! Тик ике арадагы җепләр генә өзелгән. Менә бүген аларның ялгану мөмкинлеге аермачык күренде. Бу олы куаныч иде! Ләкин ул җепләрне кем өзде соң? Үзен акларлык дәлилләрне күпме генә барласа да, бизмән аның файдасына баса алмады. Җепләрне башлап өзүче Әхнәф үзе иде. Аңа Николай Николаевичлар, тагын әллә кемнәр кирәгрәк иде. Дөрес, райкомның беренче секретаре булгач, ул Ирекне үзенә ныграк бәйләргә уйлады. Шул максат белән секретарьлык канәфиен юу сылтавы астында аны махсус чакырды. Әмма Ирек партиягә кабат керүдән дә, редакторлыктан да баш тартты. Әхнәф, болай булу ихтималын күздә тотып, алдан ук тозак корып куйган иде: ничек булса да Ирекне эчерергә! Чөнки ул бик зур көч иде, беренче секретарь йогынтысыннан читтә калган, аңа буйсынмаган кеше кирәкми иде. Шуңа күрә ул Ирекне эчертеп, элекке эзенә төшерергә, көчен сындырырга ниятләде. Әлеге адымны ни дип атарга? Ул бу сорауны читкә куалады, игътибарны тизрәк башка нәрсәләргә күчерергә теләде.

## 4

Минзаһит базардагы карттан алган үләнне, кызыл аракыга салып, подвалга төшерде. Өйгә алып керергә кыюлыгы җитмичә бик озак йөрде. Гүя бөтен җиһан, җирдәге тормыш алга ага, ә ул берүзе шуңа каршы бара, ул гына әлеге гомуми агымнан әшәкелеге белән аерылып тора һәм шуның өчен

кешеләрдән алып соңгы бөҗәккәчә аннан җирәнәләр, әмма ул алар каршында үзен аклау өчен берни дә кыла алмый иде. Ахырда Рәшат атна буе акча сорап, эчеп холыксызланып җаннарын ашагач, ул төнәтмәне диван артына алып кереп яшерде. Моны эшләгәндә, бөтен гәүдәсен вак калтыравык биләде, сулышы кысылды, күз аллары әлҗе-мөлҗе килде. Йөрәк даруларын эчеп бераз тынычлангач, диванына барып ятты да көтәргә кереште. Рәшатның гырлап йоклаганы ишетелеп тора, ул, уянгач һичшиксез алпан-тилпән атлап, аның янына килеп җитәчәк. Бу минутны Миңзаһит төне буе калтыранып көтте. Рәшатның тора башлавын ишетү белән, җәһәт кенә кухняга чыгып, пычакларны яшерде. Хәят әле тормаган иде. Менә Рәшат мәрәләп кухняга килеп керде, кызарган куркыныч күзләре белән ашардай булып Миңзаһитка төбәлде.

—Бир, төзәтергә...—диде ул гырылдап.

Шул чак кухняга Хәят килеп керде, нидер сизенгәндәй, шикле карашын әле Миңзаһитка, әле Рәшатка юнәлтте.

—Нәрсә чекрәеп торасың инде?—диде Миңзаһит, аны артка таба этеп.—Кеше болай да газап чигә, бар урыныңа кереп ят.

Хәят теләр-теләмәс кенә кухнядан чыгып китте. Миңзаһит калтыранган куллары белән шешәне алып килеп Рәшатның алдына өстәлгә утыртты. Рәшат кружканы тутыра язып төнәтмә салды.

—Әллә нинди исе бар...

—Күптән тора иде. Мускат чикләвеге салынган аңа...

Рәшат кружканы күтәргәч туктап калды, борынын якын китермичә генә иснәде, һаман эчәргә ашыкмады, шикләнгәндәй, карап куйды. Куркудан Миңзаһитка аның кулындагы сары кружка дер-дер калтырап күренде. Рәшатның имән бармагы өзелгән сул кулы йодрыкланган килеш өстәлдә тора иде. Әгәр тәменнән чит нәрсә салынганын сизсә, буып үтерәчәк, шушы бармаксыз кулы белән ул инде аны әллә ничә мәртәбә акча сорап буды. Әмма бусында исән калдырачак түгел. Эчсен генә, тынычлансын гына... Мәңгегә тынычлансын... Ул инде ничек җавап тотасын да уйлап куйды: баш төзәтергә бирәр нәрсә кертергә кушып шалтыратты да кемдер ишек аша гына бирде, диячәк. Дулкынланудан Миңзаһитның теше тешкә тимәде.

Менә Рәшат кружканы авызына китерә башлады, ул йоткандагы кебек хәрәкәт ясап куйды. Нәкъ бала чактагыча. Аның шул хәрәкәтеннән алар Хәят белән икәүләшеп рәхәтләнеп көләләр иде. Шуны күрер өчен Миңзаһит ана юри бирәр тәмле әйбер бирә иде. Ул апельсинмы, виноградмы—ни генә булмасын, кулына алуга, Рәшат иң элек тәмле итеп төкреген йотып куя иде.

—Әле бит капмадың, нәрсә йотасың син, улым?—дип көлә әнисе.

—Төкелек йотам,—ди иде Рәшат, үтә җитди итеп. Күзләрен алмыйча аларның үзен күзәтүләрен аңларга теләп, ул әле әнисенә, әле әтисенә карый иде...

Рәшат кружканы иреннәренә терәүгә, Миңзаһитның бугазын, үпкәләрен яндырып кайнар һава тыгылды. Ул, әллә нинди кыргый тавыш чыгарып, кружкага китереп сукты, агулы шәраб Рәшатның йөзенә чәчрәде, өс-башына түгелде, кружка шалтырап идәнгә очты. Шул мизгелдә Хәят та алар янына чәчрәп килеп чыкты. Рәшатның күзләре шартлардай булып акайдылар, кашлары маңгаен җыерып өскә күтәрелде. Шушы коточкыч кыяфәтендә сикереп торды да ярсулы тавыш белән:

—Ник түктең?!—дип кычкырды.

Аның бөтен гәүдәсе, билгесез кул белән тотып селкеткәндәй, дерелди иде. Ул инде кайнар даруга тиң сыеклыкның салганчы ук эчендә татлы кымырҗуын тойган һәм шуны түгүчене нишләтәсен үзе дә белми иде. Миңзаһитка ничек житезлек килгәндер, ул күз ачып йомганчы шешәне эләктереп, форточкадан тышка томырды. Рәшат бер сикерүдә аны эләктереп, буып алды.

—Нигә әрәм иттен?! Ник түктен?!—дип үкерде ул, аны тәрәзә янагына терәп.

Минзаһит аякларының идәннән күтәрелеп-күтәрелеп китүен тойды. Ана барыбер иде инде. Ике күзеннән кайнар яшь коелды, алар битеннән агып төшеп, иреннәрен чылаттылар. Хәят, үзен белештермичә, Рәшатның кулларына килеп ябышты, сүзен әйтә алмады, бары тик бугазыннан ниндидер аңлаешсыз авазлар гына чыкты.

—Үтер мине тизрәк!—диде Минзаһит сулкылдап.

—Улым, тимә!..

—Аракыны ник түкте ул, ник түкте?! Мине газаплау өчен юри түкте!

—Ул агу иде,—дип пышылдады Минзаһит.

—Нәрсә?!

—Агу иде... Мин яшәргә тиеш түгел. Мин җир йөзендәге иң кабахәт кеше! Сине агуларга теләдем...

Рәшат анын якасын ычкындыруга, Минзаһит идәнгә сыгылып төште һәм тезләнеп, анын күзләренә тилмереп карады. Күз яшьләренә чыланып беткән чырае, асылынып төшкән ияге карарга куркыныч, бөтен гәүдәсе калтырый, күзләрендә коточкыч курку һәм ялвару чагыла иде. Рәшат аңа сүзсез карап торды, гыжылдап сулаганы өйгә генә түгел, бөтен шәһәргә ишетеләдер кебек тоелды Хәяткә. Ул да, сүзсез-өнсез калып, авызына ингаляторыннан дару өрдерде. Рәшат сукмады, сүгенмәде, эчендәге барлык һавасын чыгаргандай, тирән итеп бер сулыш алганнан соң, бүлмәсенә керде дә урынына гөрселдәп ауды. Өйлә турында Хәят аны ашарга чакыргач, җавап бирмәде, арты белән борылып ятты. Ул кичтән дә ашарга чыкмады.

Хәят белән Минзаһит керфек тә какмыйча төн уздырдылар. Анын кубарылып чыгып нидер кыласын көттеләр, әмма Рәшат төнлә дә тормады. Иртән ул киенгән килеш килеп чыкты, кулына теге зур куркыныч сумкасын тоткан иде.

—Мин китәм,—диде ул әллә нинди ят, тоnык тавыш белән.

—Соң юынып, кырынып, капкалап алыр иден,—диде Хәят, курка-курка гына.

Рәшат гүя әнисенен сүзләрен ишетмәде, анын күзләре ябыштырып куйган боз кисәкләредәй хәрәкәтсез, үле иде.

—Бүтән күрмәссез... котылырсыз...

Хәят, акырып елап, анын муенына барып асылынды.

—Улым! Китмә, ташлама безне!

Рәшат, башын югары күтәреп, тыны беткән кешедәй, түшәмгә төбәлде, йөзе ачы әйбер капкандай җыерылды, муен төене йоткандагы кебек хәрәкәтләнде. Ул шул хәлдә шактый торды. Минзаһит бер сүз дә әйтә алмады, ул сындай тораташ каткан иде. Ниһаять, Рәшат тирән сулап хәл алды, әнисен ике кулы белән үзеннән аерып урындыкка утыртты.

—Кирәкми... Бергә яшәү юк безгә... Йә мин сезне, йә сез мине үтерәчәк.

Ул ишеккә таба борылуга, Минзаһит калтыранган тавыш белән кычкырып җибәрде:

—Кая?! Кая китәсен, у...—үз гомерендә беренче мәртәбә Рәшатка «улым» димәкче булды, әмма теле тыңламады, авызында хәрәкәтсез калды.—Кая китәсең?..

—Әгәр очратсагыз, миңа дәшә күрмәгез. Мине сагалаячаклар...

Тимер ишек дөпелдәп ябылды.

Алар, ниһаять, газиз балаларыннан котылдылар... Күпме вакытлар бергә-бергә дә, аерым да теләгән теләкләре тормышка ашты. Кайчандыр икесенең кайнар йөрәк тибешенән кушылуы, әллә нинди якты өметләр, матур хыяллар белән җир йөзенә китерелгән газиз балаларыннан алар, ниһаять, котылдылар... Күпме гомерләр алар бер генә теләк белән яндылар: котылырга, котылырга иде! Үлсен иде, бетсен иде, мәңгегә бу дөньядан югалсын иде! Менә теләкләре

кабул булды, аңардан котылдылар! Кулындагы тугыз бармагы, авызы тулы алтын тешләре, башындагы пеләше белән мәңгегә алардан китте, югалды... Әмма алар бернинди җинеллек тә тапмадылар. Киресенчә, капкынга ике аягыннан берьюлы эләккән һәм, кычкырсам килеп тотарлар, дип уйлап кычкыра-елый да алмаган мескен җәнлек төсле кара коелып утыра бирделәр. Тимер ишек салкын, хәрәкәтсез, тып-тын иде. Ул инде бу ишекне кабат беркайчан да килеп какмаячактыр. Алар моны ачык тойды, бу тойгы шул кадәр ачы, ул аларның калебләрен, гәүдәләрен генә түгел, өсләрендәге киемнәрен, бүлмәдәге әйберләрне дә көйдерә иде. Ул көек төтене фатирга томан булып җәелде һәм томанның эчендә, бик еракта ике кулына ике кызыл алма тоткан сабый пәйда булды, аның тәмле итеп йөту хәрәкәтләре ясаганы күренде. Алмалар әле исән иде, сабый әле йөри генә башлаган, егылмаска тырышып, өстән ике, астан өч теше чыккан авызын киереп ачып, шырык-шырык көлә-көлә аларга таба атлый иде.

Менә ул дык итеп артына утырды, кулыннан ике алмасы төшеп тәгәрәп юкка чыкты. Сабый үрмәләп алмалар артыннан кереп китте һәм томан эчендә югалды... Нишләптер колак төбендә аның сүзләре генә бертуктаусыз яңгырады да яңгырады:

—Төкелек йотам бит!

—Мин төкелек йотам бит!..

## 5

Алар бүген иртәдән бирле елмайдылар-көлделәр, туктаусыз ашыктылар, кабаландылар, бер-берләренә бәрелделәр, шуңа куанып, тагын көлделәр, әледән-әле сәгатьләренә карадылар, мәктәп коридорларының бу кадәр чырчуны әле ишеткәне булмагандыр. Ниһаять, алар, укытучылары кушуы буенча, бер сафка тезелеп бастылар, урамдагы кешеләрнең сәламнәре, котлаулары астында мәдәният сараена юнәлделәр. Әле Болынкыр күгендә мондый кояшның да булганы булмагандыр. Ул яктыртып, җылытып кына калмый, әллә нинди көлтә-көлтә куе нурлар булып, аларның өсләренә иңә, һәммәсен коендыра, дөньяны гарык итә. Аларның артыннан мәдәният сарае эченә күпсанлы кунаклар, дуслары, әти-әниләре кереп тулды. Бер-берсеннән еракта утырсалар да, Ирек белән Сөембикәнең уйлары гел Айгөл тирәсендә бөтерелде. Алар аның өчен чиксез куандылар, шул ук вакытта түземсезләнеп кызларының өлгергәнлек аттестаты алуын, чыгыш ясавын дулкынланып, хафаланып көттеләр.

Айгөл әнисе турында да, әтисе турында да уйлый алмады. Ул, гомумән, уйлау сәләтен югалтты кебек. Иртәдән бирле аның күз алдында елмаюлы йөзләр, бик күп булып чәчәкләр биеште, колагы бары тик шатлык авазлары гына ишетте. Зал шулкадәр якты, матур иде, тыштагы кояш, аларга ияреп, аның эченә үк кергәндәй тоелды. Сәхнә читеннән яшеренеп кенә залга күз ташлаганда, ул әнисен дә, әтисен дә күргәч, җинел итеп сулап куйды. Шуның белән ахрысы күңеле тынычланды, ул аларны онытты, шундук каядыр очты. Кайсыдыр бер мизгелдә күңеленең түреннән Таһир яктырып үткәндәй булды. Аннары ул да юкка чыкты, бөтенесен бергә берләштергән сихри төш башланды. Ул төш аның тормышын инде күптән хыялланган якты юлга алып кереп китәчәк, Айгөл бүген шуңа хокук алачак. Ул бүгеннән бөтен кешегә сүзсез буйсынучы мәктәп баласы булудан туктаячак, өлкәннәр кебек бер дәрәҗәдә, тигез булачак. Юк, алай гына түгел, ул киләчәктә иксез-чиксез биеклекләргә күтәреләчәк, бик тә, бик тә озак яшәячәк, әллә нинди игелекле эшләр кылып, дөньяны таң калдырачак...

Айгөл үзенең игътибарын, уйларын, күз карашын бер генә минутка да аерым нәрсәгә юнәлтә алмады. Ул кемнәр беләндер нидер сөйләште, кемнәрдер аны үптеләр, кулларын кыстылар, ул үзе шулай ук кемнәрнедер

кочты, үбеп алды, котлады. Өлгергәнлек аттестаты алырга үзен чакыргач, ул калтыранып китте, мәктәп директоры каршына күкрәгенә кайнар сулышы тулган хәлдә талпынып килеп чыкты, аттестатны тирләгән бармаклары белән тотканда, аны шудырып төшереп җибәрде, әмма ни гаҗәп, ничек анарда шундый өлгерлек туды—аны идәнгә төшкәнче, очып барган кошны эләктергәндәй, үзе үк тотып та алды. Урта мәктәп бетерүче кызларны-егетләрне район хакимияте башлыгы Әхнәф Шәрифуллин котлады. Анын артыннан тагын бер-бер артлы кемнәрдер сәхнәгә күтәрелде. Үзенә сүз биргәч, Айгөл аякларының идәнгә басканын сизмәде, әйтерсең лә ул трибунага очып кына менде. Ул һава җитмәүдән, тамак төбенә килеп утырган кайнар төенне кузгата алмаудан башта гаҗиз булып тын калды. Кинәт бөтен гәүдәсен, һәр күзәнәген ниндидер кайнар, ләззәтле дулкын өтте һәм, ул шуна буйсынып, ашкынып сөйләргә керешә, анын сүзен бүлеп, зал әллә ничә тапкыр күтәрелеп кул чапты. Менә ул укытучыларына рәхмәт әйтергә теләде, аларның исем-фамилияләрен атый башлауга, гел көтелмәгән хәл булды, дулкынланудан күзләренә яшь тыгылды һәм ул туктап калды. Зал да, анын халәтен күреп, тын алудан туктады, анда утыручыларның да күзләренә яшь тыгылды. Бу мизгел үтеп, укытучыларны котлагач, Айгөлнең күзе әнисенә төште.

—Мине тәрбияләп үстергән, тормыш күгендә очарлык нык канатлар биргән...

Дулкынланудан анын тагын күкрәге кысылды. Кызыннан бер генә секундка да күзен алмаган Ирек бөтен гәүдәсенә кайнар тир бәреп чыгуын тойды, сулышы ярты юлда туктап калды, әйтерме ул анын исемен, юкмы? Бу мизгелдә Сөембикә дә тынсыз-өнсез иде... Ул кызының әтисенең исемен әйтүен теләде, берүк калдырмасын иде, дип эченнән кабатлады, кайнар битләрен, шул уен кызына җиткерергә теләгәндәй, ике кулы белән кысты.

—Әтием белән әниемә мин чиксез рәхмәтле,—диде Айгөл.

Ул тагын ниләрдер сөйләде, әмма Ирек тә, Сөембикә дә анын башка сүзләрен әллә тынладылар, әллә юк. Алар өчен баягы әнә шул кадерле сүз генә кирәк иде, мөлдерәп тулган күңелләренә шул кадерле, иң татлы, иң кайнар бер тамчы җитми иде. Аларның бөтен газаплы тормышын сыйдырган, фаҗигале язмышларының зәһәр ачысын үзенә алган бу бер тамчы күңелләрне язгы судай ташытып җибәрде...

Айгөл, әйбәт чыгыш ясадым микән, дип борчылмады, башкаларны да тыңлый алмады, бу сихри төшнең, бу шатлыкның өзелмәвен, мөмкин кадәр озаграк дәвам итүен генә теләде. Соныннан котлаулар беткәч, әнисе белән әтисе чәчәк бәйләмнәре сузып анын каршына килгәч, ул аларның икесен берьюлы кочаклап алды һәм, әллә нинди шатлыклы да, сагышлы да тойгының буып алуына түзә алмыйча, тавышсыз гына елап җибәрде...

Татлы бу төшнең азагы Ык буендагы әрәмәлектә дәвам итте. Гүя аларның бәйрәменә ямь өстәргә теләп, яр буеннан башланган әрәмә, ун-унбиш адым читкә китүгә, ике якка аерылып, бер кечкенә генә күлгә урын биргән. Аларның Ык буена төшәсе урыны алдан билгеләнгән иде. Шуна күрә әрәмәгә килеп җиткәндә, әйләнәсен су эчендә үсүче тере ак чәчәкләр такыядай бизәгән күл буенда ак күлмәк, ак чалбар кигән Таһир аны колач җәеп каршы алды. Серле төшне инде ул Таһир белән янәшә дәвам итте. Ә бу төшнең әле бер, әле икенче күренеше алышынып тора, Ык өстеннән йөздереп, классташлары белән бергә, Таһир белән бергә кояшка таба алып бара иде...

Айгөл, арттан килеп, Таһирның инбашына кулларын салды, янагын анын янагына терәде. «Йә Аллам,—дип уйлады ул эченнән...—Мона кадәр бу гүзәллекне мин нишләп күрмәдем икән?!» Шомырт, балан, карама, тал, камырлык куакларының ялтыравыклы яшел яфраклары арасына яшеренгән мең төрле кошларның мең төрле җырлары сузып-сузып та, чут-чут итеп тә алсу тан нурларына кушылып, бөтен һавага тарала, Ыкның шул ук тан нурларын үзенә алган пыяладай өслегенә инә, су өстеннән акрын гына

шуышучы сыек томан пәрдәсеннән саркып, аның эченә тула, судан ялкау гына агучы эреле-ваклы күбекләргә дә кагыла кебек. Каршыдагы кызыл текә яр өстендә, әллә шушы кошлар җырын ишетергә теләүдән, әллә җиһанның уянуына исәреп утыручы мәгърур имәннәрне, каеннарны нигә моңа кадәр бер генә мәртәбә дә килеп күрмәде икән соң Айгөл?! Әллә соң болар бөтенесе дә чыннан да сихри, гүзәл төш кенәме? Аның шул уйларына җавап биргәндәй, төнбоекларның ак, сары чәчәкләре, сылу буйлы яшел күрәннәр ана серле итеп елмайдылар. Айгөл, җем-җем итеп торучы чык бөртекләре кунган үләннәр, тукранбашлар, меңъяфраклар һәм ромашкалар уртасында сикергәләп, аларга кул болгады, чырык-чырык көлде, ниләрдер кычкырды, тик аның тавышларын кош сайраулары барыбер күмеп китте. Алар җитәкләшеп тагын күл янына килделәр. Түгәрәк күл аларның килүен күптән көткән, әгәр шулай булмаса, ул эре ак чәчәкләрен такыя итеп әйләндереп салмас иде. Хәзер аның суы алсуга манылган, күлгә нишләптер томан төшмәгән, ә менә бераз арырак сузылган үзәнлекне ап-ак томан дингезе каплаган. Ул томанның артында ялгыз өянке кучкылланып күренә, аның да өске ябалдашлары гына шәйләнә, кәүсәсе томан эченә баскан да шунда туктап калган. Битләргә әллә нинди рәхәт дулкын кагыла. Тәннәргә җылы, йомшак аккош мамыгы белән сакланып кына сыпыргандай, җәйге һаваның кыяр-кыймас кына кагылуы сизелә. Оялчан икән җәйге таң, бөтенесе белән килешеп, бөтенесен үз кочагына сыендырып, тын гына, сабыр гына татлы йокымсыравын дәвам итә...

Йә, бер Аллам! Болар һәммәсе бер төштер, бөтенесе тып-тын, бөтенесе һаваны тетрәтеп җырлый, бөтенесе серле томан белән өретелгән, шул ук вакытта бөтенесе аермачык чатнап торган сызыклары белән яп-якты булып күренәләр, күнелгә кереп, кайнар дулкындай уйныйлар, гәүдәне җирдән аерып күтәрәләр, күз күрмәгән—колак ишетмәгән хыялый ераклыкларга, өмет нуры белән балкучы серле офыкларга әйдиләр. Алар бөтенесе дә Айгөл белән Таһирныкы. Боларның бөтенесенең хуҗасы—алар икесе. Юк, магнитофон, гармун, гитара тавышларына бу гүзәллекләрнең берсен дә алыштырып булмый. Бөтенесе шушы табигать дигән бөек дөньяның уртасында бөтерелеп биилэр, җырлыйлар, хыялларында очалар. Алар гына түгел, Айгөл ал нурларга манылган очсыз-кырыйсыз җиһанның сулыш алганын, җырлаганын сизде. Әйе, әйе, ул илаһи җиһан, кошлар җырына кушылып, тантаналы моң сузды, аларның аяк астында чайкалып торучы хәтфәдәй яшел келәм белән бергә чайкалды, аларны алкышлап торучы яшел куаклар, җырчы сандугачлар белән бергә алкышлады, бергә мәңгелек көй сузды.

Ничек тиз үткән вакыт! Алар Таһирның «Шевроле» машинасында капка төпләренә кайтып туктаганда, сәгать иртәнге алтынчы ярты иде. Айгөл арткы утыргычтан ридикюлен, чәчәкләрен алды да Таһирга ялварулы караш ташлады.

—Таһир, әйдә иртәгә. Бүген кермә син безгә.

Таһир бер сүз дә дәшмәде, аны култыклагандай итеп, капкага сөйрәде.

—Керәбез, Айгөл, керәбез.

Ишекне ачуга, тәмле булып борыннарына камыр, май исе килеп бәрелде. Сөембикә кече якта кыстыбый бөкләп маташа иде. Ул атылып аларның каршысына чыкты, кочагына күтәргән чәчәкләре арасыннан елмаеп карап торган кызын тагын бер мәртәбә күкрәгенә кысты. Чәчәкләрне кулына алып:

—Әйдәгез, түрдән узыгыз,—диде.

Айгөл белән Таһир зал ягына кереп киттеләр, ә Сөембикә кыстыбыен бөкләп бетерергә ашыкты. Ләкин аның төне буе куаныч белән типкән, татлы сулкылдау белән кызын көткән йөрәге әз генә вакытка туктап калгандай булды. Туктале, диде ул үз-үзенә, нишләп соң әле ул аны иярткән? Ничек соң әле ул бирегә килеп керә ала? Бер карасаң, монда искитәрлек әйбер дә

юк кебек. Икенче карасаң, бу һич тә башка сыймый иде. Дөрес, Сөембикә белән Ирек бергә яшәгән чакта Таһир белән Айгөл гел аралаштылар, әмма инде ул заманнар бик еракта калды. Фәһимәләрнең малае Казанда укый. Айгөл бүген генә аттестат алды, кайда ничек очрашканнар алар? Ул арада Айгөл аның янына йөгереп килеп житте, майлаган кыстыбыйларны өстәлгә куйды, чәчәкләрне вазага утыртты, ашау-эчү кирәк-яракларын тезде, үзе нәрсәләрдер сөйләнде. Сөембикәгә ул ничектер үзгәргән кебек тоелды. Төне буе йөреп бәйрәм иткәннәрдер, әллә соң ул эчкәнме? дип шомланып уйлап куйды һәм жаен китереп тә, китермичә дә кызына якынаеп, аны иснәштереп алды. Юк, Айгөлдән берниндиндә аракы исе килми иде. Ул арада икәүләп өстәл янына утырдылар. Айгөл сикергәләп аттестатын алып чыкты, аны мактый-мактый, озаклап карадылар. Шулчак Сөембикә Таһирның ак күлмәк якасына тигән иннек әзенә игътибар итте. Бу инде нәрсәнеңдер ул теләмәгән якка киткәнлеге турында искәртә иде. Алар үбешкәннәр, дигән уй йөгереп үтте Сөембикәнең күңеленнән. Ул Айгөлнең иреннәренә игътибар белән карады, аның иннеге йокмаган, бозылмаган, чатнап тора. Димәк, ул аны әле генә салган. Бу уйлардан чәй ясарга дип үрелгән Сөембикәнең кулындагы чәйнегe чак кына төшеп китмәде.

—Син утырып кына тор, әнием,—диде Айгөл, аның кулыннан чәйнекне алып.—Үзем ясыйм.

Ул сөтләп чәй ясады, әле Сөембикәне, әле Таһирны ашарга кыстады. Таһир кыстыбыйны умырып кабып, мактый-мактый ашады. Сөембикә аны астан гына күзәтте, ул әнисе кебек чибәр, чем-кара чәчләре бераз бөдрәләнеп тора, калын кашлары, тыныч карачучы зәңгәр күзләре Әхнәфне хәтерләтә. Кызыл юка иреннәре Фәһимәнекенә тартым. Кыенсынмый, иртүк килеп кергән, ул әнисеннән өзелеп төшкән булырга тиеш, дип уйлады Сөембикә, күзләрен Таһирның туры карашыннан яшереп. Ана алардан нидер сораштырырга кирәк иде, теле әйләнмәде, карашы һаман Таһирның якасындагы помада эзеннән китмәде. Ана караган саен, сиздерми генә эченә ниндидер салкын төшә барды. Әгәр алар үбешкәннәр икән, бу инде һич тә әйбәт билге түгел. Бу хакта уйлагач, Сөембикәнең йөрәге ачытып куйгандай булды, куллары калтыранып китте. Ул, үзенең борчылуын сиздермәскә теләп, урыныннан сикереп торды.

—Хөрмә алып керергә онытканмын икән,—диде дә верандага чыгып китте.

—Таһир, сизәсеңме, әни борчыла башлады,—диде Айгөл пышылдап.—Әйдә, бүгенгә калдырып торабыз.

—Юк, Айгөл, юк!—дип кырт кисте аны Таһир.

Ул арада Сөембикә кереп, хөрмә җимеше юды һәм аны алып килеп, өстәлдәге бәллүр савытка сала башлады. Таһир сиздермичә генә өстәл астыннан Айгөлнең аягына баскаларга керешә. Айгөл кып-кызыл булды, Таһирга карады, ә аның күз карашы ялварулы да, кисәтүле дә, кырыс та иде. Айгөл, башын аска игәннән-ия барып, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән:

—Әни... Без... Таһир белән бергә булабыз инде...—диде.

Башына сукканны көткәндәй, ул күзләрен йомды, тын алудан туктады. Кичә көндездән бирле дәвам иткән тылсымлы әкият дөньясы, татлы төш шушы урында өзелде. Сөембикә бөрәмләп салып маташкан җимешләрнең өстәлгә чәчелеп китүен сизми дә калды. Ул хәлсезләнеп урындыгына утырды.

—Аңламадым,—диде, көч-хәл белән телен әйләндереп.

Айгөл аңа карарга курыкты, башын тагын да ныграк аска иде.

—Без бергә яшәргә ниятләдек...

—Кайда яшәргә?

Чыннан да кайда яшәргә? Айгөлнең бөтенләй башы әйләнеп китте. Әнисенең бу соравы сискәндергеч төстә төгәл җавап сорый иде.

—Өйләнешеп...—диде ул, алдагы фикерен дәвам итеп.—Яши башлыйбыз...

Соңгы ике сүздән соң Сөембикәнең инде икеләнер урыны калмаган иде.

Ул барысын да аңлап бетерде, әмма моны күңеле кабул итәргә теләмәде.

—Кем белә-ә-ән?!—диде ул, әллә нинди ят, елак тавыш белән сузып.

Күпме генә күрергә тырышса да, кызы күзләрен яшергән иде, ул аның дерелдәп куйган озын керфекләрен генә күрә алды. Ул керфекләрнең дерелдәве йөрәгенә килеп кадалган очлы энәләр кебек тәэсир иттеләр.

—Кем белән, дип сорыйм?!

Айгөл ишетелер-ишетелмәс тавыш белән:

—Таһир...—дип кенә куя алды.

Сөембикә, ник икәнен дә сизмәстән, ялт итеп Таһирга башын борды. Ул да авызына капкан җимешен чәйни алмыйча хәрәкәтсез утыра иде. Сөембикәнең җан өшеткеч карашы астында күзләрен ачып шактый торганнан соң, түземлеге җитмичә, керфекләрен аска төшерде.

—Ә миңа ник әйтәсең?—диде Сөембикә, кабат кызына борылып.

Айгөл, курка-курка гына керфекләрен күтәреп, аңа астан кыюсыз караш ташлады:

—Син бит минем әнием.

Сөембикә, сикереп торып, калтыранган куллары белән өстәлгә таянды да Айгөлгә таба иелде:

—Мин сиңа кайчаннан әни соң?—дип пышылдады.

Айгөлнең иреннәре калтырап китте, күзләре түгәрәкләнде, ул бер сүз дә әйтә алмады. Сөембикәнең ике чигәсе пычак белән сызгандай сыкрарга кереште. Аны кызының әйткән хәбәре ул кадәр таң калдырмады, иң хәтәре аның мона кадәр яшерен уй белән йөрүендә иде. Сөембикәгә әле Айгөлнең кияүгә чыгу-чыкмау мәсьәләсе әллә кайда офык артында дөбердәгән яшенле яңгыр авазы кебек кенә иде. Ә менә хәзер ясаган шушы беренче адымы... аның белән киңәшмичә... бу аның башына берничек тә сыймады. Аның инде куллары гына түгел, бөтен тәне калтырый башлаган иде. Ул, һәр сүзенә басым ясап, тагын бая әйткәннәрен кабатлады:

—Кайчаннан мин сиңа әни, дип сорыйм?! Җавап бир!

Әнисенең куркыныч йөзеннән карашын читкә алып, Айгөл ишетелер-ишетелмәс тавыш белән:

—Туганнан бирле...—диде.

—Шула-а-аймыни?!—дип сузды Сөембикә.—Менә бит ничек икән! Мин ник кирәк соң сиңа?

Айгөлнең йөрәге каядыр төшеп китеп, күңеленә салкын елан шуышып килеп кергәндәй булды. «Ник әйттем?! Ник әйттем?!» дип өзгәләнде ул эченнән. Үзен тыңламаганы өчен ачу белән Таһирга карап алды, тик хәзер соң иде инде.

—Ник элек әйтмәдең?!

—Ул чакта... мин бит әле... өлгермәгән идем...

—Ә-ә-ә, аңлашылды!—дип сузды Сөембикә.—Менә бу катыргыны алып кайткач, өлгердең, шулаймы?

Айгөл дәшмәде.

—Мин гомерем буе синең өчен яшәдем, синнән берни яшермәдем. Ә син әллә кайчаннан үзеңчә яшәгәнсең, киңәшер өчен мине кешегә дә санамагансың!

Күзләре яшь белән мөлдерәп тулган Айгөл кычкырып елап җибәрде һәм әнисен кочаклап алды.

—Алай түгел, әни, алай түгел!

Сөембикә аның кулларын үзенең муеныннан каерып алды:

—Син бу сүзләреңне аңлап әйттеңме?

Айгөл әнисенә җавап бирә алмады, ул инде кычкырып ук елый башлаган иде. Таһир, сикереп торып, аны юатырга кереште, үзе Сөембикәнең күзләренә карап:

—Без барысын да уйладык,—диде.—Хәзер инде кирегә юл юк. Без бу

көнне сәгатьләп санап көттек. Карар озак уйлап кабул ителде...

Сөембикәнең аның янагына чабып җибәрәсе килде. Ул тешләрен кысып сабыр итәргә тырышты, кулларын йодрыклаган хәлдә, зал ягыннан урап килде. Ничектер тынычлангандай булды, кулларын күкрәк янына кушырды да, башын артка ташлап, аларның икесенә дә мыскыллы карашын юнәлтте:

—Карар кабул иткәч, барыгыз, яшәгез! Минем кирәгем юк бит сезгә. Рәхмәт, бик тиз мөстәкыйль тормыш юлына баскансыз.—Ул Таһирның йөрәгенә тиярдәй сүз эзләде, әмма таба алмады. Кинәт зиһене яктырып киткәндәй булды:—Әтиеңнең халыкныкын талап җыйган малы күп бит, яшәгез!

Таһирның бөтен гәүдәсе, чыбыркы белән сыдыргандай, тартышып куйды, ул нидер әйтмәкче булды, ләкин әйтә алмады, ахырда ишеккә ташланды, ана елый-елый Айгөл иярде.

Сөембикә урындыгына утырды да, терсәкләре белән өстәлгә таянып, ике кулы белән башын учлады. Шул хәлдә ул күпме утыргандыр, Айгөлнең дәшүенә генә сискәнеп күзләрен ачты.

—Әни, нигә инде син шундый сүз әйттең?—диде ул, тавышсыз үксеп.

—Хәзер мина сүз әйтергә дә ярамый икән,—диде Сөембикә битараф тавыш белән һәм акрын гына урыныннан күтәрелде.—Ә сина мине ничек яраласаң да ярый! Йөрәге ярылыр дип тә уйламагансың...

—Мин бүген теләмәгән идем дә... ул мәҗбүр итте...—диде Айгөл.—Бөтен гаеп миндә. Менә хәзер үтерсәң дә, син хаклы. Тик... мин аны ташлый алмыйм... Мин анардан башка яши алмыйм!

Айгөл шулай диде дә кызулап бүлмәсенә кереп китте. Сөембикә исерек кеше хәлендә иде. Кая барырга?

Кемгә эчен бушатырга да кем белән киңәшергә? Ни аяныч, аның андый кешесе юк иде. Ул салкын су белән юынды, чәчләрен төзәтте, иренен кызартты, керфекләренә сөрмә тартты. Телефоннан Чукаеваның номерын җыйды, тик ул җавап бирмәде. Сәгатенә күз төшергәч, кискен карарга килде: Мөнир Кәбиров янына барып кайтырга. Мөнир абыйсы, Казанга барып дәваланып кайтканнан соң, җир җимертеп яшәп ята, теге вакытта төшенкелеккә бирелүләре үзен-үзе чираттагы куркыту гына булып чыккан иде. Сөембикә хәзер Болынкырда калса, нindидер юләрлек эшләячәген бөтен барлыгы белән сизде. Йә кызын кыйнап ташлар, йә дулап Фәһимәләргә барып керер. Хәзергә болар берсе дә кирәк түгел, ничек булса да айну, суыну ягын карарга кирәк иде.

## 6

Таһирның Айгөлгә өйләнүе турындагы хәбәр Әхнәф белән Фәһимәне башта өнсез калдырды, сорау арты сорау яудырсалар да, зиһеннәренә бу хәбәр мәсхәрәләп көлү булып тоелды. Ин элек Әхнәф акылына килде:

—Беренче курстан өйләнергә миең сыекланмагандыр бит?!—дип җикерде.—Укуыңны бетермичә ул хакта авыз да ачмыйсың!

—Их, балакаем!—Өзгәләнүдән Фәһимәнең тыны кысылды, тавышы буылып чыкты.—Аларның тормышы—фаҗигалардан гына торучы куркыныч чылбыр. Алар белән беркем дә бәхетле була алмый!

Түземе бетеп, Таһир урыныннан сикереп торды һәм чыгып китәргә уйлады.

—Без бәхетле булачакбыз!

Фәһимә, аның каршысына төшеп, ишектән читкә этте.

—Әнисен рәнҗеткәннәр бәхетле була алмый. Аңа өйләнәм дигән сүзеңне тагын бер генә әйтсәң дә, каберемдә рәнҗеп ятачакмын, мәнге рәхәт күрмәячәксез!

—Ник соң сез мине аңламыйсыз?!—диде Таһир кызып.—Мин аны яратам!

—Бу ярату түгел!—Әхнәф имән бармагын чигәсе турында селкетеп куйды.—

Синең яшьлек җуләрлегең генә!

—Улым, аңла, син бит минем җаным!—Фәһимә калтыранган кулларын аңа таба сузды.—Туганнан бирле башың чирдән чыкмады. Ничә еллар мин сине санаторийларга йөрттем, үзем чиргә сабыштым, җанымны сиңа күчереп терелттем. Мин сине беркемгә дә бирмим!

Таһир, мәсхәрәле көлемсерәп, сүзсез генә баш чайкады, аннан тоныک тавыш белән, һәр сүзенә басым ясап, болай диде:

—Сез берни дә бирмисез. Беркемгә дә. Беркайчан да.

—Бу ни дигән сүз?!—Әхнәф йодрыгы белән өстәлгә китереп сукты.—Мин гомеремне халыкка бирдем, әниең минем белән янәшә булды.

—Юк, әти, сез аласыз гына. Аз-азлап та, күпләп тә. Күрсәтеп тә, күрсәтмичә дә.

—Әзрәк оялыр идең!—дип кычкырды Фәһимә һәм Таһирны күлмәгеннән тотып селкетергә кереште, йодрыклары белән иңбашларына сукты, аннары урындык артында эленеп торган сөлге белән йөзенә сыдырды, нәрсәләрдер кычкырды. Әхнәф аны тотып тынычландырырга маташкан арада, Таһир чыгып йөгерде.

—Улым, тукта!—дип кычкырды Әхнәф.

Таһир очып киткәндәй юкка чыкты, машинасының ишеген ачып япканы, гөрт итеп кабызып газ биргәне, көпчәкләрнең капка төбендәге асфальтны шытырдатып бер урында әйләнә-әйләнә кузгалганы гына ишетелеп калды.

Сузып-сузып телефон шылтырарга тотынды. Әхнәф юри бик озак трубканы алмыйча торды. Аның беркем белән дә бер генә сүз дә сөйләшәсе, берни ишетәсе, берни күрәсе килми иде. Сабыры тәмам төкәнгәч, ачу белән трубканы умырып алды! Шылтыратучы Рашат иде. Аның тавышын ишетүгә, Әхнәфнең йөрәген утлы чыбык кисеп үткәндәй булды.

—Мин синең заказыңны үтәдем, Әхнәф Хәсәнович,—диде Рашат.—Хәзер синең чират.

—Минем сиңа бернинди заказ да биргәнем юк,—диде Әхнәф, аның ни турында сөйләвен аңламыйча.

—Нәрсә кыланасың!—Рашатның карлыккан тавышы ачулы булып яңгырады.—Другыңны проучить итәргә хатының аша заказал.—Әхнәф эшнең нидә икәнен аңлады.—Миңа до зарезу квартира кирәк! Күп алдадың син мине. Ә хәзер никуда...

—Юк, булмаячак!—дип бөтен көченә гәүдәсен алга ия-ия кычкырды Әхнәф, гөбе тавышы чыгарып.—Юк квартира!!! Кабат шалтыратып та торма!!!

Ул трубкасын ыргытты. Рашатның җәфалавыннан ул шул кадәр туйды, аннан котылу өчен теләсә кая чыгып качарга әзер иде. Бер минуттан телефон тагын шылтырады. Рашатның янаулы тавышы яңгырады:

—Син үзеңне әйбәт тотмыйсың. Может передумаешь?

—Не передумаю...

—Ну, смотри, Шарифуллин, үзенә үпкәлә, мин алдалауны кичермим!

Бусында трубканы Рашат куйды. Әхнәф лапылдап урындыкка утырды. Олы афәтнең колак төбендә генә куркыныч итеп сулыш алганын аермачык ишетте ул...

## 7

Ирек, күпме генә баш ватса да, кызын ялгыш адымнан туктатырлык яңа дәлилләр таба алмады. Инде әйтәсе сүзләр әйтелгән, Әхнәфләрнең дә бу өйләнешүгә каршы икәнлекләре билгеле иде. Бүген иртәдән бирле аның күңелен әллә нинди хафалану биләде. Җанны ашый торган бу халәт аның зиһенен томалады, кул-аягын богаулады. Нindидер бик начар нәрсә килеп чыгар кебек тоелды. Сизенүе юкка булмады: өйлә турында елап Сөембикә шылтыратты: Айгөл белән Таһир юкка чыккан. Казанда да, туган-тумачаларда да, дус-ишләрдә дә юк иде алар. Әхнәф кушуы буенча аларны милиция

эзләргә кирәкште. Бу хәбәрне Ирек башта хатын-кыз чәпчүе кебегрәк кабул итте. Яшьләр табигатьтәдер, барлык җирне дә карап бетереп буламыни, дип уйлады. Әмма тора-бара эченә шик төште: Айгөлнең дә, Таһирның да бу көннәрдә нервылары талкынып бетте, ни булмас? Төрле шомлы уйлар белән көн үтте, кояш батты. Керфек какмыйча төн уздырдылар. Әгәр исән-имин булсалар, бер генә каршы сүз әйтмәм, үзләре теләгәнчә яшәсеннәр, дип ант сулары эчте Ирек. Иртән ул авызына тәгам ризык капмыйча эшенә китте. Музейда җанына урын таба алмыйча әрле-бирле йөргәндә, телефон шылтырады. Ирек шомланып трубканы алды. Шылтыратучы әнисе иде.

—Алар бездә,—диде ул.—Әле генә килеп керделәр. Тизрәк кайтып житегез. Сөембикәне дә ал.

Айгөлләрнең исәнлеген ишетү шатлыгын шул минутта ук Сөембикә белән уртаклашты, Зәнфирәгә хәбәр итте. Ярты сәгатьтән Зәйнуллин машинасы белән Баллы Төбәккә юл тоттылар. Тып-тын гына кайтып керделәр, салкын гына хәл-әхвәл белештеләр. Айгөл белән Таһир, куркып поскан җәнлектәй, икесе бер почмакта утыра иде.

—Яшьләрнең уен белдем,—диде әниләре, аларга таба ияге белән ишарәләп.—Син ни әйтерсең, улым?

Ирекнең иелгән башы тагын да түбәнрәк салынды. Ул өч кенә сүз пышылдый алды:

—Мәхәббәтләре чын булса...

—Син ни сөйләгәнеңне беләсеңме?!—дип сикереп торды Сөембикә.—Әле үзләре балалыктан чыкмаган килеш... Алар бит харап булачак!

Өйдә тып-тын булып калды. Моңа кадәр үзенең барлыгын да сиздермәгән стена сәгате башка суккандай тыкелдәве белән бөтен өйне тутырды. Болай да узмаган вакытка ул әллә нинди эчпошыргыч кисәтү өстәде кебек. Бөтенесе дә Гөлҗамалга төбәлде. Әниләре уртага чыгып басты:

—И, балалар, Ирекkәем, Сөембикәм! Нишләпләр бетмәдегез! Нәрсә аркасында? Кызуында сукмаганга.—Әниләре Зәнфирәнең чәчләреннән сыйпап куйды.—Барыбер килен белән кушылдың, улым. Сөембикә килен сыңар канат булып калды... Мин берегезне дә гаепләмим. Гаепне бизмәнгә салып утырудан бәхет артмый. Үлчә-үлчәмә—гомер уза да китә. Балаларга аркылы төшмәгез. Минем сүзем шул...

Бу сүзләрне әйткәндә, әнисе үзенең көйрәп торучы күзләре белән һәркайсының йөзен капшап үтте. Сүзе беткәч, сабыр гына урынына барып утырды. Аңа каршы беркем ләм-мим авыз ачмады. Бу халәт аларга балачактан ук таныш. Әниләре Ирек белән абыйсының уйларын алдан ук белеп тора һәм, сыңар сүз дә әйтмичә, йә ым ярдәмендә, йә күз карашы белән ул уйларны үзе теләгәнчә үзгәртә иде. Ни каты әтиләре дә, күпме генә карышса да, барыбер әниләрен тыңлый, ирлек горурлыгын, кырыслыгын җиңеп, аның эзенә төшә иде. Шулай итеп, ике төрле уйларга урын калмады.

Төштән соң Ирек Сөембикәне музейга чакырды.

—Әйдә бүген кич Әхнәфләргә барып сөйләшик,—диде ул.

—Юк, юк!—Сөембикә баш чайкады.—Әнкәйгә буйсынып кайттык, ә эчемнән һаман ризалаша алмыйм.

—Сөйләшмичә ярамый.

Ирек йомшак кына аның иңбашына кагылды. Сөембикәнең бөтен тәненнән җылы йөгерде, ул бу кулларның иңбашында озаграк торуын теләде, сабырлыгы өчен аларны үбәсе килде. Ниһаять, авыр сулап:

—Ярар,—диде.

Фәһимә аларны, «Кызыгызга кияү сорарга килдегезмени?» дип кимсетте, Сөембикә аны үзе турында гына уйлауда гаепләде. Ирләргә тешләрен кысып түзәргә, аларның ярсуын басу өчен төрле әмәлләр эзләргә туры килде. Ахырда Әхнәф белән Фәһимә, бер ел үтсен, яшьләрне шуннан соң гына өйләндерергә кирәк, диделәр. Әлбәттә, алар бер ел эчендә Таһирны Айгөлдән аерачакларына

шикләнмиләр иде. Ирек белән Сөембикә аларның бу сүзенә «юк» дип тә, «ярар» дип тә әйтә алмыйча кайтып китәргә мәҗбүр булдылар.

* * *

Айгөлләр ягының уңайга борылуын күргәннән соң, әтисе белән әнисен бу якка аударуның бары үзеннән генә торуын Таһир яхшы аңлады. Шуңа күрә сүзеннән бер генә мәртәбә дә чигенмәде. Киеренкелек артканнан-артты, мөнәсәбәтләр катлауланды. Соңгы сөйләшүгә ул бик нык уйлап, алдан ук җентекләп әзерләнде.

—Сез миңа тормыш бирдегез, үстердегез,—диде Таһир.—Инде үземчә яшәргә рөхсәт итегез.

—Ә син шуны беләсеңме, улым,—дип каршы төште Әхнәф.—Синең тормышың үзеңнеке генә түгел бит.

—Ничек үземнеке генә түгел?!—Таһир әтисенә аптыраулы караш ташлады.—Ә минеке? Минем өлешем бармы соң?

—Бар, бар!—дип ашыга-кабалана сүзгә кушылды Фәһимә.—Тик калганы безнеңчә булачак. Гомер буе сине кеше итәргә тырышуыбызның нәтиҗәсен күрергә тиештер бит инде без.

—Рәхмәт...—Таһир бик озак уйланды, дәшмичә торды. Аннары әле генә сискәндереп уятылган кешедәй:—Мин... нәтиҗәмени? Алайса ник җан бирдегез?!—диде ул, башы белән бәрелергә теләгән кешедәй әрле-бирле укталып.—Мин аннан азат булам хәзер! Тулаем сезнеке булам. Сезнең хакка үз өлешемнән баш тартам!

Таһир шулай диде дә атылып-бәрелеп чыгып йөгерде. Әхнәф белән Фәһимә аның артыннан ташландылар, әмма Таһир ишеккә тышкы яктагы аркылы тимерне төшергән иде. Алар ни кылырга белмичә шашынып калдылар. Әхнәф тәрәзәне ачып тышка сикерде, ишекнең тимерен ачып, Фәһимәне чыгарды. Эчке бер сизенү белән икәүләшеп сарайга йөгерделәр. Таһир матчага алдан әзерләп куелган элмәкле бавын бәйләп маташа иде. Әхнәф белән Фәһимә аны берьюлы кочакларына алдылар.

Чынында асылыну дигән нәрсә Таһирның уенда да юк иде. Аның үз дигәнен итү өчен уйлап тапкан бу хәйләсе көтелгәнгә караганда да шәбрәк килеп чыкты: әтисе белән әнисе күз яшьләре белән аның алдына тезләнделәр.

## 8

Инде барысы да хәл ителде, борчылырлык берни дә калмады, дип тынычлануга, аяз көнне яшен суккандай хәл булды: районга республика Югары Советының хисап палатасы вәкилләре тикшерүгә килеп төште. Бу палатаны бик хәтәр очракларда гына җибәрәләр. Әхнәфнең күңелен шомлы уйлар биләп алды. Тикшерүчеләр рәхимсез иде, алар табигатькә чыгу, ял итү, күңел ачу дигән нәрсәләрдән катгый баш тарттылар. Көне-төне казына торгач, бик күп нәрсәләр ачылды. Чүп өстенә чүмәлә, дигәндәй, шушы ут йоткан вакытта Әмир Саттаровның Әхнәф өстеннән президентка хат язуы, депутатлардан хатка кул куйдырып йөрүе, аны алып Казанга китәчәге турындагы хәбәр килеп ирешә. Моны ишеткәч, Әхнәф бүлмәсенә Сәлаховтан башка беркемне дә кертмәскә кушты, ишекле-түрле йөрде, бәргәләнде. Саттаров белән сөйләшүнең мәгънәсе булмаячак иде. Бердәнбер таяныч булып Ирек калды. Аны музейдан тиз генә Сәлахов шоферы алып килде. Ирек Әхнәфнең суырылып калган йөзенә күз ташлау белән хәлнең үтә дә җитди-леген аңлады. Тикшерү барганын ул ишеткән, тик, үзе эчендә кайнамагач, колак очыннан гына уздырган иде. Әхнәфнең дулкынланган чакларда уң күз кабагы тартып куя торган гадәте бар, хәзер ул күз кабагының туктаусыз дерт-дерт сикергәләп торуын күреп, Ирек хәйран калды. Әхнәф, сүзсез генә кул кысышкач, хәл-әхвәл дә сорамады, шундук сүз башлады:

—Барысы да бетте! Рәшәткә!—диде ул, калтыранган иреннәрен ялап.—Синең ярдәм кирәк.

—Ни булды?

—Бар монда хәлләр! Бер яктан тикшерүчеләр казына, икенче яктан Әмир Саттаров минем өстән президентка хат алып китәргә йөри, ди. Аны син генә туктата аласың.

Әхнәф, Ирек каршына килеп, ялварулы күзләре белән аңа төбәлде.

—Аны туктату... ай-һай!—дип куйды Ирек, бераз уйлап торгач.

—Туктатырга кирәк—башка юл юк! Юкса—рәшәткә!

—Синдәй житәкчене рәшәткә артына тыгу өчен бик күп кирәк бит ул.. .

Әхнәф урыныннан кыймшанмады, йөзен тәрәзәгә борган килеш, таш сындай басып торды. Кинәт аның гөбедән чыккандай шомлы тавышы ишетелде:

—Әгәр... күп булса?

—Нәрсә?!—ничек кычкырып жибәрүен дә, аның янына ничек барып житүен дә сизми калды Ирек.

Әхнәф ишетелер-ишетелмәс тавыш белән дәвам итте:

—Күп шул. Бик күп!.. Әллә ничә рәшәткәгә житәрлек...

Ирек, үз-үзенә урын таба алмыйча, ишек яныннан әйләнеп килде. Әхнәфнең күзләренә туп-туры карап:

—Син бит шулкадәр чиста күңелле идең,—диде ул.—Кай арада сазлыкка кереп баттың соң?

Әхнәфнең күзләре дымланды:

—Минем Сусаниным үзем белән янәшә бит...—дип куйды ул.

—Син безнең изге әйберләрне таптап киткәнсең...—Ирек сызланып баш чайкады.—Бик зур чикне үткәнсең. Моны эшләү өчен... мин белмим... ни йөзең белән эшләмәк кирәк?!

Әхнәфнең яшьле күзләрен Ирекнең үз гомерендә беренче мәртәбә күрүе иде. Бу берничек тә башка сыймый, моны күңел кабул итә алмый иде. Ул кабаланып читкә китте һәм стена буендагы урындыкларның берсенә барып утырды да куллары белән башын учлады.

—Әйе, мин нык ялгыштым!—дип кычкырды Әхнәф.—Коткар мине! Сөйрәп чыгарыгыз! Миңа бүген исән калырга кирәк. Аннары барлык гөнаһларымны юармын, чәчем белән жир себерермен! Син Саттаровны туктатырга сүз бирәсеңме?

—Тырышам,—диде Ирек.

Ул Саттаровны көне буе эзләде, хәтта машина яллап Наратбашка да барып кайтты. Әмма Саттаров беркайда да юк, кайдалыгын хатыны да белми иде. Кичен Ирек бик кәефсез хәлдә арып-талчыгып кайтып керде. Ишекне ачканчы ук борынына әллә нинди тәмле исләр килеп бәрелде. Ул бусаганы аптырабрак атлады, кояштай балкып торучы Зәнфирәне, мул табынны күреп хәйран калды.

—Нәрсә хөрмәтенә бу?—диде ул төксе генә.

—Ә син башта утыр, аннары әйтермен.

Ирек юынып өстәл янына килеп утыруга, алдындагы китапка текәлеп калды. Ул кабаланып аны кулына алды. Бу—аның китабы иде! Ирек китапның битләрен бармаклары белән барлагандай итте дә елмаеп башын күтәрде. Зәнфирә, кайнар беләкләре белән муенына сарылып, янагын янагына терәп:

—Котлыйм, карткаем!..—диде.

—Юк, мин сине котлыйм!—Ирек йөзен аңа таба борды һәм Зәнфирәнең иреннәреннән үбеп алды.—Бу китап бит синеке, син мине коткармаган булсаң, язылa алмый иде ул... Каян алдың соң син моны?

—Әхмәт салган.

Зәнфирә аңа Әхмәтнең хатын сузды. Сигнальный экземплярын жибәрәм, икенче китабыңны көтеп калабыз, дип кыска гына хат язган иде ул. Алар

өчен бу кич ничәмә-ничә еллар буе көткән олы бәйрәм киче булды. Бүген аларның бәхетле көне иде.

Төнге уннарда дөнья кубарып телефон шылтырады. Шылтыратучы Әхнәф иде.

—Эш бетте, Саттаров хатны бүген илтеп тапшырган инде.

—Президенткамыни?

—Редакциягә. Хат президентка мөрәҗәгать рәвешендә язылган. Мин таңнан торып Казанга китәм. Якын бер дус белән редакторга керәбез.

Ирек ана хәерле юл теләде.

Икенче көнне музейга елап-шешенеп беткән Айгөл килеп керде.

—Казанда Әхнәф абыйга инсульт булган!—диде ул, елавыннан тыела алмыйча һәм яшьле күзләре белән тилмереп, Ирекка карады:—Хәзер ни була инде , әти? !

—Тынычлан, кызым,—диде Ирек, аның күз яшьләрен сөртеп.—Һичшиксез тереләчәк ул. Таһир кайда соң әле?

—Ул әнисе белән Казанга больницага китте.

Ирек Айгөлне шактый озак юатты, тынычландырды, ә үзенең күнеленнән тынычлык качты...

## 9

...Имеш тә Миңзаһит Болынкырдагы бакчаларына Рашат белән Эльзаны җитәкләп килеп керә. Алар тугач, һәрберсенә атап утырткан ике алмагач шау чәчәктә утыралар. Тик шунысы сәер, аларның ботаклары имеш тә җирдән үк башлана, үзләре җәелеп бергә кушылганнар да ярты бакчаны алып торалар. Рашат белән Эльза, Миңзаһитның кулларыннан ычкынып, шул катыктай алмагач чәчәкләре эченә йөгереп кереп югалалар. Ул балаларына, «Чыгыгыз!» дип кычкыра, алмагачларны әйләнеп йөри, аларның шаркылдап көлгән тавышларын ишетә, үзләрен күреп кала. Аны бик озак үртәгәннән соң, балалары парлашып чәчәк арасыннан чыгалар да аңа таба йөгерә башлыйлар. Миңзаһит җиргә чүгәли, балаларының чәчләренә, битләренә, иңбашларына алма чәчәге тажларының ябышканлыгын күрә, аларны бөтереп кочагына ала...

Сәер төш иде бу. Ул аны башта Хәятка сөйләмәкче булды да шундук ул ниятеннән кире кайтты. Сөйләве һич тә үз файдасына булмаячагын алдан ук чамалады. Соңгы вакытларда исеп куйган җилне дә Миңзаһитка каршы борды Хәят, әгәр бүген көн бик матур, краяшлы икән, дисә, хатыны, «эчен пошадыр, башкаларга әйбәт була бит», дип аның авызын йомды. Бөтенләй аларга кагылмаган, еракдагы нәрсә турында сүз чыкса да, Хәят аны ансат кына Миңзаһитка каршы китереп салды. Кичә телевизор караганда, диктор Америка президентының белдерүе турында әйтүгә, Хәят: «Бу да синең кебек бер дивана инде», дип куйды. Аның белән сөйләшү түгел, хәтта янәшәсендә дә торырлык түгел иде. Баштарак Миңзаһит аны теленә ни туры килә, шуны әйтеп сүкте, алар кым-кырыч килеп талаштылар, хәлдән таеп, ярсып беткәч, һәркайсы үз урынына кереп ятты. Әмма болай яшәп булмый, йөрәк түзмәячәк иде. Миңзаһит өчен бер нәрсә аермачык булып тәгаенләнде: Хәят үзгәрде, аңардан курыкмый башлады. Үтә дә кызып киткән чакларда ул аны якасыннан әләктереп: «Буып үтерәм хәзер!» дип тә карады. Әмма Хәятның йөзенә курку урынына мыскыллы елмаю җәелде: «Үтер!» дип гыжылдады ул ана, күзләрен коточкыч ачу белән төбәп. Бу күзләрдә аның Мизаһиттан өстен икәнлеге, аны буйсындыруы ярылып ята иде. Үзе дә сизмәстән, Миңзаһит хатыны астында калды һәм моннан котылу мөмкин түгел иде.

Ничәдер көн үткәннән соң, теге төш тагын килеп керде. Аңардан айный алмыйча күпме йөргәнен Миңзаһит хәтерләми. Әмма ләкин бер көнне өеннән чыгып китте. Ник чыгып киткәнлеген соңрак, кибетләрне, базарларны, кафе-ресторannнарны, вокзалларны урап чыккач кына аңлады: ул Рашатны эзли

икән ләбаса! Әмма бу башка сыя торган хәл түгел иде. Алар өчен Рашаттан котылу үлемнән котылу булды. Аның нәрсәгә кирәге бар? Ләкин ул бернинди максатсыз эзләнеп йөрүен дәвам итте. Аны инде кибет-базарлардагы сатучылар, вокзалдагы таксистлар, контролерлар белеп бетерделәр. Ул ап-ак күлмәктән, галстуктан, кара костюм-чалбардан, күз явын алырлык ялтыратылган туфлиләрдән йөрде. Кайда гына күренсә дә, яхшылап кырынган, хушбуй сибелгән йөзе, чал чәчләре ана хөрмәт-ихтирам уятты. Ни эзләде соң ул? Газап-михнәтләрнеме, Рашат кулыннан теге дөньяга күчүләренме? Аның болай йөрүләре гайре табигый, бернинди мантыйкка да сыймый иде. Ул аны үзе шулай аңлады, әмма тыела алмады. Шул чакта Хәятның аны тетрәндергән сүзләре хәтеренә төште:

—Мин шушы гомер яшәп, Алланың юклыгына ышандым,—дигән иде ул, чәй эчеп утырганда.—Аның юклыгына мине син ышандырдың. Әгәр ялгышсам, син генә гөнаһлы буласың.

—Шул кадәр олы нәрсәгә мин сине ничек ышандырыйм?!

—Әгәр Алла булса, гомер буе синең мине газаплауларына түзеп тора алмас иде, нинди дә булса җәзасын табар иде. Юк ул!—Хәят шулай дип кычкырып ингаляторына тотынды.

Минзаһит соңгы вакытларда икеләнә башлады: әллә бар микән? Ул Аллага гомер буе ышанмады. Бар микәнни? Шулай булмаса, Рашат аларны шушы кадәр газаплар идеме? Инде аңардан котылдык, дип куангач, кабат аны эзләтер идеме? Ниндидер көчнең барлыгы бәхәссез. Минзаһит карыша, атларга теләми, ишек янына барып киенергә керешкәч, кабат борылып кереп ята. Күзләрен йома, берни уйламаска тырыша, яки телевизорны ачып, иң кызыклы тапшыруларны карарга керешә, әмма... Ничә минут үтәдер, телевизорны ничек сүндергәнен, кай арада киенгәнен оныта, ул инде Казанның кеше кайный торган урыннарына омтыла... Ниндидер көч аны ашкындыра, эзләтә.

Ул бер көнне Рашатны тапты да кебек. Базарда иде ул, читтә, җыен шпана кайный торган җирдә. Кызыл буяу тигән ертык фуражкадан, сакал-мыек баскан берәү белән Минзаһитның күзләре очрашты. Буе аныкы, күз карашы аныкы, йөз рәвеше аныкы, алтын тешләре иреннәре арасыннан күренеп кенә калды. Минзаһит ана таба атларга теләде, әмма аяклары буйсынмады. Теге көч атлатмады, юри богаулап газаплады кебек. Шул арада бу сәер бәндә юкка да чыкты. Минзаһит янадан ничә көннәр буе бу урынны саклады, андагы барлык шмон белән танышып бетте, әмма теге адәмне очрата алмады.

Кичен өйдә телефон шылтырады. Хәят трубканы алды, әмма җавап бирүче юк, аның сулыш алганы гына ишетелә иде.

—Улым, син бит бу!—дип кычкырды ул трубкага.—Бер генә сүз эндәш! Ичмасам ник бер генә күренмисең?! Вакытсыз үлсеннәр, дисеңме?!.

Трубканы куйдылар. Мондый хәл элегрәк тә булган иде. Анысында Минзаһит сөйләште:

—Шулай шалтырат кына,—диде ул кабаланып.—Дәшмәсәң, дәшмәссең, шалтырат кына, исәнлегеңне генә белик!..

Бервакыт Минзаһит матбугат йорты каршындагы урамда китап сатучы янында туктап калды. Алар шактый вакыт сөйләшеп торганнан соң, сатучы:

—Ни эзлисең соң син?—дип сорады.

—Юньле китап эзлим,—дип шаяртты Минзаһит.

—Менә бик әйбәт китап. Мин үзем туктый алмыйча укып чыктым.

—Үтереш, порнография, сексны беләм мин.

—Юк, бу андый түгел,—диде сатучы, ана зәңгәрсу тышлы китап сузып.

Минзаһит китапны кулына алып, күзлеген киеп карады да:

—Ирек Сабитов!—дип кычкырып җибәрде.

—Әллә танышыгызмы?

—Шулайрак,—диде Минзаһит.

Ул тиешле акчасын бирде дә китапны алып читкә китте, шунда ерак булмаган эскәмиягә утырды һәм укырга тотынды. Шуннан соң ул бу дөньядан ычкынды. Караңгы төшкәндә, күзләре күрми башлагач кына туктап калды.

Хәятка ул китапны алып кайтып күрсәтү олы вакыйга булды. Башта аны Минзаһит укыды, аннары Хәят ике көн эчендә укып чыкты.

—Дөрес түгел, ялган, арттырылган!—дип чәбәләнде Минзаһит, китапны икесе дә укып чыккач.

Ул башта, Сабитовны тар-мар итәргә уйлап, мәкалә язарга уйлады, аннары нәшриятның баш редакторына кермәкче булды, әмма Хәят аның бу уйларын бер сүз белән юкка чыгарды:

—Их, Минзаһит! Монда бит меңнән бере дә язылмаган. Безнең тормышка җиңел караган синең ул Сабитовың. Минем бер генә күнлек кичерешләрне сурәтләсә дә кешеләрнең тормышка күзләре ачылыр иде.

—Арттырасың,—диде Минзаһит.—Мин беркайчан да зверь булмадым.

—Фәрештә буласың килгәч, элегрәк уйларга кирәк иде. Һәр адымыңны. Алар узган гомерләрен актарырга керештеләр.

—Мин шуны уйлыйм: ник аерылышмаганбыз, ник кирәк булган шушындый тормыш? Ул түгелгән көчләрне, йөрәк кайнарлыкларын берәр файдалы эшкә юнәлткән булсак, нәрсә булыр иде икән? Үземә һәйкәл куярлык эш калдырган булыр идем. Ай, ничек юкка исраф ителде зиһен көче, йөрәк тибешләре! Ай, ничек юкка! Һәм моны син эшләден, Минзаһит, син! Ник эшләдең син моны?! Шушыңа җавап бирмәсәң, мин сиңа үлгәндә дә бәхиллек бирмәячәкмен!—диде Хәят.

Хәятның бу сүзләреннән соң Арсланов бик озак уйланып йөрде. Көн саен аны Хәят, «Кая җавабың?» дип кысты. Ахырда ул беркөнне:

—Син ул җавапка ышанмассың,—диде.

—Шулай да әйт.

—Берни дә уйланмаган, узган да узган, таң аткан да кич булган, матур гына атып утырган чәчәк кебек. Гел шулай мәңге дәвам итәр кебек тоелган. Менә тукталышка килеп җиттек—бүтән барыр җир калмады.

Алар ник яшәделәр? Ни калдырдылар? Бу сорауларның берсенә дә уңай җавап табып булмый иде. Бер уйласаң, ничек инде адәм баласы, җир йөзендә дистәләрчә еллар яшәп, нидер калдырмаска тиеш? Минзаһиттан ни калды соң? Ул як-ягына каранды: дүрт якта дүрт стенадан башка берни дә юк иде. Үткәннәр дә юк, киләчәк тә юк, аралашыр кешеләр дә юк. Беркөн кызы Эльза килгәч:

—Ахмакларның акыллы, кабахәтләрнең фәрештә булып кылануы чиктән аша бара,—диде.—Азагы синеке кебек, менә шушлай бетәчәк...

Кыска һәм рәхимсез карар иде бу. Минзаһит, һава җитмәгәндәй, форточканы ачып, тәрәзәгә капланды. Күк йөзендә кургаштай авыр болытлар йөзә иде. Алар каядыр агалар, әмма бер генә җире дә ачылмый, шуның бер генә урыны ертылган кебек булды, аның артында нindидер яктылык шәйләнде. Әмма ана өмет бәләкәй иде...

## 10

Әхнәфне дүрт күз белән көттеләр. Таһир белән Фәһимә больницадан кайтып кермәде. Аны ай ярымнан соң гына алып кайттылар. Ул, култык таякларына таянып, көч-хәл белән генә йөри иде. Авызы ямьсез булып кыйгайган, теле тотлыга. Сөйләшә башласа, тыела алмыйча елап җибәрә. Врачлар, авызы урынына кайтачак, аягы да рәтләнәчәк, тотлыгуы да бетәчәк, дип юаттылар. Ул кайтып бераз торгач, туй көне билгеләнде. Исемлек төзелде, чакырулар өләшенде, бүләкләр алынды.

Халык гайбәт казанына салынган бәрәңге кебек кайнады. Имеш тә Әхнәф урынына Зәнфирә малае Зирәк кайтачак икән, терелгәнен генә көтәләр икән һәм башкалар, һәм башкалар...

Туй мәшәкатьләре белән әвәрә килгән бер көнне Әхнәфләрне генә түгел, бөтен Болынкырны тетрәткән хәл булды. Нәкъ төн уртасында икмәк пешерү комбинатында көчле янгын чыкты. Котырынган җил, утны күрек белән өргәндәй, барлык урыннарга үрләтте, биш-ун минут эчендә комбинат үкереп яна иде инде. Янгын сүндерүчеләр күпме генә тырышсалар да, комбинат тулысынча диярлек көл-күмергә әйләнде. Тикшерү утның төртелүен раслады. Хәтта өч данә бензин канистрына кадәр табылды. Халык аптырашта иде. Әхнәф кенә моның Рашат кулы икәнлеген чамалады. Икмәк комбинатын күптән түгел генә ул үзенә алган иде. Бу хәлләрдән соң ул сөйләшкәндә тагын да ныграк тотлыга башлады...

Таһир белән Айгөл Чаллыга туй кирәк-яраклары юллап базарга бардылар. Шунда Айгөл тораташ катып калды: аның каршысында Айдар басып тора иде. Таһир белән Айдар кул биреп күрештеләр.

—Ни хәлләрдә ятасыз?—диде ул елмаеп.—Сөембикәнең хәлләре ничек?

—Ул сезне сагына...

—Сагына?! Син шаяртасың, Айгөл.

—Юк, юк, чынлап.—Айгөл керфекләрен аска төшерде.—Сез мине кичерегез, Айдар абый... Мин аңлап бетермәгәнмен.

—Сезнең гаебегез юк.

—Бар!—диде Айгөл.—Мин хәзер генә барысын да аңладым... Сезнең түземлегегезгә... мин сүз таба алмыйм...

Айгөл мең төрле кичерешләр уртасында бәргәләнде. Моны беркемгә дә әйтә торган, аңлата торган түгел иде. Бу—Айгөлне үзеннән-үзе оялта торган сәер тойгы иде. Ул күңеленең иң ерак почмагына бикләп куелган газаплы уй булып калды. Айдар аларда яши башлагач та, Айгөл әллә нишләде: Айдар абыйсы дәрестә дә, урамда да гел елмаеп аның каршына килде дә басты. Башта Айгөл аны, үги әтисе буларак, шулай күзенә күренә, дип уйлады. Аннары, коты очып, моның алай түгеллегенә ышанды. Айдар аның күңеленә ныклап, хәтта Таһирны читкә этеп кереп бара иде! Моны туктату өчен Айгөл, теләмәсә дә, гакылы белән боерып, аңа тупас бәрелде, туктаусыз бәйләнде, йөзен бозды... Сөембикә аның хәлен аңламады, тиргәде, Айдарга каты бәрелмәскә кушты. Айгөл күңеле белән аны иркәли, сөя иде һәм шушы тойгысы өчен үзен иң әшәке бәндә, дип сүгә, азгынлыкта гаепли иде. Йә Айдар, йә ул өйдән чыгып китәргә тиеш булып калды. Айгөл Айдарның озын керфекләр белән уратып алынган күзләренә тыныч кына карый алмады. Әйтерсең лә алардан килгән нур аны исертте, акылын алды. Мондый халәттә ул үзенә баш була алмавын аңлады. Бу—кыз кеше өчен куркыныч, хәвефле халәт иде. Айдарның тигез ак тешләрен әз генә, авызының бер як читеннән генә күрсәтеп елмаюы аны тәмам шаштырды...

Айдар киткәч, күңеле белән бик озак чирләп йөрде Айгөл. Барысы да үтте, менә хәзер ул бәхетле иде. Ул хәзер аңа абый итеп, кирәк булса үги әти итеп карый ала.

—Мин сезнең түземлегегезгә хәйран калам...

—Үткәннәрне онытыйк,—диде Айдар, кечелекле елмаеп.—Сез нинди эш белән соң әле?

Айгөл белән Таһир аңа барысын да сөйләп бирделәр. Алар Айдарны, көненсәгатен әйтеп, туйга чакырдылар. Ул Чаллыда квартира алган булып чыкты. «Һичшиксез котларга кайтам»,—диде, бәхет теләде.

Туйга өч көн кала, кучтәнәчләр төяп, ак «Жигули»ендә кайтып та төште. Ул Таһир белән Айгөлгә кухня телевизоры алып кайткан иде. Яшьләр чыгып киткәч, алар сүзсез генә бер-берсенә якынлаштылар да:

—Кайтуың өчен рәхмәт,—дип пышылдады Сөембикә.—Син киткән көннән бирле йөрәгемнән кан тамды. Көндез дә, төнлә дә...

—Врачлар күп кенә авыруларны кан агызып дәвалыйлар,—диде Айдар, аның күзләренә туп-туры карап.

—Йөрәктән түгел бит!—дип пышылдады Сөембикә. Аларның күңел дәрьялары чишелде. Айдар үзенең, әгәр Сөембикә кабул итсә, туйлар узгач кайтырга теләге барлыгын белдерде.

## 11

Ирекнең күз алдыннан барысы да ташкын кебек үтте: капка төбен—килеп туктаулар, Таһирны өйгә уздырмыйча интектерү хикмәтләре, һәр ишектән үтеп керү мәшәкатьләре, ниһаять, табын янына утырулар, анда әйтелгән матур сүзләр, Айгөлне капка төбеннән озатып калулар—барысы да артта калдылар. Әмма иң авыры алда иде. Нәкъ ул көткәнчә, Фәһимә шылтыратты:

—Әхнәф туйга барырга теләми...

—Ярый, мин кагылырмын,—диде Ирек.

Ул аларга бер сәгать алдан керде. Аны күрү белән, Әхнәф култык таякларын шапылдатып идәнгә ташлады да кысып кочаклап алды. Ирек юка күлмәк аша аның йөрәгенең очарга талпынган коштай леп-леп ярсып тибүен тойды. Ай-яй, кызу тибә иде ул йөрәк! Ирекнең сулышы тамак төбен яндырып туктап калгандай булды.

—Әхнәф,—диде ул.—Әйдә барыйк. Бергә утырырбыз. Арысаң, кайтарып куярбыз...

Әхнәф кинәт әллә ничек уң кулының учы белән күзләрен каплады да, тынсыз-өнсез калып, башын чайкады. Шул чакта Ирекнең бәгырен әллә нәрсә өздереп узды... Аның каршында зәңгәр күзле, шоп-шома йөзле, дулкын-дулкын чәчле яшьлек дусты түгел иде инде. Ирекне тагын бер нәрсә куркытты: Әхнәфнең уң як күзе, пыяла күзне хәтерләтеп, шактый зурайган һәм кабагы ябылып бетмичә кала. Әле беркөн күрешкәндә бу нәрсә юк иде.

—Синсез балаларга кыен булыр бит.

—Ю-ю-к-кы,—диде Әхнәф, әллә ничек бытыр-бытыр килеп.—Ми-минем анда уты-уты-рыр-лык эр-эр-эррә-тем юк...

—Син бит гел элеккечә. Юкны сөйләмә,—диде Ирек аның күңелен күтәрү өчен.

Әхнәф нидер әйтмәкче булды, әмма көчләп кысылган иреннәре җәелеп киттеләр—ул елый башлады. Аның бара алмаслыгын Ирек аңлаган иде инде. Шулчак Мэлс белән Нәфисә килеп керде. Алар Әхнәфне икесе ике яктан кочаклап алдылар, әллә нинди юаткыч сүзләр әйттеләр, әмма ул һәр әйтелгән сүзгә каршы баш чайкау белән җавап кайтарды. Инде кыстауның мәгънәсе калмагач, барысы да җыендылар да бергәләп кузгалдылар. Әмма ишеккә барып җиткәч, Ирек чыгып китә алмады, әйтерсең лә аның каршында таш дивар тора иде. Ул, кабат борылып, Әхнәф янына килде, кулы белән йомшак кына аның иңбашларыннан сөйде һәм җылы бер эчке тавыш белән:

—Туйдан мин синең яныңа килгәләп торырмын, андагы хәлләрне сөйләрмен,—диде.

Әхнәф янында әнисенең сеңлесе Фатыйма калды. Алар артыннан ишек ябылуга, Әхнәф көч-хәл белән ике адым сөйрәлде дә мунча миче кадәр булып утыручы, һава тутырып кабартылган кәнәфигә чумды, кычкырып елап җибәреп, Фатыйма тутасын куркытмас өчен, аскы иренен тешләде, ияге дер-дер килде, күзләреннән яшь акты. Шул хәлендә ул менә хәзер башланачак, гөрләячәк туйдан аерылып очты, гомумән, бу тормыштан умырылып, төпсез упкынга очты... Моны туктату инде хәзер беркемнең дә кулыннан килмәячәк иде. Тормышның әллә нинди тирән, баш җитмәс буталчык чоңгылларын үз гомерендә күп мәртәбәләр исән-сау кичеп чыкты Әхнәф. Һәм менә барысы да үз урынына утырды, дигәч, тип-тигез болын уртасына чыккач, үз-үзен югалтты. Чәчәк, нектар исләренә исерде, гүзәлләкләр алдында тезләнде, күз явыңны алырлык аллы-гөлле булып балкучы ялтыравыкларга үрелде, тагын әллә нинди кызыктыргыч-ымсындыргыч шалтыравык-челтерәвекләргә сузылды.

Әхнәф күзләрен ачты. Күрше бүлмәдә Фатыйма тутасының шылтыр-шылтыр китереп җеп ураганы ишетелә, ул орчыкны калай бадыянга куя да зыр-зыр әйләндерә. Әхнәф Ирекнең баягы кул җылысын кабат инбашларында тойды һәм упкынга очуыннан тукталгандай булды. Күзләрен ачып, шактый уйланып утырды. Бу җир йөзендә иң якын кешесе Ирек кенә икәнлеген, ничә еллар буе кире кагып килеп, шуның хаклыгына ул менә хәзер кабат инанды. Аның җылы кулларына гына таянып була икән. Юк, упкыннан коткарсын өчен түгел, бары аңласын өчен. Мона кадәр дә ул Әхнәфне аңлады, киләчәктә дә аңлаячак. Димәк, Әхнәфне яратучы да ул гына. Бу дөньяда иң олы байлыгы, иң кадерле кешесе булып Ирек кенә калды. Бүген килеп кергәндә, ул Ирекнең йөзендәге эчке сызлануны бер карауга ук күреп алды. Бу сызлануның үзе өчен борчылудан икәнлеген яхшы тойды. Ирек эчке газабын елмаюы белән яшерергә теләде, шуны эшләргә тырышудан аның бөтен гәүдәсе киергедәй тартылды. Әхнәфне аудармау, аны аякта тоту өчен булган бу елмаюы бөтен йөзенә җәелде. Әхнәф ана моның өчен эченнән генә рәхмәт укыды, аның ни дәрәҗәдә якын икәнлеген тойды. Ирекне бары тик күзләре генә саттылар: алар елмая алмады, алардагы эчке сызлану үзгәрешсез калды... Тик аны моның өчен гаепләп булмый иде. Дустының шушы коточкыч тырышлыгы белән тудырылган ихлас халәтенең Әхнәф үзенең җанына, канына эреп керүен тойды, адәм баласы күтәрә алмаслык, үзе өчен җәһәннәм газапларына тиң шушы минутларда ул аны гөрселдәп авудан, ә бәлкем йөрәге ярылып үлүдән дә саклап калгандыр.

Фәһимә дә шунда иде, ул да кунаклар белән бергә ишектән чыгып китте, тик аның йөзендәге тынычлык Әхнәфнең йөрәген парә-парә телгәләде. Больницада ятканда, Фәһимә аның янына беренче мәртәбә килгәч тә, йөзендәге хис-тойгылар үзләре генә дә икенче инсульт алырлык иде. Аның эчендә Әхнәфнең үзе өчен авыр йөк булуыннан курку кайный һәм болар тып-тын караңгы төндә берниндн күкрәүсез уйнап торган аҗагандай, аның йөзендә туктаусыз уйнап торалар, ул аларны берничек тә яшерә алмый, күрәсең, яшерергә теләми дә иде. Әхнәф күпме генә эзләсә дә, аның йөз чалымнарыннан, күзләреннән һич югы кызгану чаткысы таба алмады. Әхнәф хәзер ана бөтенләй кирәк түгел иде! Фәһимә ана күптән чыгарып атасы иске җиһазга карагандай карады. Тик үзенә булгач, картлар йортыныкы ярамый, үтә дә затлысы, бөтен кешенекеннән дә матуррагы, шул ук вакытта шыгырдамастай ныклысы, бик озак искәрмәстәе кирәк иде...

Моның шулай икәнлеген Әхнәф больницадан кайтканнан соң бигрәк тә нык аңлады. Хатынына аның авыр йөк икәнлеге бәхәссез иде. Аның үзенә дә Фәһимә һич тә кирәкми һәм инде күптән кирәкми. Ләкин бөтен фаҗига хәзер аның Фәһимәдән башка яши алмавында, шуның кулына калуында, тилмереп аның күзенә карап торуында. Шул яратмаган хатыны, авырыксынуын булдыра алган кадәр йотып, йотып бетерә алмаганын йөзендә, кискен, тупас хәрәкәтләрендә сиздерә-сиздерә, аны мунча кертә, ваннада юындыра. Шул яратмаган Фәһимәне бер кулы белән иңнәреннән кочып, икенчесе белән култык таягына таянып, Әхнәф өйдән ишек алдында утырырга чыгарга, күпмедер вакыттан соң шул рәвешле кабат өйгә керергә мәҗбүр. Өйнең беренче катыннан икенчесенә менү дә, икенче каттан беренчесенә төшү дә яратмаган Фәһимә җилкәсендә. Өченче катка Казаннан кайткан вакытларында Таһир гына менә. Ник кирәк булган бу икенче, өченче катлар? Беренчесендә дә буш бүлмәнең саны юк. Бер катлы дип башлаганнар иде, Фәһимә тырыша-тырмаша торгач, өчкә күтәрде. Менә хәзер үзе җәфа чигә. Хәер, җәфа чигә микән? Шоферы Сәгыйрь белән алар бер арбага мичәлгән пар атлар кебек. Ул килгәч, Әхнәфне икесе ике яктан эләктереп, җилпеп кенә йөртәләр. Ишек алдындагы иске кәнәфигә ничек чыгып утырганын да сизми кала. Әхнәф икенче катта булса, астан, ишек алдында утырса—тәрәзә аша аларның туктаусыз нидер сайрашканын, көлешкәнен ишетеп тора. Ул Сәгыйрьне

күралмый, Фәһимәне күралмый, көлешүләренә җене котыра, килеп тәненә кагылуларына, икесен дә буып атардай була. Шулай ярсып, үзен-үзе кая куярга белмәгән чакларында, әнисенең сүзләре хәтеренә килә дә төшә. Шушы йортның барлык урыннарын күрсәтеп чыккач, Әхнәф аны үзләре янына торырга чакырды. «Аллам сакласын!—дип шундук каршы төште әнисе.—Бу бит өй түгел, шайтан оясы, улым!» «Ничек алай булсын инде, әни?!» «Мин үземнең өемдә чәй эчеп утырганда, рәхәтләнеп тәрәзә төбендәге гөлләремне сыпырам, шулар белән сөйләшәм,—дип дәвам итте әнисе.—Өй зурайган саен, ана җен-пәриләр тула. Буш бүлмәгез бар икән, белеп торыгыз: ул—шайтан оясы! Буш бүлмәсе күп йортта яшәүчеләрнең тормышларын кара син! Тыштан ялтырый, эчтән калтырый. Без бәләкәй генә агач өйдә унбер җан гомер кичердек. Шунда бозау, каз-үрдәк, бәрәннәр. Элекке кешеләр нишләп җен-пәри күргән, дип беләсез сез? Алар җаныбызга керә алмаганга. Өйгә аяк басуга, без аларны күреп ала идек. Без терәлешеп, бер-беребезнең күңел җылысын алып яшәдек. Ә сезнең әйләнә-тирәгездә дә, җаннарыгызда да бушлык, шул бушлыкта шайтан котыра, күңелләрегезне шулар бутый...» Әнисе хаклы булып чыкты ахрысы. Фәһимә белән икесенең өстенә өченче шайтан—шофер Сәгыйрь килеп кушылды. Ул хәзер өйнең беренче катында да, өченчесендә дә чын хуҗа кебек йөри...

Әхнәфнең зиһене үткен, хәтта авырганчыга кадәргедән дә үткенрәк иде. Хәзер исә шул үткенлек өстенә ачы рәнҗеш, үкенү, рәхимсезлек өстәлде. Хәзер ул үзен үткен борау кебек һәр нәрсәнең төбенә төшәргә тырышу белән газаплады, йөрәген туктаусыз тырнады, кан саркып торган күңел ярасына учлап тоз сипте. Бу тормыштан, гомерен багышлаган олы мәгънәви эшләрдән аерылып билгесезлек упкынына очу фаҗигасен ул бары тик үзен-үзе җәзалап кына җиңә иде.

Әхнәф авыр сулап урыныннан торды, култык таякларына таянды. Йөгереп чыккан Фатыйма тутасын, берни дә кирәкми, дип, кабат орчыгы янына куды. Ул көзге каршына килде. Чырае көл төсенә кергән, соңгы чәчләре дә агарган энә. Күз тирәләре шешмәкләнеп тора. Иреннәре ямьсез булып тартылып, сул якка күтәрелгәннәр. Алар йомылып бетә алмаганлыктан, ике теше күренеп тора, ирен почмагында төкреге ялтырый. Өченче көн уң як күзенә дә әллә ни булды. Хак әйтәләр: берәүнең ашы сыек, икенче берәүнең авызы кыек. Искәрмәстән туа проблема. Әле кайчан гына аның авызы туры, аяклары йөри иде.

Әхнәф кабат кәнәфиенә барып утырды. Ә шулай да инсульт алырга тиеш идеме соң ул? Йөрәге бик нык борчыган чакларда, Казан больницасына кереп яткалады, тик беркайчан да дәвалау курсын алып бетермәде, вакытыннан алда чыгып ычкынды. Хаста җитәкчене сөймиләр, әнә Шакировны, җитди чире беленгәч, депутат та итмәделәр. Авырсаң, син бу машинадан алып ташланасың, урыныңа өр-яңа шестерня куялар. Машина дистә еллар буе, бер генә секундка да акрынаймыйча, дөбер-шатыр әйләнә, туктап тын алу түгел, артка борылып карарга да вакыт тими. Шуның өстенә коттедж, менә бу шайтан оясы. Алары да кирәк булгандыр инде. Башка җитәкчеләр ничек, ул да шулай. Җыен карга арасында чәүкә булып кала алмыйсың.

Инсульт сугар алдыннан, иртәгә Казанга китәм, дигән көнне очрашкач, Ирекнең әйткән сүзләре менә хәзер күпме вакытлар Әхнәфнең күңелендә утлы энә кебек бөтерелә: «Чикне үтеп чыгу...» Тормышны тотучы изге нәрсәләрне ата-бабалар сабый чактан ук маңгайга кашык белән сугып та, сыек чыбык, кычыткан тәмен татытып та, башкача да сеңдерделәр. Аннары шул ук нәрсәләрне пионер, комсомол, партия корыч кыршаулар белән ныгытты. Аларны какшату мөмкин түгел иде кебек. Әхнәфнең күңеле хәзер дә пакь иң. Ул беркайчан да кешеләр башыннан йөрмәде, аның ашкын йөрәге дә, уй-омтылышлары да гел зур нәрсәгә—яшәүне матуррак, яктырак итүгә омтылды. Юк, Әхнәф беркайчан да үз бәхете турында уйламады. Ашкын

яшьлекнең тылсымлы көннәре һәм төннәре дә, аннан соңгы житлегү еллары да бер утта—халык өчен дип дөрләп янды. Районның бер чигеннән икенче чигенәчә, бер офыктан икенче офыккача жәелгән хезмәт кырында ул гомерлек эш аты булды. Әлеге кырның өй урыны кадәр генә жирендә аның шәхси кишәрлеге бар иде. Аны зурайту Әхнәфнең исенә дә кереп карамады. Ә ул сиздермичә генә кинәйгән, кинәю генә түгел, бер-бер артлы кишелләр дә калыккан. Кишелләр шул кадәр үскәннәр, ул эш аты булып җигелгән кырның барлык почмакларыннан да күренеп торырлык дәрәҗәдә биегәйгәннәр. Канәгатьсезлеккә охшаш тойгы уята бу, сагайта. Гөнаһ та түгел кебек үзе. "Кишәрлекнең чиге дә, чамасыз жәелә торгач, югала ук язган. Тик Әхнәфнең монда катнашы юк! Дөрес, күрмәмешкә салышты... Дәшмәде... Туктатмады... Аннары бик үтенеп сорагач, нәрсәгәдер рөхсәт бирде... Тора-бара икенчесенә дә рөхсәт бирде, өченчесенә... Берни дә сизелмәде, тормыш үз көенә тыныч кына акты. Ә кырда эшләре гөрләде, аны мактадылар. Һәммәсе үз урынында. Өмет-хыяллар тагын да яктырак. Хакыйкать тә иң югары биеклектә. Дуслар да күп. Эш аты буларак тарткан йөге бермә-бер зурайса, авырайса да, Әхнәф аны яшь чактагыдан да ныграк куәт белән сөйрәде. Шушы бүгенге рәхәт, бүгенге ләззәтле тормыш дәвам гына итсен...

Әмма һич көтмәгәндә бөтенесенең асты өскә килде. Нишләп, ни сәбәпле аның кояшын аяз көнне яшен сукты?! Кайчан башланды соң бу? Төптән уйлап карасаң, Ирек хаклы бит. Чыннан да чикне атлап чыгылган. Кайчан? Бу сорау аңа торган саен аяусызрак һөҗүм итте.

Әхнәф авыр сулап тагын көзге каршына килде. Аның маңгае уртасыннан буеннан-буена тирән җыерчык уза. Ул култык таягын җайлабрак куйды һәм шул җыерчыкны бармаклары белән сыпырырга кереште һәм: «Нәрсәне икегә аерасың соң син?» диярга теләде. Әмма авызы ямьсез булып чалшайды да, ул кабаланып читкә борылды. Әлеге уттай сорауга җавап, бәлкем, күңеленең берәр ерак почмагында яшерелгәндер? Тормыш мең төрле капма-каршы сыйфатлары белән һәркемне үзенчә әвәләп, кайнар мичендә ата, көйдерә-көйдерә пешерә, аннан чыкканда, бөтенләй танымаслык та итә. Тик Әхнәф үзен андыйлар рәтенә кертә алмый. Ул узган гомеренең әле бер чорын, әле икенчесен, күзгедән карагандай, хәтереннән уздырырга тотынды. Әмма, соравына җавап таба алмады. Көннәр, айлар, еллар, вакыйгалар, шатлык-борчулар җилдәй искән дә искән, дәрья суларыдай аккан да аккан. Эчеп исергән кешегә берни кирәкми, бөтенесе житеш, ул ләззәт томанында тирбәлә, аның дөньяга сизгерлеге югала. Алайса ап-ачык сорауга, күпме вакытлар җавап эзләп тә таба алмагач, тормышның иң зур өлеше эчмәгән килеш бүтән төрле исереклек белән үтте микәнни?! «Тукта, Әхнәф!»—диде ул шунда үз-үзенә. Аның зиһене ачылып китте. Баш катырган сорауга җавап табыла бугай. Күрмәмешкә салышу... Ризалашу... Рөхсәт итү... Менә кайда ул хәтәр борылыш! Бер күзәнәктән башланган хәтәр яман шешкә ул бармагы белән килеп төртелгәндәй булды.

... Районны житәкли башлаган дәверләр. Очынып йөргән чаклар. Кул урынында канатлар. Алар икәү генә түгел, егермедер. Әхнәф бик югары күтәрелде, әллә кая, йолдызлардан да биегрәккә атылды. Әнә шул чакта, коточкыч биеклеккә ингәч, як-ягына карауның, гамәлләрен үлчәүнең кирәге калмады. Бик кыска арада эчке пружина йомшады. Аңа барысы да, кояшка туры караган кебек, каш өстенә кулларын куеп, күзләрен кысып карадылар. Ә бит ул йолдызлар биеклегенә сикергәнгә кадәрге тормышында иманыннан, ата-бабалары инандырган юлдан тайпылмас өчен, үзенә иң югары таләпләр куеп яшәде. Ул таләпләрне һәр көн күз уңында тотты, шулар буенча гына эш-гамәлләр кылды. Ә кояш булып алгач, һәркөн вакытында чыгып, хезмәт кырын яктырткач, җылыткач, аңарда бернинди таплар булуы мөмкин түгел иде. Менә Әхнәф теге хәтәр адымның ясалу урынына, ниһаять, барып чыкты.

Кеше биектә туа, туу белән түбән тәгәри башлый. Шундый сәер канунга корылган бу яшәеш дигән нәрсә. Түбән тәгәрәүне туктату өчен, адәм баласы гомере буе, көн саен үҗәтләнеп тырышмаса, упкын читенә килеп җиткәнен сизми дә кала икән...

Әхнәфнең бар дөньяга ишетелерлек итеп, күкләрне чатнатырлык итеп кычкырасы, «Зинһар мине упкынга очудан туктатыгыз!!!» дип оран саласы килде. Әмма ни аяныч, инде туктау өчен беркая да якорь ташлап булмый иде... Ул, җанына урын таба алмыйча, тагын көзге каршына килде. Тураермы бу авыз? Ныклап йөреп китәрме бу аяклар? Тутасының чүәкләрен лаштырлыштыр сөйрәп атлап килгәне ишетелде.

—Әхнәф, берәр нәрсә кирәк түгелдер бит?

—Юк, тути, рәхмәт,—диде ул, ана борылып.

—Алайса мин бройлер чебиләренең ашарларына салып кына керим әле.

Тутасының бу сүзләре Әхнәфкә юри әйтелгәндәй тоелды, йөрәге чәнчешеп куйды. Ул хәлсезләнеп кәнәфиенә барып утырды. Ничә көннәр буена ишек алдында шул мәхлукларны күзәтә торгач, ул аларны үзеннән өстенрәк дип тапты. Чебиләр барысы да диярлек аксаклыйлар, аксакласалар да, йөгерәләр. Ә менә ул култык таякларына таянып та көчкә йөри. Әхнәфнең аларга үз гомерендә бер мәртәбә дә күз төшереп караганы юк иде. Туктаусыз тыгынуларына хәйран калды. Чебиләр өреп кабарткандай күперәләр, көчхәл белән ауман-тәүмән атлыйлар. Берничәсе тәгәрәп үлгәч, Фәһимә районның баш ветврачын чакыртты. «Күп ашаудан аларның бавыры таркала,—дип аңлатты ветврач.—Аяклары гәүдә авырлыгына түзә алмыйча имгәнә. Йомыркадан чыгуга, ай үсәсен көн үстерү өчен, чебиләрне төрле препаратлар, ясалма ризыклар белән туйдыралар. Бавыр, табигый булмаган бу коточкыч йөкне күтәрә алмыйча, тузып мунчалага әйләнә. Ә чеби ашый да ашый. Инерция буенча...»

Әхнәф йокымсырап китте, бер генә мизгелдә төшләнеп алды һәм сискәнеп уянды. Төшендә әллә нинди гыйфриттәй зур бройлер күрде. Күз ачып йомган арада анын гәүдәсе кабырчык белән капланды, муены болытларгача сузылды, коточкыч зур авызында ул шатыр-шотыр китереп нидер чәйнәде дә, кояшка үрелеп, аңа очлы тешләрен батырды... «Динозавр!» дип уйларга өлгерде Әхнәф. Уянгач, ул бу саташудан үзенчә мәгънә эзләде. Динозаврлар миллион еллар элек җирдә яшәп юкка чыкканнар. Ясалма рәвештә барлыкка китерелгән бройлерлар алардан ничек аерыла? Ә Әхнәф үзе? Аны да кемнәрдер ясады, кояш итеп күтәрде түгелме соң? Мутантлар, клоннар, тагын әллә ниләр... Ясалма җан иясләре, ясалма гамәлләр, ясалма хис-тойгылар... Ясалма ризыкларга күчеп, кешелек үзе дә бройлер кебек симерә бара. Тьфү, дип төкереп куйды Әхнәф. Ясины чыгылган, язмышы хәл ителгән, бройлерлар, динозаврлар гына җитмәгән иде. Тычкан, тишегенә сыймаса, койрыгына тукмак тагар, дип хак әйтәләр ахрысы. Хәзер аңа хурлыгыннан мамык җебе белән әремгә асылынырга гына иде югыйсә...

## 12

«Таң йолдызы» кафесы каршысындагы машиналарның санына чыкмалы түгел. Алар килә тора, кулларына чәчәк бәйләмнәре тоткан кунаклар бинанын икенче катына күтәрелә бара. Ирекләр дә бергәләп туй залына үттеләр. Биредә җирен-күген тоташ шатлык алган. Елмаеп-көлеп күрешүчеләр, айкояштай балкучы йөзләр, төркем-төркем булып әңгәмә коручылар, куллардагы, өстәлләрдәге күзнең явын алырлык аллы-гөлле чәчәкләрдән таралган хуш исләр, табындагы авыз суларыңны китерерлек ризык-нигъмәтләр, стенатүшәмнәргә асылган шарлар, көмеш люстралардан түгелүче нурлар, колакларны иркәләүче ягымлы музыка, күзгә чагылып-чагылып кына алган тагын әллә нәрсәләр—һәммәсе дә бер могҗиза булып берләшеп, башларны әйләндереп, исертеп җибәрделәр. Айгөл белән Таһир, кояштай балкып, аларны каршы

алдылар, берәм-берәм кочаклап үптеләр, рәхмәтләр укыдылар, йөзләреннән ташып торган бәхет нурлары белән коендырдылар. Кызының Зәнфирәне кысып кочаклавын, аның колагына пышылдапниләрдер әйтүен, шактый вакыт яңагын Зәнфирәнең яңагына терәп торуын Ирек тын да алмыйча күзәтте, шул чакта бөтен тәнен рәхәтләндереп җылы агым йөгереп узды... Аннары башкалар белән күрешеп-тәбрикләшүләр китте, хисләр хискә, уйлар уйга сарылды, гүя һәрбарчасын бер дәү сихри каекта җырлы-моңлы дулкын талгын гына тибрәтергә кереште. Зал ай-кояштай йөзләрдән балкый, әчкерсез күрешүләрдән, күңелләргә мөлдерәп тулган шатлык хисләреннән, колакны иркәләүче әңгәмәләрдән гөрләп, корт иледәй гөжләп тора. Бөтен җирдән гөлләр тама, сихри нурлар коела, мәхәббәткә мәдхияләр укыла, бәхет җырлары яңгырый. Ирекка могҗизалы бер төш кенә күрәдер кебек тә тоела, аннары тагын моның чынлыгына ышана. Бу, әнисе әйтмешли, бисмиллалы көн, күңелләрне җилкендергеч ак җәймәле көн, бәхеткә мәңгелек сәфәрнең башы бу. Аны Ирекләрнең үткән гомерләре, үткән еллары юлдаш булып озата бара... Бәхетле, тылсымлы, җылы бу ыгы-зыгы мәңге дәвам итәр кебек.

... Ирек үзе дә, үзе дә түгел иде, ул бәхет-шатлыктан исереп елмайды да елмайды. Тәне изрәсә дә, зиһене торган саен ачыла, кайнарлана барды һәм туктаусыз бер нәрсәне искәртте: гомерләренең яңа дәвере башлана! Ул, шуны әйтмәкче булып, Зәнфирәгә карый, хатыны Ирекнең ни әйтергә теләгәнен аңлый, күзләреннән очкын сирпеп елмая. Ирек аның энҗедәй тезелгән тешләренә, чем-кара чәчләренә карап соклана, кешеләргә нидер эшләргә әзер торучы, үзен коткарып калган бу изге җанның кайгыртучан кулларын йомшак кына учына ала, үбәргә әзерләнеп, өскә күтәрә башлый, әмма Зәнфирәнең куллары карыша, шунда алар күзгә-күз төбәп сүзсез генә аңлашалар, бу гамәлнең башкаларга кылану булып күренәчәген сизеп тыелалар, әмма ярты юлда өзелгән бу үбүнең кайнарлыгын, ихласлыгын икесе дә тоялар һәм ул чынга ашмый калуы белән тагын да татлырак, кадерлерәк булып хәтерләрендә сурәтләнеп кала.

Өстәлләрдә чәчәкләр артканнан-арта бара. Аларның ак, кызыл, зәңгәр, ал, шәмәхә, күгелҗем, тагын әллә нинди күз камаштыргыч төсләре сихри нурлар белән каелган парчаны хәтерләтәләр, ул парчадан таралган хуш исләр залда талгын музыка белән бергә рәшәдәй тетрәп тора. Менә кемнәрдер аларга ап-ак лалә гөлләр китерде. Ирек белән Зәнфирә, яңакларны яңакка куеп, йөзләре белән шул чәчәкләргә терәлделәр. Лаләгөлләрнең салкынча таҗлары аларның иреннәрен, битләрен, маңгайларын иркәләде.

—Кар исе килә,—диде Зәнфирә шыпырт кына.

—Ник икәнен әйтимме соң?

Алар йөзләрен лаләгөлләр арасыннан алдылар да бераз кунаклардан читкәрәк киттеләр.

—Ни өчен?

—Бу ак чәчәкләр кайчандыр өзелеп калган бәхетебезне искәртәләр...— Ирекнең бу сүзләреннән Зәнфирәнең озын керфекләре сискәнгәндәй дерелдәп куйды.—Хәтерлисеңме теге яңа ел төнен? Мамык карлар яуган тылсымлы кич, чуар кар пәрдәсе аша чабучы кыңгыраулы пар атлар, яшел чыршылар, гирляндалар. Ак моң булып кунган кар бөртекләре... Мин сине карлы авызым белән үпкән идем... Әхнәфләр белән яңа ел каршыладык... Әмма...—Ирек туктап калды, Зәнфирәнең күзләре дымланганын күреп, сүзен ашыктырды:— Без шунда өзелеп калганны дәвам итәбез. Бүген—ак кояшлы шул яңа елыбызның дәвамы...

—Чыннан да,—дип кушылды Зәнфирә.—Бу ак чәчәкләр шул чактагы хыялыбызга охшашлар...

—Яңа еллар, үткән еллар офыгына бәрелеп, киләчәккә кайтаваз булып яңгырыйлар. Без бүген яңа вакыт бусагасын атлап чыгабыз...—Ирекнең сүзләрен бүлеп, тагын килеп күрештеләр, Зәнфирәнең кулларына алсу

гладиолуслар тоттырдылар.—Газап-әрнүләребез калсын иде...

—Хәерле кич!

Аларны уртак фикер агышыннан бүленергә мәҗбүр итүче бу тавыш Сөембикәнеке иде. Ул яшәреп киткән, битләре алланып тора, иреннәренә елмаю эленгән, кулында кызыл канәфер чәчәкләре. Зәнфирә аны кочаклап алды, аннары алар бер-берсенә мондый вакытта әйтелә торган мактау сүзләре әйтештеләр. Ирекне аларның ихласлыгы, кунаклар алдында сынатмаулары куандырды, моның өчен ул аларның икесенә дә рәхмәт укыды. Шунда Сөембикә капыл гына Ирекә борылды һәм алар шактый вакыт бер-берсеннән күзләрен ала алмыйча тордылар. Моны Зәнфирә дә, башкалар да ачык күрде. Аларның күз карашларына ифрат та күп нәрсә сыйган иде... Ирекнең Сөембикәне инбашларыннан иркәлисе килде. Ул да бу дөньяның бәхет өчен яратылган бер баласы ич. Бәхетне татып карау, аңа ия булу өчен ул да үзенчә тырышты, әмма тормыш дулкыны аны гел читкә какты, әрнүле юшкыннар гына калдырды. Ничек кенә булмасын, алар бу якты дөньяга Айгөлне бирделәр, аны Сөембикә ялгызы үстерде, кеше итте.

Алар янына ике кулына да чәчәкләр бәйләме тоткан Фәһимә килеп туктады. Ул бәйләмнең зурысын Сөембикәгә сузып:

—Балаларның да, үзебезнең дә шушы чәчәкләр кебек матур яшәве өчен!—диде.

Елмаюында күпмедер көчәнү сизелсә дә, бу аның тарафыннан эшләнгән олы игелек буларак кабул ителде. Барысы да аны хуплауларын белдерделәр, рәхмәтләр укыдылар. Әллә кай арада килеп чыккан Зирәк аларның дүртесен бергә фотога да төшереп алды. Ирекнең Фәһимәгә ниндидер ягымлы сүзләр әйтәсе килде, ләкин андый сүзләр таба алмады. Әхнәфләр белән ике арадагы дуслык җепләренең өзелүе, ике якның да бер-берсен гаепләүләре соңгы елларда Ирек өчен йөрәгеннән кан саркыткан авыр җәза булды. Менә бит, язмыш ике якның тормышын аерып җимерелгән күперне кабат ялгау өчен аларның балаларын якынайтты, шушы гаделсезлекне бетерүне аларга йөкләде, ахрысы. Барысы өчен дә яшәүнең яңа дәвере башлана! Ничек кенә булмасын, яшәешнең узганы да, бүгенгесе дә әрну-сызлануларына, бәргәләнүләренә дә карамастан, искиткеч матур, татлы һәм кадерле!

Ирекләр ашыгу-кабалану заманына туры килделәр. Аларга хыялда көйрәүче офыклар бик якын тоелды. Алар хыялланганнарына тизрәк барып җитү өчен ашкындылар, вакыт-вакыт аяусыз кыландылар, усалландылар, вакландылар, эш-гамәлләрен биектән торып бәяли алмадылар. Хыялый офыклары җирдән күтәрелмәде, үзләре дә, җәйге рәшә кебек, гел җиргә ятып йөгерделәр, җирнен ис-тәмнәрен тойдылар, шуңа канәгать иделәр.

«Ак бәхетләр телибез!» Әллә шул теләкнең чын төсе итеп, кунакларның күбесе гел ак чәчәкләр алып килгән иде. Ә алар Ирекнең хәтерен мамык карларга күмелгән теге яңа ел кичәнә сөйрәделәр. Ул кичнең карлары әллә кайчан эреп диңгезләргә җиткәндер, парга әйләнеп кабат кар булып яугандыр. Барлык әйберләргә дә вакыт тузаны сара, диләр. Вакыт дигән нәрсәнең дә карлары ява микән? Явадыр. Күктән төшеп җиргә яткан карлар, язын шифалы гөрләвекләр булып, җирне яшеллеккә күмә. Вакыт карлары эрегәндә исә, һәр әйберне сиздермичә генә ашыйдыр-ашыйдыр да мәңгелеккә озатадыр... Бу җирдә Ирекләрнең эзләре калырмы? Әллә вакыт аларны, эрегән карлары кебек, эзсез генә мәңгелеккә озатырмы?

Уйлары Ирекне исертеп, әллә нинди дөньяларга, ерак үткәннәргә алып китте. Узган гомерләрнең, вакытның ерак офыкларына бәрелеп, бүгенгедә яңгыраган кайтавазы шушы түгелмени? Кызык та, гыйбрәтле һәм мәгънәле дә! Язгы гөрләвекләр ындырлардан, таулардан шаулап Ыкка төшкән, аның бозларын күтәреп, суларын ярларыннан чыгарлык итеп, куәтле бер ташкын хасил иткән кебек, аларның уртак бәйрәменә күпме якыннары җыелган! Бу бәхет түгелмени?! Уйлап карасаң, адәм баласының югалтулары никадәр күбрәк

булса, ул тапканнарының аз гынасына да чиксез куана, шөкерана итә икән. Кеше югалтулар ачысын татымаса, бөтенесе дә житеш, теләгәнчә булса, ул беркайчан да канәгатьләнми бугай... Әгәр теге яна ел киченләге хыяллары өзелеп тә, кабат ялганып та, әллә ни кадәр четрекле, жәрәхәтле еллар кичелмәсә, Ирек белән Зәнфирә бүгенге бу көннен ни дәрәжәдә тантаналы, ни дәрәжәдә кадерле икәнлеген аңларлар идемени?!

Шул чак ишектән әниләре килеп керде. Аны ике ягыннан Таһир белән Айгөл житәкләгән иде. Нинди олпат аларның әниләре! Ул тан алсулыгын хәтерләтүче озын алсу күлмәк, анын өстеннән яшел бәрхет камзул кигән. Камзулының якалары, ялаулары, жин-итәк очлары алтын жепләр белән каелган. Башындагы яшел калфагы көмештәй ялтыраучы эре сәйләннәр белән нәкышьләнгән. Калфак өстеннән ябынган ак ефәк шәленен чуклары тез турына ук житә язган. Тышкы кыяфәте, үз-үзен тотышы белән ул бөтенесенен уртак анасын хәтерләтә иде. Аны күргәч, барлык кунаклар, тылсымлы таяк хәрәкәтенә буйсынгандай, аягүрә бастылар һәм кул чабарга керештеләр. Акыллы иде аларның әниләре, зирәк иде! Һаваланып кукрәгән дә киермәде, түбән дә иелмәде. Йөзеп кенә баргандай, чәмчәле читекләре белән түргә таба атлады, кунакларны сизелер-сизелмәс кенә баш иеп тә, илаһи карашы белән дә сәламләде, ак шәле астыннан чу..пыларының чылтыравы ишетелеп калды. Әниләре түргә узуга, барысы да дәррәү урыннарына утырыша башладылар. Мәлс белән Нәфисә, аларның Алмазы, Гөлназ, Ирекләр, Сөембикәләр әниләрен уратып алдылар. Ул һәркайсына тәмле сүзен тапты, изге теләкләрен теләде. Аннары, «Барыгыз инде, балалар, утырышыгыз», диде дә Ирекне кулларыннан тотып туктатты. Менә әнисе учы белән анын беләкләрен сыпырырга кереште, үзе иреннәре белән генә пышылдап туктаусыз нәрсәләрдер укыды. Ирекнен кулларын кысып-кысып куйды. Әнисенен кул жылысы аның бөтен тәненә таралды. Бу жылы бала чактан ук таныш, искиткеч сагындырган иде. Ирекнен күзләренә яшь тулды. Ниһаять, әнисе анын кулларын жибәрде, әмма Ирек кузгалып китә алмады, нишләптер телсез-өнсез булып басып тора бирде. Ул әнисенен олпат гәүдәсенә, тантаналы йөзенә, каядыр бик тә, бик тә еракка төбәлгән кодрәтле күз карашына йотылып карады. Анын йөзендәге жыерчыклары, каш-керфекләренен, иреннәренен тибрәнеп-тибрәнеп куюы күнелендә ниндидер кайнар, гайре табигый хәрәкәт барганын сөйлиләр һәм әнисенен аны башкару өчен ифрат та зур көч салганлыгы сизелә иде. Ирек анын кин ак мангаена вак кына тир бөртекләренен бәреп чыгуын да күрде хәтта. Әнисе ана ым какты. Бу—анын хәер-фатиха бирүе иде. Ирек күнеленә мон, күзләренә яшь тулган хәлдә Зәнфирә янына барып утырды һәм тагын әнисенә борылып карады. Күз яшьләре аша ул бераз калтырабрак күренде, аннары тоташ түгәрәккә әверелде, чит-читләре көмеш белән өретелгән алсу-яшькелт кояш рәвешенә керде... Ирек шул чак бөтен тәнен кымыржытучы бер жинел, нәфис дулкынга эләккәнен тойды. Бөтен гәүдәсе эреп юкка чыккандай жиңеләйде, йөрәге дәртләнеп тибәргә кереште. Ана әйтеп бетергесез рәхәт иде. Бу нинди тылсым? Ни булды? Ул үзенә ниндидер көч ингәнлеген аңлады...

Ирекнен зиһене ачылып, яктырып китте. Бу яктыру әллә нинди серле, туктаусыз биеккә, югарыга күтәрелә баручы яктыру иде. «Рәхмәт!» диде ул эченнән генә. Ирек моны язмышка әйттеме, теге көчкәме, әллә башка берәүгәме—үзе дә анык кына белмәде. «Кичерегез, барысы өчен дә кичерегез!» дип пышылдады. Теленә бу сүзләрнен нинди кодрәт белән килгәнен һәм аларның кемгә мөрәжәгать ителгәнен Ирек шулай ук белмәде, күрәсен, монын әһәмияте дә юк иде. «Рәхмәт!»—бусын янәшәсендәге Зәнфирәгә юллады. Аннары чак кына арырак утырган Сөембикәгә ялварып карады: «Кичер, кул күтәргәнем өчен кичер!»—диде ул эченнән генә. Ана Сөембикәнен үзенә караганда бәхеткә хакы күбрәк тоелды, Ирек хәзер шулай теләде. Инде бөтенесе урыннарына утырганнар, менә-менә мәжлес башланачак тантаналы

мизгелләр иде бу. Ирек табындагыларны рәттән күзеннән үткәрде. Нинди сөйкемле, күркәм, мәртәбәле аның кунаклары! Алар Ирекләр хыялланган, өлешчә шуңа ирешеп тә, ирешә алмаганнарын балалары тормышка ашырсын иде, дигән изге ният белән уртак мөнбәр астына җыйналдылар. Ирек бу минутларда алар өчен үзен корбан итәргә әзер иде. Алай гына да түгел, җирдәге барлык кешеләр өчен гомерен бирергә әзер иде. Шушы олы теләген кычкырып әйтмәве, яшертен генә кичерүе аңа нинди дер бер рәхәтлек бирде. Ул бәхет шәүләсен аермачык сизде. Ул шәүлә Айгөл белән Таһирны кавыштырган илаһи көч тарафыннан Ирекнең дә күңеленә иңдерелә иде... Әлеге көч, соңарып булса да, Ирек белән Зәнфирәне дә актык сулышкача бергә кушкан иде. Ирекнен һәр көне Зәнфирә белән башлана, аның белән дәвам итә, аның белән тәгалләнә, яшәү уты аның газиз кулларында яна иде...

Кемдер аларның турына зәңгәр кыңгырау чәчкәләре китереп куйды. Алар чәчәкләргә сокланып карап тордылар да, сүз берләшкәндәй ялт борылып, бер-берсенә төбәлделәр, озак итеп, бернинди сүзсез, күзләре белән генә сөйләштеләр. Дымланган керфекләр уртасында елтыраучы күзләрдән узган гомерләрнен, яшәлгән елларның дәверләр офыгына бәрелгән кайтавазы сирпелеп-сирпелеп түгелде... Ирек акрын гына әллә нинди кайнар эчке тавыш белән аның колагына пышылдады:

Соңардым, кирәкми, димә син,
Алар бит шыттылар җанымнан.
Сөюебез сагышы бөркелә
Яшьлекнең мизгеллек ярыннан...

Зәнфирә, нәрсәнедер хәтерләргә теләгәндәй, бер генә мизгелгә күзләрен йомып алды да йөзен Ireккә якын ук китерде һәм аның кып-кызыл матур иреннәре хәрәкәткә килеп, ягымлы тавышы яңгырады:

Китмә син! Соңгы кат кул сузам,
Өзмәче бәгырьне, кал туктап!
Кал зинһар! Кул җылың тоюга,
Яшь түгәр бу гөлләр шатлыктан...

Зәнфирәнең күзләре якты нурлы, гайре табигый елтырыйлар иде. Ирек бу күзләрдә үзенең шәүләсен күрде һәм ул тормышында Зәнфирәне очраттырган көчкә, аның белән бу дөньяда бик азга гына булса да бергәләп яшәве, менә хәзер янәшәсендә утыруы өчен рәхмәт укыды һәм үзен жир йөзендәге иң бәхетле кеше итеп тойды...

*2005 ел.*



Мөдәррис
Әгъләмов

## ИЛ ҖАНЫНА—ШИГЫРЬ КАКТЫ

* * *

**Истәлекләр...
Истәлекләр алар күп төрле,
Истәлекләр алар күп кала—
Бер истәлек булып әнкәмнең
Чиккән сөлгеләре саклана.**

**Чиккән сөлгеләре саклана,
Бизәге лә аның бизәге—
Карый сыман миңа бизәктән
Әнкәемнең нурлы күзләре.**

### Кош

**Йоклыйлар усаклар тынлыкны нык саклап,
Йоклыйлар каеннар бер-берсен кочаклап.**

**Тын гына атлыйм мин, атлыйм мин сукмактан,
Урманым төшлеккә кошларын йоклаткан.**

**Бары бер кош кына йокламый нигәдер.
Бер үзе—ни ямь бар, ни шатлык, ни кадер?**

**Күрәсең аңарда бик нечкә бәгырьдер...
Ул кошлар илендә, мөгаен, шагыйрьдер.**

* * *

**Каен суы дәште аңа язын:
—Эчеп кал син, дускай, мин бетәм.
Чишмә челтер-челтер тәкрарлады:
—Эчеп кал син, мин бит, мин китәм.**

**Ә ул салкын җиргә чалкан ауды:
—Сез каласыз, дуслар, мин китәм.**

* * *

*Шатлыклар да уртак безнең,*
*Сагышлар да...*
*Ике яр эченнән аккан*
*Бабичлар да.*

Чабаталар сатып яшәсәк тә,
Сатып яшәмәдек ямманат...
Казаннарда Канкай батыр булса,
Уфаларда булды Салават.

Ил өстендә патша торганда да,
Саналсак та анда без ятим,—
Илне саклаганда кимсетмәдек
Татар белән башкорт милләтен.

Париж урамының ташларына
Басып йөрде безнең атыбыз;
Патшаларында да эшебез юк,
Ил алдында чиста халкыбыз.

Бер оранның кайтавазы булып
Гомер кичерәбез илдә без...
Бер урамның ике ягы сыман,
Карашыбыз һаман күзгә-күз.

Кем белә бит, бәлки күрешкәндер
Канкай батыр белән Салават...
Кул хезмәтен сатып яшәсәк тә,
Сатып яшәмәдек ямманат.

* * *

Кем белә, килер көннәрдә
Кемнәр диярләр кемне?
Кемне хәтергә алмаслар,
Күккә чөярләр кемне?

Кем белә, беркем дә белми...
Кем дә белми—шуңа без
Ижат итәргә, яшәргә,
Көрәшергә киләбез.

* * *

*Х. Т.-га*

Төн буе утырасың,
Офыкта таң икән;
Максатың өстенә
Тамчылап там икән.

Үзеңне гомергә
Бер төскә ман икән;
Бозларга ауганчы,
Утларда ян икән.

Бу кемгә кирәк, дип
Җаныңны кыйнама,—
Дусларың уйлана,
Дошманың уйлана.

Әйтсеннәр: «Тынмаган
Ул нинди җан икән?»
Шигырьләр сыктым мин,
Кан икән, кан икән.

* * *

Шигырь язу—татлы җимеш түгел,
Катмарланып беткән нык тамыр;
Шул яшәтә, шул яшәртә телне:
Тамыр кипсә—яшәү тукталыр.

* * *

Күкрәк ачып, таштан-ташка басып,
Урал тавы буйлап йөгерәм,—
Күкрәгемә сыймас дулкын алып
Килдем Иделдән.

Йөрәгемдә бары сезнең өчен,—
Шулай агып чыккан чишмәләр
Күңелемә кабат керәләр дә
Җырга күчәләр.

Тауга менеп хакыйкатьне ачтым,—
Минә алмас таулар булмады.
Иң биек җыр,
Иң биек җир икән—
Әнкәң яткан кабер туфрагы.

* * *

Аргы якта кемдер учак яккан,
Аста актарыла Агыйдел.
Хәсән Сарьян әйтә:—Бәлки ул да
Безнең утка текәп карыйдыр.

## Шул кояшта

Җан җылысын мин кояштан алдым,
Кояш төште гомер юлыма;
Шул кояшта җиләге дә пешә,
Еланы да чыгып җылына.

* * *

*Язмышлар тудырмый ялгышны.*
*Ялгышлар тудыра язмышны.*
Зөлфәт

Без—күп кырлы
Без беләбез үзебездә
Нинди төсләр, ничә төр моң-тавыш барын;
Башкаларның кимчелеген Ходай язган,
Ә кем язган үз-үзенең ялгышларын?!

* * *

«Үс! Үс! Үс!»—дип апам сөя—
Теләге зур, үс кенә!
...Халык батырын—үстерә,
Батыр—халкын үстерә.

## Сагыну

Кеше үзе белми...
Әмма тели
Әрнүләрне, әрнетүләрне—
Ә соңыннан үзен әрли-әрли
Әрнеп сагына шул ук көннәрне.

* * *

*Ятим балачагыма*

Башыңнан сыйпап юату
Иде, юкса, уем;
Үреләм еллар аркылы,
Үреләм, җитми буем.

## Су йөгергән

Хәзер цирк. Ә бит ул урында
Булган икән мәшһүр тегермән...
Шул тегермән рәхәт кичергән ди
Су көченнән әйләнүеннән.

## Ул кала

Илне, телне саклармын дисәң—
Син китәсең—ул кала исән...

* * *

Кайгыңны да, шатлыкларыңны да
Бүләр кешең барын сизәсең,—
Күз яшьләре аша күрсәң генә
Аның күзләрендә күз яшен.

* * *

Тәннәрем чемердәп китә
Тешләп алсаң чак кына;
Чага калсаң, бал корты күк
Шифа биреп чак кына!
Бер-береңнең барлыгына
Сөенеп яшәр чак кына...

* * *

*...Гел әзер бул..*

Сыеп беттек, дип сөенмә
Заман кысасына.
Гел әзер бул
Кабат-кабат
Яман кысасына...

* * *

Үз чамамны үзем беләм,
Үз туганым—җирдә үлән.
Яшәү үзе бәхет бит ул
Яшел үлән белән.

## Мәскәү хыялы

Татар да ава-түнә
Килеп баскан икән, имеш,
Милләтсезләр рәтенә.

* * *

*Ирек мәйданы артында*
*...сессия тыңлаганда*

И кайтасы килә кайчагында...
Орчык хәтле затлы чагыңа,
Әти-әни үз исемең белән
Кочып алган затлы чагыңа,—
Шунда гына бөтен төсләр
Үз мәгънәсе белән чагыла.
...Депутатлар, әнә, йомгак сүтә
Җепнең очын тапмыйча гына.

* * *

Ярты гасыр гомер акты—
Тулыр-тулмас,
Ил жанына шигырь какты—
Кылыр-кылмас...
...Яшәү белән шаккаттырып
Булмаганны,
Үлем белән баш катырып
Инде булмас!

* * *

*Прощай, немытая Россия.*
М. Лермонтов

Рәсәй ул—шомлы бер аваз
Йөрәкне яра торган,—
Сөештән яратылмаган,
Сугыштан яратылган...

Юкка гына гербына
Кара кош куелмаган.
Лермонтовны искә алып,
Җиңел сулар микән халкы:
«Хуш!—диеп,—юылмаган!»

## Хәсрәт

Дөньясын һәм үзеңне
Китәсе килә ташлап,
Яшьлек елаган чагында
Үзен-үзе кочаклап.

* * *

Башың иелгән дисеңме!
Иелмичә? Иелер!
Гомерең буе озата
Үги ана, Үги ил!

Сабый чагымнан хәтердә
Эт кояшы иң элек;
Башың иелгән, дисәң дә,
Иелмәгән... үгилек!..

## Шул бер сорау

Без бүгенгә сулар кичеп килдек,
Без бүгенгә килдек утлар кичеп.
Киләчәккә дә без барачакбыз,
Әйе, барачакбыз!
Әмма ничек?
Әмма ничек? Гади шул бер сорау,
Шул бер сорау—
Әйтерсең лә, борау.

* * *

Кар астында кайнарланып
Тетрәнгәндә яшеллек;
Күпме җаннар китеп бара
Яшеллектә яшим дип.

* * *

*Авыруы—авыр...*

Биеклек авыруы бар,
Бөеклек авыруы;
Хет нәрсә генә дисәң дә
Бик авыр авыруы...

* * *

*Зәки Зәйнуллинга*

Аңарда гайярьлек бар,
Канатын җәярлек бар.
Туган җиренә төбәлгән
Тарихи сәйярлек бар.

* * *

Чирәмгә бастым... Кузгалак,
Язгы язма юасы;
Тукай шигырьләре белән
Бары йөзне юасы.

## Казан сабан туе

Сөйләшеп тә ирек алып булмый,
Булмый алып канга батып та,—
Рәсәй патшалары акча эзләп,
Башын тыккан чакта катыкка.

Минем халкым кайдан акча тапсын,
Казаннан соң акча сукмады.
Сабантуйда мәйданнарга чыкты,
Илдә кан түгәргә чыкмады.

* * *

Җирле халык файдаланса
Җир байлыгын гына...—
Үзе,
Сүзе,
Йөзе аның
Икмәк булып уңа.

Әгәр дә ул
Мең яшәп тә
Җирендә булса кол—
Аның өчен, татар өчен
Кирәк түгел акыл.

Андый кавем өчен хәтта
Иртә белән кояш:
Моны җылытмам микән, дип,
Чыгар кыяр-кыймас.

* * *

Бетермәгез татар шигърияттен,
Такташ кебек
«Такташ үлде»,—диеп башлагыз...
Әгәр кодрәтегез җитми икән—
Ташлагыз!

*1958-2001*

Рәфкать Кәрами

# ОЛЫ ЮЛ ДА СИКӘЛТӘЛЕ

РОМАН

## XVIII

Габделнур туган авылының елдан-ел үзгәрүенә, капка-коймаларның төзеклегенә,шул ук вакытта бертөрлерәк рәвешкә керә баруына да игътибар итте. Элек, ул бәләкәй чакта, таш коймалар да бар иде, жил капкалы өч рәт киртә тотылганнары да, хәтта буйлай яисә утыртма читәннәр дә. Ә элекке байлардан калган ихаталарны калын тактадан буйлай жибәргән койма белән юан имән баганалы урыс капкалар әйләндереп алган иде.

Әйе, капка-коймалар янартыла, соңгы елларда салып кергән өйләрнең түбәләре калай да шифер, хуҗалыкта кирәкле абзар-кураныкы—рубероид. (Авыл халкы аны түл дип йөртә.) Дөрес, араларында инде тузган-искергән йортлар, хәтта кадакланган тәрәзәле, капка төбенә үлән үскән өйләр дә күренгәли. Телевизор антеннасы, су колонкасы кебек әле кайчан гына халыкка ят булган әйберләр дә авыл пейзажының аерылгысыз бер бизәге булып тора. Бакчаларда алмагачлар ишәйгән...

Әбисе өенә барып житкәнче Габделнур байтак кына авылдашлары—олысы-кечесе белән күреште. Нинди якын иде алар солдат егет өчен! Туган авылын урамыннан атлау, кечкенәдән үк син белгән, сине таныган кешеләр белән хәл-әхвәл белешү рәхәт. Өч урамлы, зур авыл булса да очраган һәркем таныш... Хәер, болай әйтү чынбарлыкка хилафлык китерү була икән. Чөнки ул үз чордашларын, өлкәннәрне генә белә, ә үсмерләрне, бала-чагаларны тануы ана авыр иде. Ул укырга киткәндә (өеннән бер чыгып киткәч, Габделнур йә каникулга, йә ялга дип вакытлыча гына кайткалады) сигез яшьлек булган малай-кызлар бүген уналты яшьтә икән бит инде. Шулай булса да ана ифрат якын иде алар.

Әбисенең өе авылның бизәге үк булып тормаса да, һәрхәлдә, үз заманы өчен ярыйсы гына иде. Хәзер исә биек, юан кәүсәле тупыл агачлары арасында монаебрак, үзенең искерә баруыннан читенсенгәндәй оялыбрак утыра сыман. Тупылларның да берсе үзенең яшәү дәверен очлаган—корыган. Ишек алды нәкъ элеккечә: ямь-яшел чирәм, арба эзе юк, абзар тирәсенә илтүче сукмак та чак кына шәйләнә. Шомырт агачлары кыйбла якны бизәп утыралар (ләкин болар—эт шомырты, жимешен ашамыйлар, анардан малайлар язар өчен кара ясыйлар иде), алар янына карлыган куаклары елышкан, чәнечкеле крыжовниклар читтәрәк. Сул якта, түрдә, озын сиртмәле коеның баганасы бер якка кыйшайган. Сиртмәнең иң очына кунган саескан бер дә курыкмыйча озын гәүдәле, яшел киемле солдат абыйсына тасраеп карап торды да, ишләренә яна хәбәр житкерү өчен очып та китте.

Әбисе тумышы белән күрше авыл кызы иде, ул ишле, ләкин хәлле генә гаиләдә үскән. Туган авылында, төп йортта, абыйсы яши иде, мәрхүм инде.

*Дәвамы. Башы алдагы саннарда.*

Габделнурның аны монда да күргәне бар, үз авылларына да барып чыккалады. Алагаем зур гәүдәле, эре сөякле, көрәктәй олы куллы, күзләрен челт-челт йомгалап сөйләшергә яратучы ап-ак сакал-мыеклы карт иде ул. Герман сугышында әсир төшкән чакларын, андагы бер алпавытта батрак булып хезмәт иткәнен, немецләрнең нинди рәк халык, тормыш-көнкүрешләре, яшәү рәвешләре ничек икәнен сәгатьләр буе сөйли иде. Аннары әсирлектән качып, гражданнар сугышында кызыллар ягында ел ярым совет власте урнаштырып йөргән. Фәкать каты яралангач кына өенә кайта алган. Сәнәкчеләр сугышы да аны читләтеп үтмәгән.

...Габделнур кергәндә өй эченә туң май исе таралган иде. Казан янында, күлмәк җиңнәрен сызганган, яулыгын чөеп бәйләгән, озын гәүдәсе бераз бөкрәя төшкән әбисе сөзгеч белән олы бадыянга кош теле салып маташа иде. Кайчандыр аркан очлары кебек салынып торган калын кара толымнары хәзер зур көмеш тәңкә тагылган тычкан койрыгы кебек кенә булып калган. Күрше карчыгы да аңа булыша—сәкедәге куна тактасына җәелгән камырны кисү белән мәшгуль.

Габделнур кычкырып сәлам бирде.

—Исәннәрмесез?! Керергә була микән?

Бусагада солдат күренүгә әбисе борылып карады: гаҗәпләнде, күзләрен челт-челт йомгалады, җыерчыклы йөзе яктырып китте, кулындагы әйберләрен кая куярга белмичә бер мизгелгә аптырап калды. Күрше карчыгы да Габделнурның көр тавышына борылып караган иде инде. Аны танып алдылар. Шуннан китте: сөенечле каушау, аптырау, шатлык авазлары чыгарып гаҗәпләнү; онга, камырга, майга буялган кулларын ак тастымалга, алъяпкыч итәгенә сөрткәләү.

—Исәнме, әби.

—И Алла, танымый да торам. Исәнме, улым, исәнме.

Габделнур әбисе белән ике куллап күреште. Әбисе аның кулларын җибәрмичә озаграк тотты, ахры.

Күрше карчыгы:

—Мин дә күрешим инде,—дияргә мәҗбүр булды.

Кара-каршы исәнлек-саулык, юл, Казан, мондагы тормыш-көнкүреш хәлләрен сораштырдылар.

—И, бәхетле авыз булырсың икән, үскәнем,—диде күрше карчыгы.

—Белгән күек, кичәгенәк, бу арада пешергәнем юк, дип тотынганыем,—диде әбисе.—Күршеләргә бәбәй ашы да кертәсем барые...

Габделнур елмаеп:

—Солдатның борыны шулай сизгер була инде аның,—диде.—Синең кош теле пешерәсеңне белеп кайттым.

—Бик рәхмәт, улым.

—Әле бу исәнмени?—дип сорады Габделнур тимер һәм алюмин чыбыклардан челтәрләп үзе үреп биргән сөзгечкә ишарәләп.

—Исән, улым, исән. Ана рәхәтләндем генә.

Күрше карчыгы да сүзгә кушылды.

—Тәм-том пешергән саен сине искә алабыз, үскәнем.

Беразга гына эшләреннән туктап, кунакны олы якка дәштеләр. Аннары, куанычлары эчләренә сыймаган ике карчык, чәч толымына таккан чулпыларын чыңлатып, бүлмә тактасы белән аерып куелган бәләкәй якка чыгып киттеләр.

Габделнур үзе генә калды.

Бу өй—музейны хәтерләтә: борынгы зур сандык, чүпләмле, чигүле кызыл сөлгеләр һәм матча кашагалары, бизәп-сырлап ясалган савыт-саба шкафы, шундый ук бизәкле олы көзге, суга торган, герләр эленгән чылбырлы стена сәгате, киң нарат такталардан җәелгән түшәм-сайгак, туку станы, акшарланган олы мич, иске тимер караватъ, әбисе үзе суккан паласлар... бу өйдә әйбер күп, ә фотокарточкалар юк.

...Кешенең кулы гына нидер тотып эшләр өчен яратылган, ә башы—уйлар өчен. Күрше хатыны, Габделнурны күргәч, үз балаларын күргәндәй шатланды. Әйе, аналар һәрдаим газиз балаларын көтә. Тик алар гына сирәк кайта. Аның да балалары, бәхет эзләп, кайсы кая таралды: олы улы Латвия дигән җирдә балык тота, икенчесе дә армиядән соң читтә калды—Урта Азиядә ком чүлендә трактор белән канал казуда, игезәкләре нефть эзли, бер кызын әзәрбайҗан егете алып китте... «Һай бу тормыш,—дип уфтанды ирен сугышта югалткан, тугыз бала анасы, гомер буе нужа куган хатын.—Балаларның бергә җыелганын күрер көннәр булыр микән, Ходаем?!"

Күп тә үтмәде, пешекчеләр эшләрен тәмам иттеләр, олы җиз самавыр да өйне ямьләп үз урынын алды.

—Улым, утыр әйдә!—диде әбисе олы якка хәстәрләнгән өстәл янына Габделнурны дәшеп.

Әбисенең үз кулы белән әзерләнгән сый-нигъмәт өстәлгә куелган: төш, чәкчәк кисәге, кош теле... Бу бер дә гаҗәп түгел, чөнки әбисе авылда беренче аш-су остасы. Атна саен диярлек кем дә булса аны пешерү-төшерү өчен чакырмыйча калмый. Туй буламы, кунак киләме, Коръән укытырга ашка җыяларммы, яшь киленнәр бәби алып кайтамы—барысына да Габделнурның әбисе кирәк. Беркемнең дә күрше-күлән, кардәш-ыру алдында йөз кызартасы, сер бирәсе килми, шуна күрә хәзинәдә булганның һәммәсен чыгаралар, кысынкырак чакта әҗәткә кереп булса да «кешечә» аш әзерлиләр.

Хәер, әбисе үзе өчен дә пешеренә. Халкыбызның бу борынгы тәмле һәм туклыклы, айлар буена бозылмыйча саклана торган ризыклары аның өендә өзелми иде.

Чәй янында әбисе:

—Улым, йөргән җирләреңдә Әлтәф абыең күренмәдеме?—дип сорады.

Әлтәф—Габделнурның әнисенең бертуган энесе, сугышта хәбәрсез югалган. Әле авылда чакта, сугыш турында кино карап кайтсалар, әбисе гел бер сорау бирә иде: «Солдатлар арасында Әлтәф абыең күренмәдеме?» Чөнки әбиләр кинода артистлар уйнаганын аңлап-төшенеп җитмиләр иде. Әбисе улын гел исән дип өметләнде. Ул аңа кәләш тә сайлап-әзерләп куйган. Бер олы кызны (аңа насыйп ярларның күбесе яу кырыннан кайтмагач утырып калган авыл кызын), Әлтәфем кайтса, шуңа өйләндерер идем, дип әйтә торган иде.

—Юк шул, әби, күренмәде,—диде Габделнур мөмкин хәтле йомшак итеп, әбисенең хәтерен калдырмаска тырышып.

Әбисенең ире дә, ягъни, Габделнурның икенче бабасы да хәбәрсез югала, ләкин аныcы егерменче еллардагы гражданнар сугышы чорында. Авылга аклар килгәч, аны, үз атын җиктереп, олау белән Бөгелмәгә алып китәләр һәм шул китүдән әйләнеп кайтмый. Юкса, аклар урамда күренүгә ул качкан була. Балаларга әйтмәскә кушыла.

Ак офицер кереп:

—Хуҗа кайда?—дип сорый.

Хатыны:

—Ул өйдә түгел шул, күрше авылга китте,—ди.

Ә офицер, хәйләкәр нәрсә, бәләкәй Әлтәфкә күз кысып, елмая да:

—Әтиеңнең кайда икәнен син беләсеңме?—ди.

Сабый олылар кисәтүен үзенчә «үти».

—Безнең әткәй сәке астында юк!

Һәм хуҗаны өстерәп чыгаралар да алып китәләр. Карт атасының, Георгий тәресе кавалеры булган элекке патша солдатының, ялыну-ялваруы да ярдәм итми...

Чәй янында әбисе, үзалдына сөйләнгәндәй, әйтеп куйды:

—Өем искерде, улым. Кияүгә әйтеп караганыем да, ярар диде дә онытты бугай.

Габделнур бераз тын торды, атасыннан узып сүз әйтергә, вәгъдә бирергә кыймады.

Ахырда ул жайлап кына:

—Ярар, әби, уйлашырбыз,—диде.

Шулай да әбисенең шундый зур эш турында анын белән сүз кузгатуы Габделнурның күңеленә хуш килде.

...Габделнур чыгарга җыенгач, әбисе тартыныбрак:

—Улым, күземне карамыйсынмы?—диде.

Габделнур бик теләп риза булды. Әбисенең берничә керфеге күз кабагының эчке ягына карап үсә, күзен кырып аны даими борчып тора икән. Габделнур күз кабагын әйләндереп, аларны бәләкәй эскәк белән йолкыды. Кечкенәдән өйрәнгән шөгылен чыннан да онытмаган икән.

—Ай рәхмәт төшкере,—диде күрше карчыгы.

—Рәхмәт, улым, аяк-кулың сызлаусыз булсын,—диде әбисе.—Әле кая барасың? Кайтасыңмы?

—Юк, келәт арасына. Әти белән күрешмәгән бит әле.

—Улым, электр куыгын да алыштырып куй инде. Бусы нишләптер караңгы яна.

Габделнур олы яктагы лампочканы борып алды да, яңасын беркетте.

...Габделнур әбисенең бәрәңге бакчасы буйлап, тар тыкрыктан югары менеп китте. Бәрәңге бакчалары—авыл халкын иң авыр елларда да ачлыктан коткарып калган бакчалар—быел да муллык вәгъдә итә иде. Бигрәк тә урмансыз, бүтән яктан керем килер җире булмаган авылда бәрәңге—бар карап торган бәрәкәтле ризык. Тик эше-мәшәкате күп инде.

Габделнурларга бәрәңге алу икеләтә авырга туры килә иде, чөнки ике бакча бит: үзләренеке, бу әбисенеке. Әүвәл бәрәңге сабагын йолкыйлар, аннан буразнаны рәттән казыйлар, бераз җилләгәч капчыкларга тутыралар һәм, җилкәгә салып, кайсын-кая ташыйлар: орлыкка дигәнен бәрәңге базына, сатлык эресен—чиннеккә, малларга насыйп буласы вагын—сарайга, кыш ашарга җитәрлек итеп уртачасын өй базына... Шулай һәр елны ике бакча.

Берчакны абыйсы, Габделнур һәм энесе агач көрәк белән әбисе бакчасын казыйлар, авылча әйтсәк, бәрәңге алалар иде. Әниләре дә монда, гадәтенчә булышырга чыккан.

Ул:

—Балалар, бу тирәсе әйбәтме?—дип сорады.

Абыйсы турыдан ярып:

—Әни, ат башы хәтле булып күренәләр инде,—диде.

Икенче вакыт, тагын алар өчәү казыганда, сугыштан гарипләнеп кайткан, бәрәңгесен тизләнеп кенә җыя ала торган күрше абзый чыгып, эшләренә сокланып, карап-карап торды да:

—Котыра буран!—диде.

Чем кара җир, үзе йомшак, коп-коры, өч ир туган агач көрәкләр белән ут уйната иде ул көнне бәрәңге бакчасында...

Элегрәк елларны халык кызгылт төстәге галан бәрәңге утырта иде. Ул озынча, уңышы әйбәт—аны беләккә салып та ташырга була. Аннары сары бәрәңге китте—түгәрәк, кушуч йодрык хәтлеләре була—котырып уңа. Ничәнче елныдыр, хәтерендә түгел, Габделнур бер төптән унсигез бәрәңге санап алды.

Шул күрше абзый:

—Сары бәрәңге—честный бәрәңге!—дия торган иде.

## XIX

Авылның өченче урамына кертмичә юл солдатны ындыр табагына алып китте. Шифер түбәле, озын-озын келәт-амбарлар, өсте ябулы зур рига, машиналар керерлек үлчәү бинасы—барысы да элеккечә икән.

Ул тирә гөр килә: комбайннардан ипи ташучы машиналар тыз да быз чаба, мул булып өелгән көшелләр таудай кабарып тора, агач көрәк тоткан хатын-кыз ашлык җилгәрә, ир-ат машиналарга капчык төйи, бер җилгәргеч

әллә кайларга кибәк очырта, тузан тарата... Кыскасы, гөрләп тора ындыр табагы.

Тагын танышлар, дуслар, абый-апалар, хәтта өлкән яшьтәге әби-бабайлар белән мәктәп балалары да бар иде монда. Габделнур алар белән күрешеп чыкты.

Бер читкәрәк китеп, ике-өч ир-ат белән сөйләшеп торганда басу ягыннан кайтып килүче таныш машина күренде. Габделнур аны йөзләгән машина арасыннан да таныр иде мөгаен. Яшелгә буялган кабиналы, әрҗәсе такта белән күтәртелгән, кабина артына, кул белән тотыныр өчен, торба бөгеп беркетелгән, нумерлары да онытылмаган...

Егет алга таба атлады. Әтисе солдат улы янына житәр-житмәс туктады, кабинадан төште. Башында салам эшләпә, өстендә искерәк кара кәчтүм-чалбар, аягында кирза итек. Чиста итеп кырынган, кызгылт йөзе шат, елмая.

—Исәнме, әти!

Әтисенең куллары көчле.

—Исәнме, улым! Кайттыкмы?

—Әйе.

Илленең өстендә булса да әтисе әле нык, кем әйтмешли, сыендагы ир-ат, таза гәүдәле. Буйга бераз чүккән сыман. Анысы инде Габделнурның төз сыны янында шулайрак күренәдер.

Улы белән бер-ике авыз сүз алышкач, Галләм абзый машинасын көшелгә яны белән куйды. Укучы балалар, бортны ачып кузовка менделәр дә, гәрәбәдәй бодайны бушатырга тотындылар.

Галәм абзый белән Габделнур янына ир-ат жыелды. Алар сөйләшә, ә ата улына карап тора. Кай арада үсеп тә життеләр. Олы улы күптән кайтты. Менә икенче малае да соңгы елын хезмәт итә. Өченчесе әле бер елын гына тутыра. Бер гаиләдән өч солдат! Ата өчен моннан да зур горурлык бар микән?!

Галләм абзый, нидер исенә төшеп, елмаеп куйды. Зурысы армиядан кайткан көнне ул ишек алдында нәрсәдер эшләп маташа иде. Капкадан башына фуражка, өстенә бушлат кигән юка гәүдәле солдат—улы килеп керде. Кулында чемодан, авызында папирос, үзе елмая. Ул, әтисе янына килеп, күрешергә кул сузуга, Галләм абзый үзе дә сизмәстән кычкырып жибәрде.

—Ташла тәмәкеңне! Нәселдә булмаганны!

Әлбәттә, бәлки өч ел күрешмәгән улына алай каты бәрелергә дә кирәк булмагандыр. Чөнки улы армияга хәтле тарту-эчүне белми иде бит, һәрхәлдә, күрсәткәне булмады. Очрашу бик коры килеп чыкты. Соңыннан гына ата кеше болайрак фикер йөртте: «Район үзәгендә урта мәктәп бетерде, кайтышлый классташларын-дусларын очраткандыр, бераз кабып та алгандыр...—Шулай да Галләм абзый олы улының авызында кабат тәмәке күрмәде...—Монысы да тартмый ахры, ис-мазар сизелми».

Габделнурның буй-сынына, киеменә—яхшы китель, үтүкләнгән галифе чалбар, кыска гына козыреклы фуражка, сары аеллы конгырт каеш һәм бераз жыерылып торган куңычлы чиста кирза итекләр—карагач, ирексездән сугышта булган чаклары хәтерендә янарды. Сталинград тирәсендәге сугыш афәтләре, яралану, унсигез көн лазарет дигән сарайда гөбедәй шешкән аягын кузгата да алмыйча бет ашатып яту... Саратов, Ульяновск, Казан госпитальләрендә жиде ай ятып, ике култык таягы белән өенә кайтып егылу... Өстендә почтальоннар кия торган, инде төсе уңып беткән зәңгәр пиджак, иске генә галифе чалбар (берсенең балагы тезгә тикле ерык), бер аякта олы ботинка, ә икенчесе мамык, бинт белән уралган...

Ә менә улының киеме пөхтә, түшендә значоклар, погоннарында бер сары тасма... Әтисенең дә орден-медальләре байтак иде. Ләкин ул аларның кадерен жибәреп почтальон кителенә тагарга кыймады, биштәр капчыгына салып алып кайтты.

Ындыр табагында Галләм абзыйның кордашларыннан да бер-ике кеше бар иде. Алар әле аңа, әле солдатка мөрәҗәгать итеп, гәп кордылар. Бу

очрашудан һәм сөйләшүләрдән күнеле тулган карт шофер дымлы күзләрен кешегә күрсәтмәс өчен, машинасының капотын ачып, нәрсәгәдер кул тидергән булды, караштырды. Аннары, балалар йөкне бушатып бетергәч, улына дәште.

—Басу әйләнәсеңме?

—Үзем дә әйтмәкче идем. Әйдә.

—Рульгә утырасыңмы?

—Юк.

Галләм абзый улының рульдән баш тартуына үпкәләмәде. Монысы нигәдер техникага әвәс булмады шул. Бервакыт, ишек алдында дүртәүләп машина ремонтлыйлар иде. Берәр сәгать җәфалангач, Габделнур, эшен ташлап, беркемгә берни әйтмичә өйгә кереп китте. Бераздан, ун телле тальянын күтәреп чыкты да, баскычка утырып, шыңгырдатып уйнап та җибәрде. Галләм абзый аптырап калды. Алар монда муеннан дигәндәй майга, пычракка батып машина рәтли, тирбәтмә алыштыра, ә ул, берни булмагандай, әргән тарта.

Ата кешенең кулында саллы гына ачкыч иде.

Ул:

—Әллә шушының белән җибәрим микән?—дип олы улына карады.

—Тимә, әти, уйнасын. Аның уенда башка нәрсә.

...Асфальт булмаса да юл тигез, машина җай гына чаба. Ата улы белән сөйләшә. Ә башында тагын истәлекләр... Берчакны, күрше авылдан шушы юл белән кайтканда, Галләм абзый рульне унбер яшьлек Габделнурга бирде. Ярты чакрым үттеләр микән, кече малае рульгә ябышты.

—Мин утырам, мин!—дип тәкрарлый башлады тугыз яшьлек төпчеге.

Габделнур түзмәде, каты итеп тормоз педаленә басты.

—Нишлисең?—диде ата кеше.

—Әнә, утырсын!—диде кашларын җыерып Габделнур һәм кабинадан чыгып, икенче ишектән кереп тә утырды.

Әйе, шулай итеп уртанчы улына урын күчәргә туры килде.

«Анысы минем юлдан китте,—дип уйлады Галләм абзый балаларының кечкенә чакларын хәтерендә яңартып.—Армияга хәтле үк шофер булып эшләде, анда да машинада икән. Ә монысы... Ярар, бөтен кешегә дә шофер булырга димәгән. Әнә Казанда икзам биреп кайткан бит. Бу юлы үтмәсәм, хезмәтне бетереп кайткач керәм, ди. Керер. Төпле күренә. Үз юлын беләдер».

...Бункердан шаулап аккан бодайга карап торуы ук рәхәт иде. Күпме байлык! Тир түгеп табылган хезмәт җимеше! Ана Габделнур гына түгел, көнтөн тирләп-пешеп, тузанга батып басуда эшләгән комбайнерлар да, гомерен шушы авылга багышлаган Галләм абзый да, кайчандыр үзе дә штурвал артында утырып кыр корабында басулар гизгән, «каты куллы» колхоз рәисе дә карап туймый—барчасының да күнелләрен сөенеч биләп ала.

Һәр карашыннан шөлләп, кем әйтмешли, шәүләсеннән үк куркып торалар «персидәтел»нең. Чөнки ул үзе дә көне-төне чаба, кешеләрне дә эшләтә, эшләгән кешенең кадерен дә белә—тиярен муллан бирә.

Вакыты тар булса да рәис Габделнур белән дә, аны тин күреп, гәп корырга җай тапты. Үзенең япон самурайлары белән чәкәләшкән чакларын искә төшерде.

Ахырда ул сүзен:

—Авылга кайтмыйсыңмы? Бер толковый электрик кирәк иде,—дип тәгәлләде.

—Юк,—диде Габделнур икеле-микеле уйларга урын калдырмыйча.

—Ярар. Шулай да минем тәкъдим үз көчендә кала.

Машинага кереп утыргач, Габделнур тузан туздырып китеп баручы комбайнга күз салды һәм кылт итеп бер вакыйга исенә төште. Ул, җидене бетергәч, ун көн ат белән комбайннан ипи ташыды. Комбайн иске—«Сталинец-6», үзйөрешле түгел, аны трактор сөйри, ашлыгы да хәзергеләрнеке кебек туп-туры машина кузовына акмый.

Соңгы көнне, алар урамында яшәүче бер егет белән, берәр йөк солы төяп, туп-туры өйләренә кайтып киттеләр.

Габделнур ык-мык килә башлагач:

—Шым бул, йөргән аякка йөрем иярә ул,—диде егет.—Беркем дә сизмәс.

Капканы үзе ачып, ишек алдына килеп керде Габделнур. Өйдән чыккан әнисе ах-вах килә башлады.

—Бар, улым, бар, келәт арасына илт! Бер кило арыш өчен дә кешеләрне утырттылар бит. Өтермәгә ябып куярлар.

—Әни, Сәмирхан абый да өенә кайтты. Ул бушаткандыр да инде. Мин бит хәзер аны чагам булып чыга. Без бит икәү бергә ташыдык...

Ничек кирәк алай тынычландырды Габделнур әнисен. Чөнки иренең машина әрҗәсе төбенә сыланып-ябышып кайткан ярты чиләк ашлыкны да жыеп алырга курка иде Гөлзифа түти.

«Менә яшьлек-җүләрлек,—дип үзалдына көлде Габделнур.—Җүләрлек кенә түгел, башсызлык».

Комбайннар янынннан урап кайтышлый Габделнур авыл башында төшеп калды. Әтисе әле кичке якта гына эшен бетерер, тугыз-уннарсыз өйгә кайтмас...

## XX

Урам тулы чордашларының күбесе авылда юк иде инде. Берәүләр һөнәр училищесыннан соң шахтада, икенчеләр шәһәр жирендә төпләнеп калган, кайсылары Ерак Көнчыгышта балык тотуда, кемдер солдатка алынган. Шулай да ике-өч егет калган иде. Алар кунакны кереп алдылар.

—Әйдә, кызлар күзләп кайтыйк әле,—дигән булды Касыйм атлысы күз кысып.

—Авылда кызлар бармы соң?

—Җитәрлек,—диде икенчесе.—Ил сакчыларына үзебезнекеләр дә жәл түгел.

—Алырсың эт авызыннан сөяк.

—Әҗәткә генә.

—Уртак малны эт жыймас.

Шулай шаярып сөйләшә-сөйләшә егетләр клубка юнәлде.

Кичке авылның үзенә күрә бер төрле яме бар: пәрдәләре тартып куелган тәрәзләрдә утлар яна; абый-апалар авыр эштән соң ашап-эчкәч, ял итәргә әзерләнә; яшь-жилкенчәк клубка жыена. Авылда сирәк кенә булса да гармун тавышын да ишетүең ихтимал. Ул кичке тынлыкка чумган авыл өстенә әкрен генә тарала, моң иңдерә, якында гына уйнасалар еракта ишетелгән комбайн тавышларын да күмеп китә. Ә соңгылары әле басу-кырларда тәмамысы караңгы төшкәнче, хәтта фараларын яндырып та эшлиләр. Буровой вышкаларында да ут алынган, прожектор ут көлтәсе сибә, кечле лампочкалар бораулаучыларның эш урынын яктырта. Элекке кебек гөрелдәмәсәләр дә анда эш кайнавы шәйләнә.

Көнбатыш тарафта, хәлдән таеп таулар артына тәгәрәп төшкән кызгылт кояшның нурлары әле бик озак шәфәкъны балкытып тора. Сирәк болытларның итәкләренә «ут кабыза».

Клубка барышлый Габделнур ике катлы, зур кирпеч бинага тап булды.

—Бу нәрсә?

—Дом культуры төзеп яталар,—диде егетләрнең берсе.

Бина Урта урамның гына түгел, бөтен авылның бизәге булыр төсле иде. Зур-зур тәрәзәләрендә утлар балкый, эчтә кемнәрдер кайнаша.

—Ике смена эшлиләр,—диде Касыйм.—Октябрь бәйрәменә ачарга жыеналар.

Озын итеп, урамга буйлап, агачтан салынган иске клуб эчендә яшьләр шактый иде. Гадәт буенча Габделнур стена буйлап тезеп куелган эскәмияләрдә утыручы егет-кызларның, янәрак өйләнешкән парларның барысы белән дә исәнләшеп чыкты, соңрак кергәннәр үзләре килеп күрештеләр. Гармунчылар да житәрлек икән: элеккеләр дә бар, яшьләр дә үскән—ике рәтле жинел

хромкасын да, өч рәтле зур баянны да, бер-берсен алыштырып, оста тарталар.

Вальс әйләнделәр, кульяулыклы, өчле, дүртле, сигезле (анысына кунакны да чакырдылар) уйнадылар. Клуб эче гөр килеп торды, күтәрелгән тузан киң сайгаклы такта идәнгә кунып өлгерә алмый, гел аяк арасында бутала иде.

Аннары, тәбәнәк зифа гәүдәле клуб мөдире, хәзер инде шушы авыл килене, баян күтәреп, солдат янына килде.

—Габделнур, уйнале, син бию көйләрен матур уйный иден. Үзем башлап биим.

Һәм... Их, ул авыл халкының биюләре! Аз күрдеме Габделнур аларны! Яшь кызларның дәртле ашкынуы, киленчәкләрнең сагышлы тыйнак хәрәкәтләнүе, ирләре сугышта югалып, яшьли тол калган хатыннарның назга сусаган гәүдәләренең ярсулы өзгәләнүе!.. Беришләре биемиләр—йөзәләр, су өстендәге аккошлардай талгын гына йөзәләр! Кул-аякларының төрледән-төрле килешле хәрәкәт ясаулары, зифа буйларының су буендагы таллардай сыгылуы, кигән киемнәренә хәтле күңелгә ятышлы булуы... Өч ел күрмәгән иде Габделнур шушы гүзәл манзараны, хозурлыкны!..

Унбиш-уналты яшьлек кызларның канат чыгарып беренче очышка әзерләнгән кош балаларыдай талпынулары, тәүге мәхәббәттән зиһеннәре чуалыр дәрәҗәдә әсәрләнүләре—барысы да бар иде ул биюләрдә!

Ә егетләр?! Кайсыдыр дәртенә чыдаша алмыйча очып-очып кунгандай итә, ә берише кеше көлдерергә тырышып кылана-яклана, кемдер житезлек белән масая—аякларына күз иярми, ә бәгъзеләр—житдирәкләр—бөтен шартын китереп, хәтта ки үз-үзенә сокланып, буыннан-буынга югалмыйча килгән борынгы үрнәкләрне саклап бии. Биюче саен бер бизәк, биюче саен төрледән-төрле холык-фигыль... Ул гына да түгел—һәрберсенең үзе яраткан, темпераментына туры килгән көе бар!..

Хәер, гармунчылар да бер үк музыка коралын төрлечә, күңелнең иң нечкә кылларын тибрәтерлек итеп, җанындагы бар моңын кушып сайрата бит!

Габделнур, күптән кулына баян тотканы булмаса да, уйный башлагач (бер белгән һөнәр онытылмый икән), үзе дә биючеләрдән ким әсәрләнмәде—өздереп-өздереп, йөрәгенә йон үсмәгән һәркемне уртага атылып чыгарырдай иттереп уйнады да уйнады... Клубта була торган өзлексез гөләү-сөйләшүләр дә пышылдауга күчте...

Чираттагы бер кызга биергә бастылар. Төз гәүдәле, тездән түбән төшеп торган юка күлмәкле, изүләре ачык джемперлы, сары чәчләре иңбашларына таралып яткан, озынча аксыл йөзле бу кыз Габделнурга таныш түгел иде. Хәер, клубтагы кызларның байтагын ул инде танымый. Кайберәүләрен әти-әниләренең йөз чалымнарыннан төсмерләп, кайсыларын абый-апаларына охшатып кына шәйли, ә күбесен иптәш егетләреннән, бусы кем, бу кем кызы, дип сораштыргалап утыра иде. Ләкин хәзер, баян уйнаганда, сүз катып булмый, буталып китүең ихтимал.

Әмма кыз, башкалар кебек, уртага чыккан унайга биеп китмәде, ә туп-туры баянчы каршына килеп басты. Егет уйнаудан туктады.

Кызның ирен читләрендә беленер-беленмәс кенә елмаю хасил булды, йөзенә кызыллык йөгерде, зәңгәр күзләрен тутырып солдатка карады.

Ул русча:

—«Цыганочку» знаете?—дип сорады.

—Когда-то знал,—диде егет елмаеп.—С выходом?

—Да.

Клуб эчендә тынлык урнашты. Бөтен күзләр ят кызга һәм үз авылларының кунак егетенә—солдатка төбәлде. Йөрәкләр ешрак тибә башлады: сынатмаса гына ярар иде! Дөнья бит, бәлки кайберәүләр шикләнеп тә куйгандыр: ни кыйратырсың икән, янәсе. Кемдер гүя ана көч бирде сыман: «Әйдә, күрсәт маһирлыгыңны!»

Габделнур, бер генә мәлгә пауза ясап, баянның төймәләрен һәм бака ягын тәңгәлләштереп, басып алды да, сыздырып җибәрде. Яшьләр җинел

сулап куйды, йөзләргә елмаю чыкты, күнелләрдә горурлык хисе калыкты.

Кыз да төшеп калганнардан түгел икән: ике кулын ике якка кош канатыдай җәеп, бармакларын бию тактына шартлатып, озын күлмәгенең итәкләрен җилфердәтеп, табанак үкчәле кызгылт туфли кигән аякларын шык-шык басып, биеп тә китте... Музыка отыры кызулана барды, көчәйде, аның саен кыз да җәһәтрәк бөтерелде. Аның сыгылмалы гәүдәсе әле түгәрәк ясый, әле кырт борыла, әле бер урында әйләнә, икенче караганда—инбашларын калтырата... Башта әкренрәк, үз-үзенә бигүк ышанып җитмичәрәк уйнарга керешкән баянчы бармакларының отыры языла баруын, үзләреннән-үзләре кирәкле төймәләрне табып, тигез йөрешен тойды; анарда азарт кузгалды.

Гармунчы (әгәр ул чын оста икән) беркайчан да, хәзер менә шушы төймә белән әнә теге бакага басыйм әле, дип уйламый, чөнки мона аның вакыты юк. Ул бары көйне, монны саклый, ритмны тота, кирәк икән аягы белән такт биреп утыра. Ә бармаклар... алар үз эшен белергә тиеш: күз иярмәс тизлек белән йөгерергә, буталмаска, әле түбән төшеп, әле югары күтәрелеп, кирәкле төймәләргә басарга һәм өзлексез хәрәкәттә булырга. Аркасы тирләп күлмәге тәненә ябышса да, маңгаеннан яки чәч төбеннән бәреп чыккан тир бөрчекләре агып төшеп күзенә керсә дә, бармаклары суда чыланган шикелле дымланып юешләнсә дә—гармунчы сер бирмәскә тиеш.

Габделнур да менә шул халәттә иде хәзерге мизгелдә. Монда ярыш бара! Егетнең исенә төште: кичке уенда яки урамда, капка төбендә, яшүсмерләр җыелышып, гармун белән ярышып бииләр иде. Гармунчы арыймы, әллә биючеме?! Габделнурның бер үк кешегә яртышар сәгать уйнаганы булды, ләкин оттырганын хәтерләми. Дөрес, ул чакта аның кулында ун телле җинел тальян гармун, көе дә әллә ни катлаулы түгел—гел бер үк төрле мотив—ачы юмор белән әйткәндә—«Эт сөяктән кайткан көй». Аны такмаклап, кул чәбәкләп тә бала-чаганы биетәләр иде олылар: «Кенгер-кенгер, кенгә-кергер, кенгер-гергер, кенгә-кенгер... Сыер сава җингәсе лә...»

Ә монда... ярты потлы баян, күнегелмәгән берничә дистә төймә, онытылган көй-мотивлар... Юк, барыбер сынатырга ярамас! Дәрт өстенә дәрт өстәлде кунакның йөрәгенә, илаһи көч керде өч ел авыр солдат күнегүләреннән бераз тупасланган бармакларына һәм... ул бәйгедә бирешмәде. Алай гына да түгел, кыз белән гармунчының йөрәк тибеше бер ритмга салынды, күнел кыллары бергә чиртә башлады сыман.

—Ну, малай, кыжыра бу!—дип башын чайкады аның белән янәшә утырган дусларыннан берсе.

Габделнур, әйе, килешәм, дигәнне аңлатып, иңген селкетеп куйды, ярым борылып, баш какты. Ул кызның оста биюче икәнен аңлады һәм мөмкин хәтле ана булышырга тырышты. Чөнки, әгәр бик теләсә, гармунчы мәшһүр биюченен дә аяк йөрешләрен саташтыра ала, иң атаклы җырчыны да тамашачы алдында хурлыкка калдыра. Егет кызга булдыра алганча ярдәм итте. Кыз моны аңлады, һәм, түгәрәк әйләнеп Габделнур каршына килгән саен ана рәхмәт хисләре тулы күзләрен тутырып, сокланып карады, бит очларын чокырайтып мөлаем елмайды. Клубтагы яшьләр түгел, әле үзләре дә аңык тоймаган ниндидер якынлык урнашты гармунчы белән биюче арасында.

Ниһаять, иң ахырда кыз, баянчы каршына килеп, инбашларын матур боргалап, чәчләрен чөеп җибәрде һәм... башы артыннан ярты гәүдәсе дә артка бөгелеп төште. Шулай да көен һич саташтырмыйча кул хәрәкәтләре белән биюен төгәлләүне дәвам итте. Менә ул туктады, сыгылмалы билен турайтты һәм реверанс ясады—бармак очлары белән генә тотып күлмәк итәген җәйде, уң аягын артка чигереп куйды, тез чүкте, башын иде.

—Спасибо!

Егет тә, аккорд биреп, уйнаудан туктады, кызга баш иде.

—Вам спасибо!

...Баянны клуб мөдире алып китте дә икенче егеткә бирде. Габделнур, янәшәсендәге Касыймга карап, сорап куйды.

—Бу кем булды соң?

—Үзем дә белмим. Хәзер сорыйм.

Ул бераздан әйләнеп тә килде.

—Күрше авылга Әлмәттән практикага бер группа гыпытыу кызлары килгән. Болар монда икәү. Берсенең иясе бар, безнең урам егете, монысы—буш. Барасыңмы? Әйтеп куям.

—Ярар.

Авыл егетләре кунак кызларын, алдан ук сөйләшеп, элекке заманда колак тешләп үзләренә атап куйган шикелле, үзара бүлешәләр. Габделнур, барам, дигәч, каршы төшүче булмас бәлки.

Армияга киткәндә аны авылдан озатып калучы кыз юк иде. Шуңа күрә бүген аңа кем булса да барыбер. Клубка чыгып, кыз озатмау (бигрәк тә солдат кешегә) да егетлек саналмый.

...Кызлар клубтан чыгуга ук аларны як-яктан ике егет култыклап алды. Монда өлгер булырга кирәк: йә алар качып китә, йә кызларны чаярак егетләр эләктерә. Кунак, дип тә, солдат абый, дип тә намус саклап тормас хәзерге яшьләр, жебеп торсаң, борын төбеннән алып сыптырырга да күп сорамаслар кулга керә язган малны! Калырсың авыз ачып...

## XXI

Яшьләр клубка җыенганда күк йөзе чалт аяз иде. Ләкин хәзер аны болыт каплаган. Яңгыр алдыннан була торган бөркү һава. Шуңа да карамастан, егетнең күңеле күтәренке. Бигрәк тә кызлар белән барганда Ходай тел ачкычларны бирә бит ул! Табигать турында башлап җибәрәсең дә вак-төяк лыгырдый башлыйсың. Телең генә тик тормасын!

Клуб ягыннан дүртәү китсәләр дә бераздан алар пар-пар булып аерылыштылар. Габделнур белән Наташа (кызның исеме шулай икән) алгарак киттеләр, ә икенче кунак кыз белән авыл егете артта калды.

Габделнур, кызны биленнән алып, аңа иелә төшеп, әйтте.

—Әлмәт кызлары шундый оста биидер дип күз алдына да китермәгән идем.

—Нигә алай дисез? Әлмәттә булганыгыз бармы әллә?

—Армияга хәтле мин шунда эшләдем, тулай торакта яшәдем.

—Кайсы урамда?

—Шевченкода.

—Ә-ә, беләм.

—Әллә егетләр янында булганың да бармы?

—Әйе,—диде кыз һәм, бераз баргач, үзенең ялгыш сүз ычкындыруын абайлап, хатасын төзәтергә уйлады.—Абый янында.

Ләкин сүз әйтелгән, ул—кош түгел, ычкынды—тотармын, димә. Габделнур моны уена салып куйды.

—Без яшь чагында кызлар болай ук чибәр дә түгел, матур да биемиләр иде.

—Комплимент?!

—Чыны шулай. Бик оста биисез.

—Ә сез—уйныйсыз. Кайда өйрәндегез?

Солдатка бераз гына үзенең тәрҗемәи хәле, кайда укуын сөйләп узарга туры килде. Аннары әйтәсе итте.

—Армияда бер чегән егете бар иде безнең. «Цыганочка»ны һәм чечетка бии иде. Безне дә өйрәтте. Казармада, ике урындык аркасына тотынып, яртышар сәгать чечетка тыпырдата идек. Миңа күбрәк хромка тоттыралар иде.

—Әйтәм оста уйнадыгыз?!

Урта урамнан унга борылып, тыкрыкка төшеп киттеләр. Габделнур, кыз белән араны якынайту өчен, сингә күчте.

—Ә син кайда биергә өйрәндең?

—Училищеда. Безнең анда түгәрәк эшли, бер егет өйрәтә.

—Алабугада укыганда безне дә биергә өйрәткәннәр иде, дөресрәге, танцыларга. Әле без укый гына башладык, ноябрь аенда бугай, «Вальс кичәсе» булды. Аның тарихы турында махсус доклад сөйләделәр. Аннары бию, танцы, төрле уеннар булды. Ахырдан, хәтерем ялгышмаса, «Висла өстендә җырлар» исемле фильм карадык.

—Ә нинди танецлар өйрәндегез?

—Безгә «Падэграс», «Падэспан», «Кроковьяк», «Конкобежцы», «Танго», «Вальс» шикелле борынгыларны өйрәттеләр,—диде Габделнур «борынгы» сүзенә басым ясап.—Хәер, бөтенесен дә иске заманныкы дип булмый. «Танго»ны, мәсәлән, хәзер дә бөтен Аргентина бии. Биючеләр бер-беренә нык терәлеп, сарылып бетеп биегәнгә кемдер аны, вертикальное выражение горизонатльного желания, дигән. «Вальс» шулай ук мәңге яшәр төсле. Әлбәттә, сез, яшьләр, «Джайв», «Пасодобль», «Румба», «Ча-ча-ча» кебекләрне өйрәнәсездер?

—Юк, безгә аларны өйрәтмиләр шул. Болар—бальный танецлар бит. Ә сез аларны каян беләсез?

—Кайчандыр «борынгы» танецларны өйрәнсәм дә, мин үзем замана кешесе бит. «Квикстеп», «Самба» дигәннәре дә бар бугай әле.

—Соңгысы көрәш төре түгелмени?—диде кыз үз-үзенә бигүк ышанып җитмичә.—Минем абый, армияда шөгыльләндем, дигән иде.

—Юк,—дип кызны төзәтте егет,—алар—икесе ике әйбер: бию булса—«Самба», ә көрәш—самбо. Мин үзем дә ярты ел шул секциягә йөрдем.

Кыз беравык дәшми барды да, егеткә карап, сорап куйды.

—Ә сез нигә үз авылыгыздан берәр кызны озата бармадыгыз?

Бу—кызлар бирә торган гадәти, беркатлы сорау булса да, монда бераз хәйлә дә бар. Кызлар шулай егетләрне сыный. Асылда, Наташа үзен нәкъ шушы солдат озатуына һич тә үкенми, якынрак белә барган саен күңеле ана ныграк тартыла кебек. Дөрес, беренче тәэсир алдаучан. Ләкин тышкы кыяфәтенә карап бирәләр бит беренче бәяне дә, ә ул—Габделнур файдасына иде. Әгәр бу егет бүтән берәүне озата киткән булса, кызның бәгырен көнчелек корты кымтырыклап торган булыр иде. Чөнки биегәндә шулхәтле җайлы һәм оста итеп баянда уйнавы белән үк ул кызның күңелен яулаган иде.

Габделнур Наташаның колагына:

—Син дип кенә дәш,—диде.—Минем авылдан чыгып киткәнгә сигез ел инде, ә бөтенләй кайтмаганга—өч.

—Армиядан кунакка кайталар бит.

—Бөтенесе дә түгел. Дөрес, чираттан тыш отпуск игълан иткәннәр иде. Ләкин көтмәгәндә бер солдатка, әниең үлем хәлендә, дигән печатьле телеграмма килде. Аны җибәрдек. Ә авыл кызларын озатуга килсәк, безнең яшьлек мәхәббәтләре күптән бәби үстерә инде.

—Кияүгә чыкмаганнары да бардыр әле.

Габделнур кызны тагын да үзенә якынайтып, колагына пышылдады:

—Тагын бер сәбәп бар: клубта синнән дә чибәр кыз юк иде.

Әлбәттә, дөнья күргән егет буларак, андый сүзләрнең кызлар йөрәгенә сары май булып ятасын ул яхшы белә һәм Наташа колагына мөмкин хәтле мулрак итеп йомшак «токмач элә» иде.

Дөрес, кызны ямьсез дип әйтеп булмый. (Хәер, ямьсез кыз дөньяда була микән?!) Аның сары чәчләре матур булып иңнәренә яткан, ул хәрәкәтләнгәндә алар да урыннарыннан кузгалып, дулкынланып алалар, юка борыны аның аксыл озынча йөзенә килешеп, үзенчә бер тәңгәллек биреп тора, иреннәрен мулча иннеккә буяса да, кызларга кызыл килешә ул, дигән төшенчәдән чыгып караганда, аннан гына гаеп табып булмый. Сары кашлары нечкәртелеп, йолкынган-кыркылган һәм көрәнгә буялган булса да нур өстенә нур гына. Кыскасы, бөтен килеш-килбәте аның инде шәһәрдә беренче генә көн яшәмәүче

авыл кызы икәнен сиздереп-белдереп тора иде. Аның озынча аксыл колагындагы кашлы алкаларына хәтле шәһәрчә иде инде. Киң маңгай һәм әлеге көрән төскә буялган кашлар астында озын керфекләр һәм зәңгәр күз—болар кызга сокланып карауны таләп итә иде. Наташаның күз төпләре күгәребрәк торуы да егет игътибарыннан читтә калмады.

Ике урамны бер-береннән кечкенә елгачык аерып тора, аңа салынган тар гына күпернең ике ягыннан да эреле-ваклы таллар тезелешеп киткән. Һәм алар, ялга кайткан кунак солдатны да, ул житәкләгән зифа буйлы кызны да сәламлиләр: башларын иялэр, шыбырдашалар, лепердәшәләр. Агачлар арасыннан сирәк-мирәк кош тавышлары да ишетелә; болытлы булса да киче жылы.

Габделнурлар урамына килеп кергәндә вак кына яңгыр сибәли башлады. Егет, кызны култыклаган хәлдә бәләкәй капканы ачып, аны ишегалдына алып керде. Алар урыс капка түбәсе астына ышыкландылар.

Күрәсең, хәрбиләрнең погонындагы «ф» хәрефе бик күп кешеләр өчен яңалык, моңарчы андыйны күргәннәре булмагандыр. Наташа да шул хакта солдаттан сорады. Әлбәттә, егет, гадәтенчә, башта үзен, футболчы, дип таныштырды. Фәкать берникадәр паузадан соң гына бу хәрефнең ни-нәрсә аңлатканын әйтеп бирде.

—Ә диңгезне без ерактан гына күзәттек. Дөрес, Кронштадтта чагында уртасында ук яшәдек. Бу шәһәр Фин култыгындагы Котлин дигән утрауга салынган. Фин култыгы—кечерәк диңгез кебек. Бер ай Выборг шәһәре тирәсендә, фин чигендә, диңгез буенда яттык, хәрби өйрәнүләр вакытында. (Бер белмәгән кызга, урман кистек, дип дөресен әйтеп, дәрәжәсен төшерә алмый бит инде солдат егет!)

—Диңгез матурдыр, әйеме?

—Искиткеч. Шуңа күрә без әйтә идек: люблю море... с берега. Балык та тоттык.

—Ә анда давыллар булдымы?

—Без барында алай бик көчле штормнар булмады.

—Анда куркынычтыр?

—Билгеле. Шуңа күрә моряклар әйтә бит: люблю шторм... в ресторане. Ресторанга гади матрос керә алмый инде, моны офицерлар уйлап чыгаргандыр яисә сәүдә флоты моряклары. Мина калса, алар, гомумән, диңгезне күбрәк беләләр. Бик күп китапларда алар белән булган мажаралы хәлләр бәян ителгән бит. Алар диңгездә төрле жанварларга, су хайваннарына тап булалар, бигрәк тә сигезаякка. Ә ул ялгыш суга мәтәлеп төшкән морякны сагалап кына тора икән дә, имеш, үзенең сигез аягы белән берьюлы аны эләктереп ала икән дә, су төбенә өстери икән...

—Нинди куркыныч!—диде кыз егеткә карап.

Габделнур кызны кочагына алды да аның колагына ук пышылдады.

—Менә шулай итеп, үзенә тартып китереп, аны кыса икән...

Наташа егетнең кайнар кочагына кереп бетте, аңа үзенең гәүдәсе Габделнурныкы белән тоташып, бер тән, бер жан кебек тоелды; аларның иреннәре кушылды. Тансыклаган солдат аны озак итеп, суырып-суырып үпте, кыз да шундый ук дәрт һәм ихтыярына буйсынучанлык белән жавап кайтарды, аның күзләре йомылды, гәүдәсе йомшады, егет кочагында эреп бетү теләге бөтен вәжүден биләп алды. Болар берсе дә Габделнурның сизгер тоемлавыннан, моңарчы туплаган тәжрибәсеннән (Зоя өйрәткәннәрдән) читтә калмады. Ул, сигезаяк роленә кереп, кызны жайлап кына үзенә арты белән борып бастырды һәм, джемпер төймәсен ычкындырып, юка күлмәге аша имиләрен тотты. Алар йомшак иде. Тәмам мәлжерәгән кыз фәкать беркавым торгач кына солдат куенынннан чыкты.

Аннары Габделнур Кронштадт, Петродворец фонтаннары, Ленинград турында сөйләп, кызны тәмам әсир итте. Ахырда, булган булсын инде, дигәндәй, кайчандыр, кемнәндер (әллә экскурсия вакытында гид сөйләдеме?) ишеткән бер вакыйганы да кыстырып жибәрде.

—Ленинградта заманында бик күп атаклы кешеләр яшәгән. Бөек композитор Штраус берничә ел рәттән җәен шунда үткәргән. Билгеле, ул чорда шәһәрнен исеме—Санкт-Петербург. Штраус бу шәһәргә берничә әсәрен багышлаган: полька, полонез, вальс. Ә вальсны ул Ольга Смирницкая исемле кызга атап язган. Кыз бик акыллы, зифа гәүдәле, нәкъ менә синен кебек гүзәл икән. Штраус ана үлеп гашыйк була, Ольга да композитор егетне ярата. Ләкин алар кавышмыйлар.

—Нигә?

—Монда ниндидер киртәләр, социаль хәлләренен тигезсезлеге сәбәп була.

—Анысы нәрсә?

—Ул чорда бай кызы ярлы егеткә кияүгә чыга алмаган, ә дворян баласына берәр мещан кызына өйләнү тыелган, чөнки аларны социаль яктан тигез түгел дип караганнар. Менә шул: сонгы җәендә Штраус «Петербург белән хушлашу» дигән вальс яза. Ул бик матур, ләкин монсу вальс. Аны калын тавышлы виолончель башлап җибәрә, оркестр дәвам итә, тора-бара кларнет кушыла... Вальс беткәнче бу көйне буеннан-буена монсулык аһәннәре озата бара...

Габделнур теленә килгән бер мелодияне шыншып та күрсәтте. Шулай итеп ул Наташаның зиһенен тәмам чуалтты.

Аннары Ленинградка багышланган тагын бер җыр җырлап күрсәтте. Ул солдат-матрослар арасында кин таралган, җинел мелодиягә салынган иде.

Всю ночь над городом в ненастье,
Всю ночь колдует темнота.
Остановилось чье-то счастье
У разведенного моста...

—Анда күперләр төнлә ике якка ачыла, өскә күтәрелә.

—Ни өчен?

—Кораблар Нева елгасына керсен өчен.

Янгыр явудан туктамады.

—Без монда чыланабыз,—диде Габделнур капка төбәсенә ымлап һәм кызны култыклап ишек алды түренә алып китте.—Өйдән дә чыгалар бугай, бәләкәй якта ут кабыздылар шикелле.

Алар, мыш-мыш килеп, авыр сулап күшәп яткан сыер, бер-беренә сыенышкан сарыклар ябылган туры лапас янынннан узып, бакча капкасын ачып керделәр. Турыга—сукмак биек сиртмәле коега илтә, ә сулга—мунчага. Кыз аны-моны абайлап өлгергәнче, Габделнур, теленә салынып, анын игътибарын үзенә җәлеп итте һәм, тиз генә баскычтан күтәрелеп, мунча алдынын ишеген ачып, кызны эчкә үткәрде. Ләкин кыз үзенен тозакка эләгүен сизде, ахры, мунча эченә керүдән баш тартты.

—Мин анда кермим!

Әмма егетне туктатырлык көч юк иде инде.

Аны кызнын кайнар, яшь тәне, чәчләреннән анкып торган исерткеч хуш ис, сыгылмалы нечкә биленен һәрдаим дәрт бөркеп торуы—күптән кызлар назы күрмәгән солдатнын анын томалаган иде. Бу минутта анын алдында фәкать фәрештәдәй гүзәл кыз һәм шул мизгелдә барлыкка килгән максат—аны яулап алу—биләгән иде. Гасырлар буена килгән инстинкт алдында ул көчсез иде, аны хәзер беркем дә, берни дә бу юлдан кире кайтара алмас, анын ташкын дәртен тыеп тора алмас кебек иде. Ана ут та кирәк түгел: ул кайсы ишекнен кайда икәнен күз йомып та белә. Габделнур тышкы ишекне эчтән бикләп куйды һәм, бер кулы белән мунча ишеген ачып, икенчесе белән Наташаны култык астына кыстырып диярлек, эчкә үк керде. Бу ишекнен дә келәсен төшерде.

Бая капка төбәсе астында торганда ул беренче мәртәбә кызны үпте, анын иреннәренен егеткә буйсынып, үзенә дә ләззәт алуын сизде, имиләрен зур

учлары белән иркәләде, назлады һәм аларның бигүк каты түгеллеген белде. Шуңа күрә хәзер артык нәзакәтлек саклап тормады.

Ләкин мунча эчендә кызны алыштырып куйдыларммыни: ул киреләнә башлады, үзе бертуктаусыз сөйләнде:

—Син нигә мине монда алып кердең? Мыскыл итәргәме? Мин кеше күзенә ничек күренермен? Кызлар ни әйтер? Әнигә ни дип җавап бирермен?..

Тик Габделнурның каты кулыннан ычкыну мөмкин түгел иде инде. Егет аны бөтереп алды һәм уң як стена буендагы эскәмиягә сузып салды. Кыз елый ук башлады. Һәрхәлдә, Габделнурга башта шулай тоелды.

—Әрәм итмә минем яшьлегемне! Мин бит әле саф кыз! Кирәкми, кирәкми! Ой, әнием! Нишлим мин? Әнием-бәгърем! Сезгә шул гына кирәк. Ә без... теләсә нишлик... Балага узсам?.. Нигә шулай кыланасың? Салдырма... Син әйбәт егет бит... Мин бит сине... Ой, кирәкми!.. Не губи мою молодость!..

Кыз бәргәләнә, чәбәләнә, карыша, үзе һаман сөйләнә, ә егет аны тагын да көчлерәк дәрт белән үбә, коча, үзенә буйсындырырга омтыла иде. Бермәл, зиһененә ачыклык кереп, Габделнур, әллә ялгыштыммы соң, чыннан да саф кыз микәнни, дип уйлап аның өстеннән тормакчы да булган иде. Ләкин шулчак тавышында бернинди дә елау-сыктау чагылмаган кыз аны үзе шашкын дәрт белән үбә, коча, яратуын аңлата башлады. Аның өзек-өзек җөмләләре каяндыр еракта ишетелә сыман, йокы аралаш эндәшкән дә кебек, аерым сүзләре бөтенләй аңлаешсыз иде.

Бераздан кыз:

—Мин үзем, сабыр ит,—диде һәм, урыныннан торып, чишенә башлады.— Син дә чишен...

...Габделнур янәшәсенә эскәмиягә торып утырган Наташа аның куенына кереп бетте. Ул озын бармаклары белән солдатның кыска каты чәчләрен назлады, юан беләкләрен сыйпады, аның дәү кулын үзенең бәләкәй учына салып иркәләде.

—Син нинди көчле! Мин сине яратам!—диде ул һәм, башын күтәреп, Габделнурның иреннәренә үрелде.

Егет аны тыны кысылганчы үпте.

Аннары:

—Ә син нигә башта карыштың?—дип сорады.

—Ә миңа шулай рәхәт,—диде кыз берни булмагандай карангыда аның колагына ягымлы кайнар сулышын өреп.—Бер кыз әйткән бит: "И Алла, зачем дала, еще бы девочкой была". Ә минем үземне һәрчак саф кыз итеп тоясым, күрсәтәсем килә. Шуңа күрә мин көч белән алганнарын яратам. Мямля, хлюпикларны җенем сөйми. Ә син—көчле! Мин сине беренче күргәч тә ошаттым. Кил, тагын телисеңме?!...

## XXII

Алар мунчадан чыкканда яңгыр туктаган, күк йөзе ачылган, көнчыгыш тарафта алсуланып таң беленә башлаган иде.

Габделнур кызны алдан үткәрде. Ул мунча ишегеннән япкан арада Наташа кичә килгән сукмак буйлап бер-ике адым атлап өлгерде.

—Наташа, анда барма,—диде егет.—Мин сине моннан гына озатам.

Ул бәдрәф янындагы, бәрәңге бакчасына чыга торган арт капканы ачты. Алар күршеләр бакчасы белән ике арада калган киң бураздан—ызаннан үргә таба киттеләр. Кеше йөргән сукмак булса да ул тар иде. Юеш бәрәңге сабакларыннан, яфраклардан коелган салкынча яңгыр тамчылары кызның аягына тама, артык биек булмаса да туфли үкчәләре йомшак җиргә батып керә иде.

—Мин яланаяк барам,—дип кыз туктады.

—Салма,—диде солдат һәм кызны җәлт кенә кулына күтәрде.

—Ой, мин авыр бит,—диде Наташа чытлыкланып, ә үзе Габделнурның таза

муенынннан кочып алды.—Мине әле берәүнен дә шулай кулында күтәреп йөрткәне юк иде. Загстан чыккан кәләш кебек булдым. Какой ты славный! Рәхмәт.

Ул егетнең иреннәренә үрелде. Габделнур туктарга мәҗбүр булды... Янә алга атлады.

Бакча башына җиткәч, кыз:

—Булды, җитте, үзем барам,—диде.

Габделнур аны сак кына җиргә бастырды; үр аша чыктылар. Алда, ундарак күренгән ферма өе яшьләрне озатып калды. Дөресен генә әйткәндә, ул ферма өе түгел, ә мәчет иде. Заманында Урта урамны (калган ике урамнын—мәхәлләнең үз мәчетләре булган) бизәгән бу мәчетнең кайчан урын кузгатылганын Габделнур хәтерләми, анын истәлеге булып янындагы күл генә һәм анын атамасы—Мәчет күле генә калган. Габделнурлар үскәндә манарасыз бу мәчет алар урамындагы бер буш ихатада тора һәм ашлык складлы ролен үти иде. Хәзер әнә бәрәнге бакчаларыннан да читкә, ындыр артына ук, дуңгыз фермасы янына ук күчереп салганнар. Ул әле дә кыйблага каратылган михрабы, калай түбәсе, зур-зур тәрәзәләре белән горур утыра, тик искергән, таушалган, ремонтланмаган кыяфәте белән иртә-кичме, көндез яки төнләме яныннан үткән-сүткәннәргә рәнҗеп кала сыман. Наташаны озата баручы Габделнурга да шулай үпкәләп калды микән, әллә аны сәламләде микән, солдат ул турыда уйлап баш ватмады. Бу горур бинага бары бер генә карап алды да, юлын дәвам итте. Дистә еллар дәвамында рәнҗетелгән мәчет түбәсендә утырган бер карт карга, әллә мазасын китәргәнгә ачуланып, әллә гадәттәге табигый бер халәтен—вазифасын үтәү йөзеннән, аны бимазалаган кыз белән егет артыннан әле төнге йокыдан айнып җитмәгән карлыккан тавышы белән ризасызлык белдереп калды.

Колхоз фермасы яныннан борыннарын җыерып беразбаргач, элек кичке уен була торган болыннан киттеләр. Аннан алар таш юлга чыктылар. Уң якта зиярат агачлары моңсу гына утырып калды, сулда урылмаган иген басуы тымызык җилдә беленер-беленмәс кенә чайкала, чөнки тук башаклар җиргә чыланып тагы да авырая төшкәннәр. Иске авыл күпереннән межага хәтле уйный-шаяра бардылар. Каршыларына машина-фәлән очрамады. Тирә-юнь гаҗәеп тынлыкка чумган иде.

Межа турысыннан, алар сөйләшкәнгә уянган таң кошларының тавышларын тыңлый-тыңлый берникадәр юл үткәч, Габделнур туктады.

—Моннан үзең генә кайт инде,—диде ул.—Курыкмыйсынмы?

—Юк,—диде кыз ана сарылып.—Минем әле синнән аерыласым килми.

—Минем дә, ләкин... кирәк.

—Тыңлыйм, иптәш командир,—диде кыз һәм, уң кулын чигәсенә тидереп, честь биргәндәй итте.

—Пустой голове рука не прикладывается!

—Как? У меня пустая голова?!—диде Наташа ярым шаярып, ярым шелтә белән.

—Үпкәләмә. Синең баш киемең юк.

—Аңладым,—диде кыз һәм кисәк кенә үрелеп солдатның фуражкасын алып киде.—Хәзер честь бирергә ярыймы?

Габделнур: «Син честеңне әллә кайчан кемгәдер биргәнсең инде»,—дип уйлады, ләкин үзенә бәхетле минутлар, ләззәт биргән кызны рәнҗетәсе килмәде.

—Ярый,—диде ул көлеп, аннары өстәде.—Хәзер син минем кырык көнлек хатыным булдың!

—Ничек?

—Хатын-кыз берәр ир-атның баш киемен кисә, шулай әйтәләр.

—Аңладым,—диде кыз, фуражканы солдатның башына кидереп, моңсу гына әйтте.—Мин синең бер көнлек хатының булдым.

Наташаның күнелен тыелгысыз сагыш биләп алды. Ул, күзләрен тутырып, егеткә карады. Бер кич, бары бер кич! Ә никадәр якын иде бу асыл егет аңа!

Горур килеш-килбәте, чын ирләрчә кырыс йөз-чырае, хатын-кызга мәңге онытылмаслык чын ләззәт бирә алырдай көчле, таза-сәламәт тәне һәм... гади, ләкин ательеда теккәндәй таман киеменә хәтле үзенә тартып тора иде кызны. Ул аның белән гомер буе менә шушылай назлашып-сөешеп яшәргә, хәтта колы булырга да риза иде. Тик ул гына каршы килмәсен... «Хыялый, исәр,—дип үз-үзен битәрләде кыз.—Житте синә... әгәр очрашуны дәвам итәргә теләсә, ул үзе бу хакта сүз кузгатыр иде. Ул бит Әлмәттә эшләп киткән. Мөгаен, анда бармый калмас. Ләкин ул бу турыда ләм-мим... Димәк... Бер кич өчен дә рәхмәт әйт». Бүген аларның практикасы бетә, алар китәргә тиеш. Үзенең күңеленә хуш килгән тагын берәү белән аерылыша...

Кыз, егеткә яны белән борылып, сагышлы карашын унга, каядыр еракка-еракка, зәңгәрләнеп күренгән биек тауларга төбәп, йөрәк өзгеч тавыш белән җыр сузды.

...Ах, я сама, наверно, виновата,
Что нет хорошей любви у меня.

Хәер, бу җыр гына түгел, ә яшьлегенең алсу чәчәкләрен вакытсыз койдырган җилбәзәк кыз баланың бәгыреннән ташып чыккан сагыш, әрнү-өзгәләнү, инрәү авазы иде.

Наташа: «Ах, я сама, наверно виновата...» дип җырласа да, чынында, әгәр вакытны бер-ике елга арткарак чигереп караганда беренче мәртәбә егетләр астына ятуында ул үзе гаепле түгел иде. Аларның авылы кечкенә булганлыктан, ул урта мәктәпкә күрше авылга йөреп укыды. Соңгы елны, җәй көне, туганнан туган абыйсы аны мотоциклга утыртып алып китте дә урман эчендә көчләде, беркемгә дә әйтмәскә кушты, куркытты. Аннан инде китте... Кызның үзенә дә рәхәт була башлады...

...Ах кавалеров вполне хватает,
Но нет хорошей любви у меня.

Егет дәшмәде. Кыз, кисәк аны муенынннан кочып, иреннәреннән суырып-суырып үпте дә, килеп тыгылган күз яшьләрен күрсәтмәс өчен, кырт борылып, торып йөгерде. Габделнур урыныннан кузгалмыйча аның артыннан карап калды. Бераздан Наташа туктады, борылды һәм, солдатның әле һаман урынында басып торуын күргәч, күңеле күтәрелеп китте: елмайды, кул изәде.

—Ху-уш!

Габделнурга килеп ирешкән соңгы сүзе шул булды.

## XXIII

Икенче көнне, чәйдән соң, Габделнур зияратка юл тотты.

—Исәнмесез, кабер әһелләре,—диде һәм, иелеп, киртә арасыннан эчкә атлады.

Куе булып үскән тупыл агачларының юан-юан ботаклары як-якка җәелгән, бер-берсе белән аралашып, укмашып-буталышып беткәннәр. «Нәкъ авыл кешеләре кебек,—дип уйлады солдат аларга карап.—Бер уйласаң, бөтен авыл кан-кардәшкә әйләнеп беткән бит инде: кыз биреп, ул өйләндереп туганлашканнар. Бик сирәкләр генә читтән өйләнә. Бүтән җиргә кыз бирә. Авыл халкы үлгәч тә бер тирәгә туплана.»

Сирень куаклары буй җитәрлек кенә түгел, иркенләп үскәннәр: ботакларын ботарлаучы-сындыручы юк. Яз көне булса алар аксыл-шәмәхә чәчкәләре белән әллә каян күренеп торырлар иде, хәзер яфраклары да сирәк—корт ашап бетергән. Сиреньгә корт төшүчән.

Каберләр сул якта, ә унда—бушлык. Түргә барып җитәрәк Габделнур сулга борылды һәм күбесе такта коймалы каберләр янынннан отыры эчкәрәк

керде. Кечкенәдән үк килгәләп йөргәнгә бабасының кайда ятканын чамалый иде. Янында сабый чакта ук үлгән өч баласы, ә бер-ике адым читтәрәк—анасы, ягъни, Габделнурның карт әбисе.

—Менә шушы тирәдә иде бугай,—дип үзалдына сөйләнә-сөйләнә егет, алан-йолан карангалап, сулга таба баруын дәвам итте.

Ул туктады. Унга карады, сулга—бабасы каберен күрмәде. Чөнки монда инде чытырманлык—бик куе булып чия агачлары үскән.

—Кайда булыр соң ул?—дип үз-үзенә сорау бирде Габделнур.

Ләкин җавап таба алмады; бабасының каберен дә таба алмыйча интекте.

—Тупыл агачлы иде балалары кабере. Бабайныкы—сәрвәриле.

Солдат, башын күтәреп, югарыга карады. Бер ботагы сынган иде түгелме? Әйе шул. Исенә төште. Әнә бит, әнә! Ул шатлыктан кычкырып җибәрә язды. Ләкин зиратта сөйләшкәндә дә тавышыңны баса төшеп, шыпырт сөйләшергә кушалар иде.

Ул элеккегә караганда дәү булып, тармакланып үскән тупыл агачын таныды; ана хәтле куе чытырманлык аша үтәсе бар иде. Чия агачлары шулхәтле куе булып үскән, сафта барган шикелле генә җинелдән үтәрмен димә.

—Нишләргә соң?—дип туктап калды солдат пәрәвезле, кычытканлы чытырманлыкка карап.

Ул үзенең үтүкләнгән галифе чалбарына, гәүдәсенә сыланып торган, җиз төймәле кителенә күз ташлады. Әгәр шушы килеш барып керсә, киеменең карарлыгы калмаячак иде. Дөрес, каккалап чистартырга мөмкин. Ләкин... Рота старшинасының, солдат теләсә нинди ситуациядән дә югалтуларсыз чыга белергә, нинди генә хәлгә тарыса да исән-имин котыла алырга тиеш, дигән сүзләре хәтеренә килде. Әлбәттә, Габделнур кабер янына ничек тә керәчәк, ул турыда шикләнмәскә мөмкин. Ләкин... «Монда бит әле баш китәрлек бернәрсә дә юк. Хәзер барып карадым ни, соңрак карадым ни...» Шуннан егетнең башына икенчерәк фикер килде һәм ул кайту юлына борылды.

Габделнур, верандага кереп, кием алыштырды: утын кискәндә кигән кара төстәге иске эш киемнәрен, ак фуражка киде. Келәттән балта, кул пычкысы һәм чиннек янында тимер көрәк алды. Балта йөзенә баш бармагын тидерде—үтә икән. Ярый әле беркөн кул белән әйләндерә торган чарны табып, ялгашка су салып, әтисе белән балталарны үткенләп куйганнар иде.

Егет зиратка китте.

Чия куакларының юанракларын балта белән чабып, нәзекләрен көрәк белән кистереп, бабасының каберенә бер атлам чамасы киңлектә юл-сукмак ясады.

Бер сәгатьтән артыкка сузылды бу мәшәкать, фуражка астында кыска чәчләре дымланды, маңгаеннан тир бәреп чыкты, күлмәге аркасына ябышты. Ләкин ул бер генә минутка да туктамады, баш күтәрми эшләде. Әйләнә-тирәсен агачлардан әрчеп бетергәч, кабернең өстен дә чистартты. Янәшәдәге каберләрне дә онытмады. Корыган сәрби агачларының бер-икесен пычкы белән кисеп ташлады. Эчкәрге агачларда чиясе дә калган,—бисмилла әйтеп,—бер-ике чия дә капты: мәмрәгән, баллы, авызда эриләр. Бөтен чыбык-чабыкны зиратның тышына ук илтеп ташлады—берничә тапкыр юллады. Кабер ташын абыйсы Чупай карьерында ясатып, үзе үк гарәпчә һәм хәзерге хәрефләр белән язуын да язып куйган иде. Ап-ак таш инде саргайган, бер якка янтая төшкән. Габделнур аны этеп карады. Бирешә икән. Читкәрәк китеп, турылыгын чамалады, якын килеп, тагын бераз этте, төбен көрәк сабы белән тыгызлады. Таштагы язуларны, саннарны укыды, бармаклары белән сыпырып, тузанын койды. Беркавым кабер янында уйланып торды. Бер уйласаң, күп тә яшәмәгән бабасы—алтмыш бердә генә булган. Инде вафатына да егерме ел вакыт узган. Нindирәк булды икән ул? Карточкасы да юк. Әтисе сөйләве буенча—кара сакал-мыеклы. Хәзер, билгеле, ап-ак сакаллы намаз карты булыр иде.

Китәр алдыннан егет:

—Бу такталар озакка чыдамас, пожалуй, тимер рәшәткә кирәк булыр,— дип куйды.

Килгәндә ул күрде: кайберәүләр инде тимер чардуган куя башлаган, искеләрен алыштырганнар да бар. Авыл тирәсендә нефть чыга башлагач, тимер-томыр, торбаише нәрсәләргә кытлык сизелми иде булса кирәк.

Бер кулына балта, икенчесенә пычкы белән көрәк тотып, эшләп арса да гәүдәсен төз саклап, зияраттан чыгып баручы кунак егетне сирень куакларындагы чыпчыклар чыркылдашып озатып калдылар. Үзләренчә рәхмәт әйтүләре булды микән...

## XXIV

Кичке якта, жизнәсе кереп, кунакны үзләренә, сигез чакрымдагы авылларына алып китте. Солдатның бертуган апасын күрмәгәненә дә өч елга якын иде инде.

Габделнурның апасы аңардан өч яшькә олы. Авылда җиде класс бетергәч, алар, ике кыз, Алабуга китапханә техникумына (апасына кечкенәдән үк китап җене кагылган иде) укырга керергә дип китteләр. Апасы кергән, ә иптәш кызы имтихан бирә алмаган. Ләкин, яшьлек юләрлеге димичә ни дисең, апасы, иптәш кызыннан аерыласы килмичә, документларын алып, аның белән бергә авылга кайтты.

Ул кышын фермада сыер сауды, ә җәен, берничә ел рәттән, кызлар белән җыйнаулашып, Горькийга китәләр иде. Күз житкәч, өс-баш бөтәйтеп, сандык-чемоданнарын кием-салым, ситсы (күбрәк үзләренә бирнәлек) һәм күчтәнәчләр белән дыңгычлап тутырып, су юлы белән—пароходка утырып—Чаллыга кайталар. Ә аннан кызларны машина белән барып алалар иде.

Горькийга дип китсәләр дә, эшләре шәһәрнең үзендә түгел, ә шул төбәктә—торфта. Бу хезмәтнең никадәр авыр икәнен, көннәр буе бил бөгеп эшләүләрен, каз оясы хәтле зур кәрҗиннәр белән торф кирпечләре ташуны, кулларына һәм иң башларына кан төшүне шунда эшләгән кеше үзе генә белә. Чөнки кайбер җегәрсезрәкләр, ата-ана канаты астыннан чыкмыйча жылыда гына үскән чәрексез кызлар, бер күреп кайткач, икенче елны ике аякларының берсен дә атламыйлар иде. Әмма авыл җирендә андый кызлар сирәк була. Горькийдан кайткан кызларның абруй зур—«базары тиз күтәрелә»—аларны үз авыл егетләре дә, елгыррак күршеләр дә «чүпләп» кенә тора. Жир җимертеп эшләгән кешене кем генә тормышта үзенә юлдаш итмәс икән?!

Жизнәй буласы кеше белән танышканчы, Габделнурның апасы авылның бер егете белән йөри иде. Ләкин аны зур фаҗигадан соң төрмәгә утырттылар.

Ул чорда авылларда үтә торган Сабан туен—мәйдан, дип, ә райондагысын—жыен, дип атыйлар иде. Район жыенына һәр авылдан берничә «тройка»—эскәмия рәвешендә кара-каршы беркетелгән такталарга яшьләр тезелешеп утырган, өчәр ат җигелгән арба—бара иде. Егет-җилән булган төштә күп бәхәс кул көче белән хәл ителә: тәртә яки күчәр башы тиеп китсә дә, үрәчәләр эләгешсә дә, кемдер каршы килгән атларга сигездән үргән каеш чыбыркы белән селтәнсә дә, кызлар бүлешә алмасалар да...

Уникe чакрымдагы күрше авыл егетләреннән берәү җыенда Шәяхмәткә суга. Ни өчен? Нәрсә ошамаган? Ул ничек берүзе аларга туры килгән? Күпләр өчен болары карангы булып кала. Күрәсең, үче булгандыр. Низаг кызлар аркасында килеп чыкса кирәк. Туган Йорт егетләре, гомумән, авыл кызларын читкә җибәрмәскә тырышалар, кызлар элек-электән тирә-күрше авыл егетләренә бик сирәк эләгә. Шуңа күрәдер, үпкәләгән егетләр, рәнҗеп, җыр да чыгарып калдырганнар.

Туган Йорт ул бик бай авыл,
Алагаем зур авыл.

Кызларын читкә бирмиләр—
Итәк саен каравыл.

Кыскасы, Шәяхмәткә дә тиктомалдан китереп сукмаганнардыр (аның буй житкән сеңлесе бар иде), берәр егетнең үче булгандыр. Хәзер инде ул үчен кайтарырга тиеш. Егетлек—шуны таләп итә. Мәсьәләне шунда, җыенда ук хәл итә алмыйлар—район үзәге, милиция бар.

Ә егетләрнең кайту юлы нәкъ Туган Йорт аша узасы.

Шәяхмәт, алданрак кайтып, берничә егет белән авыл башына олы юлга чыга. Әтисенең ике энесе дә яшьләргә ияргә: алар инде өйләнгән ир-егетләр булсалар да, туганнарын рәнжетергә беркайчан да ирек куймыйлар, сәбәп чыкканда үзләре дә көч-җегәрләрен күрсәтеп алырга атлыгып тора. Нәселләре шундый, данлыклы иде.

Тегеләрнең каршыларына чыгып, өчләп җиккән атлы егетләр-кызлар утырган арбаны юл уртасында туктаталар. Дугадагы кыңгырау, мичәүдәге атлар муенындагы шөлдерләр, өздереп уйнаган гармун, яшьләрнең дәртле җыр тавышы—барысы да ярты юлда өзелеп, тынып кала. Бары янәшәдәге иске зиратта бер кошның зар елагандай сагышлы тавышы гына ишетелеп тора.

Аякларын җәеп баскан, иң көчле өлкән агай сорый:

—Кайсыгыз минем энекәшкә тиде?

Таза-таза кызмача егетләр арбадан коела. Каршы басалар. Кирәк бит, әзмәвердәй берсе, алгарак чыгып баса.

—Мин!

Беләк юанлыгы имән күсәк күз ачып йомганчы егетнең чигәсенә килеп тә тия. Бу орудан әзмәвер сүз дә әйтә алмыйча гөрселдәп җиргә ава...

Исенә төшсә, Габделнур ул егетне әле дә күз алдына аермачык китерә: юл кырында, чирәмдә, озын гәүдәле берәү ята; йөзе яулык белән капланган, терсәктән сызганулы беләкләре өй бүрәнәседәй юан... Аның янында яулыгын бөркәнеп диярлек япкан бер кыз утыра, елый-елый шешенеп беткән, бер учында кульяулык—әледән-әле борынына тидереп ала...

Берникадәр вакыттан авылга районнан милиция килеп төште. Башка вакытта урам малайлары милиция күренүгә кайсы-кая таралыша торганнар иде, бүген зират киртәсе яныннан китмәделәр. Берсенең, авылга карап, револьверын болгый-болгый кычкырынганы, янаганы әле булса Габделнурның хәтерендә.

—Шушы Туган Йорт кешеләрен бөтенесен атып үтерәсе бар! Җыен саен кеше үтерәләр!

Монысын малайлар бигүк аңлап бетерә алмадылар. Чөнки андый хәлләр һәр елны булмый иде шикелле. Сугышу—була, кеше үтерү—гадәттән тыш хәл иде.

Шул көнне, кичке якта, Габделнурлар күршесендәге бер егетне арбасына салып алып кайттылар. Гөнаһ шомлыгына каршы, колхоз көтүен калдырырга кеше булмагач, ул җыенга бармаган һәм берьялгызы кайтып килгәндә теге авыл егетләренә тап булган. Аның карар җирен калдырмаслык итеп кыйнаганнар иде. Ул берничә ай урын өстендә ятканнан соң гына тернәкләнеп аякка басты.

Шул хәлләрдән соң Шәяхмәт тә, ике абыйсы да ябылуга эләктеләр.

Өч елдан Габделнурның апасы күрше авылның шушы егеткә—Насифка—кияүгә чыкты.

Җизнәсен Габделнур бик якын итте. Ул кара чәчле, уртача буйлы, гәүдәгә таза, нык бәдәнле, хәрәкәтләре җитез, йөзендә һәрчак елмаю. Өйгә килеп керсә, әби, бабай, дип үлеп тора, карт әбиләре белән дә сөйләшергә сүз таба. Каенишләрен һәм каенагасын—хатынының абыйсын—хөрмәт итә. Салып алса, гармун да тартып җибәрә, кеше уйнаса, кушылып та җырлый. Эшкә килгәндә, колхоз шоферлары арасында беренчеләрдән санала. Яшьли авылда һәм шахтада эшләп чыныккан егет иде.

Сөйләве буенча, аны мәҗбүри рәвештә «фызыу»га алганнар, аннары ул, яше унсигезгә җиткәч, бер ел шахтада, җир астында эшләгән. Армиядан соң да берничә ел күмер чабып бәхетен сынаган һәм, сагынуына түзәр әмәле калмагач, туган авылына кайткан. Армияда өйрәнгән шоферлык һөнәре колхозда бик ярап куя аңа.

...Өйләре каршына килеп туктауга, Насиф кабинадан сикереп төште дә, бәләкәй капканы ачып, солдатны ишек алдына уздырды. Веранда ишегенең биген шакылдатып, көр тавыш белән эндәште.

—Карчык! Гөлсылу! Чык, кайниш килде!

Кояштай балкып, өйдән Габделнурның апасы килеп чыкты.

—Кайниш, апаңны бик каты кочаклама!—диде җизнәсе авызын ерып.— Малайны имгәтә күрмә!

Кем әйтмешли, апасының корсагы борынына җиткән—түм-түгәрәк— баскычтан яны белән кырын-кырын, култыксага ябышып һәм аска карап төште.

—Исәнме, апаем,—диде ул энесенә ике кулын сузып.—Исән-сау кайттыңмы?

—Әйбәт кенә...

Өч ел күрмәгән, гәүдәгә тәбәнәкләнеп калган апасы белән Габделнур бик җылы күреште. Яшь чагында Гөлсылу бик чибәр иде. Ул әле дә матурлыгын җуймаган: шул ук кыйгач кашлар, биек маңгай, килешле туры борын, якыннарына үз итеп карый торган ачык коңгырт күзләр. Шулай да хәзер әзрәк төс салган: битенә вак, соры ком бөртекләре сыман сипкелләр чәчелгән, авызын йоммыйча сулыш ала, иреннәре кабарып-бүлтәеп тора. Кул кысуы элеккечә каты, карашы—ягымлы.

Аның белән бер-ике сүз алышкач, Габделнур җизнәсеннән сорады.

—Малай көтәсезмени?

—А как же! Кыз—бар. Хәзер малай кирәк.

—Ходай ни язган инде,—диде апасы уйчан гына.

—Ярар, кем булса да. Әйдә, кайниш, кулларыңны юарсың. Карчык, ашың әзерме?

—Ие.

—Тегесе?—дип күз кысты Насиф хатынына.

—Анысы да бар.

—Вот маладис минем хатын! Эш кешесенең кадерен белә.

Шулчак бәләкәй капка ачылды һәм курчак кебек кенә бер кыз бала, йөгереп килеп, әтисенә сарылды.

—Кызым, солдат абыең белән күреш. Карточкасын күргәнең бар бит.

Кызчык, сары чәчле башын чайкап, аскы иренен кысып, әтисенә сырпаланып, ятсынып торды. Әтисе тагын әйткәч, аның кочагыннан чыгып, Габделнурга килеп сыенды.

Солдат абыйсы аны култык астыннан күтәреп һавага чөйде...

Кечкенә булса да, башка чыккач яшьләр үзләре салып кергән йорт бик күркәм: шифер түбәле, урам якта—өч, ишек алды ягында ике тәрәзә, рамнары акка, наличниклары зәңгәргә буялган, бизәкләр төшерелгән. Үзенә күрә, җыйнак кына итеп, абзар, келәт, сарай ише каралты-кура да тергезгәннәр. Алардан читтәрәк тагын бер корылманың кыегы күренә.

—Җизнәй, әллә мунча да салдыгызмы?

—Быел өлгертеп булырмы-юкмы, күтәреп, түбәсен ябып куйдык.

Табын янында җизнәсе дә, апасы да Габделнурны кыстый-кыстый сыйладылар. Аш-су тәмле, кыздырган балыкка хәтле бар (елгалы авылның кунакларга куяр өчен үзенә күрә ят, затлы ризыгы), аш алды да мул иде— ир-атлар икесенә бер шешә бушаттылар.

Өй эче җиһазларына да күз салды кунак. Карават, шифоньер, өстәл, урындыклар—кибетнеке, ә идәнгә һәм караватка җәелгән паласлар—карчыклар кулыннан, тәрәзә пәрдәләре һәм башка чүпрәк-чапрак—апасы теккән-чиккән әйберләр иде.

Аштан соң Насиф ишегалдына чыгып, бакча буендагы эскәмиягә утыргач, ике рәтле хромкасын тартып жибәрде.

Аннары, бераз уйнагач:

—Олуг барда—телен тый, оста барда—кулың,—дип гармунын Габделнурга бирде.—Мәле, кайниш, «Шахта»ны сыздыр әле.

—Онытмаган булсам...

—Бөгештермә,—диде жизнәсе рәхәтләнеп көлеп.—Кичә син анда бер маржа кызын «эштән чыгаргансың» диделәр.

—Юк ла...

Габделнур кызарды, ахры.

—Мин, биеткәнсең, диюем... Маладис, анда бөтен ындыр табагы сөйли синең баянда ничек оста уйнаганны...

Габделнур жиңел сулап куйды. Ул уйный башлауга Насиф моңлы тавыш белән, ишегалдыннан читкә таралмаслык кына итеп, әкрен генә жыр сузды.

Шахтер егет күмер чаба,
Вак-вак итеп кисәген...

Бераздан ул жырлаудан туктады.

—Их, кайниш, андагы хәлләр төшкә керсә дә сискәнеп уянып китәм. Яшьлек юләрлеге белән эшләдек инде. Кырык сантиметрлы пластны, аркага ятып, кәйлә белән чапкан чаклар да булды... Ничек Ходай саклаган... Ну, аның каравы, акчасын да күрәп ала идек инде. Шуннан кайткан акчага өй салып кердек. Ничава, монда да эшләгән кешене күрәләр. Узган ел бабай белән икебезгә орден бирделәр. Икебезнең бер төсле... Келәт тулы ипи, малтуар да бар үзенә күрә...

Шуны раслагандай көтү кайтты: капкадан сыер, бәрәннәрен ияртеп сарыклар керде. Аларны әнисе белән бәләкәй кыз каршыладылар. Гөлсылу ап-ак чиләк тотып, ишек алдында ук сыер саварга кереште.

Шулчак капкада Насифның энесе күренде.

—Кунак бар икән,—диде ул абыйсыныкы кебек зур кулларын сузып.—Исәнме, кода. Дембельме?

—Юк әле,—диде Габделнур күрешеп.

Энесе гәүдәгә Насиф чамалы—эре сөякле, ләкин кыяфәте бераз үзгәрәкчәче сап-сары. Шушы авылда, төп йортта яши, быел гына өйләнгән.

Бераз вакыт ничек, ни белән кайту, армия хәлләрен (үзе дә вакытында хезмәт иткән) сораштыру булды.

Аннары ул кыяр-кыймас кына:

—Абый, бая синең кайтканыңны күреп калган ием,—диде.—Кода булгач, әйтүе дә читен... Капка баганасы утыртасы бар иде. Булышмассыңмы?

—Була ул,—диде Насиф берсүзсез.—Әзрәк жибәрәсеңме? Алып чыгам...

—Юк. Әле анда эш каты. Осталар бар. Соңынтын...

Габделнур:

—Мин дә барырмын,—диде.—Алыштырырга кием булса...

—Юкны сөйләмә,—диде жизнәсе.—Кунакны эшләтергә... Әллә син теге...

Энесе дә аның сүзен жөпләде.

—Килешмәгәнне... Анда кеше житә. Олы абый да киләсе.

—Син клубка чыгарсың,—диде жизнәсе Габделнурга һәм елмаеп өстәде.—Любой кызны озат, миннән рөхсәт.

*Ахыры киләсе санда*



Айрат
Суфиянов

# ТОТАШЫЙМ ЯКТЫ ТАҢНАРГА

## Иң олы бәхет

Таң аткан чакта, кояш чагылган
Чык белән юам күзем, битемне.
Әйтерсең җиргә яңадан туам...
Иң олы бәхет шушы бит инде.

Шагыйрь язмышы, ләззәтле язмыш,
Теткәли, йолка йөрәк итемне.
Бу татлы газап, бу татлы сагыш
Раббым бүләге—бәхет бит инде.

Аллаһ яраткан гөлләр исеннән
Үземне үзем мәхрүм итимме?!
Гөлгә сыенсам, Аңа сыенам.
Шушы сыену бәхет бит инде.

Сокланам карап җәйгор[1] төсенә,
Сокланам димәк Аллаһ көченә.
Җанымда—Коръән. Иман—җанымда
Яктырып китә күпкә аңым да:
Аллаһ—хакыйкать, шуны төшенәм.

Тынгылык тапмый, борчылып янам,
Ташып торганга илһамым тулып.
Аллаһ яраткан бу дөньялыктан
Китмәсәм икән мәҗүси булып.

[1] Җәйгор—салават күпере

Айрат СУФИЯНОВ (1958)—*шагыйрь; «Кылычлы җил» исемле китап авторы. Чаллыда яши.*

* * *

Кичә бергә булганнар да,
Якын дуслар, туганнар да,
Кызганыч, аерылган...
Милли моң йөрткән максатның
Канаты каерылган.

Әллә һәркем хакимлеккә
Омтылып, юл ярмакчы?
Үз мәнфәгатен кайгыртып,
Дәүләтен коткармакчы?
Көрәштәшен, яшьтәшен дә
Таптап узганнар күпме?
Бу түбәнлекнең дәвамы
Әллә соң гомерлекме?..

Аерылганны аю ашый,
Бүресе—бүленгәнне.
Без үлгәнне көтүчеләр
Күралмый бердәм гамьне.

Тартмый ла татар—тартарны,—
Татарны тарта аска...
Түбәтәй кигән башка да
Еш кына шайтан баса.

Кем нәрсә өчен көрәшә?
Ач күзең, аңлап кара.
Тыштан аклык чәчкәннең дә
Асылы төннән кара...

Көн үтте инде бүген дә,
Кояш та сүнә баеп.
...Кайда ышанып бассам да,
Аягым китә таеп.

* * *

Таш явамы, боз явамы,
Тау-ташлар ишеләме?
Әллә дөньялык туфанны
Исенә төшерәме?
Әллә инде язмышларның
Түземе тишелгәнме?
Әллә үлеп барамы соң
Кешелек—кешедәге?
Әллә елый, ятимсерәп,
Кояшлы көннәр яме?
Иреннәрдә бал тәмеме,
Әллә соң әрем тәме?
Тоз салып заман йөрәккә,
Ярасын әрнетәме?
Әмир булып башбаштаклык
Бирәме ахмак әмер?
Ил ятканмы, утырганмы,
Әллә соң, тезләнгәнме?
Тапты халкым, югалттымы
Үз жаны эзләгәнне?

Ничекләр җавап бирим соң?—
Аңлавын үзем аңлыйм.
Сүзләр кодрәтен җуямы?—
Аңлатып бирә алмыйм.
Әллә юкса, аңлыйм диеп,
Үземне-үзем алдыйм?
Аңлатып бирә алмыйм...

## Соңгы яфрак

Алтын көзнең сукмагына басып,
Матурлыкка карыйм, шашып-шашып.
Тормышны да аңлап тирәнерәк,
Дулкынланган чакта, әллә йөрәк
Һәр сулышка, хәрәкәткә гашыйк? —
Каным кайнап чыга калса, ташып,
Ходай Тәгаләгә якынлашып,
Китәр кебек җаным күккә ашып...
...Кәрван-кәрван уйлар кайта урап.
Шул халәттә мин дә акыллырак,
Яшәешнең сары көзен күреп,
Бәхилләшүнең дә күзен күреп,
Кадерлерәк күпкә баскан туфрак.
Дөнья фани, ул вакытлы торак.
Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз диеп,
Җиргә кадәр башкайларын иеп,
Каңгылдаша казлар... кыр казлары...
Туган якта кала авазлары:
—Кыйгак! Кыйгак! Юллар авыр, ерак...
Дөнья фани, ул вакытлы торак...
Чагылдырып карашында гүрне—
Мең бөре дә ача алмас серне,
Өзелгәндә мәңгелектән сорап,
Ачар кебек миңа соңгы яфрак!
Соңгы яфрак...

* * *

Туфрак кардан арчылганда
Шигырьгә кергән мизгел
Сөенде тормыш булып,
Карады, гүя, дөньяга
Балачак томырылып.

Яфрак булып өзелде дә
Шигырьгә кергән мизгел
Чайкалып торды өстә.
Гүя әйтергә теләде:
«Тереклек, сулыш өстә!»
Сары сагыш пәрәвезе
Йөрәкне телгән хистә.
Кайтара алмый үткәнне
Ялвару, үтенеч тә.

...Ике мизгел арасында
Уйланып янган гомер—
Шагыйрь гомере иде...
—Яшәдемме җирдә?—диеп

Бары бер сорау бирде.
Мәңгелек хәят алдында
Агарган башын иде...

* * *

Язар сүзләр—чиксез Галәм,
Язмышым—каләм.
Бер сүз яздым—бетте карасы.
Тетрәнеп тә, әрнүле дә карыйм
Дөньяга мин—адәм баласы.
Фатиханңы бирче, Хак Тәгаләм,
Шул бер сүздә килә каласым...

* * *

Кара төндә әгәр, бәгырем,
Кояш кирәк дисәң,
Бер йомарлам нәни кояш—
Мәхәббәтем исән!

* * *

Тоташыйм якты таңнарга,
Кара төннәргә түгел.
Булсын яктылык илчесе
Нурларга гашыйк күңел.

Кешеләрдән аклык табып,
Ачсам күңелем түрен,
Үзем дә күргән төслемен
Кешелеклелек үрен.

Күңел—галәм, кулда—каләм,
Уйлар—аңымны кочкан.
Гомер буе сыендым мин
Көч биргән ышанычка.

Өстән ямап, карагруһлар
Кискән чакта да астан,
Ышанам, бөтен кешедә
Үлмәс дип иман ачтан.

Изгелек эзләп күзләрдән
Ардыммы? Армадым ла...
Эзләгәнгә табыла ул,
Изгелек һәр адымда.

...Кемдер әйтә: ялгышасың
Инде ничәнче кабат...
Ялганырмын дип ышана
Иңнәрдә сынган канат—
Талгын гына күтәрелә
Инде ничәнче кабат.

Яшь аралаш елмаям мин
Һәр яңа таңга карап.
Инде ничәнче кабат...



# Наилә Миңнеханова

## «КЫЗЛАР ТАВЫ»Н ЙӨГЕРЕПЛӘР КИЧТЕМ...

### Күктән төшкәндә.

**Күктән җиргә очып төшкән мәлем:**
**Канатланган хәтта күләгәм...**
**Мең кат янып, мең сүрелгән жаным,**
**Әйтерсең лә, үлеп терелгән...**

**Тере җаным, ак фата ябынган**
**Кәләшмени дәртле куенда,—**
**Күктә хисап тотасын «онытып»,**
**Гөнаһларым туйлый уемда.**

**Пакъләнәсе җиңел булмас, беләм:**
**«Сыйлы» җирнең сансыз максаты...**
**Урынсыз сүз катып, әнә берәү**
**Күләгәмә басып туктатты.**

**Күләгәмә Кояш кадакланган,**
**Әйтерсең лә Коръән сүрәсе,**
**Пакъ күңелем алып китәр,шиксез,**
**Җирдән—күккә тиеп түбәсе.**

### Догалы кыш

**Әйтерсең лә тәсбих тарта галәм:**
**(Сыным белән мин ак нурга күмеләм!)**
**Бөтен җиргә ак намазлык җәйгән**
**Аллаһуга мактау сүзе белән.**

**Бер-берсенә үрелеп тереклек иткән**
**(Әлиф таягына охшаш икән!)**
**Урман-кырлар ак җирлек өстендә**
**Дога дәфтәредәй ачылып киткән.**

Наилә МИҢНЕХАНОВА—*шагыйрә; Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Башкортстанның Туймазы шәһәрендә яши.*

«Эш-көш»ләрдән җиңеләеп калган
Табигатьне бәйрәм төсе алган.
Бурап-бурап карлар ява гына!
...Һәр килгән кыш—укылмаган дога...

## Кичү

Бу кичүне җәяү атлап чыктым,
Тарымадым зарга әллә ни.
(Әүвәлгесен йөзеп чыккан идем...)
Арымадым болай әллә ни.

Чираттагы кичү—чокыр аша
Тигезлеген җуйган Җир йөзе.
Сынар өчен генә яратканмы
Мине әллә Раббыбыз Үзе?

...Текә таш кыялы «Кызлар тавы»н
Йөгерепләр кичтем төшемдә.
Кичүләрне югалтусыз кичү
Юрап, тибә йөрәк—түшемдә.

• • •

Өндәү билгеседәй табан эзе,
Әйтерсең лә дисбе чәчеп, тезә.
Биек үкчә... өндәве дә нечкә.—
Эзләр калмасыннар үкенечкә...
Эзләр—ия зур мәгънәви көчкә!

• • •

Синең миңа, минем сиңа
Хаҗәтем беткәндәй,
Бәрелеп-сугылып оча
Яфрак, көз киткәндә.

• • •

Мендәр сүрүедәй күңелемдә
Уйнык уйлар—«каурый өере»:
Тормыш егәреннән илһам алыр
Мизгелләрдә яшем төерле.

• • •

Сөю яше татлы,
Сөйгән җаннар затлы,
Изгелеккә тартым
Сөю—сөймәс шартны...

* * *

**Юктырсыңдыр, диеп уйламыймын.**
**Мин йөретәм сине уемда.**
**...Башкаларның, әнә, куенында!**

* * *

**Кан катыша икән сырхау җанда.**
**Катнаш никахлар мисалы?**
**...Сырхау, димәк, заманы да!**

* * *

**Теләк теләп тора—чуклы**
**Дисбе бүлмә түрендә:**
**Көнкүрешем чуктин-чуклы (мәгънәле!)**
**Догалар тәэсирендә...**

* * *

**Баш, бәрелгән саен ишегенә**
**Туган йортның, түбән иелә:**
**Аллаһ үзе ишарәли, гүя,**
**Хәләл көчнең бөеклегенә.**

* * *

**Тылмач белән кайткан татар, «табылып»...**
**Күршеләрнең кара мунчасыннан**
**чыгып килә,**
**Кызарынып... чабынып.**

* * *

**Тәндә чемердәгән наз-кайтаваз**
**Күккә йолдыз өстәп җемелди...**
**Якты уем белән ялгыз калып,**
**Бәхетләләр санын тигезлим.**



Гайсә
Гатауллин

## БЕЗДӘН СӘЛАМ БУЛЫР...

### Борынгы һәм бүгенге

«Бу дөньяда шундый хәлләр булып торыр»—
Карга-козгын түр башында урын алып,
Былбылларны һаман читкә куып торыр...

«Бу дөньяда шундый хәлләр булып торыр»—
Укымышлы барча кошлар арасында
Түрә булып чуар кыртлый тавык торыр...

«Бу дөньяда шундый хәлләр булып торыр»—
Ялт-йолт килеп мөнбәрләргә менгән түрә
Арзанлы бер корыкуык булып торыр...

«Бу дөнья шундый хәлләр булып торыр»—
Чүплекләрдә көн күргәндә күпме үксез,
«Яңа байлар» читтән карап көлеп торыр...

«Бу дөньяда шундый хәлләр булып торыр»—
Зиратларга илткән юллар киңәйгәндә,
Мәктәпләргә илткән юллар кимеп торыр...

...«Бу хәлләрне фәрештәләр күреп торыр»—
Югалырга йөз тотканмы бу кавем?—дип,
Күңелләре мөлдерәмә тулып торыр...

### Булмады...

Безгә шулай язгандыр инде:
Җылы диңгез ярларында
Каләмнәрне җылытып булмады...

Безгә шулай язгандыр инде:
Халык өлешенә керә-керә
Кесәләрне тутырып булмады...

---

Гайсә ГАТАУЛЛИН (1948)—*шагыйрь; балалар өчен язылган «Этнең койрыгы ник кәкре», «Тавык иле һәм батыр черки», «Очар кошлар кебек» исемле китаплар авторы. Арчада яши.*

Безгә шулай язгандыр инде:
Ялтыравыклы иномаркаларда
Җилләр белән узышып булмады...

Безгә шулай язгандыр инде:
Бишәр катлы коттеджларда
Хатын белән куышып булмады...

Кайгырмыйбыз!
Хәере белән булсын, дип булганы—
Иртән торабыз да, укыйбыз...
Догабызны!

* * *

Кызыкмагыз:
«Халык каргышын җыйганнар
Рәхәт яши, диеп, бу дөньяда...»

Ул каргышның бер мыскалы
Бер поттан да арта, ди бит,

Теге—
Кылдан нечкә күперне чыкканда!!.

## Саубуллашу

Ярый, матурым, хәерле көннәр,
Атналар-айлар телим мин сиңа!
Тезелеп килгән яз һәм җәйләрең
Алсу гөлләр тик сипсен юлыңа!

Ә көзләр сиңа килмәс, билгеле:
Чөнки көзләрне мин алып китәм.
Каралтмас инде якты юлыңны
Минем шәүләм дә... Тыныч бул, иркәм!

Яшьләнеп китсә бераз күзләрең,
Нурга төренеп атлап барганда:
«Шулай тиештер,—диген, сер бирмә!—
Яңгырлар да бит, килеп, бер ява»...

## Серле дөнья...

Басуларга чыксаң—күпме серләр!

...Динозаврга әйләнеп
Сикерешеп өскә килер кебек
Былтыргы эскертләр...

* * *

**Әйтер сүзен әйталмыйча,**
**Мәңгелеккә алып киткәннәрнең—**
**Үз итмиләр, бәлки**
**Хәтта гөлләр—каберләрен?!.**

* * *

*Чыгар кояш—сибәр нурын,*
*Бездән сәлам шул булыр...*
Халык җырыннан.

**Хисләремне яза-яза,**
**кайнап, чыкка—**
**Парга әйләнәм инде...**

**...Алсуланып чыкса иртән Кояш—**
**Чык нурларыннан эзләрсез**
**Минем дә сәламемне...**

* * *

**Исми калган җилнең канатлары**
**Каерылып калган киң кырларда...—**
**Килми калган болытларның**
**яумый калган**
**Тамчылары тама...**

---

## Киләсе санда укыгыз


«Казан утлары»ның 11 нче саны кызыклы һәм бай булачак.

Проза яратучыларны **Рауль Мирхәйдәровның** «Үзем хөкем итәм» исемле романының дәвамы, **Рәфкать Кәраминең** «Олы юл да сикәлтәле» романының ахыры һәм **Вакыйф Нуриевның** «Жиденче палата» повесте сөендерәчәк.

Шигърият бүлегендә **Салисә Гәрәева, Бикә Рәхимова, Рөстәм Кутуй, Хәмит Латыйфның** яңа шигырьләре һәм яшь шагыйрә **Йолдыз Миңнуллина** иҗаты белән таныша аласыз.

Сара Садыйкованың 100 еллык юбилее уңаеннан **Рафис Әхмәт** мәкаләсе һәм Г. Камал театрының танылган актеры **Әзһәр Шакировның** «Артист язмалары» сәнгать бүлегендә урын алган.

Күренекле әдип **Мөхәммәт Мәһдиев** көндәлекләре, **Рафаэль Хәкимнең** төрки-татар цивилизациясе хакындагы публицистик мәкаләсе, күптәннән басылып килүче «Миллият сүзлеге», «Авылларыбыз тарихы», «Татар энциклопедиясе битләреннән» һ.б. кызыклы язмаларны журналыбызның киләсе санында укый аласыз.



Равил Бикбаев,
Башкортстанның халык шагыйре

# МӘХӘББӘТ ДӘФТӘРЕ

Татар халкының каһарман шагыйре Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре» дөньяны яңгыратты, ничәмә дистәләрчә телләргә тәрҗемә ителде, илләрне һәм кыйтгаларны җыр булып урады.

Тоткындагы шигырьләрен Муса Җәлил мәхәббәткә табынып, сөю хисләре белән канатланып яшәр яшендә—гомеренең яңадан-яңа уй-хыяллар белән канатланыр чагында язган. Ләкин фашистлар Муса Җәлилне азатлыктан мәхрүм итсә дә, мәхәббәттән аера алмаган.

«Моабит дәфтәре» дигән сүзләр миңа кайсы чакта «Мәхәббәт дәфтәре» булып ишетелә. Әйе, чынлап та, «Моабит дәфтәре»—ул бит бөек мәхәббәт дәфтәре. Муса Җәлилнең тоткынлыкта иҗат ителеп, могҗиза белән сакланып калган йөзәрләгән шигырьләре бергә тупланып, гадәти җыентыкны гына тудырмый, алар канатлы сөю җырына, каһарман мәхәббәт дастанына әйләнә.

Әйе, «Моабит дәфтәре»—мәхәббәт дәфтәре ул. Тирә-ягын күзләре аларынган ерткычларның шашынган нәфрәте уратып алганда да, шагыйрь хәйран калырлык мәхәббәт поэмасы иҗат иткән.

*Бар җырымны илгә багышладым,*
*Гомеремне дә бирәм халкыма—*

бу канатлы сүзләрне шагыйрьнең Ватанга тугрылыгы, туган халкына кайнар сөюе тудырган.

Караңгылыкта туган яктылык, зинданнан бөркелгән нур, боз эчендә кабынган ялкын—«Моабит дәфтәре»нең һәр юлын мин менә шулай атар идем. Канатларын каерсалар да, канатларына ташлар таксалар да, иленә һәм халкына булган тугры мәхәббәте шагыйрь рухын илаһи биеклекләргә күтәрде.

*Мин тез чүкмәм, катыйл, синең алда,*
*Кол итсәң дә, тоткын итсәң дә,—*

Муса Җәлил бу сүзләренә соңгы сулышына тиклем тугры калды. Катыйл аның рухын кол итә алмаган.

Ирек сөючә күпме шагыйрьләрне дөнья хакимнәре зинданнарга бикләгәннәр. Ләкин анда да җыр үлмәгән. Дөнья әдәбияты тоткынлыкта иҗат ителгән асыл әсәрләрне хәтерендә саклый.

Ләкин фашист төрмәсендә Муса Җәлил тудырган көрәш һәм мәхәббәт җырлары шәхес ихтыярының ныклыгын раслаучы, шагыйрьнең тугрылыгын һәм батырлыгын мәңгеләштерүче тиңдәшсез һәйкәл булып кала.

*Соңгы җырым палач балтасына*
*Башны тоткан килеш языла,—*

бу сүзләр образлы мәгънәдә генә әйтелмәгән, шагыйрьнең күпме көннәре һәм төннәре шушы фаҗигале хәлдә үткән бит. Андый дәһшәтле шартларда кечкәй генә васыять кәгазе язар өчен генә дә күпме көчеңне һәм ихтыярыңны тупларга кирәк. Кеше рухы мондый авырлыкларга дучар булганда таралып төшсә дә, күнеле сынса да гаҗәп түгел.

Муса Җәлил исә башына балта терәгәндә дә үлемсез җырлар иҗат итә. Берәү генә дә түгел, унау гына да түгел, йөзләгән шигырь язып калдырырлык бөек көчне шагыйрьгә, әлбәттә, Ватанга тугрылык һәм туган халкына мәхәббәт бирә. Гасырларны тетрәндерерлек язмыш! Таш диварлар кысымында сүзләр алмаска әйләнә.

Муса Жәлилнең бүгенге йөз еллык тантанасына мин башкорт язучыларының ихлас теләкләрен, Башкортстан Республикасының олы ихтирамын алып килдем.

Муса Жәлил егерменче-утызынчы елларда башкорт әдипләре белән аралашып яшәде. Ырымбурда Муса минем авылдашым, кардәшем, азак күренекле галим һәм шагыйрь булып танылган Габдулла Амантай белән комсомолда бергә эшләде, иҗади бәйләнешләрен артабан да өзмәде.

Муса Жәлилгә Башкортстан илһамлы көннәр бүләк итте. Безнең гүзәл Өфебезгә, Агыйдел, Дим буйларына, ул башкортның җәннәттәй табигатен, башкорт кымызын гына түгел, Башкортстан кызын да сагынып килде. Шагыйрь хакында дөреслек өскә чыккач, Муса Жәлилнең «Моабит дәфтәре» 1954 елда Мостай Кәримнең баш сүзе белән башкортча басылды.

Сабакташы Сәгыйт Агиш Муса Жәлилгә багышлап «Якташлар» повестен, Нәҗип Асанбаев «Канат җәйгәндә» пьесасын язды.

Башкорт шагыйрьләренең Муса Жәлилгә арналган шигырьләре, бездә дөнья күргән истәлекләр, быел шушы көннәрдә шагыйрьнең йөз еллыгын каршылаганда республикабыз матбугатында киң урын алган мәкаләләр үзләре калын китап булырлык. Башкорт халкы башка милләт шагыйрьләренә булган шундый зур ихтирамын Муса Жәлилгә тиклем бөек Пушкинга һәм бөек Тукайга карата гына әйтә алган иде.

Муса Жәлилгә Советлар Союзы Герое исеме бирелү турындагы шатлыклы хәбәрне мин туган якларымда—Ырымбур далаларында юлда, кышкы каникулдан Акбулак педучилищесенә поезда китеп барганымда ишеттем. Шул вакыттан бирле Муса Жәлилнең батыр образы минем аңыма юл белән, хәрәкәт белән бергә уелып калган. Моннан нәкъ илле ел элек, минем буын иҗат дөньясына әле тәүге адымнарын ясаганда, безнең өчен Муса Жәлил исеме аеруча абруйлы булды. «Моабит дәфтәре»нә кергән шигырьләр белән танышу безнең өчен югары иҗат мәктәбенә, Ватанга тугрылык үрнәгенә әйләнде.

Каһарман татар шагыйре Муса Жәлилнең бүгенге йөз еллык тантанасы илебездәге олы бәйрәм—Ватанны саклаучылар көне алдыннан үтә. Нинди матур һәм мәгънәле туры килү! Бүген дә Муса Жәлил сөекле илен, газиз милләтен саклаучылар сафында, туган телен яклаучылар сафында кала. Ватанны саклау бер көнлек кенә вазифа түгел, һәр шәхеснең гомерлек бурычы икәнлеген раслап, көрәш юлында кала. Ил өчен башларын салганнарның газаплары һәм бөеклекләре алдында бүгенге бик күп ыгы-зыгылар бөтенләй вакланып югалырга, изге максатларны онытып җибәрүләр сәер генә түгел, гөнаһ булып күренергә тиеш. Ил азаматы Муса Жәлилнең шигъри аманатлары егерме беренче гасыр кешеләрен мәңгә шул хакта искәртә. Аманатка хыянәт итү безнең халыкларның гадәтләрендә юк. Ил таяныр ир-егетләрнең аманатларына тугры булу, аларның изге эшләрен дәвам иттереп, халык хәстәрен хәстәрләп яшәү—шушыннан да мөкатдәсерәк хезмәт, шушыннан да бәхетлерәк язмыш бармыни? Шушы бәхетебездән аермасын, кадерле туганнар!

* * *

**Күрше хакы—тәңре хакы,**
**Күршең—күзең карасы.**
**Савыктырсын ил ярасын**
**Өфө—Казан арасы.**

**Башкорт белән татар сымак**
**Җирдә якын зат булмас.**
**Башкортлар азат булмаса,**
**Татар да азат булмас.**

**Татарга да ябырылыр**
**Башкортка килгән бәла.**
**Татарга төбәлгән пушка**
**Башкортка да төбәлә.**

**Атсалар бергә атарлар,**
**Асарлар бер үк дарга.**
**Сак булаек,**
**Кагылмаек**
**Авырткан яраларга.**
**Йә бергә-бергә атларга,**
**Йә бер түмәргә ятарга**
**Башкорт белән татарга!**

*Казан. 22. 02. 06.*

Рафаэль
Хәким

# ТАТАР РУХЫ

*"Аларның гадәттән тыш бөеклегенә һәм мәртәбәле хәленә күрә бүтән төрки ырулар, дәрәҗәләре һәм исемнәре төрле булса да, алар исеме белән мәгълүм булдылар һәм барысын да татарлар дип йөрттеләр. Аларның төрле ырулары үз бөеклеге, үз абруе үзләрен алар дип санауларында икәнлекне аңладылар һәм алар шул исем белән билгеле булдылар, хәзерге вакытта Чыңгыз хан һәм аның нәсел-ыруы идарә иткәнгә күрә (чөнки аларның асылы монголлар) җалаирлар, татарлар, айратлар, онутлар, кераитлар, найманнар, тангутларише күп кенә төрки кабиләләр, һәрберсенең үз исеме һәм махсус кушаматы булса да—алар барысы да, электә бу исемне танымасалар да, мактанышып, үзләрен монголлар дип атыйлар бит—шуның кебек".*

*Рәшидеддин. "Җәмигъ-әт-тәварих"*
*1330-1311 еллар.*

## Этноним язмышы

Теләсә нинди этноним метаморфозалар, ягъни үзгәрешләр, әверелешләр кичерә, вакыт-вакыт алар шулкадәр катлаулы була ки, башлангыч тамырларын эзләп табу да кыенлаша. Йә, кем әйтеп бирә ала: "рус" (русские) дигән этноним каян килеп чыккан? Варяглардanмы, әллә славяннарданмы? Һәм ни өчен халык исеме сыйфат белән белдерелә, башка халыкларда бит "татарныкы" яки "французныкы" димиләр, алар—татарлар, болар—французлар...

"Татар" этнонимының язмышы шактый катлаулы. Башлап бу атаманы Бөек Кытай диварыннан төньяктарак яшәгән халыклар йөрткәннәр. Аларның көч-куәтенә карап, кытайлар Кытайдан төньяктарак яшәгән барлык халыкларны татар дип атый башлаганнар, ә территориянең үзе "Дәште Татар"—"Татар җире" дип исемләнгән. Кытай тарихчылары исәпләвенчә, "татар" термины җыелма мәгънәгә ия. Э. Х. Паркер "Татарлар тарихыннан мең ел" дигән хезмәтендә, Кытай хроникаларына таянып, гуннарны һәм һуннарны, аварларны, төркиләрне, сяньбийларны татарлар дип атый.[78] Ул заманнарда без уйлаган мәгънәдә этниклык та, милләт тә булмаган. Кабилә-ырулар җиңел генә килеп кушылганнар да, җиңел генә аерылып та киткәннәр, кабиләләр үзара берлекләр оештырганнар, ә нәсел-нәсәбәләрнең яисә юлбашчыларның исемнәре этносларның атамасына әверелгән. Шул ук вакытта тел һәм мәдәният элеккегечә кала алган.

Кайбер белгечләр фикеренчә, иң борынгы татарлар монгол телендә сөйләшкәннәр, әмма Рәшидеддин, шул заманның иң абруйлы тарихчысы, алар-

[78] Э.Х. Паркер. Тысяча лет из истории татар. – Казань, 2003, с.193.

*Дәвамы. Башы журналыбызның 7-9 саннарында.*

ны төркиләр дип санаган. Монголлар тарихи хроникаларда татарлардан соң берничә гасыр соңрак искә алыналар. Мәхмүт Кашгари, төрки телләр буенча зур гыйлем иясе, татарларны бары тик төркиләргә генә кертә һәм "Дәште Татар"ны Төньяк Кытай белән Көнчыгыш Төркестан арасына урнаштыра.

Гоби чүленнән көньяктарак яшәгән күчмә халыкларны "ак татарлар" дип йөрткәннәр. Аларның күбесен төрки телле онгутлар тәшкил иткән. "Кара татарлар", шул исәптән кераитлар да, мәдәни үзәкләрдән ерак далаларда яшәгәннәр. Алар төнгелеккә арбаларын божра итеп тезгәннәр дә үзенә күрә бер ыстан корганнар. Көньяк Себернең "кыргый татарлары" аучылык һәм бакчачылык белән көн иткәннәр, аларны аксакаллар—өлкәннәр идарә иткән, аларның ханнары булмаган. Төрле татар дәүләтләре (Кытай һәм гарәп елъязмачылары шундый алты дәүләт булган дип санийлар) барлыкка килгәнгә күрә, "татар" этнонимы политонимга әверелгән, бу атама күп кенә монгол һәм төрки телле халыкларга таралган. Һәм соңрак, Чыңгыз хан бөтен дөньяда монгол яулап алучысы буларак дан казангач та, кайбер тарихчылар аны татар дип атыйлар, этник яктан туры килмәсә дә, бу Кытай традициясенә туры килгән. Торабара бөтен Евразияне "Тартария" белән тиңләштергәннәр, бу урта гасырлар карталарында нәкъ шулай.

Чыңгыз хан заманындагы монголлар исә үзләрен татарлардан аерып йөрткәннәр, алар бит идарәче катлам булган, гаскәрләрнең иң өске катламын тәшкил иткәннәр, меңбашларның күбесе монголлар арасыннан сайлап куелган, шул сәбәпле татарлар дип әкренләп төрки телле яугирләрнең төп өлешен һәм халыкны атый башлаганнар. 1236 елда Урал алды җирләрен буйсындыруның шаһиты булган венгр монахы Юлиан болай дип белдерә: "Яулап алынган барлык патшалыкларда алар үзләрендә шик тудырган кенәзләрне һәм вельможаларны шунда ук үтерәләр... Яу чыгарга яраклы гаскәриләрне һәм тыныч халыкны коралландырып, ирексезләп үзләреннән алда яуга кертәләр. Яу чабарга яраксызларын җир эшкәртергә калдыралар... һәм аларга үзләрен татар дип атарга кушалар". Башта ясалма политоним булган нәрсә соңыннан мәдәни һәм тел бердәмлеге белән ныгытыла. Моңа Алтын Урданың мөстәкыйль дәүләт буларак формалашуы ярдәм итә, аның мәдәнияте гаять көчле була, шуңа күрә дә ул көчсезрәк халыкларны үз орбитасына суырып ала. Калганын уртак үзаң һәм кыпчак диалектына[81] нигезләнгән дәүләт теле эшләп бетерә, нәтиҗәдә урта гасырларның яңа бергәлеге булган "татарлар", төгәлрәге "төрки-татарлар" барлыкка килә.

Татар теленең кыпчак теле белән якынаюы татарлар нигез салган һәм кыпчаклар килеп кушылган Кимәк каганлыгы кысаларында VIII-IX гасырларда ук башлана. Иң гаҗәбе шул: телләре төп телгә әверелгән кыпчаклар халык буларак яшәүдән туктыйлар. Әл-Гомәри "Дәште Кыпчак" турында болай дип яза: "Борын заманда бу дәүләт Кыпчаклар иле иде, әмма аны Татарлар яулагач, Кыпчаклар алар буйсынуында булалар. Аннары алар белән туганлашып бетәләр һәм бу җирләр аларның [Татарларның] табигый һәм раса сыйфатларыннан өстен булып чыга һәм алар барысы да Кыпчакларга әверелә, гүя бер ырудан чыкканнар диярсең".[82] Кыпчак тамырларын татарлар арасында табарга мөмкин булган кебек үк казакъларның да, үзбәкләрнең дә, нугайларның да, башкортларның да һәм хәтта русларның да (аеруча казаклар арасында) нигезен кыпчаклар тәшкил итә.[83] Тагын бер куәтле этнос—болгарлар этносы да татарлар,

---

[81] Франческо Пеголотти (1340 ел) "Сәүдә эше" ("Торговое дело") дигән китабында Алтын Урдага сәүдә эшләре белән йөрүче сәүдәгәрләргә тәрҗемәче, куман ягъни кыпчак телен бик яхшы белгән, кем дигәндә, ике хезмәтче ялларга киңәш итә. "Codex Cumanicus" 1303 елда Венеция сәүдәгәрләре өчен кулланма буларак төзелә.

[82] Золотая Орда в источниках..., 259, 406, сс. 408.

[83] Лев Гумилев болай дип яза: " Безнең бабаларыбыз кыпчак ханнары белән дуслашканнар, "чибәр кыпчак кызлары"на өйләнгәннәр, чукынган кыпчакларны үз араларына алганнар, әлеге чукынган кыпчакларның бабалары Запорожье һәм Бистә казакларына әверелгән, гадәти славян суффиксы "ов"ны (Иванов) төрки "енко"га алыштырганнар (Иваненко)". Карагыз: Л.Гумилев. Черная легенда...,1126. Сергей Кляшторный, традицион фәнни әдәбияттан аермалы буларак, половецларны һәм кыпчакларны аера, шулай да тегеләрен дә, боларын да төркиләргә кертә.

чуашлар һәм славянлашкан Дунай болгарларында эреп юкка чыккан. Әмма кайбер этнослар локаль үзенчәлекләрен этнографик төркемнәр сыйфатында саклап калганнар.

Теләсә кайсы халыкның состав өлеше катлаулы һәм еш кына күп җепләр белән бүтән этносларга барып тоташа. Татар белән чуашны тамырларында болгар каны булу берләштерә. Башкортларны нугайлардан (нугай татарларыннан) "үткен аналитик акыл" [84] гына аера ала, шул ук вакытта алар барлыкка килүдә татарлашкан мадҗарлар (венгрлар) шактый роль уйнаган. Плано Карпини башкортларны мадҗарлар белән тәңгәлләштергән: "башкортлар—алар бөек венгрлар ("basgard id est Magna Hungaria"). Гийом де Рубрук белдерүенчә, Башкортстан халкы инде XIII гасырдан ук венгрларга аңлаешлы үз телен саклап калган.[85] Урта гасырларның күренекле тарихчылары Әл-Җүвәйни һәм Рәшидеддин Көнчыгыш Европа венгрларын "башгирдлар" дип атаганнар. "Патша уллары башгирдларның, мадҗарларның һәм сасаннарның барлык өлкәләрен яулап алганнар, аларның патшасы, келаре (короле) качып киткән, җәйне Тиса елгасы буенда уздырганнар",—дип яза Рәшидеддин венгрларны һәм саксоннарны буйсындыру турында.[86] Кайвакыт елъязмачылар венгрлар белән бергә төрки телле кабиләләрне дә башкортлар дип атаганнар.

Татарларны һәм нугайларны совет чорында гына төрле халыклар дип саный башлаганнар, әмма әлегә кадәр Үзәк Азиядә татарларны нугайлар дип атыйлар. В. Трепавлов болай дип яза: "Нугай" этнонимы вәкилләре тирә-юньдәге барлык халыкларның составына кергәннәр. Күршеләре нугайларны юкка гына полиэтник бергәлек дип бәяләмәгәннәр инде һәм бу этноним белән төрле этнос вәкилләрен атаганнар. Кырым ярымутравыннан читтәге далаларда яшәүче Кырым татарларының төньяк төркемен дә нугай дип йөрткәннәр; казакълар өчен *нугай*—башкортлар һәм Идел буе татарлары; башкортлар һәм казакълар өчен элегрәк вакытларда *нугай*—Себер татарлары; калмыклар өчен *ииштиг мангад (*ягъни иштәкләр—мангытлар)—башкортлар, ә *уулун мангад* (тау мангытлары)—балкарлар, карачайлар һәм башкалар"[87],—дип яза.

Бүген без нугайлар белән татарлар арасында аерма күрәбез, ә бит урта гасырларда аларны бер халык дип санаганнар. Шул елларның бер рус китабында болай диелгән: "Ул үзе (Мөхәммәт Гәрәй) Кырым татарларын яратмый башлады, әмма нугай татарларын бик ярата башлады, алары аның бик күп һәм ул аларны үзенә якынайтты һәм үзенә яхшылык эшләүчеләр дип саный".[88] Күргәнебезчә, монда нугайларны далаларда, ягъни билгеле бер үзенчәлекле территориядә яшәүче татарлар буларак кабул итәләр. Кайвакыт татарлар белән нугайларны хуҗалык итү рәвешенә карап аерганнар. XIX гасырда хәтта Кырым бакчачысын һәм игенчесен—татар дип, ә Перекоп аръягындагы чабанны нугай дип йөрткәннәр.

Төрки халыклар үзара тугандаш кабиләләрдән җыелган. "Идегәй" дастаны түбәндәге сүзләр белән башлана:

*Борын үткән заманда*
*Болгар белән Сарайда,*
*Җаек белән Иделдә,*
*Алтын Урда, Ак Урда –*
*Данлы кыпчак җирендә,*
*Татардан туган Нугай илендә,*
*Туктамыш дигән хан булды.*

[84] Алтын Урда таркалганнан соң 1570 нче елларга кадәр башкортларны нугайлар идарә иткән.
[85] Рубрук Г. Путешествие в восточные страны. – М., 1957, с.122.
[86] Золотая Орда в источниках..., сс.259, 406, 408.
[87] В.В.Трепавлов. История Ногайской орды..., сс.650-651.
[88] В.В.Трепавлов. История Ногайской орды..., с.168.

"Төрек" этнонимы[89] тел һәм мәдәният бергәлеге нигезендә V йөз азагында кабиләләр кушылуы нәтиҗәсендә оешкан. Этнонимның таралуы Ашина ыруыннан башлана, ул Төрки каганаты башында торган. Галимнәр фикеренчә, Ашина ыруы башта төрек тирәлегенә эләккән сяньбий (төрки һәм монгол кабиләләре конгломераты) чыгышлы булган. "Суйшу" кытай тарихи елъязмаларында болай дип язылган: "Туцзюэ (төркиләрнең) бабалары Пинлянның катнаш *хулары* (һуннары) булган. Аларның ыру кушаматы ашина. Төньяк Эй императоры Тай У-ди Цзюйцюйны юк иткәч (439 ел), Ашина бишьйөз гаиләсе белән жуҗуга (жужалыларга) кача. Алар Цзиньшань (Алтай) таулары итәгендә ырудан ыруга күчеп яшәгәннәр һәм тимер эшкәртү белән шөгыльләнгәннәр". Әсән-шад, "бөек ябгы" Туу һәм Бумын җитәкләгән кабиләләр төркеме 551-555 елларда Җуаньҗуань каганлыгына җимергеч һөҗүм ясый һәм бу чорны Төрек каганлыгы барлыкка килү вакыты дип санап була.

Төркиләр яшәгән ареалларда, чыганаклардан күренгәнчә, төрле этнимнар искә алына, әмма чынлыкта исә әледән-әле тегә яисә бу ыру өстенлек итә һәм хәтта халыкка яки дәүләткә исеме дан казанган юлбашчы исеме бирелә. "Он-огуз", "докуз-огуз" этнонимнары тугыз-ун кабилә дигәнне аңлата. "Уйгыр" этнонимы—шул ыру исеменнән, "карлук" шушы җирлек исеменнән килеп чыга. Хәтта күп кенә гасырлар узгач та, Алтын Урда дәверендә шундый күренешләрне күзәтергә була. Нугайлар үзләре дә исемнәрен Нугай бәк исеменнән алганнар. Алтын Урданың фанатик мөселманнары үзләрен XIV гасырда Үзбәк хан хөрмәтенә яңа исем белән "үзбәк" дип атаганнар, 1428 елда Төмән Урдадан аерылып чыга, анда Әбел-хәер хан һәм аның олысы үзбәк "халкы вә олысы" дип исемләнгән. Алтын Урда белән көрәшендә аларны Аксак Тимер файдаланган. Урта Азиянең үзендә ул заманнарда үзбәкләр дигәндә көнчыгыш "Дәште Кыпчак"ның күчмә кабиләләрен күз алдына китергәннәр. XVI гасыр башында Исфахани бу хакта болай дип яза: "Өч кабиләне үзбәкләргә кертәләр, алар барысы да Чыңгыз хан биләмәләрендә данлыклы. Бүген (шуларның) берсе шәйбанилар... Икенче кабилә—казакълар, алар бөтен дөньяда көч-кодрәтләре һәм батырлыклары белән атаклы, ә өченче кабилә—мангытлар...".[90] бу очракта, В. Трепалов фикеренчә, Себер мангытлары дигәндә мангытларга бүлеп бирелгән җирләрдәге кыпчаклар дип аңларга кирәк.[91]

Үзбәк берлегендә Әбелхәер исән чакта ук киләчәк казакъларның үзәге барлыкка килә башлый. Габделразак Сәмәркандии 844 елда: "Вакыт-вакыт казакларга әверелгән үзбәк гаскәреннән бәгъзеләре мазандаранга киләләр һәм, бөтен җирләрне талап, кире китәләр иде".[92] Кайчак аларны тарихи елъязмаларда үзбәкләр-казакълар дип йөртәләр. Җучи хан улы Шәйбан үзе, тарихчысы раславынча, үзбәк дигәндә—Шәйбан олысының күчмә кабиләләрен, ә казакълар дигәндә Урда-Ичен олысы күчмәләрен күз алдында тоткан, алар бер-берсеннән этник яктан бик аз аерылганнар. XVI гасырда гына Әбелхәер оныгы Шәйбани хан, Сәмәркәнд белән Бохараны яулап алып, тимурчылар дәүләтен буйсындыра һәм "үзбәк" исемен Урта Азия төркиләренә дә тарата. Шул заманда ук татарлар, үзбәкләр, казакълар арасында реаль аерымлыклар барлыкка килә.

Хәзерге дәвердә этносларның атамалары яшәү урыннарына бәйле рәвештә килеп чыккан. Себердә яшәгән төрки-татарлар—"Себер татарлары", Кырымда яшәүчеләр—"Кырым татарлары", Әстерханда—"әстерханлылар", Мещера җирендәгеләр—"мишәрләр"[93], башкорт җирендәгеләр—"башкортлар" һәм башкалар. Кайсыдыр халыкларда—кыпчак "каны" күбрәк дию белән, кайберләрендә—болгарлар йогынтысы көчлерәк дию белән, кайдадыр—хәзәрләр

---

[89] Риваятьләргә караганда төрек атамасы Алтай тауларының җирле исеме белән бәйле.

[90] Фазлаллах ибн Рузбихан Исфахани. Михман-наме-ий Бухара (Записки бухарского гостя). – М., 1976,с. 47.

[91] В.В.Трепавлов. История Ногайской орды..., с.487.

[92] Золотая Орда в источниках..., с.381.

[93] Бөек кенәз Василий Мещера җирендә татарларга Олуг Мөхәммәд улы Касыйм өчен махсус җир бүлеп бирә, аны "Касыйм ханлыгы" дип атыйлар.

чагылышы тирән булу белән, бәгъзеләрендә—угыр "каны" көчлерәк булу белән килешергә дә мөмкин. Бүген гомер сөрүче төрки халыклар—шушы ук кабиләләрнең катнашмасы. Дөресен генә әйткәндә, алар барысы да төрки-татар сөйләменең гаҗәеп тотрыклыгына нигезләнгән бердәм мәдәният вәкилләре.

Табигатьтә саф этнослар булмый. Һәр халыкта күп кенә кабиләләрнең һәм этносларның состав элементлары була. Садри Максуди фикеренчә, "Туры-дан-туры этник, ыру яисә кабилә дәвамчылыгын, этник тәңгәллекне борынгы һәм урта гасырлар төрки кабиләләре, шулай ук урта гасырлар һәм хәзерге этник төрки берәмлекләр арасыннан эзләү бернинди уңай нәтиҗәгә китермәячәк".[94] Шуңа күрә дә без борынгы һәм урта гасырлар тарихы турында сөйләгәндә "татар цивилизациясе" терминына караганда "төрки-татар цивилизациясе" термины кулайрак. Мондый термин тарихны тар этник аңлатудан качарга ярдәм итә, аны объективлаштыра һәм төрки халыкларның тыгыз бәйләнешен аңлатып бирә.

Алтын Урда таркалганнан соң һәм күп санлы төрки-татар халыклары барлыкка килгәч, территориаль аерымлыклар тагын да ачыграк чагыла башлый. Ак Урда нигезендә казакълар барлыкка килә, Үзәк Азиядә төрки телгә фарсы теле йогынты ясый һәм хәзерге үзбәк теле барлыкка килә, Кырым татарлары, төрек (угыз) мәдәниятенең күп элементларын үзләштереп, озак вакытлар Госман империясе протекторатында булалар, ә бүтән этник төркемнәр чагыштырмача изоляциядә калалар һәм локаль үзенчәлекләрен үстерәләр. Бүген аларны әзәрбайҗаннар, кумыклар, балкарлар, карачайлар, нугайлар һ. б. дип атыйлар.

Төркиләрнең тагын да бүленеше һәм хәзерге милләтләр нигезендә яңа халыклар барлыкка килү тәгәлләнгәнгә ошый. Ахыр чиктә, Россиядә 2002 елдагы халык санын алу барышында татарлардан керәшеннәрне, Себер һәм башка татарларны аерып чыгару нияте уңышка ирешмәде. Төрки цивилизацияне этник ваклауга тарих үзе нокта куйды, глобализация дә , күп кенә халыкларны инглиз-саксон мәдәнияте тарафыннан йотылу алдына китереп бастырып, вәзгыятьне бик кискен үзгәртте. Хәзерге заман процессларының басымы астында төркиләр реинтеграция юлларын һичшиксез эзли башлаячаклар.

Әлегә кадәр татарларның киң катламнары да, галимнәре дә халыклар арасындагы аермаларны гына эзлиләр иде, аларны уртак сыйфатлар кызыксындырмый иде. Акыл сатулар мәгънәсезлеккә әверелә иде—кайбер авазларны әйтү үзенчәлегенә карап, үзенчәлекле диалект булу турында нәтиҗәләр ясала иде. Мондый анализның методикасы нинди мәгънәгә ия соң? Бернинди мәгънә дә юк. Бу бары тик провинциаль аң рудиментлары гына, тикшеренүләрнең тарлыгы, галимнәргә республикадан читкә чыгарга рөхсәт булмау гына. Диалектлар белән фән тирәсендәге күнегүләр совет галимнәре даирәсендә генә аңлашыла, дөньяда бу термин башка мәгънәгә ия. Лингвистика буенча безнең мәкаләләрне чит телләргә тәрҗемә иткәндә җитди терминологик шәрехләр таләп ителә. Әгәр аларны турыдан-туры тәрҗемә итсәң, чит ил кешеләре минзәләлеләр Казан арты татарларын аңламый икән дип уйлаячаклар, ә мишәрләр калган татарларга аңлаешсыз телдә сөйләшә икән дигән фикер туачак. Чит ил журналистларының һәм галимнәренең гадәти соравы шундый була: "Татар һәм башкорт телләре арасында берәр төрле уртаклык бармы?" Җавап аларны аптырашта калдыра. Алар, бик шикләнеп, сораша башлыйлар: ни өчен соң, алайса, алар шулкадәр охшаш булгач, мөстәкыйль телләр дип аталалар? Бу—совет чорыннан калган авыр мирас. Бүген демократия күп нәрсәләр рөхсәт итә, әмма элекккедән килгән инерция үзенең йогынтысын җуймый әле. Бу зыянлы инерцияне җиңеп чыгар өчен интеллектуаллар көче таләп ителә.

[94] Садри Максуди Арсал. Төрекләр тарихы һәм... хокук. 291 б.

*«Татарлыктан татар һич гарь итәрме,*
*Кеше үз исмене инкяр итәрме,*
*Татарлыкта татар угълы татармын,*
*Татар түгел димә—башың ватармын!»*

Дәрдемәнд

Кайчандыр кабилә, этнос, милләт–дәүләт этнологлар һәм антропологлар тикшеренүләренең төп объектлары иде. Бу төшенчәләр күплэгән процессларны аңлатып бирәләр иде. Бүген классик этнология барысын да аңлатып бирә алмый. "Без"—"алар" һәм "үзебезнекеләр"—"читләр" мөнәсәбәтләре төңгәллекнең катлаулы гаммасы белән алмашына, бу исә постиндустриаль дәверне ачык чагылдыра. Дөрес, бөтен илләр дә үсешнең мондый баскычына күчмәгәннәр әле, әмма барысы да шушы процесслар орбитасында әйләнә һәм бер-берсенә уртак икътисадый базар шартлары белән бәйләнгәннәр. Милләт-дәүләтләр эпохасы тәмамланды.

Үз вакытында милләтләр һәм, билгеле инде, милләтчелек (Европа аңлаган уңай мәгънәсендә) Австро-Венгрия империясе, Оттоман империясе һ. б. җимерелүгә китерде. Сәбәбе гап-гади—милли икътисад байлык чыганагы буларак иң нәтиҗәлесе һәм ул территорияләр яулап алуны файдасызга әверелдерде, милләтләр яңа империяләр төзелүгә киртә булдылар. Әмма шул ук икътисадый көчләр бөтендөнья базарын оештыру юлы белән милли каршылыкларны бетерергә ярдәм итәләр. Тагын шунысы бар, "сәяси һәм этник чикләр туры килгән җирләрдә җәмгыять үсештән туктый һәм милләтләр артка алып ташлана, алар башка кешеләр белән аралашудан туктаган кеше хәленә төшәләр".[95] Тарихи күзлектән караганда, милләтчелекнең идеология буларак киләчәге юк. Глобализмның барлыкка килүе милләтчелекнең көчсезләнүен күрсәтә, дөнья буйлап экология өчен көрәшүчеләр, трансмилли корпорацияләр җитәкчеләре, финансистлар, дизайнерлар, язучылар һәм сәнгатькярләр сыйфатында планетар аң-акыл сәяхәт итә һәм моңа аралашуның заманча чаралары ярдәм итә.

Этнос—тарих күләгәсендә калган мәдәниятнең иң соңгы сыену урыны ул. Ачык мисалы—АКШтагы индеецлар резервациясе. Милләт-дәүләт исә—индустриаль эпоханың артта калуын консервацияләп кую гына ул. Дәүләт чикләре, халыкның үзтөңгәллек үзенчәлеге буларак, үз ролен югалта бара. Шундый эпоха килер ки, анда үзенчәлекләре беленер-беленмәс булган мәдәни конгломератлар идарә итәр. Евросоюз—халыклар бергәлегенең принципиаль яңа формасы ул. Бу—"европалылар"милләте түгел, бу—мәдәни конгломерат. Һәм монда бәйләү чарасы тел дә, дин дә түгел, либерализм. Ирекә омтылу—тарихның төп лейтмотивы, димәк, Европа башка халыклар да барачак юлдан атлый. Европада инглиз-саксон яисә пангерман цивилизацияләре өстенлек итү этник, төбәк яки хәтта чиктәш мәдәниятләргә әверелгән субэтник мәдәниятләр исәбенә тигезләнә.

Шушы үзгәрешләрдән чыгып, Американың "эретү казаны" да яңача аңлауны таләп итә, әмма ул постиндустриаль эпоха өчен яраксыз. Глобальләшү, америкалыларның эчке дифференциациясе процессларын көчәйтеп, америкалыларның этник күптөрлелеге, котылгысыз бер күренешкә әверелә бара.

Милләт-дәүләтләр белән хушлашу күп кенә гадәти күзаллаулар үзгәрүне таләп итә. Россия исә милләт-дәүләт буларак оеша алмады. Ул империя буларак яшәде һәм советлардан соңгы киңлекләрдә дәүләтләр барлыкка китергән милләтләр басымы астында җимерелеп төште. Бүген россиялеләрне милләт буларак җыю омтылышы файдасыз эш, чөнки индустриаль эпоханың сәяси процессларын кире кайтару мөмкин түгел. Дәүләт чикләре эчке базар барлыкка китерми, тел мәсьәләсе һәм мәдәният функциясе бүген бөтенләй башкача. Россия Федерациясендә этник дифференциацияне нивелирлау да мөмкин түгел, мәдәни күптөрлелекне хуплаучы заман килде. Мондый шарт-

[95] Лорд Актон. Очерки становления свободы..., с. 127.

ларда "россиялеләр" милләтен-дәүләтен оештырырга омтылу көймә бата башлагач кына агымга каршы йөзәргә тырышу белән бер. Әгәр Россиядәге аз санлы халыкларның үзбилгеләнүгә хәтта көче җитмәсә дә, икътисад, халыкара сәясәт, мәдәниятләр үсеше иҗтимагый тормышны милләтләштерүдән читкә этәрәчәк. Ул инде күптән мозаиканы хәтерләтә, е төбәкләр икътисады үсә барган саен күптөрлелек колач җәячәк. Үзәктән килүче унификацияләнгән карарлар анахронизмга әйләнәчәк. Шуңа күрә дә Россия икътисады үзәкләшүдән качачак. Шуннан соң ук бюджетка, салымнарга, җиргә, энергия чыганакларына, табигать байлыкларына контроль үзгәрәчәк. Бу бик авыр барачак, әмма бу—котылгысыз гамәл. Бүген үк инде мәнфәгатьләр һәм теләкләр күптөрлелеге арткannan-арта. Климат һәм география масштаблары, икътисадый ихтыяҗлар һәм ил чикләрендәге вәзгыять, этник канәгатьсезлек, мигрантлар проблемасы һәм башкалар—болар барысы да мәдәнияттәге, диндәге, сәнәгатьтәге стандартлаштыруга китереп суга. "Милләтчелек югары технологик мәгънәсендә төбәкчелеккә әверелә,—дип раслый Элвин Тоффлер.—Эреткеч казаннарның басымы этнослар басымы белән алышына. Массакүләм мәдәнияткә алмашка килүче тирәлек аны массалашудан азат итә. Мондый үсеш энергия формаларының барлыкка килүче күптөрлелегенә һәм массалардан тыш җитештерүгә туры килә".[96] Гәрчә аның киләчәктәге уңышлы үсешен карарлар кабул итүне унификацияләү белән түгел, нәкъ менә шул күптөрлелек белән бәйләргә кирәк булса да, Россия һаман моңа каршы тора.

Милләт белән хушлашу халыкара мөнәсәбәтләрне дә үзгәртә. Берләшкән Милләтләр Оешмасы милләт-дәүләтләр берлеге буларак сакланып кала алмаячак, чөнки яңа чынбарлыкка туры килми, ул әгъза дәүләтләрнең генә түгел, ә бәлки дәүләтчелеге булмаган халыкларның да мәнфәгатьләрен исәпкә алырга мәҗбүр булачак.

Этнология һәм антропология турындагы Россия фәне терминнарны аңлауда гына түгел, чынбарлыкны кабул итүдә дә буталып бетте, күрәсең. Россиянең төп этнологы В. А. Тишков "милләт"атамасын да, этнос төшенчәсен дә бөтенләй кабул итми, "милләт фәнни категория түгел һәм ул фән һәм сәясәт теленнән төшеп калырга тиеш"[97], дип саный. Милләтчелек, миллилек һәм хәтта дәүләт—болар бар да аның өчен ясалма нәрсәләр. "Яңартылган анализ өчен,—дип яза ул,—"милләт-дәүләт беткәнне" кәтеп ятарга кирәкми, чөнки милләт-дәүләт—шул ук "чынбарлыкка" карамастан, үзгәртеп коруны таләп итүче акыл метафорасы".[98] Халык санын алу күрсәткечләре аныңча "халыкның үзенә карата шартлылык кына". Аның фәнни эзләнүләре асылын аңлау гаять кыен. В. Тишков хезмәтләрен укыганнан соң Геллнер, Барт кебек Көнбатыш белгечләре идеяләре начар бәян ителә дигән тәэсир кала. Геллнер бит катлаулы нәрсәләрне гади итеп язган, В. Тишковта исә гади әйберләр дә бик нык буталган. В. Тишковта боларның барысы да бер идеягә буйсына: барлык этник, милли, дәүләти күренешләр—ниндидер милли активистлар маташтыруы гына. Үзенең манипуляция теориясе нигезендә В. Тишков шуның белән үзе үк шөгыльләнергә җыена. 2002 елгы халык санын алу алдыннан миңа Россия Фәннәр Академиясенең Этнология һәм антропология институтының Гыйльми советында катнашырга туры килде, анда керәшеннәр мәсьәләсе күтәрелгән иде, керәшеннәрне "ирекле", "мөстәкыйль", "җәберләнгән" халык дип белдерделәр һәм миңа анда гыйльми чыгышлар урынына бик күп кирәкмәгән нәрсәләр ишетергә туры килде. Гыйльми совет кысаларындагы митинг иде бу. Бернинди анализ да юк, саф манипуляция гына. Андагы кешеләр, татарча бер кәлимә сүз белмәгән килеш, "керәшен теле"нең мөстәкыйль яшәве турында фикер йөрттеләр. Бу тамашага каршы сүз дә әйтеп булмый иде, чөнки ул үзе этнология фәненә ясин чыгу иде. "2002 елгы халык санын алуга әзерлек барышында,—дип яза В. Тишков,—экспертлар һәм статистиклар арасында

[96] Элвин Тоффлер. Третья волна.—М., 2002, с.379.

[97] В.А.Тишков. Реквием по этносу. Исследования по социально-культурной антропологии.—М., 2003, с.151.

[98] В.А.Тишков. Реквием по этносу..., с.135.

бәхәсләр кузгалды һәм билгеле бер буталчыклык килеп чыкты".[99] Моңа аптырыйсы юк, бу буталчыклыкны ул җитәкләгән институт тудырды ләбаса. Нугайбәкләрне татарча сөйләшүче мөстәкыйль халык буларак язуга мин каршы чыккач, тиешле графада тел «нугайбәк теле» дип үзгәртеп язылды. Берәүнең "җитез" кулы белән тагын бер тел дөньяга килде—нугайбәк теле! Әгәр Себердә яшәүче русларны Себер телле аерым халык дип язсалар, руслар ни әйтер иде икән? В. Тишков белән республикалар, халыклар, башка галимнәр килешмәскә мөмкин, ул чакта В. Тишков аларны дилетантлар дип атый. Ул Н. Бердяев хезмәтләрен дә мәгърифәтчел публицистика дип кенә җибәрә, "анда сүз нәрсә турында бара: дәүләтләр турындамы, сәяси яки этномәдәни бергәлекләр турындамы—аңлашылмый", янәсе. Тагын болай ди: "Н. А. Бердяев "милләт" сүзен "халык" сүзенә алмаштырырга тәкъдим итә, әмма бу аның фәлсәфи публицистикасын эмоциональ өстән-өстәнлектән коткармый"[100]. Николай Бердяев идеяләренә төрлечә карарга мөмкин. Мәсәлән, ирек идеясен Ходайны саф христианча эзләүләр белән бәйләүне аңлау минем өчен бик кыен. Әмма, әгәр дә Н. Бердяевны рус җанын, рус психологиясен, халык характерының тирән катламнарын өйрәнүче философ буларак бәялисәң, аның "Русская идея" исемле бер кечкенә хезмәте генә дә Россия Фәннәр Академиясенең Этнология һәм антропология институтының соңгы елларда басылып чыккан барлык фәнни хезмәтләренә торырлык. Н. Бердяев, һичшиксез, рус философиясенең иң югары ноктасы, ә В. Тишков хезмәтләре—кайчандыр күренекле булган рус этнографиясенең кояш баешы. Ул—этнология тирәсендә манипуляторлар, сәяси технологлар барлыкка килү дәверенең үзенчәлекле билгесе. Әмма халыклар мондый манипуляцияләрдән бәйсез рәвештә яши бирәләр. В. Тишков: "Россиядә 2002 елгы халык санын исәпкә алу үзенең төп миссиясен—дәүләт өчен халык булдыруны үтәмәде"[101],—дип үкенеч белдерде. Димәк, халыклар үзләре өчен яшәмиләр, алар дәүләткә хезмәт итәләр, әмма тарихтан бит башкасы мәгълүм: дәүләт үзе—халыкның яшәү рәвешләреннән берсе.

Милләт-дәүләт төзеп өлгермәгән һәм яңа тенденцияләр йогынтысын үзендә татып өлгергән татарларның конфигурациясе нинди булыр соң? Татарлар стратегиясе үткәндәгегә охшамаган катлаулы культурологик процессларны аңлаудан килеп чыгарга тиеш. Милләт корылышы процессларының ниндидер бер аналогиясе хәзер Татарстанда да бара, анда рус-татар симбиозы псевдомилләткә охшаган, ягъни ике теллелек номиналь рәвештә булса да нормага әверелә, ахыр чиктә үсеп килүче буын өчен өстенлекле нәрсәләр бар: уртак икътисадый мәнфәгатьләр, торыклылыкка омтылу. Боларның барысын да халык хуплый бит. Болар бар да, социологик тикшеренүләр раславынча, татарстанлылар психологиясен формалаштыра.

Татарстан бер үк вакытта татар халкының үзәге буларак сакланып калачак, татарның локаль субкультуралары, сөйләмнәре исә төбәк аерымлыгы буларак сакланып калачак. Бу—гадәти һәм табигый нәрсә, мәдәни интеграция көчәйгән саен локальләшү дә көчәячәк. Себер татарлары телен булдырырга омтылу, керәшеннәр хәрәкәте, башкорт милләтчелеге—болар бар да хөрлек шартларында шәхеснең үз-үзен раславының табигый күрсәткечләре. Идеологик басым юкка чыгуга, кешеләр үзләренең аерымлыклары турында уйлана башладылар. Бу да бик табигый. Шәхес формалашу да шулай ук бара, башта ул үзенең уникальлеген тоярга, аннары инде бергәлеген сизәргә тиеш. Шуңа күрә дә Себердәге татарлар үз үзенчәлекләрен эзли башладылар, керәшеннәр белән мишәрләр—үзләренекен. Әмма бу—вакытлы күренеш, ул аңлылыкның югарырак дәрәҗәсенә күчү чоры гына, мондый дәрәҗәдәге кешеләр аерымлыклары хакында түгел, ә бәлки халык белән, республика, ил белән кушылу турында, төрки һәм мөселман дөньясындагы, ахыр чиктә, җир йөзендәге урыннары турында уйлана башлыйлар. Шул чакта локаль аңлылык дәрәҗәсен алыштырмый

[99] В.А.Тишков. Реквием по этносу..., с.185.

[100] В.А.Тишков. Реквием по этносу..., с.139.

[101] В.А.Тишков. Реквием по этносу...,226 нчы бит.

һәм юкка чыгармый торган интегратив аң барлыкка килә. Интеграция берничек тә унификация дигән сүз түгел, унификация—кирәксез, зарарлы һәм мөмкин булмаган нәрсә ул.

Тагын бер башлангыч тезисның мәгънәсе түбәндәгечә: панславянизм кебек үк пантюркизм яки төрки глобализм да мөмкин түгел, чөнки боларның вакыты узган инде. Пангерманизм Лютерга рәхмәтле булырга тиеш, руслар исә ассимиляциягә ышанганнар, нәтиҗәдә украиннар һәм белоруслар килеп чыккан, гәрчә этник үзенчәлекләрне саклап, уртак әдәби тел нигезендә немец тибындагы бергәлек төзи алган булырлар иде. Хәзер инде ул мәйдан поляклар кулында. Әгәр дә руслар украиннар белән уртак тел тапмасалар, тегеләре полякларга китәчәк, болгарлар исә македонлылар, серблар һәм черногориялеләр белән берләшәчәк.

Пантюркизмның мөмкин булмавы билгеле бер төрки бердәмлек идеясен юкка чыгармый, шул ук вакытта уртак мәнфәгатьләр, территория, мәдәни симбиоз җирлегендә татар-рус теләктәшлеге туу ихтималы да бар. Шулай ук чиктәш субкультуралар белән бергә үзенчәлекле төрки-татар конгломераты да оешырга мөмкин, ул исә үз чиратында тагын да киңрәк төрки конгломерат орбитасына килеп кушылырга мөмкин. Чиктәш тел һәм мәдәни үзенчәлекләр үзара мөнәсәбәтләрнең күпләгән күчеш рәвешләрен тудырачак, әмма ул татар-башкорт мөнәсәбәтләре кысаларында түгел, нугай-, балкар-, карачай-, кумык-, Кырым татарлары-, казакъ-, кыргыз-татар мөнәсәбәтләре кысаларында булырга мөмкин. Билгеле бер мәдәни багланышлар, үзбәкләрне, әзәрбайҗаннарны, төрекләрне, уйгырларны да кертеп, тагын да киңрәк төрки конгломератта барачак.

"Татар" этнонимы язмышның төрле борылышларын кичерде: кабиләләр төркеме исеменнән ул төркиләр синонимына әверелде, аннары Алтын Урда халкының үзатамасына әйләнде. Озак вакытлар татарларны суперэтнос дип санаганнар. Англия илчесе Дж.Флетчер 1589 елда "Россия дәүләте турында" язмалар иҗат итә, анда ул татарларга нугайларны гына түгел, чирмешләрне дә, мордваларны да, чиркәсләрне дә, щелкалларны да, пермякларны да, самоедларны да кертә. Европалылар күзаллавынча, Кырым ул—"Кече Татар иле", Идел аръягыннан Көнчыгышка таба исә "Бөек Татар иле" җәелеп ята. Хәтта Петр I заманнарында да карталар шул ук атамалар белән чыгарылган. "Татар иле" Евразия белән тәңгәлләштерелгән. Ниһаять, "татарлар" термины XX гасырда "Идел буе" (географик мәгънәдә түгел, этник мәгънәдә, моңа мишәрләр, керәшеннәр, Әстерхан, Себер татарлары һәм башка татарлар кертелә) һәм Кырым татарлары буларак ныгып кала.

"Татар" этнонимының үз катлаулы тарихы булганга күрә, аның төрле дәверләрдә тарихи хроникаларда нинди төгаен эчтәлеккә ия булуын онытмаска кирәк. Бүгенге татар халкына килгәндә исә, аның теле һәм мәдәнияте барлыкка килүгә көнбатыш һуннары һәм, мәсәлән,болгарлар, Төрки каганат, Алтын Урда зур йогынты ясый, һәм тагын—Россиядәге этногенез процесслары. Хәзерге татарларны болгарларга яисә VII гасыр татарларына гына кайтарып калдыру дөрес булмас иде, әмма тарихыбызны Аттила яки Батый хан походларыннан аеру да мөмкин түгел. Татарларга XX гасырда югары мәдәният үсешенең заманча институтлары да зур йогынты ясый, шуңа күрә дә соңгы йөзьеллык үзенең йогынтысы буенча берничә гасырга тиң.

Татарлар тарихы төрки халыклар белән генә түгел, фин-угыр, билгеле инде, рус халкы һәм башка халыклар белән дә тыгыз бәйләнгән, бу хәл татар этносы барлыкка килүнең аңлатмасына тагын бер фактор өсти.

*Дәвамы киләсе санда.*

Илшат
Вәлиулла

# «КАЙ ЙӨРӘКТӘН КИЛӘ БУ МОҢ?»

*Яралганмын кара туфрагымнан,*
*Идел-судан, халык җырларыннан.*
*Ак яулыклы татар карчыгының*
*Яргаланып беткән кулларыннан.*
Мөдәррис Әгъләмов

Уйлап баксаң, татар дөньясына, татар тереклегенә, татар яшәешенә искиткеч гүзәл ике күренеш хас—Моң һәм Сабантуй...

Әмма монда шунысы кызыклы: татар тереклегенә хас шушы ике олы күренеш—Сабантуй һәм Моң—татар шигъриятендә дә үзләренең дәвамлы вәкилләрен табалар түгелме?! Минем үземә кайчак татар шигъриятендә берничә фәлсәфи шигърият яки шигъри фәлсәфә юнәлеше күзаллана. Мәсәлән, Сабантуй фәлсәфәсе, Моң фәлсәфәсе... Билгеле, бер генә олы шагыйрь иҗатын да теге яки бу тормыш фәлсәфәсенә генә кайтарып калдырып булмый. Олы шагыйрьләр иҗаты һәрвакыт мондый абсолютлаштырудан, билгеле бер идеягә генә буйсындырылудан киңрәк. Ләкин, шулай да мәгълүм бер шагыйрь иҗатында аерым бер тормыш фәлсәфәсе, фәлсәфи-әдәби-мәдәни күренеш аеруча калку чагылырга мөмкин...

Әйтик, бүгенге татар шигъриятендә Равил Фәйзуллин Сабантуй рухын аеруча тирән чагылдырган шагыйрь булса, Мөдәррис Әгъләмов исә Моң рухын, Моңлылыкны аеруча тулы, тирән чагылдырган шагыйрьләрнең берсе. Һәм түбәндә сүз Мөдәррис Әгъләмов шигъриятенең барыннан да элек Моң белән бәйләнешле фәлсәфи асылы турында барыр.

Мөдәррис Әгъләмов шигъриятенең Моң белән бәйләнешен, ягъни, аңа хас фәлсәфәнең Моң белән, аның фәлсәфи эчтәлеге белән тирән бәйләнешен тәнкыйтьчеләр шагыйрь иҗатының башлангыч чорында ук күреп алганнар иде. Мәсәлән, Әмир Дәминов шагыйрьнең «Учак урыннары» дигән икенче китабына 1974 елда язылган рецензиясендә ук инде түбәндәгечә билгеләп уза: «...Ләкин Мөдәррис Әгъләмов, уйлана белү белән бергә, Дәрдмәндтән сагыш, хәсрәт, моңны да кабул иткән. Җыентыкта мондый юллар бар:

*Сагышларны күбрәк йөртә,*
*Күбрәк саклый картлар җаны.*

Бит шагыйребез әлегә өченче дистәне дә ваклап бетерергә өлгермәгән. Шуңа да карамастан, Мөдәррис моң, сагыш, моңсулык, хәсрәт кебек сүзләрне шактый күп куллана./«Казан утлары», 1974, 4-сан.

Тора-бара Мөдәррис Әгъләмов иҗатының фәлсәфи эчтәлегенә карата шушы фикер ныгый төшә, хәтта вакыт-вакыт ул шагыйрь иҗатының төп сыйфаты буларак тәкъдим ителә башлый...

Шул ук вакытта, әдәбият белгечләре М. Әгъләмов иҗатында Моңлылык белән янәшә торган тагын бер мөһим сыйфатны аерып күрсәтәләр: ул—халыкчанлык. Нигә? Чөнки, шагыйрь иҗатында сүз еш кына Халык Моңы турында бара бит...

Шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов үзен барыннан да элек халкының улы дип тоя, саный... «Табигать ялгышы» шигырендә болай ди ул:

*Зур дәүләтләр ясавың бар,*
*Үз -үзеңне ашавың бар.*
*Баш игәннәр юнан, чиннар—*
*Ә мин бары бер углың ла...*

*Таш эретер моңнарың бар,*
*Мәңгелекне сынландырган*
*Моңнан куйган сыннарың бар—*
*Ә мин бары бер углың ла...*
*..............................................*
*Маңылган бүзгә төрсәң дә,*
*Мунчала итеп урсаң дә,*
*Тиенгә сатып йөрсәң дә,—*
*Сине сатмас бер углың мин.*

Сүз дә юк: Мөдәррис Әгъләмов өчен Моң эзлекле рәвештә Халык яшәешендә табыла. Халык, нәкъ менә халык үзенең гасырларга сузылган яшәешендә Моңны тудырган! Моң – халыкның йөрәгендә, бәгырендә. Моң ул—халыкның Хәтере дә, Жаны да, Илаһә белән тоташтырып торган үзенчәлекле садә Жеп тә...

1965 елны үзенең бер шигырендә Мөдәррис Әгъләмов болай дип язган иде:

*...Табарсың тау кадәр*
*шатлыклар,*
*Табарсың янәшә*
*«сак -соклар».*
*Халыкның уйлары*
*мең булыр.*
*Мең елга сузылган*
*моң булыр.*

*...Ярып бак жанымны*
*урталай,*
*Сорама: «Ник болай,*
*ник алай?»*
*Ярып бак!*

Әйе, шагыйрь өчен иң мөһиме: Халык Моңын бөтен тирәнлегендә, бөтен табигыйлегендә тыңларга өйрәнү, аңлау, тою...

Шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов өчен Халык төшенчәсенең еш кына Моң төшенчәсе белән бәйләнүен аның ижатына бәя бирүчеләр еш искәрттеләр. Күренекле тәнкыйтьче Фәиз Зөлкарнәй әле 1979 елны язган «Халык рухына якынайганда...» мәкаләсендә түбәндәгечә фикер йөртте:

«...Мөдәррис Әгъләмов—әдәбиятның әлеге төп вазифасын нык аңлап, халыкның язмышын үзенеке итеп кабул иткән, үзенә укучыларны да иярткергә омтылган шагыйрьләрнең берсе. Аңарда халыкны, аның психологиясен, омтылышларын үзенә генә хас аңлау бар. Шуларны укучыларына да төшендереп, ул аларны шушы жирлектә берләштермәкче, аларны халык рухына багланышлы итмәкче...


*«Казан утлары» редакциясендә. Утырганнар—уңнан: Р. Фәйзуллин, Р. Гаташ; басканнар—сулдан М. Әгъләмов, М. Кәбиров, Н. Гамбәр, Зөлфәт. 2002 ел.*

Уйчанлыгы Дәрдмәндчә булса да, халыкны аңлавы, аңа мөнәсәбәте шагыйрьне Тукайга якын итә. Халыкчанлык аңа эстетик категория генә түгел, бәлки, иң элек йөрәктәге әрнүле, татлы моң ул, авыруы ул аның».

Димәк, халыкчанлык ул Мөдәррис Әгъләмовчә «иң элек йөрәктәге әрнүле, татлы моң ул, авыртуы ул аның». Әйе, сүз дә юк: Моң-Моңлылык соңгы гасырларда татар халкын «берләштереп, якынайтып» торган олуг күренеш булды... Ул татар халкы күңеленә хас аерым бер тирән мәгънәле олуг гүзәл халәт.

Мөдәррис Әгъләм шигъриятенең фәлсәфи асылы әнә шуны ачып бирү түгелме?! Әгъләмов халык күңелендәге меңъеллык олуг Моң турында сөйли безгә... Кем халыкның Моңын тыңлый белә, ишетергә сәләтле, ул үз халкының яшәешен дә аңлый ала, шул яшәешне аңлау аша гына, бәлки, ул үзен дә анарда таба ала...

Ижатының башында ук, 22 яшендә үк, ул үз шигъриятенең киләчәктә ниндирәк кыйммәтләргә таяначагын әйтеп бирә:

«Бер жәйне халык ижаты жыю буенча Свердловск өлкәсенә чыктык.

Халык ул үзенең асыл ирләрен югалтмый... Бабичны жырлап йөри, Акмулла-

нын тапкыр сүзләре белән җавап кайтара, Тукай турында әйткән дә юк, ул халкынын җанына әверелгән...

Без бередә Уралнын кайда икәнен генә түгел, шагыйрьнең җирлеге яки таяну ноктасы кайда икәнен дә белеп кайттык.» /»Казан утлары», 1968, 11-сан.

Әйе, шушы гади дә һәм уйландыргыч та сүзләрдә шагыйрь башта ук үзенең иҗат кредосын, иҗат маякларын ачып, әйтеп бирә.

Билгеле ки, һәрбер олы, киң күңелле шагыйрьгә хас булган төсле, Мөдәррис Әгъләмов шигърияте дә Моңлылыкка гына кайтып калмый. Сүз дә юк, анын шигъри фәлсәфәсе—киңрәк... Анын шигъриятендә Сабантуйлык рухы да, анын шатлыклы-гүзәл-җинүчән фәлсәфәсе дә зур урын алып тора.

Чөнки, татар яшәеше көрәшне дә, җиңүләрне дә, тормыш бәйрәмен дә белә! Иҗатында кайта-кайта ул Сабантуй дигән бөек яшәеш тантанасы турында сүз йөртә. Ул анын татар күнеле, татар яшәеше өчен никадәр Олы Шатлык һәм Бәхет Мизгеле икәнен ачык тоя:

*Июнь киче... Әллә шуңа йөрәк*
*Авызлыгын чәйнәп уйнады...*
*Җырларымнан мәйдан сорап килә*
*Туган якның Сабантуйлары.*
*Бер хат-хәбәр килсә туган өйдән,*
*Күзен бәйләп чыга теләкләр..*
*Бер сугуга челпәрәмә килә*
*Сагыш дигән сары чүлмәкләр.*

Кызыклы: һәр татар ир-егетенә хас булганча, шагыйрь дә үзен Сабантуй көрәшчесе кебек итеп тоя ала, һәм... шигырьләре—«көрәшчеләре» белән ул «саф татарча», ягъни, гадел көрәшергә тели:

*Килешәбез, бары саф татарча.*
*Саф татарча йолкып алырга. . .*

Әйе, Сабантуй яшәешкә, көрәшләргә мәдхия белән тулы, тик... кайчак... ничектер... татар күнелендә Сабантуй һәм Моң күренер-күренмәс бик нечкә җепләр белән тоташып та торалар төсле:

*...Бүлмәдә төн. Тоныкшаулый сулар.*
*Тәрәзәмә төннәр сыена...*
*Колагымда тояк тавышлары,*
*Ерак калмый Сабантуена.*

Үзенең тагын бер шигырендә Мөдәррис Әгъләмов болай дип уйлана:

*Һай ерактан килә бу моң, кай тарафтан?*
*Кай йөрәктән килә бу моң, кай төбәктән?*
*Кем йөрәге сыкрана ул, кем җаны?*
*Нинди ялар кичергән ул, кем имгәткән?*

Сораулардан торган бу шигырь Моңнын тирән, ерак чыганакларына ишарәли түгелме?!.

Халык Моңы... Халыкнын йөз еллар аша күнелдән-күнелгә күчә килгән искиткеч тирән Моңлылыгы... Каян килә соң ул?

Башка күптөрле фани һәм бакый сәбәпләр белән бергә (әйтик, туганнарыңны, якын кешеләреңне югалту; җавапсыз мәхәббәт; туган җирдән еракта яшәү һ. б.) татар милләте эчендәге Моңны анын 450 ел тирәсе дәвам иткән милли коллыктан ахыргача котыла алмавы да тудыра.

Ни өчен татар күнелендә Әрнү, Үпкә, Рәнҗү, Өметләнү төсле хис-тойгылар белән мавыгу бар? Ни өчен татар яшәешендә Моң культы көчәйгән? Чөнки татарга авыр язмыш бирелгән... Уйласаң, аңласаң: татар халкынын соңгы гасырлардагы

яшәеше ул—тоташ Моң яшәеше...

Мөдәррис Әгъләмов шушы дөреслекне яхшы аңлый, тоя. Иҗатының башлангыч чорларында ук инде ул тарихның татар халкы өчен фаҗигале, болгавыр чорларына әйләнеп кайта.

*Дәште аңа бер юлаучы :*
*—Әй, егет!*
*Бу ташлар ни? Нурлы йөзең ник сүрән?*
*Туктады, әйтте:*
*—Бабамнар кичергән*
*Йөрәк өзгеч кайгыларны кичерәм.*

*Кайткан чакта кабат, дәште:*
*—Әй, егет!*
*Тагын ни бар? Нурлы йөзең ник сүрән?*
*—Кайчандыр кандаш бабайлар җиңелгән*
*Бәйгеләрне күңелемнән кичерәм.*

Әйе, Казан ханлыгының «егылуы», шулай ук Хаҗитарханның, Себернең «егылулары», җиңелү һәм озак гасырларга сузылган колониализм татар-болгар күңелендә дәвамлы авыр тойгылар калдырган. Ә бит бу татарның беренче генә авыр, олы югалтуы булмаган... Казаннан берничә гасыр алда мәшһүр Болгар «егылган»... Борынгы бу дәүләтебез кайчандыр Көнчыгыш Аурупаның иң көчле, иң мәдәниятле дәүләтләренең берсе булып торган! Ә хәзер без бары тик хәрабәләр генә күрәбез.

*Каеннар иле син, Болгарым,*
*Ярый ла китерде юлларым.*
*Үкенеч икән бит, үкенеч*
*Зиярәт кылмаган елларым.*
.............................................
*...Моң салып нәселем үткән бит,*
*Кодрәтем бередә күптән бит.*

Менә каян икән ул «ерактан килүче Моң»!—«Моң салып нәселем үткән бит»... Моңның күңелебездәге Шәҗәрәсе—Казанның, Хаҗитарханның Себернең, Болгарның һәм Күлтәгиннәрнең авыр, үкенечле, сагышлы елларыннан да килә икән...

Татар күңелендәге мондый тарихи яралар шигырьдә, җырда, бәеттә, чәчмә әсәрләрдә Моң булып кабынып-кабынып алалар... Шуңа күрә, хәтта соңгы чорда туган татар балалары да татарның моңлы хәятының варислары алар. Шагыйрь үзенең халкы яшәеше, аның асылы турында уйланып болай дип яза:

*Яралганмын кара туфрагымнан,*
*Идел-судан, халык җырларыннан...*
.............................................
*Яралганмын җил-давыллар узып*
*Исән калган агач башларыннан,*
*Чиркәүләргә нигез булып яткан*
*Бабамнарның кабер ташларыннан.*

Әйе, татар халкы—Империя тарафыннан аеруча эзәрлекләнгән халыкларның берсе. Шушы эзәрлекләүләр нәтиҗәсендә татар халкы Ил-Ватансыз гына калмады, ә көчләп диярлек Туган теленнән дә читләштерелде. Алмашка исә үги Ватан һәм үги тел бирелде...

Шуна да халык күңелен тыңларга яраткан шагыйрь болай дип ачыргалана:

*...Һәр сабый сорар җавап:*
*—Кем тарафыннан киселде*

*Туган тел дигән канат?*
*Ил, Ватан дигән изгене*
*Кайсыгыз алды талап?*

Гасырлар буена һәм бөтен Империя киңлекләрендә дәвам иттерелә бу татарның милли-дини эзәрлекләнүе... Эзәрлекләнү исә татар халкын бөтен Ил буенча сибә, тарата. Үги Ил... Сорау куярга була: үз Ватанын югалткач бу илдә бәхетле була алдымы соң татар халкы? Аның кагылмас «Ватаны» булып Моң калмадымы?!. Мөдәррис Әгъләмовнең «Җырлар калка» шигыре (1967) нәкъ менә шул турыда...

*Кайсы буын килгән бу якларга,*
*Кайсы нәсел,*
*Кайсы бабасы?*
*Беркем белми моны, халык моңы*
*Ишетелгәч тынып каласын.*

Урал якларына килеп чыккан татар шагыйре шулай ди. Һәм шигъри уйлана... Әйе, милли эзәрлекләнүләрнең елъязмасы алып барылмаган, күп нәрсәләр онытылган, хәтердән кичкән, әмма халыкның уй-фикерләре, кичерешләре Моңда сакланып калган.

Урал татарларының Моңы... Ниләр калган анда? Нинди тирән уйлар, якты кичерешләр таба шагыйрь анда? Җавап: Ватанны сагыну... Ә татарның югалган Ватанының, дәүләтчелегенең Җирдәге бөек символы—теләсә кайсы чорда да (хәтта, ул аның чын хуҗасы булмаган чорда да)—Казан каласы. Шуңа күрә шагыйрь ачык тоя: татар җаны кайда гына булса да татарның мәдәни, тарихи, геополитик Йөрәге—Казанга ашкына:

*Үзәннәрдән күтәрелгән җырлар,*
*Таулар эргәсенә кагылып,*
*Юнәлешен үзгәртә дә оча,*
*Оча Казан ягын сагынып.*

Татар Җыры... Аларның исемнәре борын-борыннан татар күңеленә уелып калган: «Гөлҗамал», «Карурман», «Тәфтиләү», «Ак калфак», «Әллүки», «Сак-Сок», «Шәһре Болгар»... Менә кайда саклана татарның олуг рухи байлыгы! Менә ни өчен Җыр-Моң татарларның рухи Ватанына әверелгән!.. Урал якларында шул турыда уйлана шагыйрь:

*Һәрбер ташка монда җыр сыенган,*
*Җыр сыенган һәрбер куакка...*
*Кичләрендә чыксаң, юлдай озын*
*Халык моңы керә колакка.*
*Ул моңнарны читкә җибәрмичә*
*Саклаганмы Урал таулары?*
*Таулар түгел, халкым шундый минем,*
*Тик моңнардан тора бар җаны.*
*Аларның бит ерак бабаларын*
*Патша монда сөреп җибәргән...*
*Җирдән сөргән,*
*Җырдан сөрәлмәгән,*
*Җырлар калка, калка тирәннән.*

Уйласаң: халыкның башкаласын, шәһәрләрен, йортларын, мәчетләрен тартып алырга була, әмма аны—халыкны—Җырдан, Моңнан, димәк, саф-пакъ Рухтан тартып алып булмый икән...

Моң бит ул гаять тирән мәгънәле күренеш! Бер караганда ул—кеше эчендәге «илаһи мин»нең тавышы. Монда Әрнү, Зарлану, Шатлану, Өмет, Сыкрау кебек хис-тойгылар гел алышынып тора һәм кеше эчендәге «илаһи мин»нең ихлас те-

лен—аның ишетелергә, аңлашылырга һәм юатылырга теләвен тудыра.

Үз вакытында, XX йөзнең 90 нчы еллары башында, Татар Моны һәм аның тамырлары, табигате турында «Татар декадансы» / «Татар фаҗигасе»/ дигән эсседа мин болай язган идем:

«...Татарлык тышкы дөньяга омтылышында, үсәргә теләвендә кинәт кире кагыла һәм Моңга кача... Татарлык—ярымдекаданс чынбарлыгы, аның бу дөньядагы яшәеше яртылаш барып чыкмаган. Чөнки шушы дөньядагы кайбер чынбарлыклар Татарлыкка карата артык тискәре мөнәсәбәттә булып, аның үсеш вә яшәешен чикләгәннәр... Һәм ул Моң аша яхшылыкка, бер-беренне аңларга чакыра. Бу чакыру ачык сүз—текст аша түгел, ә бәлки җан тибрәнешләренә корылган Моңлылык аша ачып барыла...»

Татарның онытылмас халык җырлары... Кешенең бәгырь түреннән чыккан Әрнү, Сыкрау һәм шул ук вакытта Өмет, Яктылык, Сафлыкларда! Аларда фани яшәештә авыр халәткә дучар булган «илаһи мин»нең дулкынланулары да, бәргәләнүләре дә... Әйе, юкка гына тумый икән бит ул йөрәк өзгеч, бәгырьләргә тиюче Моң!

Ә Мөдәррис Әгъләмовнең шигъри җаны өчен халык җырлары гаҗәеп мөһим! «Юлдашым» шигырендә болай дигән иде ул:

*Ваем юар дип, кайгым бар дип,*
*Ярты юлда туктама!*
*Вайларыма дәва булып*
*Телләремә җыр тама.*

*Халык җыры—юл башым.*
*Халык җыры—юлдашым.*

Табигый: халык күңелен тыңлый белгән шагыйрь Мөдәррис Әгъләм Татар Монын ачып, сөйләп бирүчеләр, аны—«чын Ватанны»—саклаучыларлар турында шигырьләрендә еш искә ала: Акмулла, Тукай, Бабич, Сәйдәш, Туфан, Зөлфәт, Илһам Шакиров...

Ни өчен соң халыкка бик тә кадерле аның кайбер җырчылары? Ни өчен соң бөек дип саный ул аларны? Ни өчен аларны тыңлаганда аның йөзенә олы гамь чыга?.. Чөнки, татар халкының күңелендә, җанында җыелган гүзәл һәм олы Моңны ачып, сөйләп бирә алучы сирәк җаннар алар.

Бөек җырчы Илһам Шакировка багышланган шигырендә Мөдәррис Әгъләм ошбу Моң илчесе җырлавының халык өчен никадәр кадерле булуы турында уйлана:

*Ник сазыңны уйнадың син әле,*
*Бәлки, уйнамаска калгандыр?*
*Тукай сазы өзелгәнен белеп*
*Халык сине сорап алгандыр.*

Ә моңлы җырчы «сазын уйнамый» кала алмаган! Чөнки Тукайдан соң Моң чылбыры өзелергә тиеш булмаган. Чөнки, үз күңелендә йөрткән гамьнәрне ишетер һәм ишеттерер өчен, үз хәятын рухи биеклектә саклап калыр өчен халык аны Раббысыннан сорап алган...

*«Карурман»ы, «Сарман»нары белән*
*Ничә меңнәр еллар буталып,*
*Коры җирнең алтыдан беренең*
*Кан тамырына сеңгән бу халык.*

Халыкның Моңын, моңлы күңелен җырлаучы Җырчы образы гаять драматик халәттә күз алдына килеп баса:

*Читлектәге җанвар бит син, туган...*
*Ыңгырашуың*
*Әмма дә—моң белән,*
*Мең гасырлык халык бүләк иткән*
*Мәңгелеккә киткән тын белән.*

*Аңлы килеш кертелми ул бүген*
*Сан алуның исәпләренә.*
*Читлектәге җанвар,*
*Ыңгырашып,*
*Син керәсең аның хәленә.*

Җырчы читлектәге җанвар төсле... Тик ул Моң белән ыңгыраша... Ни өчен? Чөнки аның халкы озак гасырлар буена үз-үзенә хуҗа түгел икән. Моң шагыйре аңлый: Илһам Шакиров кебек җырчылар халыкка аның җанындагысын әйтеп бирә алганы өчен кадерле дә. Моңны тирәнтен тоюы, аңлавы белән; Моңны әйтеп бирү сәләте, тәэсир, тавыш мөмкинлекләре белән; ихлас хисчелеге белән... Мөдәррис Әгъләмов иҗат кичәсенең миссиясен үзенчә күзаллый. Шагыйрь исемен йөртүче инсан, мәсәлән... Кем ул? Халык күңелендә дөньяви яшәеш тәэсиреннән туган, җыелган олы хис-тойгыларны, уй-фикерләрне әйтеп бирүче түгелме?

*—Шагыйрь—яра. Дөнья ваклыгыннан*
*Бетте инде дисәк вакланып,*
*Халык барыбер үз ярасын таба,*
*Әрнесә дә, таба актарып.*

Әйе, безнең җанда яралар күп. Үз-үзенә, үз ирегенә, үз җиренә үзен хуҗа була алмау күңелләрдә тирән сагыш уятмый кала алмый. Билгеле, XX йөзнең соңгы елларында Татарстан азмы-күпме мөстәкыйльлек ала алды. Мөдәррис Әгъләм дә милли романтизм чорында өметләнеп болай дип язган иде бит:

*Сабыр гына моң тараттың,*
*Урта Идел уртасыннан.*
*Яшең түктең, билең бөктең,*
*Язмышыңны Былтыр кыскан...*
*Кычкырырга,*
*Эш кырырга*
*Вакыт җитте, Татарстан!*

XX йөздә Җир өстендәге күп кенә халыкларга колониаль богаулардан арынырга вакыт килде... Әмма, әмма... соңгы елларда Татарстанның мөстәкыйльлегенә, дәүләтчелегенә карата кысулар башлануы күңелләрдә күңелсез хисләр, уй-фикерләр уятты. Күңелләрдә Өмет катыш Моңсулык арта төште.

*...Без кайдыр бармак булган идек,*
*Азат булмак булган идек әле...*
*Алла бәндәләре булмак булдык,*
*Ә һаман да—Мәскәү бәндәләре.*

Сүз дә юк: чын шагыйрьне Халкының язмышы борчымый кала алмый... Нинди булыр ошбу бик тә катлаулы заманда аның киләчәге? Үзенең пакъ-саф хыял-өметләренә ирешә алырмы ул? Ә шагыйрь уенча, инануынча аның бу көрәше хак:

*Беркайчан да онытмагыз, диеп*
*Оран сала тарих киңәше:*
*Максат илә дөрес юлдан бара*
*Мең гасырлык татар көрәше—*
*Дөрес юлдан бара!*

Әйе, Мөдәррис Әгъләмов шигырьләре халык күңелен тыңлау һәм әйтеп бирү кебек... Халык, аның кичерешләре, аның ни белән яшәгәнлеге, аның теләк-хыяллары бу шагыйрь өчен искиткеч мөһим. Шагыйрь Наис Гамбәр «Ерактан килгән—еракка китәр...» мәкаләсендә (1996) Мөдәррис Әгъләмов иҗатының фәлсәфи асылы турында болай дип язган иде: «Мөдәррискә килсәк, халык төшенчәсе аның шигырь-

ләренең бер кисәк-өлеше, матур бизәге генә түгел, ә бәлки гомуми иҗатының юнәлешен билгеләүче гамь, моң. Бу шуннан килә: халык рухы аның канына, җанына ана сөте белән кергән. Яшьли ятим кала да... Тукай кебек... Кайчакта... шаяртыбырак булса да, Мөдәррисне «бүгенге көн Тукае» дип атап йөртүебез әнә шулардан килми микән әле? Чынлап та, шушы тәбәнәк буйлы, какча гәүдәле, орчык кына хәтле, кыяфәте белән үсмерне хәтерләткән «нәни гигант» ничәмә-ничә еллар буе халыкның рухи йөген үзенең юка гына җилкәсендә сыгылмыйча күтәреп бара! Мөдәррис һәм халык җаны—болар янәшә төшенчәләр. Аның сәбәбе ачык:

*Җырны чикләмәгән вакыт,*
*Ә гомерне чикләгән...*
*Рәнҗеп туктамасын*
*Сиңа*
*Халкың тапшырган каләм!*

Мөдәррис Әгъләм өчен Моң халык күңеленнән табигый рәвештә үсеп чыга. Халык Моңы...—анда барысы да җыелган шул! Ул—яшәешнең күңелләрдәге олуг гүзәл кайтавазы. Зур тормышның һәрбер дулкын кагышы кеше күңеленең пакь ярларына нинди генә хис-тойгылар, нинди генә кичерешләр алып килеп ташламый! Анда Әрнү дә, Үпкә дә, Шатлык та, Инрәү дә, Өмет тә, Тантана да бар... Уйласаң, бер кеше язмышында гына да күпме кичерешләр, күңел тетрәүләре, табу һәм югалтулар була! Сагышлар да, шатлыклар да... Алар барысы да көнен көнгә, айның аена халыкның киң күңеленә җыела киләләр һәм гүзәл Моң булып уяналар, кабыналар.

*«Җиңеләйде еллар»,—дисәк тә без,*
*Һәр көн саен юллар ураулар.*
*Кешегә бер килә, килми калмый*
*Суга карап авыр сулаулар...*

Шушы шигырьдә Агымсу образы татар халык җырларындагы Гомер Агышы символына әверелеп кала кебек.

*Арган йөзен, үз язмышын күргән*
*Гәрәбәле сулар төбендә.*
*Су ярсуы, сулар сабырлыгы*
*Кешеләрнең күркәмлегендә.*

Агымсу монында—гомер агышы монында еш кына мәхәббәт белән бәйләнешле тарихлар яңара... Чөнки, борын-борыннан яшь кызлар су алырга төшкәч яки кер югаңда агымсуларга үзләренең саф мәхәббәтләре белән бәйле серләрен сөйләгәннәр, җырлаганнар...

*Кызлар җыр җырлаган, ярларына*
*Барып кына җитсен моңнары.*
*Ул җырларны сулар меңәр еллар*
*Тыңлый инде... Әйе, тыңлады.*

...Ана темасы, Ана образы Мөдәррис Әгъләмов шигъриятенең башыннан алып ахырына кадәр уза.Үзенең Намусы алдында баскан кебек ул кайта-кайта бу изге темага игътибарын юнәлтә. 1964 елны язылган «Әнигә» шигырендә түбәндәге юллар бар:

*Гомерең буе илне кайгырттың да*
*Соңга кадәр безне уйладың.*
*Синең хисең белән яшим, әни,*
*Син бардагы кебек иманым.*

Менә кайдан да туа икән бу садә Моң: кырыс чынбарлыкта якты күңелле әни-

еннен иманлы яшәешен искә төшерүдән... Әниләр генә тормыштан зарланмыйча авыр йөкне җилкәләрендә күтәреп барырга сәләтле икән...

Әби, дәү әни, бабай, дәү әти, абыйлар, апалар белән дә бәйле Моң еш килеп керә Мөдәррис Әгъләмов шигырьләренә. Мәсәлән, анын әбисенә кагылышлы шигырьләре аеруча күңелгә тия:

*Үлемтеккә җыйган әйберләре*
*Бәйләм-бәйләм, кисәк-кисәкле...*
*Курка-курка ачты ул сандыгын,*
*Курка-курка гына күрсәтте.*

*Таратты да элмә чигешләрен,*
*Җәеп салды азан сөлгесен:*
*—Менә моны әни чиккән иде,*
*Ә монысы—минем кул эшем.*
*Хәситәсен әби тезгән булган,*
*Ә монысын—әти ясады...*

*...Тезеп китте шулай,*
*Күзгә карый*
*Хәситәләрнең ахагы...*

Шагыйрь Мөдәррис Әгъләмовнең башка ак әбиләргә дә, мәсәлән, «Канат» әбигә багышлап язылган моңлы шигыре дә күңелдә янара. Шундый шигырьләр безгә үзебез күреп үскән иманлы татар карчыкларын, пакъ күңелле ак әбиләрне искә төшерә. Бу Моң белән бәйле рәвештә күңелдә Якты Сагыш та, Үкенү дә, иманлы яшәешкә Өмет-Ышаныч та, Яхшылык та янара. Алар кеше яшәешендәге изге төшенчәләрне янарта... Мөдәррис Әгъләмов «Төнге сулар» шигырендә язганча:

*Моңы барның йөрәгеннән*
*Һәрвакытта җылы чыгар.*

* * *

Ахырда күпмедер нәтиҗә ясап тагын бер кат уйланырга, фикер йөртергә мөмкин: ни өчен Мөдәррис Әгъләмов бүгенге көннен олы татар шагыйре булып, XX йөз ахыры—XXI йөз башы татар әдәбиятының әйдәп баручы шагыйрьләренең берсе булып күз алдына килеп баса? Ни өчен анын үзенчәлекле шигърияте менә кырык еллап инде әдәби тәнкыйтьчеләрнең даими күз унында, шигърият сөючеләрнең игътибар үзәгендә?

Ошбу сорауларга, мөгаен, һәр әдәби тәнкыйтьче, һәр ихлас шигырь сөюче үзенчәрәк җавап бирергә омтылыр иде. Безненчә исә, Мөдәррис Әгъләмов иҗатының әдәбиятта, милли җәмәгатьчелектә зурлануынын, югары бәяләнүенең кайбер мөһим сәбәпләре түбәндәгеләр:

Мөдәррис Әгъләмов шигъриятенә аеруча хас булган олы, гүзәл сыйфат ул—халыкчанлык. Халыкның ерак гасырлардан килгән гамьле яшәешендә үз гамьле яшәешен, халыкның шатлыклы һәм хәсрәтле вакыйга-кичерешләргә бай язмышында үз язмышын табарга омтылу хас бу талантлы шагыйрьгә.

Мөдәррис Әгъләмов халыкчан шагыйрь буларак халык бәгыренә, күңеленә җыелганны аеруча тулы, тирән ачып-сөйләп бирүче шагыйрьләрнең берсе. Сәләтле һәр иҗат иясенә дә бирелгән бәхет түгел бу.

Шагыйрь үз иҗатында татар җан-күңеленә хас булган гүзәл, гамьле күренеш—Монны ачып, билгеләп, сөйләп кенә калмый, ә халык традицияләре рухында аны үзенчә дәвам да итә, үстерә дә. Ягъни, халыкнын тарих-яшәеш кырларында борын-борыннан шәкелләшеп килгән күңел Монына ул үз йөрәге түреннән чыккан, тормышта яши-яши туган бүгенге шигъри Моңын китереп куша...

Аннары, тормышчан шагыйрь буларак, Мөдәррис Әгъләмовка үз иҗатында яшәешкә, тормыш дөреслегенә мөмкин кадәр тугры калырга омтылу, кин чын-

барлыкны, реальлекне бар булганынча, бизәмичә сурәтләү хас. Бәхет-шатлыгын да, кайгы-җәфасын да.

Тагын бер сыйфат: хакыйкатькә, яшәеш чынлыгына тугры калырга омтылу шагыйрьне рухи кыйммәтләрне матди кыйммәтләрдән, бакый төшенчәләрне фани төшенчәләрдән өстен куюга, ягъни, татар шигъриятенең кешелеклелек-гуманизм традицияләрен дәвам итүгә этәрә. Чөнки, яшәешнең чын нигезе, Хакыйкать үзе ахыр чиктә нәкъ менә рухи кыйммәтләр белән, әнә шул иң изге төшенчәләр белән бәйләнгән дә бит!



*Мөдәррис Әгъләм һәм Әхсән Фәтхетдинов. 1999 ел.*

Шигъриятендә, кешеләр көнелендә, бүгенге җәмгыятькә авырлык белән үзенә юл салучы рухи кыйммәтләрне яклау-саклау мәсьәләсендә (димәк, хакыйкый кыйммәтләргә, халык көнелендәге мәңгелек рухи традициягә тугрылыкта) шагыйрь ахыргача принципиаль һәм эзлекле кала...

Мөдәррис Әгъләмов халык иҗатының гүзәл традицияләренә, классик шигъриятнең югары үрнәкләренә тугры калу белән бергә традицион шигырь кысаларында беркемнекенә дә охшамаган, беркемне дә кабатламаган үзгә олы шигъри Дөньясын тудыруга ирешкән шагыйрь. Нәкъ менә гасырлардан килгән, буыннар яшәеше аша сыналу узган рухи традицияләр җирлегендә үзенең үзенчәлекле шигъри Галәмен дөньяга китерү аның шигъриятен тагын да олырак, тормышчанрак, озын гомерлерәк итә.

Шагыйрь Мөдәррис Әгъләмовнең гади дә, катлаулы да, табигый да, фәлсәфи дә иҗатына хас сыйфатларны санау-тасвирлауны әле тагын дәвам итәргә булыр иде...

Без Мөдәррис Әгъләмов шигъриятенең бер генә, әмма мөһим булган ягын— Моң белән бәйләнешле фәлсәфи үзенчәлеген, асылын—карап, күзәтеп үттек. Әмма, әйткәнебезчә, аның кырык ел буе үсә-байый килгән шигърияте күпкә зуррак, тема-идея ягыннан күпкә мәгънәлерәк.

Ә ни өчен соң без шагыйрь иҗатының Моң белән бәйләнешле ягына гына игътибар юнәлтүне кирәк дип таптык?

Чөнки шушы бәйләнештә Мөдәррис Әгъләмов шигъриятенең халыкчанлыгы, тормышчанлыгы югары кимәлдә ачыла. Моңга, гомумән, халык Моңына кагылу—халык күнелендәгене ишетүнең, тоюның, әйтеп-сөйләп бирүнең бер матур үрнәге ул. Халык күңелендәгене, моннарны сөйләү аша М. Әгъләмов Моңга мөкиббән халыкның үз шагыйре булып күз алдына килеп баса. Тукай төсле... Сибгат Хәким төсле... Хәсән Туфан кебек...

*Татар театрына 100 ел*

Юныс
Сафиуллин

# СӘХНӘБЕЗНЕҢ ӨЧ ЙОЛДЫЗЫ

Алар өчесе дә Галия исемен йөрткән. Этимологик сүзлек Галия дигән сүзне бөек, югары дәрәҗәле, кыйммәтле мәгънәләргә ия ди. Балаларын бәхетле итеп күрергә теләүче зыялы ата-аналар гына балаларына шундый затлы исем куша аладыр. 1926 елны Казан театр техникумын бергә тәмамлап чыккан өч сабакташка, татар сәхнәсенә хезмәт иткән елларында йолдыз булып балкыган өч артисткага сүзлек санап күрсәткән олы мәгънәләрне өләшеп карасак, бөек дигәне тиңсез тавышы белән татарда опера театры тууга да зур өлеш керткән Галия Кайбицкаяга, югары дәрәҗәле дигәне таланты өстенә искиткеч гүзәл дә булган Галия Булатовага, кыйммәтле дигәне, һичбернинди икеләнүсез, затлы, бик бай гаиләдән чыккан Галия Нигъмәтуллина өлешенә тияр иде. Инде беркадәр шаянрак булган фаразлауга шушында чик куеп, кадерле истәлекләр дөньясына күчик.

Кәгазь битләрендә үзенчәлекле мәкалә рәвешен алган бу хатирәләрне Марсель Сәлимҗанов миңа үзе исән чагында әйтеп яздырткан иде. Безнең бу уртак хезмәтебез аның тормышындагы иң зур тетрәнүләр кичергән соңгы өч-дүрт аена туры килде. Күләме артык зур булмаган шушы истәлекләрне ни өчен өч-дүрт ай язып утырырга мәҗбүр булганыбызны укучыга аңлатыр өчен, яшәү белән үлем арасында калган Марсель Хәким улының рухи дөньясын да берникадәр тасвирлау сорала. Үлем чын мәгънәсендә бугазыннан алса да, үзе турында уйламавын, ә халык ышанып тапшырган театрны яшәтүне беренче итеп куеп, өерелеп килгән сынауларны да сугышчан рухын тагын да арттырып каршылавын күрсәтә алсак кына, өч Галия турындагы истәлекләре үзе сөйләгәндәгедәй яңгырар, бөтен зурлыгы белән ачылыр.

Шулай итеп, аның иң соңгы әңгәмә-интервьюсын укучыларга житкерү миңа насыйп булды. «Насыйп булды» дип әйтүем белән, минем тарафтан аның махсус эшләнгән эш булмавын, ягъни, Сәлимҗановның Чехов урамындагы 33 нче йортта урнашкан фатирына башка мөһимрәк эшләрне эшләргә барып йөргән арада гына кәгазьгә теркәп куйганымны искәртүем.

Имеш, адәм баласы үзенә үлем якынлашуын алдан ук сизеп ала икән. Марсель Сәлимҗанов мисалында моның да мөмкин хәл булуына ышана башладым. 2001 ел декабренә аяк басканда театрларның сәхнә арты дөньясында «Марсель Сәлимҗанов «миңа күп яшисе калмады» дип әйткән» дигән ямьсез сүзләр йөри башлады. Моны ишетүгә, нәфрәтләнеп, «ялган бу» дип кире кактым. Болай итүемә ике нәрсә сәбәпче иде. Шушы вакыйгадан берникадәр алдарак та, ягъни баш режиссер директорыбыз ярдәмендә Казанның иң яхшы врачларына операция ясатырга кергәч, шундый ук гайбәт китте. Янәсе, «врачлар аңарда яман шеш табып операция ясамаганнар». Ни гаҗәп, Алман илендә моның ялгыш диагноз булуы ачыкланып, уңышлы операция дә ясалды. Әмма ләкин артистка була алмый калуын Марсель абыйдан гына күргән бер бик билгеле ханым үз сүзен бирмәве белән шомландырды. Озак та үтмәде, шул шикле сүзләрне раслагандай, «калкансыман бизен дәваларга чакыралар» дигән хәбәр дә кеше теленә керде. Түзмәдем, «беркемгә дә ышанмагыз, саклагыз үзегезне, врачлар кулына бирелмәгез инде, Марсель абый» дияргә кабинетына махсус барып кердем. Шунда аңардан сәер, әмма күтәренке рухтагы: «Мин бу театрга бер биш еллап бик кирәк әле, эшлисе эшләрем күп»,—дигәнен

ишеттем. Бер дә онытылмаслык итеп, үпкә катышкан ярсу аша әйтте ул аны. Янәсе, театрны 35 ел алып барган Марсель Сәлимҗанов артыннан әҗәл үзе килсә дә, театр хакына саклап каласылар—саклап калырга тиешләр!.

Нибары 67 яшьтә генә булган, яшьләрчә дәрт, егәр, гайрәт ташып торган көчле рухлы бу шәхеснең кинәт үлеп китәсенә ышануы бик авыр иде, әлбәттә. Дәвалануы ничек булгандыр, әйтүе кыен, әмма, ул врачлар яныннан бик тиз чыкты. Һәм, үләсен сизгән кебек, ун Марсельдәй эшләргә, моңача вакыты җитмәгән барлык мөһим эшләрен дә үзе исән чагында ук тормышка ашырып калдырырга теләгәндәй яшәргә кереште. Үлеменә нибары берничә ай кала эшләгәннәренә күз төшерсәк, күп еллар яздырырга дип йөргән «Өч Галия»сенә дә аның, ниһаять, вакыт тапканын күрербез.

Шул ук вакытта, үлемнең якын йөрүен сизенү белән бергә, сөекле Гөлнары сызланып искә төшергәнчә, тагын бер ун ел яшьнәп яшисенә, үзенең житмеш яшьлек юбилеен, Казанның мең еллыгын, театрның йөз еллыгын уздырасына да өмет итә иде. 1997 елны үлем белән күзгә-күз очрашырга өлгергән Гөлнарасы гына өсләренә килгән бәланы иренә караганда алдарак бөтен зурлыгы белән сизенеп алды. Алдагысында президент ярдәме белән Марселен Алманиягә алып барып үлем авызыннан тартып алып калалган Гөлнара, театр йөкләгән авырлыкларны ире белән бергә күтәргән искиткеч акыллы хатын, баласына куркыныч янаган ана арысландай үзен бик сак тотты. Әмма, Марсель абый үз каршына тезләнеп ялынган, ялварган Гөлнарасының: «Әйдә, кабат Германиягә барып кайтыйк»,—диюенә дә карамады.



*Марсель Сәлимҗанов әнисе Галия Нигъмәтуллина белән (60 нчы еллар).*

М.Сәлимҗановның кыйммәтләрне үлчи торган бизмәнендә 35 ел алыштыргысыз җитәкләп үстергән театры бар нәрсәдән өстен чыкты. Һәм ул, дәваланып чыгуга ук, ярты юлда калган репетициясен дәвам итте. Авыр репетицияләрдән соң тамагын тоткан килеш бик еш сөйләшә алмый утырган чаклары да күп булды. Әмма, ләкин бүген инде Галия апалар турында сөйли алмас ахры, дип уйлый гына башлыйсың «кил, моны да өстәп куй әле» дигән сүзләрен ишетәсең. Яшь драматург М. Гыйләжев язган «Баскетболчы»ның куелып бетәсенә инде беркем ышанмый башлаганда да чигенергә җыенмады. Аяз Гыйләжев, Нәкыя ханым больницадагы М. Сәлимҗанов өчен бер кайгырсалар, улларының бөек режиссер кулы белән дөньяга килә башлаган хезмәтенең юкка чыгасыннан да бик куркып, Гөлнарадан йә миннән хәлен гел белеп кенә тордылар. «Баскетболчы» театрда укылганда ук бер генә тыңлаучының да яклавын таба алмаганга, алар күңеленә борчу ныклап кергән булгандыр. Артистлар гына түгел, тәҗрибәле Празат абый да бу әсәр мультфильм куярга гына ярый дип каршы чыкты шул. Аны хәтта әсәр белән бөтен кешедән алда танышкан Фәрит Бикчәнтәев тә кире кагарга өлгергән иде. Эшнең яртысына җиткән режиссерына алай-болай берәр нәрсә була калса, «Баскетболчы »ны берәү дә дәвам итмәс һәм итә дә алмас иде. Хәлбуки, гомерен бик нык кыскартса да, Марсель абый бу эшкә ифрат җитди килде. Чөнки монда күпләр уйлап та карамаган бер мөһим нәрсә бар иде. М. Сәлимҗанов гомере буе әзер дип әйтерлек әсәрләр белән генә эш итәргә өйрәнгән, әйе, олы театр йөген тартып баручы өчен бу табигый хәл—яшьләр белән эшләп азапланырга аның вакыты да калмый иде. Һәм, чын дөреслек хакына, бик теләге дә булмады дип тә өстәргә кирәк табам. Ә инде 1992-93 нче елларда бөтенләй тәҗрибәсез бер авторның пьесаларын бишәр

кат үзгәрттертеп, бу эшкә артистлар һәм әдәби бүлекне ныклап җигеп эшләткән очракка килсәк, ансын аңлату өчен башка һәм шактый күләмле дә мәкалә язу кирәк. Хәзерге кереш сүз исә, фәкать, күренекле режиссерның өч Галия турындагы истәлекләрен сөйләгәндә нинди халәттә булганлыгын тасвирлап бирү өчен генә язылды.

М.Сәлимҗановны яңа яшьләрнең үсеп китә алмавы күптән борчып, нык уйландырып торган, күрәсең, аның матбугат битләренә үк сыркып тамган: «Өмет чаткысы булган авторның рәттән берничә пьесасын кире кагасың икән, ул сүнә»,— дигән үкенү хисләре нәкъ әнә шул хакта сөйли иде. Яшәргә күп калмады, ахрысы, дигән эчке сизенү аңа гомеренең соңгы елында бу юнәлештә дә берни белән дә исәпләшмичә эшләп калу кирәклеген искәртеп торган, күрәсең. «Саташкан сандугач» авторын сәхнәгә күтәрү белән үк «Баскетболчы»га тотынуы, бу әсәр аның яшәү көчен көнләп түгел, сәгатьләп суырса да аннан качмавын бары шуның белән аңлатырга мөмкин. Кайчандыр пьесалары куелмау аркасында бизнес өлкәсенә күчеп торган Мансурны башка драматурглар да күреп ымсынырлык итеп канатландырасы килде аның. Беркөнне, репетициянең алга бармавына көенеп, репетиция залын ташлап Кабан күле буена ук чыгып барганда, мине дә ияртәсе итте. Шунда, азрак тынычлангач: «Хәзер кергәч тә мин сиңа «Черная бурка» дигән пьеса бирәм, укып чык та кичен миңа кил әле»,—диде. Өендә сүз башта шул «Кара чикмән»не бик тиз генә тәрҗемә итү кирәклеге турында булды. Бер ай эчендә үк куям, мюзикл жанрында, әмма син гади тәрҗемә эше белән генә шөгыльләнмәссең, әсәргә бик иҗади килүең сорала. Ул хакта соңрак тагы бер җентекләп сөйләшербез. Монда әле икенчерәк эш тә бар. Минем өчен шулай ук үтә мөһим ул...

Марсель Хәким улы бөтенләй көтмәгәндә мине эш кабинетының түр почмагындагы шкафы янына алып килеп шундый эчтәлектәге әңгәмә башлап җибәрде:

—Галия Кайбицкаяның быел 95 еллыгы, син аны беләсеңдер бит?.

—Хәким абый үлгәч, әниегезнең Зарядагы фатирында таныштырдыгыз...

—Әнә шул Галия апаң турында язарга кирәк.

Галия Кайбицкая хакында сөйләшү моннан биш ел элек тә булганга күрә, мин шул чактагы сөйләшүне исенә төшерергә тырыштым: «Андый гына белү аз бит ул. Ни театрда уйнавын күргәнем, ни опера театрында җырлавын ишеткәнем юк. Хәзер бит инде икенчерәк заман, совет чорындагыча итеп язудан китә баралар, Марсель абый. Элек кенә ул әнә җәмгыять рупоры булып язу тиеш иде. Мәҗбүри иде. Теге язылганнардан берәр нәрсә йолкып алып, боларның язмаларыннан нәрсәләрнедер чәлдереп ансат кына әмәлләп куюлар «дөрес язу» булып саналды... Мәскәүдә дә күптән бөтен дөньядагы кебек кеше турында кешечә итеп, ягъни, бары үзе яхшы белгән нәрсәләрне генә яздырталар. Менә әгәр сез үзегез хәтерләгәннәрне, Галия апалар белән бергә үз башыгыздан кичергәннәрне, үзегез генә белгәннәрне әйтеп торсагыз..., шунда, ерып чыгып булыр иде кебек?»

—Риза, булышырмын. Мәле башта шушыны укы.

Кулыннан бәллүр вазаны алам. Ваза Галия апаның Марсель энесенә юбилей бүләге икән.

—Монда тагы шунысын да хәл итәсе иде, Марсель абый, Галия Кайбицкая кебек үк Галия Булатова белән сезнең әниегез Галия Нигъмәтуллиналарның да яшьләре шул бер чама бит...

—Әнигә әле 2002 елда гына тула... ул бит 1907 елгы.

—Аның каравы алар өчесе дә театр техникумын 1926 нчы елда тәмамлыйлар. Быел әнә шул мөһим вакыйгага 75 ел булды.

—Син өч Галияне бер мәкаләдә кушып язарга тәкъдим итәсеңмени?—диде ул кинәт яктырып.

—Шулай кирәктер шул. Бергә укып, укуны бергә тәмамлап, гомер буе бер-бере белән аралашып яшәгән өч дус, өч Галия турында аерым-аерым язуга караганда уртак мәкалә язуы кызыклырак булыр кебек...

Безнең бергә язу тәҗрибәбез булгач, шундук язарга керештек. Дөресрәге, ул сөйләп, мин ул сөйләгәннәрне кәгазьгә терки башладым. Чөнки, кәгазь-каләмне Марсель абыйның җене сөйми иде. Мине партиягә үзе мәҗбүриләп керткән чагында бер битлек рекомендацияне дә өч-дүрт көн буена сырлады ул. Бу юлы хәлләр тагы

да катлаулырак иде. Мәгәр, үз кадерлеләре турында үзе генә яза алганын да яхшы аңлый иде ул. Хәтта хәле бетеп ятып кына торган чакларында да хатирәләрен искә төшерүдән туктамады. «Баскетболчы» куелып бетмәгән килеш инде «Кара чикмән» белән эшне җәелдереп җибәргәндә дә, тәрҗемәмне укыганда да, спектакльнең булачак рәссаме (С. Скоморохов), композиторы (А. Хәсәенов) белән киңәшеп, яки балетмейстры турында сөйләшеп, рольләргә артистларны сайлап утырган чакларыбызда да кинәт бүленеп теге яки бу истәлекне сөйләп ала иде. Шуннан, кулындагы дисбесен тарта-тарта, үзенә бүләк ителгән уннарча картиналары янында йөреп килә. Соңгы елларда белгән догаларын ачыктан-ачык укып йөри башлавын күреп торганлыктан, дисбе тотып йөргән чакларында М. Сәлимҗанов Галия апаларга багышлап дога укып йөридер кебек тоела иде. Беренче итеп әнисен сөйләр дип уйлаган идем, ялгышканмын, ул Галия Кайбицкая турында сөйләп башлады.

—Менә бу почмактагы шкафта миңа бик кадерле булган кешеләр белән бәйле ядкәрләр саклана. Күнелем бүген дә нишләптер мине шулар янына тартып китерде.

Күзләремне, ирексез, иң түрдә торган бәллүр ваза үзенә җәлеп итте. Анда: «Марсельнең 50 еллыгына. Галия апаң Кайбицкаядан» дип язылган.—Әлбәттә, бу бәллүр ваза дөньядагы иң затлы, иң матур ваза түгел, әмма аны бүләк итүче Галия апа минем өчен әнием кебек үк бик якын шәхес иде. Ул да мине үз баласы шикелле итеп сөя иде. Һәр премьерамны карап бара, уңышларыма куанып коча, үбә иде. Җанымны кай яклары белән үзенеке итә алды икән соң ул? Тумыштан йомшак холыклы, сабыр, беркемне дә үпкәләтә белми торган холкы беләнме, әллә тинсез талантына гашыйк идемме мин аның? Шушы сораулар мине Галия апа турында белгәннәремне тагын бер кат барлап чыгарга мәҗбүр итәләр.

Әйтәсе сүзем тулы булсын өчен өч Галия турында сөйләп башлау уңышлырактыр. Татар театр сәнгате тарихын Галия Кайбицкая, Галия Булатова, Галия Нигъмәтуллина кебек олы язмышлы артисткалардан гайре күз алдына китерүе кыен. Һәр өч Галия дә татар халкы зур янарышлар кичергән чорда туган. Китап бастыру чәчәк аткан, күпләп газета-журналлар чыгарылган, инде профессиональ театр да бөреләнгән 1906, 1907 елларда дөньяга аваз сала алар. Галия (Төхфәтуллина) Кайбицкая—Уральск (Җаек) шәһәрендә, Галия Булатова Әлки районының Югары Әлки авылында, алардан бер-ике яшькә яшьрәк булган Галия Нигъмәтуллина Орск шәһәрендә. Язмыш бу өч Галияне башта Казан театр техникумын тәмамлатып Г. Камал исемендәге театрда бергә бер төркемгә берләштергәнчегә кадәр үк, аларны үзара әледән-әле очраштыргалап тора. Партия кая җибәрсә, шунда барып эшләгән Зәйтүнә Булатова бер дә бер көнне, авылдан килгән сеңлесе Галияне дә ияртеп, Уральск шәһәренә килеп чыга һәм Галия Кайбицкаяның абыйсы Камил Төхфәтуллин (Мотыйгый) чакыруы буенча аларда яши башлый. Чөнки, алар Ишембайда укыткан чакларыннан ук яхшы танышлар булалар. Белгәнебезчә, Камил Мотыйгый шул чорның иң алдынгы кешеләреннән санала. Тарихка ул Тукай һәм Кариевларның якын дусты, нәшир, журналист, атаклы җырчы буларак та кереп калган. Кичләрен әлеге гаиләгә төрле талантлы яшьләр җыела. Анда төрле уен коралларында уйныйлар, җырлыйлар. Әлеге талантлы яшьләр арасыннан киләчәктә зур җырчылар, драма артистлары, хәтта режиссер да үсеп чыга.

Сүз иярә сүз чыга. «Марсель абый, Галия апага моннан 3 ел элек музей да ачтылар бит»,—дим.—Дәүләт музее. Тау ягының Кайбыч районында. Юкка гына Кайбицкая дигән тәхәллүс-псевдоним алмаган икән. Кайбычныкы дигән сүз бит...

—Беләм. Галия апаның олы улы Сәйяр, моннан биш ел элек үк нигезенә таш салдым, дип әйткән иде. Гомумән, нәселләре бик затлы, талантларга бик бай булган. Шәҗәрәләре зур укыгын муллалардан башланган.

—Ә менә Галия Булатованың апасын искә төшергән идегез, ул бит бөтен җирдә совет власте урнаштырып йөрүче булган. Икенче апасы да шул юлдан киткән. Совет власте төзүчеләрдән чыккан Галия белән сыйнфый дошманнары булган мулла һәм зур байлар нәселеннән чыккан Галияләр арасында дуслык булуы берникадәр сәеррәк...

—Тормыш шундый күптөрлелеге белән кызык. Инде шуннан партия работнигы булган апасын янә каядыр күчерәләр. 15 яшьлек Галиягә кабат Әлкиенә, атасы Фатыйхның ярлы гаиләсенә кайтырга туры килә. Шуннан инде Мәскәүдә булырга да, Ташкентта яшәп алырга да өлгерә ул. Мөхәммәт Әблиев белән дә таныша. Шул

булачак драматург ана, Казанда театр техникумы ачыла икән, дигән хәбәрне житкерә. Театр белән кечкенәдән женләнгән Галия Булатова нәкъ менә аның киңәше белән театр дөньясына килеп керә. Сонрак аның «Шәмсекамәр»ендә төп рольне уйнап әлеге спектакльнең озак елларга сузылган уңышын тәэмин итә.

—Сезнең әтиегез Хәким ага сөйләгән иде. Мифтах Әпсәләмов—татарның тиңсез артисты безнең Орск шәһәрендә туган, безнең шундагы театрда эшләгән, дип. 1919 елны ана хәтта Казаннан килгән Габдулла Кариев кул астында да эшләп алырга туры килә. Янәсе боларның күп санлы репетицияләре Орск шәһәренең иң зур бае булган Нигъмәтуллиннарның таш өендәге күп санлы бүлмәләренең берсендә алып барылган.

—Ул йорт әле дә исән. Мин аны гастрольгә баргач карап кайттым. Бер сөйләгән дә идем бит. Ул минем әниемнең туып үскән йорты. Алай гына да түгел, әтинең күңелендә әнигә ниндидер тойгылар уяна башлаганына шаһит йорт та ул.

—Әйе, анда Хәким абый яшүсмер егет чагында ук килеп кергән, булачак бабасына башта йомышчы малай, аннан приказчик рәвешендә хезмәт иткән.

—Әни әйтә иде: «Кариев бездә репетицияләр ясап йөргән көннәрдә мин яшүсмер кыз бала гына идем, әмма әлеге репетицияләрне хәтерлим, кичә күргәндәй күз алдымда тезелеп торалар»,—дип. Иң мөһиме Габдулла Кариев шушы килүдә Мифтах Әпсәләмовка «син олы сәхнә өчен тугансың, үсешеңне туктатма, халыкка хезмәт ит, Мифтах дус» дип васыять әйтеп китә. Әпсәләмов шуннан Уфа һәм Казан театрларын шаулата башлый. «Һижрәт»тә Гайнетдин мулланы, «Иван Грозныйның үleme»ндә явыз Иванны, «Галиябану»да Бәдри картны, «Хажи әфәнде өйләнә»дә Юныс хажины искиткеч уйный. Орскига ял итәргә кайткан саен гел театрга да килә. Орск театры дәрәжәле театрлардан санала. Моңа вакытында Габдулла Кариевның спектакльләр килеп куюлары да тәэсир иткәндер. Орск шәһәре татар театры тарихында гына түгел, татарның милли тарихында да аерым урын биләгән шәһәр. Казагыстан белән Урта Азияне тоташтыручы шәһәр. Орскидан ерак түгел жирдә Күкшел дигән авылда үлемсез «Галиябану»ның авторы М. Фәйзи дә дөньяга килгән. Ул үзе чыгышы белән безнең әтиләр кебек үк Татарстаннан. Атасы Балтач янындагы Шода авылыннан чыккан. Нәкъ менә шушы берсеннән-берсе бик ерак урнашкан ике авыл арасында кайтып-китеп йөргәндә «Галиябану»ы язылган. Тагы да бик күп бөекләрне биргән Орск. Башкорт театрына нигез салучыларның берсе татар кызы бөек Бәдәр Йосыпова да чыгышы белән шуннан. Ул Кариев куйган спектакльдә Галиябану була, аның әнисен Мирхәйдәр Фәйзи үзе Мирфанская дигән сәхнә псевдонимы астында уйный.



*Рәсемдә (сулдан уңга): Ә. Мәҗит, Ә. Уразаев, Г. Нигъмәтуллина, Г. Булатова, Һ. Такташ. 1927 ел.*

—Габдулла Кариев Орскта тагын ниләр куя?

—«Хажи әфәнде өйләнә». Аларда әтинең абыйлары да катнашалар. Тагы ике әйбер куя, аларын искә төшкәч әйтермен.

—Шулай, «Галиябану» авторын башкорт итеп күрсәтергә тырышып көчәнүләре көлке. Әни белән әтинең сәхнәдә беренче чирканчык алулары да шушы Орск театрында була. Мифтах Әпсәләмов туган шәһәренә кайткан саен, әлеге ике яшьне үзе куйган спектакльләргә катнаштыра башлый. Әти белән әни аның кул астында «Таһир-Зөһрә»дәге төп рольләрне дә башкаралар. Кыскасы, Мифтах Әпсәләмов соңгы кайтуында аларны үзе белән Казанга китәргә өнди. Яңа ачылачак театр

техникумына керергә киңәш итә. Казанга Җаектан 17 яшьлек Галия дә килеп төшә. Шулай итеп, 1923 ел өч Галия язмышына, өч талантны бергә очраштырган, гомерлеккә дуслаштырган бәхетле онытылмас ел булып кереп кала... Кемнәр була соң аларның остазлары. Иң беренче чиратта актерлык осталыгына укыткан рус драма театры режиссеры Зинаида Михайловна Славянованы атау кирәктер, аннары музыка белеме буенча дәресләр алып барган Салих Сәйдәшевны, тел һәм әдәбият буенча белем биргән язучы Фатих Әмирханны. Безнең өч Галиябез, укуларының беренче елыннан ук, театрда Кәрим Тинчурин ярдәме белән төрле зурлыктагы рольләр башкара башлыйлар һәм уку елларында ук артистлар булып танылалар. Шуңа Галияләр гомерләре буена үзләренең техникумдагы остазлары янәшәсенә Кәрим Тинчуринны да куеп олыладылар, сагындылар.

—Иң беренче рольне Кәрим Тинчурин Галия Булатовага биргән. «Зәңгәр палас»та.

—Ансы гына хәл итми. Һади Такташ шулай ук әнә «техникумның әле беренче генә курсында укып йөргән Галия Кайбицкая, Ф. Бурнашның «Таһир-Зөһрә» спектаклендә катнашып, хан кызларының берсен халык күңеленә кереп калырлык итеп башкарды» дип язган. Композитор Солтан Габәши белән Шәрыкъ музыка техникумы директоры А. Литвинов Галиягә музыка белән чын-чынлап, җитди итеп шөгыльләнергә киңәш итәләр. Аларның тырышлыгы белән Галия укуын берьюлы ике техникумда алып барырга мәҗбүр була. Театрда ул, гомумән, аерым мәхәббәт казана. Аңа рольләрнең яңадан-яңалары бирелә. Икенче курста укыганда «Асылъяр» музыкаль драмасындагы төп героиня Ләләне башкара ул. Партнерлары Габдрахман Камал, Мохтар Мутин, Гөлсем Болгарская, Нәфига Араповалар була. Бу спектакльне Мирхәйдәр Фәйзи үзе дә карый. Ләлә-Галиянең уенына, соклангыч тавышына бик югары бәя бирә, гүзәл киләчәк юллый... Шулай итеп, студентка шаңлы артист Ситдыйк Айдаров һәм Кәрим Тинчуринның үзе белән партнерлык итә башлый. Чиратта «Казан сөлгесе»ндәге Мөршидә роле, «Зәңгәр шәл»дәге Мәйсәрәсе исә Р. Кушловская белән алмашлап башкарыла. «Таһир-Зөһрә»дәге Зөһрәсен дә ул студентка булып уйный башлый.

—Марсель абый, драматург Нәкый Исәнбәт һәм аның фикердәшләре музыкаль спектакльләргә каршы булганнар икән бит. Зур бәхәсләр купкан...

—Алар музыкаль спектакльгә каршы килеп түгел, ә спектакльне концерт белән алыштыруга каршы көрәшкәннәр.

—Ялгышмасам, бу чын көрәш төсен алган. Бу хакта күп укырга туры килде, алар М. Фәйзи, К. Тинчурин һәм башкаларның музыкаль әсәрләренә каршы чыкканнар.

—Мин үзем жанрларның бай булуы ягында.

—Шуның өчен «Кара чикмән»не мюзикл итеп куясызмы? Азат Хөсәенов бик популяр композитор... «Казан егетләре» белән дә шаулатты бит...

—Режиссер сәхнәдә художественный мир (сәнгати дөнья) тудыра алмаса, музыка, биюләр белән генә спектакльне коткара алмый. Бер француз язучысы бу хакта бик шәп әйткән. Мәгънәсез спектакльне чәчәкле-чуклы декорациягә төреп, музыка, бию белән шыплап тутырсаң да, ул, барыбер мәгънәсез спектакль булып кала, дигән. Монда тагын бик мөһим нәрсә бар. Айдаров һәм Кайбицкаялар белән эшли башлагач, композитор үз иҗатында яңа борылыш кичерә. Әйтик, Тинчуринның «Ил», «Кандыр буенда» Тажи Гыйззәтнең «Наемщик» спектакльләренә музыка татар операсы туарлык югарылыкта языла. Галия белән Ситдыйк кебек бик катлаулы иҗатны да сәхнәдә гәүдәләндерерлек артистлары булу Салих Сәйдәшев музыкасын тагын да үстерә. Арияләре дә, хорлары да, дуэтлары да, увертюра һәм балетлары да һәммәсе әзер халык моң-көйләренә генә таянудан түгел, ә үз күңелендә өр-яңа музыка тудыруы аша дөньяга килә. Әгәр ары таба да Салих Сәйдәшев шушы юнәлештә иҗат итә алу мөмкинлегенә ия булса, татар моңын урыслаштыру өстенлек алмаса һәм сәхнә түре Илһам Шакировныкыдай татар моңына ия тавышларга тапшырылса, бүгенгесе көндә татар опера театры сүнүгә юл тотмас иде...

—Галия апа Зифаны уйнаганда мин аның улы Иделне уйнадым. Шуннан соң бу рольне Рәшидә Жиһаншина һәм Галимә Ибраһимовалар белән дә уйнарга туры килде. Ай-һай, аерма зур иде. Менә әле дә Галия апаның йөрәкне уяткан уены сагындыра. Ул чын әни кебек иде.

—Бәхәс кузгатырлык нәрсә күрмим. Өч Галиянең икесен Г. Камал театрында эшләргә калдыралар.

—Әниегез әйткән иде шул, Галия Кайбицкая, Каюм Бариев, Зариф Закиров һәм Хәким абыең белән менә мине генә Академия театрында эшкә калдырдылар, дип.

—Галия Булатованы Мәскәүгә татар эшче театрына чакырып алалар. Аның чоры шундыйрак. Артистлар туктаусыз хәрәкәттә. Казанда нибары бер сезон эшләргә өлгергән Галия Нигъмәтуллина да Мәскәүгә чакырыла. Ә Булатова исә Астрахань театрына юл тота. Бу вакытта инде Галия Кайбицкая чын-чынлап театрның музыкаль героинясына әверелгән була. Драма театрында ул 1933 елга кадәр эшли.

—Сезгә дә аны драма сәхнәсендә күрергә туры килмәгән икән.

—Әмма мин аның драма театрындагы иҗатын артистка белән бер чорда эшләгән Фатыйма Ильская, әнием, әтием һәм башка артистларның сөйләгәннәре буенча бөтен зурлыклары белән күзаллыйм. Галия апага Фатыйма Ильская, Мәрьям Сульва, Гөлсем Болгарская, Нәгыймә Таҗдарова кебек бер-берсенә бөтенләй охшамаган артисткалар янәшәсендә иҗат итү образлар тудыру осталыгының бөтен нечкәлекләрен өйрәнүгә юл ачкан. Алар Фатыйма Ильская белән утызынчы еллар башында куелган Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт»ендә ике көндәшне Луиза белән Леди Мильфортны уйныйлар. Фердинанд өчен барган көрәш-бәрелеш сәхнәсенең Галия Кайбицкая тарафыннан искиткеч эмоциональ һәм шул ук вакытта иң нәзакатьле бизәкләр ярдәмендә башкарылуын Фатыймаападан күп тапкырлар ишеткәнем булды. Актрисаның драма театрындагы соңгы музыкаль рольләре «Кандыр буенда»гы Гөләндәм һәм «Наемщик»тагы Гөлйөзем образы була...

—Галия Кайбицкая Мәскәүгә киткәндә Галияләрнең башкалары да Академия театрына җыелган булалар бит...

—Күптән. Алар инде һәр өчесе дә Академия театрының танылган артисткалары. Булатова әти куйган «Камил» спектаклендә төп героиняны уйнагач, монардан Һади Такташ аеруча илһам ала. Спектакльне киносценарий итеп эшли. Вакытсыз үлеме генә эшенең тормышка ашуына комачаулый. Г. Кутуй әсәрендә дә бик яратып кабул итәләр Булатованы.

—Без өч Галиянең өчесе турында да язарга дип килешкән идек. Әле әниегез турында бөтенләй диярлек телгә алмадыгыз. Әллә сез әниегез булган өчен Галия Нигъмәтуллинаны мактарга уңайсызланасызмы?

—Ул бит минa 1934 елдан соң гына әни. Мин туган елны ике Галия адашларын Мәскәүгә озатып калалар. Галия Кайбицкая белән Ситдыйк Айдаровлар опера сәнгате серләре дигән олы диңгезгә кереп китәләр. СССРның халык артисты, атаклы дирижер Натан Рахлин әйтмешли, әлеге очрак опера тарихында бердәнбер булгандыр, мөгаен. Гадәттә бит ул шулай: драмадан опера артистына түгел, ә киресенчә, операда берничә еллар җырлап алган артистлар драма артистлары булып күчәргә мәҗбүр булалар. 1934 елда башланган укулары 1938 елда тәмамлана. Шушы вакыт эчендә Д. Беляевская классында Галиянең тавышы янара. Ул колоратур сопрано булып ачыла. Бусы инде үзе бер могҗиза. Һәм менә, ниһаять, татар операсының беренче карлыгачы, Нәҗип Җиһановның «Качкын» операсы сәхнәгә күтәрелә. Төп партияне Галия Кайбицкаяга тапшыралар. Опера сәнгатендәге беренче зур уңышы ана «Галиябану», «Алтынчәч» «Башмагым» операларындагы төп героиняларга юл ача. Татардан тыш рус һәм дөнья композиторлары иҗат иткән операларда да ул тудырган үлемсез образлар бик күп. «Ин-иннәре» дип бик хаклы рәвештә Вердиның «Травиата»сындагы Виолеттаны, «Риголетта»да Джильданы һәм Римский-Корсаков иҗатыннан «Царская невеста»дагы Марфа образларын саныйлар. Минем тормышыма опера сәнгатенең бөтен зурлыгы белән килеп керүендә опера театрының ике бөек артисты төп роль уйнады дияр идем. Әйе, әнием белән туктаусыз аралашып торган, якын ахирәте дә булган Галия Кайбицкая һәм Фәхри Насретдиновлар иҗаты аша мин катлаулы сәнгать төре булган опера сәнгатен аңлап кына калмадым, ә чын-чынлап гашыйк та булдым. Галия апа опера театрында 19 ел эшләде. Халык артисткасы дигән исемне казанды... Әмма дә ләкин үзенең таланты белән, башкарган эшләре белән, ул, һичшиксез, мактаулы исемнәрнең иң-иң зурларына да лаек иде. Опера театрына күчеп эшләсә дә Галия Кайбицкая гел беренче яшьлеген бүләк иткән һәм үзенең адашлары эшләгән Г. Камал театрына килеп йөрде. Якын дуслары ирешкән һәр уңыш белән дә

үзенеккеннән дә артык күреп сөенә белде. Галия Булатованың Островский язган «Гаепсездән-гаеплеләр»ендәге Кручининасы, М.Әмирнең «Минлекамал»ындагы Минлекамалы, Нәкый Исәнбәтнең «Рәйхан», «Зифа»ларындагы төп рольләре, Шекспирның «Король Лир» трагедиясендәге уртанчы кыз Реган кебек рольләренә чын күңелдән сокланса, Галия Нигъмәтуллина тудырган Мәпә, Зәмзәмбану кебек кире образларның халык арасында бик киң таралыш алып әнигә үзенчәлекле дан алып килүләренә ничектер гаҗәпләнә дә, горурлана да иде. Шул образлар мактап язылган газеталарны өйгә алып килгәләгәне дә булды аның. Әнинең үзенә дә, яратып кына, шул тискәре рольләрнең исемнәре белән эндәшкән чакларын хәтерлим.

—Әниегез турында Наилә Гәрәева хәзер дә яратып искә төшерә. «Кеше буларак та юмарт күңелле иде» дип мактый-мактый да, «бөтен хәерче артисткаларны акча белән тәэмин итеп торды инде» дип куя. Галия апаның бер китапка бик хәтере калды да, сез дә ул очракны беләсез, министр исеменә миннән хат яздырды. Шуны язып йөргән көннәрдә Галия апаның табыннарындагы муллыкка, кешегә күрсәткән ихлас хөрмәтенә мин дә сокландым. Бик горур да иде ул. Хатны да бит әлеге китапта ни үзен, ни Хәким абыйны һәм тагы да башка күпләрне искә алмауларына ачынудан яздырды. «...Үз гомеремдә мин күпне күрдем, әмма 80 яшемне тутырганда бөтен тормыш юлымны бер селтәнүдә сызып ташларлар дип һич көтмәгән идем. Югарыда исеме аталган 192 битлек китапта Академия театры сәхнәсендә тоташ 52 ел буе эшләгән артистканың фамилиясен хет бер генә тапкыр телгә алып китсәләр дә язык булыр иде микәнни? Без Кәрим Тинчурин шәкертләре, ул өйрәткәнчә татар театр сәнгатенә фидакарь хезмәт итәргә тырыштык. Хөкүмәтебез аны күрде-таныды, кайгыртты, тиешле бәяләде. Миңа, мәсьәлән, төрле елларда обком һәм Министрлар Советының, РСФСР һәм ТАССР министрлыкларының Мактау грамоталары бирелде. 1957 елда Почет билгесе ордены, шулай ук төрле медальләр дә тапшырылды. Башта атказанган, аннары халык артисты исеме дә бирделәр. Менә болар китапта исемнәре мактаулы кешеләр янәшәсенә димим, хет берәр бушрак җиренә «Галия Ниъмәтуллина дигән артистыбыз да бар иде» дип теркәтерлек тә хокук бирмиләрмени. Дөрес, безнең буын артистлары исем алу чире белән авырмыйлар иде...» Менә шушында тагын Галия апа Булатованың ТАССРның гына түгел РСФСРның да халык артисткасы булып үсеп җитүен искә төшерәсем килә. Галия Нигъмәтуллинаны андый югары исемгә лаек дип санамаганнар. Мәгәр Рәүф Игъламов артистка турында язганда аның уенына СССР халык артистларына гына бирелергә лаек бик кыйммәтле бәһане куя. «Театрның төрле чорлары булды, анда төрле агымнар өстенлек итте, бүген мөһим саналган нәрсәләр иртәгесен юкка чыкты, әмма Галия Нигъмәтуллина гомере буе театр өчен бик кирәк артистка булды». Чыннан да, Галия Нигъмәтуллинаның иҗатында яңарган, үскән традицияләрне дәвам итүчеләр бүген дә сәхнәдә уңыш казана. Артистка кайсы гына жанрда иҗат итмәсен, ул тудырган гүзәл үрнәкләр бихисап.

—Әни озак еллар дәвамында куела, яңартыла килгән «Зәңгәр шәл»дә Ишанның дүрт хатынын да уйнап чыкты.

—1971нче елны «Сүнгән йолдызлар»да туган олы җанлы Гөлнур карчыгы да исән... Әлмәндәр килене Өммиядә ул тапкан образ әле дә башка артистка уены аша булса да яшәвен дәвам иттерә.

—Әйе, иҗатлары, эшләгән яхшылыклары күңелләребездә урын алды. Сере моның шундадыр: Өч Галия үзләре исән чакта бер-берсен онытмыйча, бер-берләреннән көч алып, бер-берләрен кадерләп яши белделәр. Аларның якты дуслыгы иҗатларында да чагылды. Мин әле ышанам Галияләр тудырган үлемсез образлар галереясы килер буын артистларына да алга бару юлларын күрсәтеп торыр. Бәлкем әле безнең киләчәк буын артистларыбыз да аларның шундый катлаулы тормышта да олы булып кала алуларыннан үрнәк алып яшәрләр. Бөекләребезнең урыннары җәннәтнең түрендә булсын иде!

# ЧЫН ТАТАРЧА МИЛЛИ КӨЙ...

Утыз ел буе иҗади эшчәнлек белән шөгыльләнгән теләсә кайсы художник, ягъни сәнгать кешесе турында нәрсә әйтсән дә урынлы булыр кебек. Менә шундыйрак уйлар белән мин дә каләмгә тотындым. Сүзем—Татарстанның бик үзенчәлекле, башкаларны кабатламый торганрак композиторы Шамил Тимербулатов турында булачак.

Ул—татар музыкасының данлы традицияләрен дәвам итүчеләрнең берсе бүгенге көндә. Аның иҗатындагы **якты мелодизмны**, югары осталыкны, тирән эчтәлекле аһәңнәрне танымый мөмкин түгел. Бүгенге татар музыкасына житеп бетми торган якты мелодизмны хәтта аерым билгеләп үтәргә кирәктер, мөгаен. Бер дә унайсызланмыйча әйтә алам, соңгы елларда һаман саен сәхнәләргә сикереп менә торган дәртсез, көйсез, талантсыз күп кенә әсәрләр белән чагыштырганда аның музыкасы тере-шифалы чишмә суы кебек күңелләргә үтеп керә.

Шамил Тимербулатов иҗаты кайсы ягы белән үзенә шулай тарта соң? Иң әүвәле турыдан-туры тыңлаучыга, кешеләр йөрәгенә, аларның күтәренке хис һәм фикерләренә моң-музыкасы белән тәэсир итә алуы нәтиҗәсендә, әлбәттә.

Ш. Тимербулатовның композиторлык биографиясе яшьлек елларыннан ук башлана. Баянчы буларак Казан музыка училищесына укырга кергәннән соң, ул композитор А. Лупповның композиция буенча факультатив дәресләренә йөри башлый. Шушы тырышлыклардан соң ул 1972 елны Казан дәүләт консерваториясенең композиторлар бүлегенә укырга керә (житәкчесе—шул ук профессор А. Луппов). Укыган вакытларында ук үзен житди шәхес, иҗат кешесе икәнлеген таныта. Аның «Баянда оркестр белән концерт» дигән диплом эше әле дә булса сәхнә тота, репертуар әсәрләреннән санала.

Үзенең 30 еллык эшчәнлегендә композитор төрле жанрларда—җырлардан алып симфоник оркестр өчен колачлы әсәрләргә хәтле иҗат итте. Болар—баян өчен дә, думбра һәм балалайка өчен дә, шулай ук халык уен кораллары өчен миниатюралар циклы («Авыл күренешләре», «Табигать серләре»), Батулланың Сөембикә ханбикәгә багышланган романына нигезләнгән симфоник картиналар.

Күренекле иҗатчылардан, гадәттә, һәркайсының яраткан тема һәм сюжетлары була. Аның геройлары исә—үзенең үткәне, бүгенгесе, киләчәге белән шатлык һәм борчуларын чагылдырган татар халкы. Әлеге уйлану-тетрәнүләр аның күп кенә әсәрләрендә лирик кинлек яисә мәһабәтлек чагылыш таба. Мондый констрастлыкны баян белән оркестр катнашындагы концертында, бигрәк тә «Симфоник күренешләр»ендә ишетми мөмкин түгел. Әйтергә кирәк, соңгы әсәр үзенең төрледән-төрле образлар гәүдәләнеше белән аеруча сокландыра. Бирелә—оркестр портретларының өр-яңа үрнәкләре, алар геройларның күңел халәтен һәм психологиясен дөрес, ышандырырлык итеп чагылдыра, («Сөембикә йокысы», «Үтәмешнең күңел ачуы», «Кара кошчык», «Кызның күз яшьләре») һәм күп бизәкле көнкүреш-жанр картиналары («Гашыйклар бакчасы», «Кәрванның кайтуы», «Әстерхан биюе», «Амазонкалар юлы»).

Композитор иҗатындагы тагын бер сыйфатны билгеләп үтәсе килә, монысы—туган як табигатен, аның илаһи кинлекләрен музыка аша сурәтләү. Аның инструменталь концертын яисә оркестр пьесаларын тыңлаганнан соң ирексездән: «Бу бит безнең туган Татарстаныбыз, Казан арьягы!»—дип кычкырып җибәрәсе килә. Өстәвенә, Ш. Тимербулатов бу очракта табигатьне әле куе, әле якты-көчле тоннар белән тасвирлый («Сабантуй», «Әйлән-бәйлән аланнары» һәм башкалар). Гомумән, бу авторның «язмалары»нда күптөрле рух халәтләр гәүдәләнеш таба: яки халыкның бөеклегенә соклану, дан җырлау, яки күпне кичергән табигатебезгә әрнү-сызлану кебек уйланулар белән мөрәҗәгать итү.

Композиторның бер әсәренә аерым тукталасы килә. Ул Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында башкарылды һәм искиткеч көчле алкышлар белән бәяләнде. Сүз танылган пианист Марат Сиражетдинов зур осталык белән башкарган

«Минем Казаным» дигән фортепиано өчен оркестр Концерты турында бара. Әсәр бер сулышта башкарылды. Музыкадан энергия ташып тора, ул чын мәгънәсендә рухи күтәренкелек, тинсез шатлык белән сугарылган.

Биредә Ш. Тимербулатовның башкалабызга карата чиксез мәхәббәте ярылып ята, ә Казанны шулай матур итеп үзгәртүдә дә бер Кешенең эшчәнлеге һәм тормышчан зирәклеге, һичшиксез, зур роль уйнады. Әсәренә карата язылган аңлатмасында композитор үзе болай дип яза:

*«Минем шәһәрем—шатлык, яшьлек һәм яктылык мәркәзе. Мөгаен, андагы кешеләр дә яхшырып, матурланып китте шикелле. Кремль стенасына караш ташласаң, анда торгызылган мәчет манараларының, чиркәү гөмбәзләренең күккә төбәлеп торулары күнелгә ятып тора. Шәһәребез—үзе яшь, үзе борынгы... Әлеге үзгәрешне үзенең туган халкын яраткан, иҗади төзелеш, мәхәббәт һәм янарыш программасын чынга ашыра алырдай кеше генә башкара ала. Шуңа күрә мин үземнең фортепиано концертымны Татарстан Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиевкә дә багышлыйм».*

Әгәр без аның камера-инструменталь өлкәдәге эшчәнлегенә тукталмасак, Шамил Тимербулатовның иҗат портреты тулысынча булмас иде. Музыка мәктәбе, училищелары репертуарын тулыландыру өчен аның тарафыннан язылган җыр һәм ансамбль әсәрләре күп кенә инструментлар (халык, кыллы, өреп уйнала торган) ярдәмендә башкарыла ала. Бу өлкәдә аның игътибарын Г. Зәйнәшева, Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Вәлиева, Р. Миңнуллин, Р. Корбанов, Ш. Җиһангирова һ. б. шигърияте үзенә тартып тора.

Бу юнәлештә дә Тимербулатов жанрлар төрлелегенә юл таба: вокаль цикллардан алып романс һәм эстрада-көнкүреш җырларына кадәр... Ул хәтта лирикада да монсу-элегик ноталардан комедиячел-шаян дулкынга күчә ала. Һаман да шул хәзинә инде—мәхәббәтне һәм табигатьне җырлау, зурлау. Әсәрләрнең исеме генә дә әнә шул хакта сөйли түгелме соң: «Аланда», «Табигать кочагында» (Р. Фәйзуллин сүзләре), «Язгы наз» (Р. Харис), «Сандугач балалары» (Р. Корбанов), «Урман чишмәсе» (Р. Вәлиева). Мәхәббәт турындагы яхшы җырлар зур талантларның игътибарыннан читтә кала алмый. Менә шуңа күрә затлы, оста җырчыларыбыздан Х. Бигичев, З. Сөнгатуллина, В. Ганиева һ. б. репертуарын бизәп тора. Бу моңнар төрле радиолардан еш яңгырап тора, һәркемнең күңелендә.

Сүземне түгәрәкләп, шуны әйтәсе килә: Ш. Тимербулатовның иҗатында оста художник «кулы» сизелеп тора, ул башкаларны кабатламый, җиңел юлдан бармый. Аның музыкасы—катлаулы, ләкин бик ачык һәм үтемле. Ул, һәрхәлдә, объектив образлар тудырырга омтыла һәм моңа ирешә дә. Юкса кайберәүләр бүгенге көн музыкасына тәэсирлек, кайнар канлылык, субъективлык, темаларның күп кисәкләргә «таркалган» булуы тиеш дип саныйлар. Шундый агымнан аермалы буларак, Тимербулатов—тормышчанлык, көнкүрешебезгә якын булган заманча чараларны, мелодик чишмәләрнең табигыйлеген сайлый. Ягъни үзенең гармоник, оркестр язмаларын милли рухка, татар стиленә буйсындыра. Миңа калса, мондый юл, мондый максат беркайчан да искермәячәк! Аның музыкасы тыңлаучыларны халыкчан-милли нигезгә корылганлыгы белән үзенә җәлеп итә.

Шамил Тимербулатовның уңышларын танымый мөмкин түгел. Хәзер исә композитор, киң колачлы әсәр—Г. Тукай һәм Р. Фәйзуллин шигырьләренә таянып, «Тукайның ике язы» дигән ораторий-симфониясен төгәлләп килә. Без аңа алга таба да иҗат уңышлары, шатлыклар теләп калыйк!

**Земфира СӘЙДӘШЕВА.**

Надир
Дәүләт

# ЧИТ ИЛЛӘРДӘГЕ ТАТАРЛАР ҺӘМ ТУКАЙ

Бай тарихка ия булган татар халкының соңгы йөз ел эчендә, бигрәк тә Советлар чорында, үткәннәре белән бәйләнеше шактый көчсезләнгән иде. Дәүләт режимы рөхсәт иткән кадәр милли гореф-гадәтләрен яшәткән, әдәбиятларын һәм тарихларын өйрәнеп, буыннан-буынга тапшыра килгән татарлар һәм алар хәлендә үк яшәгән башка халыклар да, асылларын саклап калу өчен төрле символларда үзләренә таяныч табарга тырышканнар. Бәйсезлеккә ирешкән кыргызларның Манас дастанына, үзбәкләрнең Әмир Тимергә, казакъларның Абай Кунанбаевка, башкортларның Зәки Вәлиди Тоганга, төрекмәннәрнең Мәхтүмкольйга (соңгы вакытларда «Рухнамә»гә), башкаларның тагын да шундый берәр шәхескә тартылуларын, бу шәхесләрне һәм дастаннарны бик тә үз итеп, аларның юбилейларын милли бәйрәмнәр дәрәҗәсендә олылап үткәрүләрен, исемнәре белән бәйләп премияләр билгеләүләрен, һәйкәлләр куюларын әлеге халыкларның мондый символларга, бигрәк тә аларның берләштерү көченә булган ихтыяҗы белән аңлатырга мөмкин. Дәүләтнең яки халыкның барлыгы, яшәвенең дәлиле булган милли байрак, милли марш кебек яңа символлардан да мәхрүм милләтләр исә, халык булып берләшү процессында яки бәйсезлеккә күчү чорында, боларның урынын алырлык башка символларга мөрәҗәгать итәләр. Бу хәрәкәт халыклар тарафыннан аңлап та, кайчакларда аңланмыйча да эшләнә килде.

Шул рәвешле, 454 елдан бирле Рус хакимияте астында яшәгән, чит илләрдә, аеруча Төркиядә, шималь (төньяк) төркиләре, Казан төркиләре, Идел-Урал төркиләре кебек төрле исемнәр белән аталып йөртелүләренә дә карамастан, үзләрен татар дип танучы бу төрки халык, алда әйтеп үтелгән омтылышлар белән булса кирәк, төрле символлар барлыкка китергәннәр.

Татарстан Җөмһүриятендә 1992 елдан башлап «Канатлы Ак Барс» рәсемле дәүләт гербы һәм яшелле-аклы-кызыллы байрак кулланыла башлады. Тик боларның халык тарафыннан ахыргача үз ителүе әле озак еллар үткәннән соң гына тормышка ашачак. Башка төрки җөмһүриятләрдә булган кебек, Татарстанда да бу төр яңа рәсми-милли символларның кабул ителүе, халыкка инде булган-беткән, хәл ителгән эшне игълан итү һәм кабул иттерү юлы белән башкарылды. Шуңа күрә, мәгънәсе һәм әһәмияте бөтен татарлар өчен диярлек ачык аңлашылган символ буларак, бу яңалары түгел, ә Казан кремлендәге Сөембикә манарасы (Хан мәчете) әле дә булса беренче урында тора. Икенче урынны милли шагыйребез Габдулла Тукай (1886-1913) били дип әйтә алабыз. (2005 елдан башлап, Кол Шәриф мәчете дә бер яңа символ буларак татар мәдәниятендә урын алачак). 1988 елда

Надир ДӘҮЛӘТ – *Тарих фәннәре докторы, Мәрмәрә университеты профессоры.*

башланган мөстәкыйльлек өчен көрәш елларында, Тукайның танылган «Туган тел» исемле шигыре милли җыеннарда, Төркиядәге «Истикъляль (бәйсезлек) маршы» кебек, аягүрә басып җырлана торган булды. Хәтта, ул чорга кадәр тыелып килгән соңгы ике юлы да, аерым бер басым ясап җырлана башлады, белмәгәннәргә махсус өйрәтелде. Бу күренешне, моңа кадәргe чикләү-кысуларга каршы үзенә бер төрле баш күтәрү иде дип тә шәрехләргә мөмкин. Әлбәттә, бирeдә тагын шуны да ассызыклап үтәргә кирәк: совет режимы милли шагыйрьне тыймаган; киресенчә, аңа һәйкәлләр куярга, музейлар ачарга, аның исемендәге премияләр билгеләргә мөмкинлек биргән. Тик, «Васыятем», «Тәэсир», «Аллаһы Тәбарәкә Тәгалә» кебек дини мотивлар кергән шигырьләрен, «Туган тел» шигырендәге кебек кайбер юлларны бастырмыйча, чикләү куйган.

Без биредә, ерак диаспорадагы, ягъни 1950 елларга кадәр, нигездә, Кытайда, Япониядә, бераз соңрак Төркиядә, Финляндия һәм АКШ кебек илләрдә яшәгән аз санлы татарлар һәм аларның Тукайны аңлау һәм кабул итү рәвешләре хакында сүз алып барырга телибез. Югарыда санап кителгән дәүләтләр демократик яки советка каршы булганга, бу илләрдә яшәүче татарлар Тукайны үзләре теләгәнчә искә алу (яки искә алмау) ирегенә тулысынча ия иделәр. Шул сәбәпле, ниндидер бер режимның тәкъдиме, этәрүе яки кушуы белән түгел, нәкъ менә үзләре хис иткәнчә һәм теләгәнчә Тукайны һәр форсатта файдаланып, шулкадәр еш искә алдылар ки, шул илләрдә үсеп килгән яшь буын вәкилләре, бер заман, татарларның башка шагыйрьләре юк микәнни, дигән шөбһәгә дә төшә башладылар. Ватаннарын сагынып читтә гомер итүче олы буын, балаларына Тукай шигырьләре аша туган илгә мәхәббәт хисләре тәрбияләргә, аның шигъри юллары (аеруча, «Туган тел» шигыре) ярдәмендә туган телгә карата кызыксыну уятырга тырыштылар. Башкача әйтсәк, Тукай – милли телне, милли әдәбиятны, ватанга мәхәббәтне, җыеп әйткәндә, татарлыкның мәдәни кыйммәтләрен гәүдәләндерүче бер чара булды. Тукайның мондый роль уйнавының сәбәбен түбәндәгечә аңлатырга мөмкин. Беренчедән, аның шигырьләренең теле шактый гади, ватаннарыннан читтә, бөтенләй ят мохиттә үсеп җитешкән һәм туган телен бөтен нечкәлекләре белән белеп бетерми торган буын вәкилләре дә аңлый алырлык саф һәм аңлаешлы. Икенчедән, иҗаты искиткеч бай—халык әкиятләреннән башлап, иҗтимагый һәм милли дип берләштерергә мөмкин булган күп санлы темаларны эченә ала.

Иҗтимагый яраларны, беренче карашка гади булып күренсәләр дә, халыкның күңеленә бик якын булган вакыйгаларны, хөррият белән бәйле хис-тойгыларны, кешенең туган теле, тарихы белән горурланырга тиешлекне саф һәм аңлаешлы тел белән сөйләве үз илендә дә, читтә дә татарлар арасында Тукайны милләт башындагы таҗ иткән иде. Шул чор шагыйрьләре – М. Гафури, С. Рәмиев, Дәрдмәнд, З. Бәшири, Н. Думави, М. Укмаси, З. Ярмәкиләрдән артыграк яратылуының сәбәбе дә, Тукайның шигырьләре белән һәр иҗтимагый сыйныфка, һәр буынга эндәшүе иде, мөгаен.

Тукайның менә шул үзенчәлекләре ерак диаспорадагы татарларның аны күбесенчә туган һәм үлгән көннәре туры килгән апрель айларында искә алуларына сәбәп була иде. Кечкенә генә булса да татар җәмәгатьчелеге тупланган һәр җирдә, мәдәни эшчәнлек алып бару мөмкинлеге туу белән үк «Тукай кичәсе» үткәрүләр гадәткә керде. Бу милли кичәләрдә Тукайның тормыш юлы сөйләнгәннән соң шигырьләре укыла, хор белән «Туган тел» җырлана торган иде. Гомумән, Тукайга багышланган кичәме, башка милли кичәме,

һәрберсендә ул башкарыла, ә инде аның җырланмыйча калуы бик сирәк күренеш була торган иде. Чөнки «Туган тел» татар халкының бәйсезлеккә омтылышының бер чагылышы итеп кабул ителә иде. Тукай кичәләре үткәрелү белән бергә, Тукайга багышлап махсус җыентыклар да чыгарыла килде. Шул рәвешле, ерак диаспорада да Тукайны мәңгеләштерүгә омтылыш яши иде.

Ерак Көнчыгышта яшәгән татарларның Тукай белән бәйле эшчәнлекләренә күз салсак, иң башта шулар күзгә ташлана. Беренчедән, Япониядә Тукайның үлеменә 20 ел тулган көнне билгеләп үтү максатында чыгарылган басмалар шактый әһәмиятле урын алып тора. Токиодагы «Матбагаи исламия» җәмгыяте 1933 елда, ягъни үлеменең 20 нче елында, Тукайның бөтен әсәрләрен эченә алган «Габдулла Тукай мәҗмуга-и асаре» исемле 4 томлык җыентык чыгара. Бөтенесе 543 битлек булган бу җыентык татарлар тарафыннан кулланылган гарәп хәрефләре белән нәшер ителгән. Япониядә яшәгән, бер уч дип әйтерлек аз сандагы, татар-башкорт өчен, шагыйрьне искә алып, бу җыентыкны хәзерләү һәм бастырып чыгару, әлбәттә, җиңел бирелмәгәндер. Әлеге вакыйга Токиода чыккан «Япон мөхбире» исемле журналның 1933 елгы 2 санында да яктыртылган. Япониядәге мөселманнарның җитәкчесе булган Габделхәй Корбангалинең журналда басылган мәкаләсеннән һәм башка хәбәрләрдән («Япон мөхбире».—1933.—№ 50 Тукайның үлеменә 20 ел тулган көнне билгеләп, зур эшчәнлек алып барылганлыгы аңлашыла. Бер ел үткәннән соң исә, шушы ук журналда (1934.—№ 16) шагыйрьнең бары тик бер генә—«Сәфилгә каршы язарга теләгән каләмгә» исемле шигыре басылып чыккан.

Ерак Көнчыгышта Тукайга багышлап, дөресрәге, үлеменең 25 нче елын искә алу өчен чыгарылган тагын бер хезмәт 20 мәкаләдән һәм шагыйрьгә багышлап иҗат ителгән шигырьләрдән торган 98 битле «Габдулла Тукай (1913-1938): вафатына 25 ел тулу уңае белән» дип аталган җыентык була. Ул «Ерак Шәрык Идел-Урал төрек-татар мөселманнарының дини милли мәркәзе мәгариф шөгъбәсе» тарафыннан 1938 елда Мукденда нәшер ителгән. Шул вакытларда, 1935-1945 елларда Мукденда чыгарылган «Милли байрак» газетасы Тукай шигырьләрен, шагыйрь турында мәкаләләр һәм аңа багышлап иҗат ителгән шигырьләр дә бастырган. Моннан тыш, 1929-1939 елларда Гаяз Исхакый мөхәррирлегендә Берлинда чыккан «Милли юл» («Яңа Милли Юл») исемле айлык журналда да Тукайга бик еш урын бирелгән.

Диаспорадагы татарларның тагын бер үзәге—Финляндиядә дә Тукайны искә алу кичәләре оештырыла торган булган. Әмма аның исеме кергән беренче басма әсәр биредә бары тик 1953 елда басылды. Ул—«Төрек халык мәктәбе ярдәмләшү оешмасы» тарафыннан Хельсинкида бастырылган «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» дигән китап иде. 1969 елда Хөсәен Садыйкның «Габдулла Тукай шигырьләре» исемле 102 битле җыентыгы, Япония белән Кытайдагыча гарәп язуында түгел, ә латин хәрефләре белән шул ук Хельсинкида басылып чыкты.

Татарлар иң күп санда яшәгән Төркиягә килсәк, биредә алып барылган Тукайны таныту эшчәнлеген түбәндәгечә характерларга мөмкин. Төрек укучысы Тукай исемен беренче тапкыр «Төрек йорды» журналында 1913 елда чыккан «Габдулла Тукайның вафаты» исемле хәбәрдән белә. Бераздан, журнал «Тукаевның җеназасы» турында хәбәр бастыра. Иң әһәмиятле язма, әлбәттә, Фуад Күпреленең Тукайга багышлап язган мәкаләсе («Төрек йорды».—1913.—№ 4) иде. Ф. Күпреленең бу зур мәкаләсендә: «Бары тик «Тасвири әфкяр» белән «Ислам дөньясы»нда гына Тукаевка бернichә

баганалык язма багышланды»,—дип хәбәр итүе, ул вакытларда Габдулла Тукайның Төркиядә танылмаган булуына ишарә итә. «Төрек йорды» бу санында, астына «Төркиләрнең яшь халык шагыйре Габдулла Тукаев мәрхүм» (16 нчы санга кушымта) дип язып, бер биттә зур рәсемен һәм Румыниядә яшәүче Ногман Байбуриның аңа багышлап язган «Габдулла Тукаев» исемле шигырен бастырган. Моннан соң биш ел үткәч «Кырым» журналында (1918.—№ 22) кечкенә генә бер мәкалә басылып чыккан. Күргәнебезчә, Ф. Күпреледән соң, бу чорда Тукайга башка җитди кызыксыну күрсәтүче булмаган. Шигырьләренең ул елларда төрек теленә тәрҗемә ителмәве дә роль уйнамый калмагандыр, әлбәттә.

Шактый озак вакыт үтеп, Җөмһүрият чорында яңадан чыга башлаган «Төрек йорды», 1926 елда «Габдулла Тукайның мәҗмугаи асаре» исемле хәбәре белән (IV, 20 нче сан, август 1926, 189 б.). Казанда аның шигырь җыентыгының чыгуын төрек укучысына ишеттерсә дә, моның әллә ни зур тәэсире булмаган. Гаяз Исхакый 1933 елда (ягъни Тукайның үлеменә 20 ел тулган вакытта) «Азәрбәйҗан йорт билгесе» журналында (№ 16) Тукайны кабат ишеттерсә дә, моның да әллә ни эз калдырмаганлыгы аңлашыла. Нәтиҗәдә, Төркия матбугатындагы бер-ике мәкаләдән соң ярты гасыр буе Тукай турында берни диярлек чыкмаганлыгын, исеме дә телгә алынмаганлыгын күрәбез. Ниһаять, 50 ел үткәч, «Төрек культуры» журналында Тукай исеме кабат татар галимнәре тарафыннан искә алына башлый. Болар – тарихчы Габдулла Баттал Таймас, профессор Рәшит Рәхмәти Арат һәм профессор Әхмәт Тимер[1] иде. Бу басмалардан соң өч айлап вакыт үткәч, профессор Хәмзә Зөлфекарның шул ук журналда (1968.—№ 66) «Габдулла Тукай (1886—1913)» дип аталган җитди бер фәнни мәкаләсенең басылып чыкканлыгын күрәбез.

Шул елларда, Истанбулдагы татар-башкорт яшьләренең «Тукай яшьләр клубы» оешты. Бу яшьләр оешмасы 1965 елның март аеннан алып 1968 елның көзенә кадәр барлыгы 24 санлык (һәр саны якынча 10-12 битле) «Тукай бюллетене»н чыгарып килде. Бу бюллетеньнең 1965 елның апрель аенда чыккан 2 нче санында профессор Әхмәт Тимер «Габдулла Тукай» исемле мәкаләсен (3-7 б.) бастырды. Шул елгы бюллетеньнең 4 нче саныннан алып соңгы санына кадәр (бары тик 1965 елның ноябрь саны гына «Рәшит Рәхмәти Арат (махсус сан)» буларак басылганга, бу саннан кала һәммәсендә) «Тукай почмагы» рубрикасы (төзүчесе Надир Дәүләт) бирелеп барды. Анда Габдулла Тукайның сайланма шигырьләре татарча һәм төрекчә тәрҗемәләрдә басылды.

1966 елда шул ук «Тукай бюллетене» Наилә Бинаркның балалар өчен язган «Тукайның тормыш юлы» исемле 4 пәрдәлек пьесасын 16 нчы (8-10 б.) һәм 19 нчы (12-16 б.) саннарында бастырып чыгарды. Бераздан бу пьеса Әнкарада сәхнәгә дә куелды. Шул вакытларда Гали Акыш, Сәидә Арсланбәк, Наилә Бинарклар тарафыннан хәзерләнгән «Тукай брошюрасы» исемле 8 битле бер хезмәт басылып чыкты. Бу брошюрада Арсланбәк һәм Бинаркның «Габдулла Тукай», шул ук авторлар тәрҗемәсендә Тукайның «Туган тел», «Гомер юлына керәчәкләргә», «Таз баш» шигырьләре һәм Гали Акышның «Бөек төрек-татар шагыйре Габдулла Тукайның халыкчанлык һәм милли позицияләре» исемле мәкаләсе бар. (Бу мәкалә «Азәрбәйҗан» журналында да басылды).

[1] A. B. Taymas. Kazanlı Abdullah Tukay Üzerine // TK.—№9 (Temmuz 1963).—S. 40-48; R.R Arat. Abdullah Tukay (1986-1913) TK.—№19 (Mayıs 1964).—S.76-81; A. Temur. Abdullah Tukay—52. Ölüm Yıldönümü Münasebetile /TK.III.—№31 (Mayıs).—S.49 (469)—52 (473).

Болардан тыш, «Тукай яшьләр клубы» тарафыннан 1964—1967 елларның апрель айларында «Тукай бәйрәме» исеме астында милли кичәләр оештырылуын да искә алып үтәргә кирәк. Бу милли кичәләрдә Тукайны искә алудан тыш, аның шигырьләре укыла, кечерәк пьесалар куела һәм фольклор үрнәкләре күрсәтелә торган иде. 1967 елгы «Тукай бәйрәме»ндә башка елгыларыннан аермалы буларак, Гаяз Исхакый Иделленең «Жан Баевич» исемле 4 пәрдәлек зур күләмле пьесасы Чагалоглунда (Истанбул шәһәрендә) «Милли төрек студентлар берлеге» сәхнәсендә уйналды. Озакламый (28 октябрь, 1967) «Тукай бәйрәм»нәре «Казан төркиләре тантанасы» исеме астында дәвам итте. Тик моны Тукайның онытыла баруы дип аңларга ярамый. Чөнки «Тукай яшьләр клубы» 1969 елда клубка әгъза булуның яшь чикләвен бетереп, «Казан төркиләре мәдәният һәм ярдәмләшү җәмгыяте»нә әйләнгәч, Әхмәтвәли Мәңгәрнең матди ярдәме белән өч айлык «Казан» журналын чыгара башлады. Бу журнал да Тукайны таныту эшчәнлеген дәвам итте. Әлеге журнал «Тукай бюллетене»нә караганда халык арасына киңрәк таралганга, аның тәэсире көчлерәк булды. «Казан» журналы беренче санында (1970 ел) Тукайның «Сак-Сок бәете» исемле шигырен Надир Дәүләт тәрҗемәсендә бастырды. Журналның 1971 елгы март (3 нче) саны күп өлешен тууына 85 ел тулу уңаеннан Тукай белән бәйле язмалар алып тора.

Читтәге татарлар Тукайны һәрчак искә алырга тырышалар иде. Шуңа күрә Габдулла Тукайның үлеменә 60 ел тулу белән бәйләп, «Казан» журналының 1973 елгы 10 нчы саны тулысынча Тукайга багышланды.

Моннан соң да, «Казан» журналының 11 нче санында (1974 ел) «Мөхәрриргә» (46-47 б.), 14 нче санында (1975 ел) «Театр» (31-32 б.), 17 нче санында (1976, бу санында тууына 90 ел тулу билгеләп үтелде) «Су анасы» (36-39 б.) белән «Кадер кич» (40 б.) шигырьләренең Наилә Бинарк тәрҗемәләрен күрәбез. 17 нче санга Сания Ышыкайның шагыйрьгә багышлап язган «Габдулла Тукайның тууына 90 ел» исемле шигыре дә кертелгән иде. 18 нче санда (1976 ел) Нәркиз Дәвеш-Гиелингнең «Тукайга хөрмәтләр белән» (37-38 б.) һәм 22 нче санда (1978 ел) шагыйрь Минһаҗның «Даһи Тукайны искә алу» (44-46 б.) дигән шигырьләре басылды.

«Казан» журналын матди ярдәме белән яшәткән Әхмәтвәли Мәңгәр 1978 елның 10 ноябрендә вафат булганнан соң журнал чыгуыннан туктады. 1980 елның 12 октябрендә булган гаскәри түнтәрелеш Истанбулдагы татар-башкортларның «Казан төркиләре мәдәният һәм ярдәмләшү җәмгыяте»нең ябылуына сәбәп булды. Бу үзгәрешләр Тукайны киң җәмәгатьчелеккә таныту эшен тагын да кыенлаштырды.

Читтәге төрки халыклар әдәбияты белән кызыксыну Төркиядә әллә ни көчле булмаса да, төрки әдәбият белән таныштыру вазифасын фидакярләрчә башкарган «Кардәш әдәбиятлар» 1982 елның 2 санында И. Корбанның «Габдулла Тукай» мәкаләсе белән төрек укучысына Тукай исемен кабат ишеттерде. 1986 елда, Тукайның тууына 100 ел тулганда, бу юлларны язучының шагыйрьне танытуга багышланган берничә мәкаләсе басылып чыкты.[2]

«Кардәш әдәбиятлар» журналы 1987 елгы 16 нчы санын (1987) тулысынча Тукайга багышлап (мәкалә, шигырь һәм хәбәрләр урнаштырып),

[2] N. Devlet. Abdullah Tukay Ateist mi Idi? // Türk Kültürü. XXIV.—№277 (Mayıs 1986).—S. 320-326.; N. Devlet. Abdullah Tukay (1886-1913) // Türk Edebiyatı.—№151 (Mayıs 1986).—S.54-55; N. Devlet. Tatar Şairi Tukayın 100 Yılı (1886-1913) // Türk Dünyası Araştırmaları.—№41 (1986.—S.201-205. N. Devlet. Was Tukay An Atheist? On the Occasion of His 100th Anniversary // central Asian Survey VI.—№1 (1987).—S. 93-98. N. Devlet. Büyük Tatar Şairi Abdullah Tukay (1886-1913) // Kardaş Edebiyatlar.—№16 (1987).—s. 5-18.

татар шагыйренең тагын да киңрәк танылуына юл ачты.

Тукайның тууына 100 ел тулу вакыйгасын Төркиядә шул рәвешле иштетерергә тырышканнан соң, 1988 елда Гали Акышның Тукайны искә алу максаты белән «Төрек йорды» журналының 18 санында басылган бик кечкенә (1 битлек) мәкаләсеннән башка, Төркия матбугатында өч-дүрт ел буе бер җитди язма да булмады.

Мостафа Өнәр 1990 елда Измирдә Тукай темасына бәйле кандидатлык диссертациясен яклады.[3] Аны Төркиядә Тукай темасы белән бәйле беренче гыйльми хезмәт дип атарга мөмкиндер, мөгаен. Тукайның тууына 100 ел тулуга багышлап хәзерләнгән ике хезмәт, матди сәбәпләр аркасында бары тик 1991 һәм 1993 елларда гына җәмәгатьчелек хөкеменә тапшырылуын күрсәтеп үтәргә кирәк.[4]

Төркиядә Габдулла Тукай белән бәйле башкарылган иң мөһим хезмәт булып, һичшиксез, фән докторы Фатыйма Өзканның докторлык диссертациясе саналырга тиеш. Шул рәвешле Фуат Күпреле, Хәмзә Зөлфекар һәм Мостафа Өнәрдән соң чыгышы белән татарларга бәйләнеше булмаган беренче төрек кешесе Тукай иҗатын гыйльми яссылыкта өйрәнеп, Төркиянең мәдәният тормышына, «Гомум төрки әдәбият»ка үзеннән җитди өлеш кертте. Аның бу диссертациясенең Төрек мәдәниятен өйрәнү институты тарафыннан «Габдулла Тукайның шигырьләре: анализ-текст-тәрҗемә» (Әнкара, 1994) исеме белән басылуы бу хезмәтнең киң катлам укучылар арасына таралуын тәэмин итте һәм зур казаныш булды. Мостафа Акбаш тарафыннан хәзерләнгән «Татар шагыйре һәм язучысы Габдулла Тукайның сайланма әсәрләре һәм алардагы тел үзенчәлекләре» исемле докторлык диссертациясе Истанбул университеты Иҗтимагый фәннәр институтының борынгы төрки тел бүлегендә 1996 елда якланды.

1991 елда, «тимер пәрдә» ачылып нибарысы биш ел үткәннән соң, Төркиядә Тукай темасына багышланган тагын ике докторлык диссертациясенең хәзерләнүе гаҗәеп күренеш булды. Мондый тикшеренүләр Төркиядән читтәге төрки халыкларның әдәбиятларын да гыйльми яссылыкта өйрәнү һәм бәяләү мөмкинлеге барлыгын күрсәтә. Әлбәттә, Төркиядә булган бу үсеш-үзгәрешләрдә, 1991 елда Советлар Берлеге таркалуның һәм төрки дөньяның яңадан оеша башлавының йогынтысы зур иде. Төркиядә яшәүче һәм фәнни эшләр башкарырга мөмкинлекләре бик булмаган шәхесләрнең милли тамырлары белән бәйле тикшеренү эшчәнлекләре җитәрлек түгеллеген дә исәпкә алсак, университетлардагы яшь тикшеренүчеләрнең һәм галимнәрнең бу төр темаларга мөрәҗәгать итүләре кардәш халыклар белән бәйләнешләребезне ныгытуга уңай йогынты ясаячагын ачык күзаллый алабыз.

Соңгы елларда яшь тикшеренүчеләребезнең хезмәтләре аша Тукайның исеме тагын да ешрак ишетелә башлаганлыгын билгеләп үтәргә кирәк. «Кардәш әдәбиятлар» журналы 1994 елгы 28 нче санында Мостафа Өнәр тәрҗемәсендә Эмди Гәрәйбәйнең «Тукайга» исемле шигыре белән 1995 елда (32 нче сан) фән докторы Фатыйма Өзкан тәрҗемәсендә Габдулла Тукайның «Исемдә калганнар» исемле язмасын бастырды. «Төрек культуры» журналы

[3] M. Öner. Abdullah Tukain Şiirleri (Giriþ-Metin-Sözlük). Dokuz Eylül Univ. SBE YL Tezi. Izmir 1990. LXIV+559s.

[4] M. Öner. Abdullah Tukain Bir Şiiri: Sürelı // Ege Üniversitesi Türk Dili ve Edebiyatı araþtırmaları dergisi. VI. İzmir. 1991 — S. 193-215. N. Devlet. Büyük Şair Abdullah Tukain (1886-1913) Tatar Edebiyatı hakkında Görüşleri // İstanbul Üniversitesi Edebiyat Fakültesi Türk Dili ve Edebiyatı Dergisi. XXVI (1986-1993). İstanbul: 1993. — S.79-116.

1996 елның 395 нче (март) санында Тукайның тууына 110 ел тулуны билгеләп, Фатыйма Өзканның «Гомеренең язында вафат булган бөек шагыйрь Габдулла Тукай» исемле мәкаләсен (148-158 б.) бастырып чыгарды. Шул ук журналның 1997 елның февралендә (406 нчы санда) бу юлларны язучының да бер мәкаләсе чыккан иде.[5]

Ниһаять, күптән түгел генә, шагыйрьнең тууына 120 ел тулу уңаеннан Төрксой (TURKSOY) оешмасы шигырь һәм мәкаләләреннән тупланган яңа бер җыентыкны хәзерләп, 2006 елның уртасында бастырып чыгарды. Җыентыкта шигырь һәм мәкаләләрнең татарчалары белән бергә төрек теленә тәрҗемәләре дә бирелгән. Шигырьләрнең төрекчәсе профессор Фатыйма Өзканның элек басылып чыккан китабыннан сайлап алынган, мәкаләләрнең төрекчәгә тәрҗемәсе исә, Казан дәүләт университеты доценты Асия Рәхимова тарафыннан башкарылган.[6] Әмма шуны да әйтергә кирәк, Төрксой нәшер иткән китаплар, сатуга чыгарылмаганга күрә, гадәттә, тар мохит эчендә генә кала. Шул сәбәпле бу җыентык та тиешле игътибарны җәлеп итә алмас дип уйлыйм. Төркиядә Чыңгыз Айтматов белән Җәңгиз Дагҗыдан башка төрки язучылардан беркемне дә диярлек белмиләр. Соңгы елларда кайбер азәрбәйҗан язучыларының әсәрләре төрек теленә тәрҗемә ителә башлады. Ләкин, шулай сирәк-мирәк кенә басылса (әле алар профессиональ тәрҗемәләр дә булмаса), татар язучылары һәм шагыйрьләренең Төркиядә танылуы шактый авыр булачак.

Тик ни генә булса да, үз илендә бик мәшһүр татар халык шагыйре Габдулла Тукай тууына 120 ел һәм үлеменә 93 ел тулган елда Төркиядә чын-чынлап таныла башлады дигән фикергә киләбез. Бу безнең өчен зур шатлык, чөнки без кардәш халыклар арасындагы бәйләнешләрнең аеруча мәдәният юлы белән алга китәчәгенә нык ышанабыз. Шул рәвешле, тууына 120 ел тулганда, Тукай, ерак диаспорадагы татарлар өчен генә түгел, гомумән Төркия белән Татарстан арасында әһәмиятле мәдәни күпер вазифасын үти башлады дип әйтә алабыз.

*Истанбул, 2006*

*Төрекчәдән* ***Асия Рахимова*** *тәрҗемәсе.*

[5] N. Devlet. Diasporadaki tatarlar ve Tukay (Doğumunun 110 yılında) // TK. — №406 (1997). — S. 88-97.

[6] Abdullah Tukay. Ankara: TÜRKSOY Yayın. Ankara. 2006. — 378 s.+10 s. Resim.

Адлер
Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***ТӘГЪТЫЙЛЬ, ТӘГЪТИЛ*** *г.* — Каникул (мәдрәсәләрдә), эштән бушап ял итеп тору вакыты, отпуск; туктатып кую; ябып, бикләп кую (*гатыйл* — буш торучы, эшсез, эшлексез). //*Каникул дип тәгътыйль вакытына әйтәләр.* Фатих Кәрими. *Яз көннәрендә мәдрәсәләр тәгътыйль булгач, меңләп Идел буе шәкертләре казакъ-кыргыз сәхрасында йөрүче вакытлы мөгаллим, мулла булып, вак сәүдәгәр сыйфатында күп вакытлар кыргыз куйчуларын көтүче булган булып, бу кара халыкны агартырга хезмәт итәләр.* Г.Исхакый. *Гәжур идарәсенә үтенеч: шагыйрь Такташны шул эш вакытында тәгътыйльгә җибәрсәгез иде.* Г.Ибраһимов.

***ТӘДАФИГЫЙ МИЛЛӘТЧЕЛЕК*** *гт.* — Үзен, үз вөҗүден саклау өчен көрәшә торган милләтчелек. //*Хәтта бу гына да түгел: төрек милләтчелегенең бу көндә тәдафигый булып та, киләчәктә тәҗәвезигә әйләнү ихтималы да инде соңгы гасырларда вөҗүдкә килгән бәйнәлмилал вазгыять белән катгый сурәттә бетерелгән иде.* Ф.Әмирхан.

***ТӘҖАВЕЗИ (ТӘҖӘВЕЗИ) МИЛЛӘТЧЕЛЕК*** *гт.* — Басып алу, башкаларны буйсындыру милләтчелеге; һөҗүмчән, агрессив милләтчелек. //*Без тәдафигый милләтчелекнең дә җае чыкканда тәҗәвезигә әйләнеп китә алуын инкяр кыйлучылардан түгел, без төрек милләтчеләрен генә гомуми кагыйдәләрдән аерып калдырып, аларга гына махсус бер гуманизм иснад итүчеләрдән дә түгел. Шуның белән бергә, без катгый сурәттә әмин була алабыз ки, төрек милләтчелеге инде тәҗәвезигә әйләнә алмый, төрек халкының бәйнәлмилал вазгыяте бу ихтималны катгый сурәттә истисна итә.* Ф.Әмирхан (1920 ел).

***ТӘҖАҺЕЛ ГАРИФ*** *г.* — Белмәмешкә салышучы белекле кеше. //*Хәсән әфәнде мәшһүр вә могтәбәр адәмнәрнең тәрҗемәи хәлләре хакында бик күп нәрсәләр беләдер, ләтыйфа сөйләүне сөядер, белгән нәрсәләрен хикәят итәргә ашыкмыйдыр, кешеләрне сынау касды берлә түгел, бәлки истифадә касды берлә тәҗаһел гариф юлын илтизам кыладыр иде.* Р.Фәхреддин.

***ТӘКИЙ(Й)Ә*** *ф.* — "Туктыйсы урын" мәгънәсендәге сүздән. 1.Шигыйларда мөридләрнең дини мистерия йолалары үткәрә торган һәм тупланып яши торган урыннары. Атнаның аерым көннәрендә тәкийәнең ишекләре теләсә кемгә ачык булып, зур гыйбадәт мәҗлесендә һәркем катнаша алган ("Суфичылык серләре"). Монда яшәүче суфиларга тирә-юнь халкы садака китергән, ләкин бу садакаларны бирүче кеше үзен белгертмәгән. Электә тәкийәләр үзенә бер төрле психиатрия мәркәзләре булганнар, ягъни биредә рухи авыруларны дәвалау һәм психоанализ сеанслары үткәрелгән.
2.Урта гасырларда кабер өстенә төзелгән дүртпочмаклы төрбә, мавзолей. Рязань өлкәсендә *Шаһгали хан тәкийәсе* (1556) һәм *Әфган Мөхәммәд Солтан тәкийәсе* (1649) сакланган. Бу мәгънәсендә *тәкийә* термины русча *усыпальница* сүзенә туры килә кебек.

Мәккәгә хаҗга килүчеләр өчен төзелгән кунакханәләрне дә тәкийә дип атыйлар.

Язылышта *тәкия* һәм *тәккә* вариантлары да очрый. Синонимнары: *хәнәка* (*ф.*), *рибат* һәм *завия* (*г.*).

---

*Дәвамы. Сүзлек журналыбызның 2004 елның 1нче санынннан басылып килә.*

**ТӘМӘКЕ** — Фарсы телендәге *тамаку* сүзеннән. Татарга Урта Азия аркылы кергән сүз дип уйланыла. Ләкин тәмәке үсемлеген һәм тәмәке тарту гадәтен Европага испан сәяхәтчеләре Американы ачкач алып кайтканнар. Алар Гаити атавы кешеләреннән беренче тапкыр *тобако* сүзен ишеткәннәр (тәмәке тутырылган челем, тәребкә). Шулай булгач, тәмәке сүзе фарсыларга да европалылар аркылы кергән булып чыга. Төрек телендә исә тәмәке *тутун* дип атала. Үзбәк телендә тәмәке — *тамаки*, ягъни калын әйтелеш сакланып калган. Аларда бу сүздән ясалган башка төшенчәләр дә байтак: *тамакишунос* — тәмәкешөнас, тәмәке белгече, *тамакифурош* — тәмәке сатучы, *тамакизор* — тәмәке плантациясе һ.б. (барысы да шәркый сүзләр). Татар телендә тәмәке мәгънәсендә параллель рәвештә *духан/дохан* сүзе дә яшәп килгән (мәс., *дохканкәш* — тәмәкече).

1698 елда Петр патша Англиядә төзегән килешү буенча Россиядә тәмәке сатыла башлый һәм аны куллану рөхсәт ителә. Ә Петрга кадәр русларда да тәмәке тарту хурлык саналып, тәмәкечеләргә җәза бирелә торган булган. Татар авылларында тәмәке тарту гадәте XIX гасыр ахырларында гына (әүвәле керәшеннәрдә) тарала.

Нәкый Исәнбәт ни кадими Кышкар мәдрәсәсе шәкертләре чыгарган бер такмазаны силлогизмга мисал итеп китерә: "Әт-тәмәке рәва, Фә иннәһү трава, Вә көлли трава рәва, Фәттәмәке рәва." ("Тәмәке ярый, чөнки ул үлән, һәрбер үлән ярый — шулай булгач, тәмәке дә ярый".) Шәкертләр жаргонында: тәмәке тартуны *дохан чигү* дигәннәр (ягъни төтен чигү).

"Шәригать хөкемнәре"ндә: "Әфьюн вә тәмәке кебек исертә торган үләннәрне йотып йә авызга салып, яки суын, яки төтенен сулап исермәгез" дигән ныклы күрсәтмә бар. Рузә вакытында тәмәке төтенен сулау да ярамый. Мәүла Колый: "Тәмәкене тартмыш кеше, бел, нә паки," — дип яза.

Тәмәке иснәү һәм тәмәкене тел астына салу да дөньяга Америкадан таралган.

**ТӘҢРЕ** — Бу сүз төрки һәм монгол телләре өчен уртак. Бурятлар, мәсәлән, "тэнгэри", монголлар "тэнгэр" диләр. Кыпчаклар исә "таңре" дигәннәр. Р.Әхмәтьянов "тәре" сүзенең этимологиясен "мәҗүси алла, тәңре" сүзе белән янәшә куя һәм "чыңгыз" сүзен дә "күк алласы" мәгънәсендәге "таңыр" сүзенә илтеп тоташтыра. Морад Аджи да "түрә" сүзен "тәңре" сүзе белән бәйли. Борынгы шумер телендә *диңир* — күк, алла; тәңре. Ә борынгы төрки телдә "тәңре" төсне белдерүче *зәңгәр* һәм *күк* сүзләре белән синонимдаш булган. В.Хаков фикеренчә, "Тәңре сүзендә зәңгәр сүзендәге кебек үк төс мәгънәсе чагылган, соңыннан ул табигатьтән өстен көч, күктәге алла төшенчәсен белдерә башлаган." Ләкин шуны да әйтеп китик, 1240 елгы монгол елъязмасы "Алтан тобчи"да "мәңгелек зәңгәр күк" күп тапкырлар телгә алына. XIII-XIV гасырга караган эпиграфик ядкярләрдә дә "Møngke kүke tengri" гыйбарәсе очрый. "Тәңре"нең хәзерге мәгънәсе — алла, күк алласы, күкләрдә яшәүче. Төрки халыкларда күкне һәм ирдарлыкны символлаштыручы, язмышны хәл итүче югары көч. VI-VII гасырларга караган Орхон-Енисей чөй язмаларында сөйләнгәнчә, Тәңре ихтыяры белән башта зәңгәр күк, аннары соры җир яратылган, соңыннан алар арасында кешегә урын бирелгән. Борынгы төркиләр Тәңрегә биек агачлар багышлаганнар һәм корбан итеп күк яисә җирән атлар китергәннәр. Нәкый Исәнбәттә ("Татар теленең фразеологик сүзлеге") "тәңре" сүзен "таң ире" рәвешендә таркатып, электә кояшны шулай атаганнар дип аңлатуга тап булабыз. Ләкин борынгы төркиләрдә "көн тәңресе", "кояш тәңресе" дигән аерым төшенчәләр булуы мондый фаразны кире кагарга мәҗбүр итә.

Шаманилар күзаллавынча, һәр кешенең үз тәңресе — саклаучы фәрештәсе бар.

V-X гасырларда тәңре культы Көнчыгыш, Үзәк һәм Урта Азиядә, хәзерге Казагыстан җирләрендә, Көньяк Себердә, Җаек белән Идел һәм Урал буйлары арасында киң таралган булган ("Татары", 2001). Рухы белән Исламга якын торганлыктан, Ислам дине тәңречелек (рус телендә — "тенгрианство") таралган төбәкләрдә җиңел генә тамыр җибәрә һәм бу диннәр бер-берсен тулыландырган кебек булалар.

Хәзерге татар телендә "тәңре" сүзе гомумән "алла" мәгънәсенә ия. Мәс., *тәңре йорты* дигәндә гыйбадәтханәләр-мәчет-чиркәүләр күздә тотыла.

//*Тәңре хакы. Тәңре Тәгалә. Тәңреләр. Хан-Тәңре* (*Тянь-Шань* тауларында биек тау түбәсе, рус чыганакларында: *Хан-Тенгри*).

Борынгы телдә тәңре мәгънәсендә "*үгән*" сүзе дә булган.

Тагын кара: **БОРЫНГЫ ТӨРКИ ТӘҢРЕЛӘР.**

*Дәвамы киләсе саннарда*

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Күккүз

Матур яңгырашлы һәм шактый күп санлы тарихи атамаларның берсе — Күккүз.

Зур Күккүз район үзәге Апастан 18 чакрымда, Кече Күккүз — 20 чакрым ераклыкта урнашкан.

Бу атама тарихи чыганакларда еш кабатлана. Д. А. Корсаков мәгълүматларына күрә (XVIII йөз), Зур Күккүз авылында ясак түләүче татарлар — 63, керәшен татарлары 16 кеше исәпләнгән. Коры Үләмә суы ярына утырган Зур Күккүз һәм Кече Күккүз авылларын А. Артемьев (1866 ел) болай сурәтли: «Кече Күккүздәге 73 хуҗалыкта 127 ир-ат һәм 134 хатын-кыз, ә Зур Күккүздә 110 йорт булып, анда 288 ир-ат һәм 312 хатын-кыз яшәгән, авылда 1 мәчет эшләгән. К. П. Берстель хезмәтендә (1908) күрсәтелгәнчә, Зур Күккүз авылында — 1180, ә Кече Күккүздә 586 татар кешесе яшәгән.

Нәҗия Борһанова мәгълүматлары күрсәтүенчә, Зөя суының уң кушылдыгы Коры Үләмәнең түбән агымында урнашкан авыллар, шул исәптән Зур Күккүз һәм Кече Күккүз авыллары халкы да, Калатау уен җыены уткәргәннәр.

Күккүз атамасы нинди мәгънә аңлата соң?

Бу турыда төрле фикерләр әйтелгән. Гомәр Саттаров бу атаманы кеше исеме белән бәйләп карый. Безнең уебызча, Күккүз атамасы, нугай кавем-кабиләләре оешканда, бу җирлеккә кергән һәм соңыннанрак бу этноним авыл атамасы булып ныгып калган. Күккүз дигән ыру атамасы каракалпак этнонимнары исемлегендә дә очрый. Төрки күккүзләрнең бер өлеше каракалпак халкын оештыруда, икенчеләре исә татар халкын барлыкка китерүдә катнашкан. Татарстанның Арча районындагы Иске Өҗем һәм Яңа Өҗем авылы халкы күрше Ташчишмәлеләрне тазлар дип, ә ташчишмәлеләр өҗемлеләрне күккүзләр дип атыйлар. Ташчишмәлеләр телендә югарыда искә алынган күккүз этнонимы кулланыла.

Бу этноним белән ясалган атамалар кайчандыр төрки халыклар яшәгән һәм хәзер дә яши торган төбәкләрдә дә очрый. Төрекмәннәр Каспий диңгезен Күккүз дип йөртәләр. Күккүз суы Кырымда бар, ул — Бакчасарай районындагы Бәлбәк суының сул кушылдыгы. Мондый атама югарыда сүз алып барылган этнонимга мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән дип уйларга кирәк.

Зур һәм Кече Күккүз авыллары янында елга-күлләр, басу-ышналар, кизләү-чишмәләр, сазлыклар, урманнар, тау-калкулыклар һәм башка географик берәмлекләр шактый.

Зур Күккүз авылының бер ягында биек таулар. Бу озын тау ике исем белән йөртелә: Ислам тавы һәм Кала тавы. Тау өстендә урман. Элеккерәк заманнарда бу урман зур һәм калын булган. Тау итәгендә — хәзер умарталык. Кала тавының бер ягында тирән ермаклар бар. Җитмешенче елларда ул ермаклар ишелгән. Авыл халкы сөйләвенә караганда, Кала тавы өстендә бик борынгы заманнарда зур кала булган. Ислам тавы дип тауның иң биек җире атала. Бу тауның бер өлешендә Юкәле куак урманы бар. Урманда каен, нарат, зелпе, чикләвек куаклары һ. б. агачлар үсә. Тауда Тирән һәм Сай үзәк дигән урыннар бар (ике тау аралары). Тауда чишмәләр күп, кое да бар.

Зур Күккүз авылы янында Яхшылар (Изгеләр) зираты бар, болында Изге кизләү челтерәп ага. Изге зират Кече Күккүз авылында да бар.

*Башы журналыбызның 6 санында.*

Зур Күккүз өлкәннәре экспедиция-сәфәр дәфтәремә авыллары турында шактый мәгълүмат яздырганнар. Авылларны агалы-энеле ике туган нигезләгән, олысы Зур Күккүзгә, кечесе Кече Күккүзгә башлангыч биргән дип сөйлиләр. Алар урман төпләп чәчү җирләре ачканнар.

Зур Күккүз авылында урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә, медпункт, май заводы һәм балалар бакчасы бар.

Дин тотучылар өчен мәчет ачылган. Авыл халкы ата-баба ята торган зиратны карап һәм тәрбияләп тора. Авыл халкы электән килгән әйбәт традицияләрне саклап яши.

## Ябынчы

Ябынчы авылы Әтнә районында, район үзәге Әтнәдән 16 чакрым ераклыкта утырган.

Бу авылда татар халкының мәшһүр галиме Шиһабетдин Мәрҗани туган.

Ябынчы атамасы тарихи чыганакларда еш очрый.

Казан ханлыгы чоры авыл атамалары исемлеге бирелгән тарихи хезмәттә (Е.И. Чернышев) Алат юлы өстендәге, хәзерге Әтнә районына кергән Ябынчы теркәлеп калган. Бу авыл исеме Казан өязенең теркәү кенәгәләрендә телгә алына. Анда йомышлы һәм ясаклы татарлар яшәгән. 1673 елның 8 февраль көне белән авыл исеме П.И. Ермолаев хезмәтендә телгә алына. Д.А. Корсаков җыентыгында (XVIII йөз) элекке Арча өязендә Ябынчы исеме йөрткән ике авыл күрсәтелә. Аларның берсендә 19, икенчесендә 62 йомышлы татар яшәгән. А. Артемьев җыентыгындагы мәгълүматларга караганда (1866 ел), Ябынчы авылындагы 53 хуҗалыкта 180 ир-ат һәм 166 хатын-кыз яшәгән. Авылда бер мәчет эшләгән. Ябынчы авылы галим Н.Н. Вечеслав төзегән чыганакта (1878 ел) искә алына. Андагы 64 йортта 199 ир-ат һәм 193 хатын-кыз яшәгән, бер агач мәчет эшләгән. Шәмәк суы ярына утырган Ябынчы авылын И.А. Износков болай тасвирлый: «Авылда 78 хуҗалык булып, анда 232 ир-ат һәм 209 хатын-кыз исәпләнгән». К.П. Берстель белешмәсендәге мәгълүматларга караганда, авылда барлыгы 530 татар кешесе яшәгән.

Авыл аксакаллары, аерым алганда Газыйм Гарифҗанов сөйләвенә караганда, Ябынчы авылы бик борынгы. Элек аның урынында калын урман үскән.

Ябынчы авылының табигате бик матур. Авыл янындагы елганы халык су буе дип атый. Хәер, аны тагын Нарат асты дип тә йөртәләр. Су буена авыл басуыннан тагын Җәнәм, Олы Кала, Чиркәс, Сикертмә, Бәрәсәңгер, Кабак суы, Җәнәй елга-инешләре кушыла. Басуда Туктамыш күле бар. Каенлык басуында элек урман булуы аңлашыла. Рафманкол, Ташбилге, Тәүкәлиле ягы һ. б. басулар исеме халык телендә әлегә кадәр сакланып калган.

Ләкин хәзер Ябынчы авылы бетте, юкка чыкты.

Икенче бер Ябынчы авылы Каманың уң ярында булган һәм хәзерге Лаеш районына кергән (кызганыч, ул урыннар инде Куйбышев сусаклагычы сулары астында калган).

Бу авылның исеме Казан ханлыгы чоры документларында теркәлеп калган. Авыл зиратында Һарун Йосыпов 1519 елда куелган кабер ташы тапкан.

Авыл Д.А. Корсаков җыентыгында (XVIII йөз) теркәлгән. Анда 101 ясаклы татар яшәгән. А. Артемьев мәгълүматларына караганда (1866 ел), авылдагы 117 хуҗалыкта 297 ир-ат һәм 326 хатын-кыз көн иткән. Авылда почта станциясе һәм Кама аша кичү булган. И.А. Износков хезмәтендә (1895 ел) Ябынчының икенче исеме Мишә тамагы дип бирелә. Авылдагы 92 хуҗалыкта ислам дине тота торган 380 ир-ат, 344 хатын-кыз яшәгән. XIX йөздә авылда меңгә якын кеше яшәгәнлеге һәм мәдрәсә булуы билгеле.

Ябынчы сүзе нәрсә аңлата?

Фәнни дөньяда бу авылларның исеме Казан ханлыгы чорының данлыклы гаскәр башлыкларыннан берсе булган Япанчы белән бәйле дигән фикер бар.

Кызганыч, тарихлары борынгылыкка киткән авыллар Татарстан картасыннан юкка чыга баралар.

# В

**ВӘЛИЕВ** Наил Мансур улы (3.9.1949, Чистай ш.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1996), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1997), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2001), гуманитар фәннәр бүлегенең академик-секретаре (2002). Алабуга пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1971), Чистайда урта мәктәптә укыта. 1975-77 елларда һәм 1981 дән Алабуга пед. ин-тында: рус һәм чит илләр әдәбияты каф. мөдире (1983 тән), проф. (1997), бер үк вакытта 1991 дән фәнни эш буенча проректор, 2000 нән – ректор. Фәнни хезмәтләре рус-татар әдәби багланышларына (Ф.Әмирхан һәм рус әдәбияты), туган төбәкне әдәби һәм тарихи яктан өйрәнүгә, Дм.Стахеевның һәм К.И.Невоструевның тормышларын һәм иҗатларын өйрәнүгә карый.

Хезм.: В мире нравственных исканий. К., 1985; Дмитрий Стахеев. Судьба и творчество. Уфа, 1996; Высокое служение Отечеству. Капитон Иванович Невоструев (1815-1872). Елабуга, 1998; Гармония культур. К., 2001.

**ВӘЛИЕВ** Рөстәм Шәвәли улы (19.10.1936, Чиләбе өлкәсе Троицк ш.), язучы. Рус телендә яза. М.Горький исем. әдәбият ин-ты каршындагы Югары әдәби курсларны тәмамлый (1979, Мәскәү). Чиләбе шәһәрендә яши. «Тугрылык» («Верность», 1960) исемле беренче китабы стиленең реалистик манерасы, мәгънәви кыскалыгы б-н әдәби тәнкыйть тарафыннан уңай бәяләнде. Г.Тукайга багышланган «Дөнья гаме» («Заботы света», 1986) романында 19-20 йөзләр чигендә татар җәмгыятенең киеренке рухи тормышы чагылдырыла. «Шәһәрләр җире» («Земля городов», 1990) романында традицияләрнең тәрәккыят б-н, үткәннәрнең киләчәк б-н үзара мөнәсәбәте проблемасы куела. «Фининспектор һәм бабай» («Фининспектор и дедушка», 1970), «Күршенең ягымлы карашы» («Добрые глаза соседа», 1974), «Йөк» («Ноша», 1989), «Җәлләмим, чакырмыйм...» («Не жалею, не зову...», 1990), «Хикәяләр» («Рассказы», 1996) һ.б. җыентыкларга кергән хикәяләрендә һәм повестьларында автор хәзерге заманның актуаль проблемаларына зур игътибар бирә. Рус теленә Г.Исхакый, Ә.Еники әсәрләрен тәрҗемә итте. 1992 елдан «Уральская новь» ж-лының (Чиләбе ш.) баш мөхәррире.

Әд.: Мустафин Р.А. Биография духа // Новый мир. 1984. N2; Лейдерман Н. В поисках птицы самрух // Урал. 1989. N11.

*Р.Ә.Мостафин.*

**ВӘЛИЕВА** Майя Диас кызы (1.5.1962, Казан), язучы. Рус телендә яза. Казан ун-тының биол. ф-тын (1984), М.Горький исем. әдәбият ин-ты каршындагы Югары әдәби курсларны (1992, Мәскәү) тәмамлый. В. китапларының төп проблематикасы – табигать һәм кеше дөньясы: «Кара эт турындагы повесть» («Повесть о чёрной собаке», 1980), «Башлангыч» («Начало», 1983), «Торна тавышы» («Крик журавля», 1987), «Текә яр читендә» («На краю», 1989), «Гафу ит мине, дустым» («Прости меня, друг», 1990), «Сакчы Селәүсен тавы буенда» («У сопки Стерегущей Рыси», 1991), «Кара Дикның тормышы һәм үлеме» («Жизнь и смерть Чёрного Дика», 1993), «Торна Крунын кайтуы» («Возвращение журавлёнка Кру», 1996) китапларында, «Шәһәр бүресе» («Чужая», 1998), «Кешеләр һәм бультерьерлар» («Люди и бультерьеры», 2003) повестьларында кискен экология проблемалары куела. Язучы хезмәтен В. фәнни, иҗтимагый эшчәнлек б-н бергә алып бара, периодик матбугатта экологиягә, әхлакка багышланган мәкаләләр бастыра. 1990 елдан В. диварларга рәсем ясау б-н шөгыльләнә. 2000 нән АКШта яши.2004 елда Тайваньдә (Тайбэй ш.) уздырылган анималист рәссамнар дөньякүләм күргәзмәсендә катнашты.

*Р.Ә.Мостафин.*

*Дәвамы. Журналыбызның 2005 ел, 4 санынан басылып килә.*

# БУ НИНДИ... СУГЫШЛЫ БАЛАЧАК?

Рәшит Бәшәрнен урта һәм олы яшьтәге мәктәп балалары өчен Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән хикәя һәм повестьлар җыентыгын укып чыккач, күңелгә шундый сорау килде: мәктәп баласы чакта без нинди китаплар укый идек соң әле? Яратып кат-кат укылганнары—«Замана балалары», «Маякчы кызы». ...Хәер, мин үзем татарча китапларга талымсыз булдым, кулга эләккән һәммәсен укып бардым. Соңрак матбугат хезмәтенә кереп китүем дә шул китаплардандыр. Югыйсә, каләм тотып тудым диярлегем




юк. Авыл мәктәбенен өченче сыйныфында укыганда мөгаллимебез мәрхүм Закир абый бер көнне Рифат дустым белән икебезне чират буенча стена газитенә мәкалә язарга алып калган иде. Кичкә кадәр—үзе өем-өем дәфтәрләребезне тикшереп бетергәнче—тотса да, икебездән бер юл мәкалә чыкмады. Шуннан соң җиде ел узгач, колхоз маллары көткәндә, фамилиям район газитендә күренгәли иде инде.

«Маякчы кызы»нын соңгы бер җөмләсе һаман да хәтердә йөри: «Эх, сөяр дә соң илен, Илсөяр!». Шул заман Илсөярләренен, Хәлимнәренен бүгенге хәлен уйлаган саен бу сүзләр кинаялерәк булып күңелдә янара. Сөйде менә! Әлеге «балалар» төзегән җәмгыятьне «кеше чырайлы»га үзгәртәбез дип тотындылар да, иблис кыяфәтле мәнсез империя корып маташалар.

Менә шуна күрә дә хәзерге балалар язучысы Илсөярләрне сурәтләми инде. Аларга охшашлар тормышта ук юктыр, бәлки. Узган гасырнын утызынчы-кырыгынчы еллары әдәбиятыннан бүгенгегә мирас булып... сугышлар гына калды, ахры. Рәшит Бәшәрнең «Ачык капка» исемле яна китабыннан да сугыш сөреме бөркелеп, кан саркып торгандай тоела.Әмма бу китаптагы «сугыш»ка беркем дә барам дип, иленең азатлыгын, үз халкымның бәхетен саклыйм дип тормый. Әфганнәрне яисә чеченнәрне үтерүдән нинди азатлык, кемгә бәхет килсен?! Балалар язучысы моны аңламый диме?

Рәшит иҗаты турында үзара сүз чыккач, кемнендер «Һаман да шул үткән балачакны сагыну» дигәне истә калган. Сагыну... әйе, бар анда. Яна китабына исем биргән «Ачык капка» повестена керешен ул үзе үк «Балачак хикәятләрем! Бик кайтасым килә минем сезгә!» дигән сүзләр белән тәгәлли. Ахыр сүзендә дә шуна охшаш фикер: «Балачак хикәятләрем! Рәхмәт сезгә!» Хәер, сагыну гына да түгел бу. Рәшит Бәшәр балалар турында үзе яхшы белгән чордан, үз балачагыннан алып яза. Һәм шулай булуы табигый да. Ул балачакта без дә үзебезне таныйбыз. Бигрәк тә «Ачык капка»дагы Рәфит «тормыш»ында кайчандыр без күреп үткәннәр ачык тоемлана. «Акбалык»тагы Айдардан, «Бер өйдә җиде кеше»дәге Дамирдан, «Минем әтине сугышта үтерделәр»дәге Айбулаттан бүгенге балалар үзләрен танырлар. Укысалар, әлбәттә. Үтеп киткәч, шул балачакларын сагынырлар да әле. Сагынырлыгы юк та кебек үзе. Көенечебезгә күрә, аларга да сугышлар чоры язган икән. Игълан ителмәгәне,

---

Рәшит Бәшәр. Ачык капка. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004 ел.

астыртыны. Бу сугышның җиңү бәйрәмнәре дә, шәһитләрне зурлап искә алу көннәре дә булмаячак. Әле азагы да буламы-юкмы... Рәтле илләрдә хәрби чыгымнар халыкны имин яшәтү, афәтләрдән саклау өчен тотылса, бу илдә ул кешеләрнең бер-берсен үтерүенә сарыф ителә. Җитмәсә, бүтән бер илдә дә булмаганча күп сарыф ителә. Рәсәй бюджетының өчтән бере чамасын көч структуралары «ашап бара» дип язалар. Менә нилектән балалар әдәбияты да, аларның чын тормышы кебек үк, сугышлар белән үрелеп беткән.

«Ачык капка» китабына җәмгысы дүрт повесть, бер хикәя кергән. «Адашкан кош тавышы»н хикәя дип атавы авторның малайларча бер шукланып алуыннан яки бәләкәй әсәр язып олы исем куючыларны үртәп алырга теләвеннән генәдер, чөнки элегрәк «Мәйдан» журналының аны повесть дип тәкъдим итүе бик урынлы иде. Сурәтләнгән вакыйгаларның зурлыгы белән дә, мәгънә, фикер тирәнлеге ягыннан да бу әсәргә повестьтан кимне бирерлек түгел. Һичсүзсез, арада иң камиле дә бу. Рәшит Бәшәр аны әле генә диярлек—теге дүрт әсәреннән соң ун-унбиш ел узгач язган. Әдип иҗатының отыры җитлегә, камилләшә баруын, үсүдән туктамавын белдерә ул. «Адашкан кош тавышы» безне бүтән төрле сагыну хисенә батыра. Ул—кеше күңеленең, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтнең шушы әсәрдәгедәй сафлыгын һәм матурлыгын юксыну хисе. Безнең шундый бик зур югалтуыбыз барлыгын һәм аны эзләп, табып әдәби әсәрләргә кайтару кирәклеген балалар әдибе бик вакытлы тойган. Дөрес, монда да бар «мөнәсәбәтләр» һәм «кешеләр». Майор Убойкин, мәсәлән. Алардан башка бу әсәр реаль булмас та иде.

«Адашкан кош тавышы»—безнең бик үк күңелле булмаган бүгенгебез хакында. Хәер, адашкан кош тавышлары бездән башка кемнәргә һәм кайчан ишетелсен соң тагын? «Саташу», «Саташып аткан таң», «Саташкан сандугач», «Сакау күке»—һәммәсе дә безнең хакта бит, авторлары гына төрле-төрле. Рәшит Бәшәр әсәренең Гөлйөземе, Нәфисәсе, Шәүкәте безнең күбебездән шактый аерыла да. Адашкан кош тавышы күңелләрен хәвефләндереп, җаннарын борчып торса да, гаҗизлек измәгән, авыр уйлары йөзләрендә һәм эш-гамәлләрендә, бүтәннәргә мөнәсәбәтендә чагылмый аларның. Һәм берсе дә үзен «мин бәхетсез» дип ышандырырга омтылмый. Дөресрәге, үз каһарманнарын ихлас яраткан Рәшит Бәшәр аларны әнә шундыйлар итеп күрә. «Су тартуны» жанының әллә кайсы кылы белән тоеп торган шаян-шук Гөлйөземнең дә, Шәүкәтнең дә, Шәүкәт күңелендә әкрен генә Гөлйөзем урынын ала барган Нәфисәнең дә зарлансалар зарланырлыклары бардыр үзе. Ә зар—юк. Чөнки әдип аларның мескен булуын теләми. Монда тормыш төбенә төшеп, чүплектән туенучы Хәмит абыйга кадәр эчтән елап, тыштан җырлый ала, җан кертәм мин боларга дип, ташландык гармуннар төзәтә. Шәүкәтнең яшьтие—балачак дусты, запойга китеп эчә торган Миңлевәли дә—автор тарафыннан яратып сурәтләнә, нәкъ шундый җылы мөнәсәбәт аңа соңрак үз теләге белән дәваланырга килү өчен сәбәп була. Кирәкле акчаны әҗәткә җыйган. «Авылдашлар шәп бит, яшьти. Адәм кыяфәтенә кереп кайт, дип озатып калдылар».

Яшьлегендә Гөлйөзем белән бергә тыңлаган адашкан кош тавышы милиция сержанты Шәүкәтне чеченнәр иленә кадәр озата килә. Егетне милиционер итү авторга, бәлки, вакыйгаларны Чечнягә китерү өчен кирәк булгандыр да. Алай дисәң, бүген үзләрендә эш таба алмаган авыл егетләре Казанга яисә Чаллыга килеп нинди хезмәткә урнаша ди тагын? Һәм Чечня кебек җирләргә иң элек шуларны җибәрмичә кемне җибәрәләр ди? Яулап алынган халыкларны һәм диндәшләрне үзара үчләндереп тору «кызык» ич. «Ике эт талашканда бүрегә тыныч» дип, читтән генә күзәтәсең. Үзе турында шулай уйлавыбызны белсә, бүре дә гарьләнер иде.

Ә чеченнәр иле, кошлар авазыннан бигрәк, куркытылган, әмма туган тауларын ташлап китәргә теләмәгән бүреләр улавы белән үзгә икән бүген. Бүреләр һәм... Ходаем, үз киностудиябез булмау һәм чын нәфис фильмнар эшли алмавыбыз хакында тагын күпме әрнеп уйланасы икән безгә? Горур таулар итәгендә, адашуны белми торган бүреләр улавы ишетелеп торганда чечен малае Муса белән Шәүкәтнең кыска

гына, ләкин бик тирән мәгънәле әңгәмәсен талантлы режиссер ничегрәк гәүдәләндерер иде икән? Чыңгыз Айтматов атлы кыргыз туганыбызның дөньякүләм танылуына ул язган «Җәмилә», «Хуш, Гөлсары», «Ак пароход»ларның шәплеге өстенә, әлеге әсәрләр буенча төшерелгән унышлы фильмнар да булышты бит. Бик күпләр кыргыз дигән халыкны да шул фильмнар аша белде. «Адашкан кош тавышы» да менә дигән кинофильм өчен әзер сценарий, югыйсә. Андагы вакыйгалар хәрәкәте, фикер тыгызлыгы, сурәтләр жетелеге һәм... нәкъ Чыңгыз Айтматовтагыча гуманизм, кешеләрне, бар тереклекне, тормышны сөю. Шәпләп төшерергә дә, татар кем соң әле ул, дию- челәргә күрсәтергә иде шул фильмны. Китаплар азрак укыла торган бу заманда унышлы иҗат ителгән һәр повесть-романны фильмнарга күчереп тарату бер дә артык булмас иде. Ни сәбәптәндер, милли әдәбиятның милләткә йогынтысы кимеде, бүген китапны ябырылып укымыйлар. Ә бит бүген матур әдәбиятка ихтыяҗның урынлымы-урынсызмы кимүе иртәгә әдәби иҗатка килүчеләрне кискен азайтырга мөмкин. Ә алардан башка милли тәрбияне дә, мөкатдәс туган телне дә бетте дип исәпләү инде. Күрүебезчә, мондый хәвеф кайбер күрше халыклар өстенә ишелеп килә, татардан да ерак йөрмәс. Ничек «шәбрәк» глобальләшергә дип бимазаланган арада, әдәбиятлы чорыбызны сагынырга калмагаек! Шуңа күрә, әлегә сәламәт яшәп килгән, үз дәрәҗәсен саклаган әдәбиятны, бүген язылa торган унышлы әсәрләрне мөмкин булган барлык юллар белән халыкка житкерү, бу эштә кино казанышларыннан да тулы файдалану дәүләткүләм әһәмиятледер. Әйбәт әдәби әсәрләр санынча милли кинофильмнарыбыз булса, телевидениегә дә ят әдәпле чит ил сериалларын сатып алу, болай да аз акчаны файдасыз сарыф итеп бүтәннәр мәдәниятен үстерү ихтыяжы бетәр, ул яктан да милләтебез күпне отар иде. Спорт-фәләнгә, «бөтен Рәсәйдә бердәнбер» уен йортлары төзүгә акча жәлләмәүчеләр нигә бу хакта уйлап карамыйлар икән? Яхшы милли кинофильмнар татарның һәм Татарстанның танылуына да ярдәм итәчәк бит. Безгә артистларны да читтән чакырасы юк, үзебезнекеләр беркемнән ким түгел.

«Адашкан кош тавышы»н киноэкранда «ишетәсе» килү менә шундый уйларга китерде. Кошның шөбһәле авазын беренче булып ишетәчәк Гөлйөзем кечкенә чагында иртән әнисе кыздырып куйган тәбәне «табага төшкән кояш» итеп күрә. И бу балачакның кабатланмас фантазиясе!. Ашкындырып торган хыяллар һәм уйлап чыгарылган матурлыклар! Сугыш арты чорының ач балалары да бөтенләй үк мәхрүм түгел иде алардан. Балалык чорының озынлыгы да шул хыяллар гомере белән үлчәнәдер, бәлки. Менә «Акбалык» повестендагы Айдарның инештә серле Акбалык яши дип ышануы юкка чыкканда әсәр дә тәмамлана, малайның балалык чоры да тәгәлләнә. Моның гаепләре—без, өлкәннәр. Ә ышануы чын иде, балаларча ихлас иде малайның. Шул ук вакытта, ачуландырсак, Акбалык безнең суларны ташлап китә, дигән хәвефле уйдан да котыла алмады. Берәрсе чынлап та ачуландырып куйса! Гөнаһлы жир бит бу, аның кеме генә юк! Бала хыялындагы тылсымлы балыкны эләктереп табада кыздыру өчен ятьмә үрүчеләр дә бар анда. Балачак хыялларыннан, әкият-легендаларга ышанудан мәхрүм кешеләр... «Акбалык» повесте әнә шундыйлар (Ибәт) белән күнеленә пакьлек җуелып бетмәгән, ялгышы өчен үкенә белгән Хөрмәтуллаларның көрәше хакында. Бу көрәш балалар күз алдында, аларның турыдан-туры катнашында бара. Айдар да Хөрмәтулла ягында. Аның дусты һәм күршесе. Ибәт улы Салих та әтисе явызлыгын якламый әлегә. Чөнки бала бала инде: аның кемнән туганы да сабый чагында, язылмаган дәфтәр битедәй, ак күңелле була.

Повесть авторы балалык чорының мондый үзлеген дөрес күрсәткән. Талантлы балалар язучысының балалар тормышын кәгазьдә яңартып чагылдыручы гына булмыйча, фәрештәнекедәй канатларын жәеп, үз каһарманнарының балалыгын саклаучы, аларны яклаучы, һәртөрле бозыклыктан аралаучы да икәнлеге ачык беленә. Әсәрләрендәге һәр бала кадерле аңа. Ул баланың хыялларына кадәр газиз. Айдар үз хыялындагы Акбалыкны ничек кадерләп саклый әнә. «Кешеләр әйбәт булса, Акбалык безнең елгада озак яшәр әле, улым»—ди Ай-

дарга Хәмдүнә әбисе. Автор повесть башында ук әбидән шушы сүзләрне әйттерә дә, аның тирәсендәге кешеләрнең әйбәт булуын әсәр буена «кайгырта». Заманында «авылның атаклы бер сугыш чукмары» булган, «авызына әзрәк аракы керсә, нәрсәгә очып кунганын белми» торган Хөрмәтулла да төрмәдән ипкә кереп кайткан. «Кешеләр усалланса, Акбалык бөтенләй башка җиргә йөзеп китә. Шуның өчен син сугышма да, төрмәгә дә барма» ди аңа Айдар. Бабасы заманыннан бирле яшәп килгән Акбалыкның юкка чыгуы, бала карашынча, бөтенесенә ниндидер хәтәр хәл китерер иде. Акбалыкның югалмаячагына ышану—Айдар өчен кешеләрнең гел әйбәт булачагына ышану ул. Кешеләр явызланса өскә бәла киләчәк ич. Бер Ибәтнең генә кара күңеллелеге дә күпме авылдашларына бәхетсезлек китерә бит әле.

Бала күңеле һәрнәрсәгә шәрран ачык: күркәм гадәтләрне дә, усаллыкны да сеңдерә. Китапның «Ачык капка» дип исемләнүе дә тикмәгә түгел. Балалар өлкәннәрнең сөйләшү рәвешен дә тиз отып алалар. Менә Гариф бабайның, үз башыннан кичкәннәрне хәтерләгән чакта, Донбасс шахтасында күпме күмер «ашавын» телгә алуы була, Айдар шул көнне үк ул сүзләрне күрше авыл кызы Рәхиләгә кабатлый:

«—Урлап китәм әле мин сине, Рәхилә. Гариф бабай шикелле урлап китәм.

—Кая?

—Шахтага күмер ашарга.

Рәхилә аптырап калды, шахтага китеп, күмер ашарга җыенган малайны беренче тапкыр күрә иде әле ул.

—Бар да аша әнә клуб артына. Кичә бер машина күмер апкайттылар.

—Синең белән ашыйм.»

Бала җанын мөмкин кадәр керсез саклау, аның матур-пакь яшәүгә хокукын яклау теләге Рәшит Бәшәрне үз әсәрләрендә һәр сүз белән нәзберек эш итәргә этәрә. Айдар алдында Хәмдүнә әби белән Хөрмәтулланың сөйләшүен ишетеп туярлык түгел. Ярый, Хәмдүнә әби бер хәл инде, оныгы каршында вазифасы шундый диикме соң. Төрмәдән кайткан Хөрмәтулла да бер килешсез сүз чыгармый әнә.

Без хәзер заман әдәбиятыннан күбрәк ничек яшәргә ярамый дигәнне укыйбыз, Рәшит Бәшәр исә өлкәннәргә балалар янында үзләрен ничек тотарга кирәклеген дә матур үрнәкләр белән күрсәтә. Дөрес, бер иҗат җимеше—Ибәте—әдипнең бу кагыйдәсенә буйсынмый, әмма, ни күенеч: Ибәт кебекләр булмаса әсәрнең тормышчанлыгы кимер иде бит! Әйе, балалар әдибе Рәшит Бәшәр язган әсәрләр өлкәннәр өчен дә бик гыйбрәтле. Балалар күзендә ниндиләр булып күренәбез икән, дип кызыксына калсак, китаптагы повестьларны укып, шактый төгәл җавап табар идек. Җавап безне куандырмаска да мөмкин, әмма шулай булуына балалар гаепле түгел инде. Көзгегә үпкәләп буламыни? Өлкәннәрнең ниндилеге бала теләгеннән торса иде дә бит! Тормышның рәхимсез чынлыгы кайчакта әдип ихтыяры белән дә исәпләшми шикелле. Рәшит Бәшәр «Акбалык»ны болай күңелсез тәмамларга, бик яраткан Айдарының гөнаһсыз хыялын челпәрәмә китерергә теләдеме икән? Юктыр. Ә бит малай эзләгән серле балыкның барлыгына Хөрмәтулла да ышана иде. Әнә ул да бөтенесенә кул селтәп авылдан китәргә мәҗбүр. Ак күңелле булганнары өчен Айдар белән Хөрмәтулла икесе дә җәзалана. Авылдашлары, күршеләре, җирдәшләре җәзалый аларны. «Адашкан кош тавышы»ндагы Шәүкәт әйтмешли, «Йа Хода, нишләдек без? Нишләдек?» Хөрмәтулланың сөенә-сөенә кешеләргә игелек кылып йөргән тимерчелеген яндырудан, аның «брат»ы Айдарның яраткан көчеген атып Акбалыклы суга ташлаудан «Адашкан кош тавышы»ндагы майор Убойкин гамәлләренә дә ерак калмый ич. Кая барабыз?

«Бер өйдә җиде кеше» повестенда күпчелек вакыйга Дамир исемле малай «күргәнчә» тасвирлана, ягъни, әсәрнең байтак өлеше Дамир көндәлекләреннән тора. Авыл малае Дамир шәһәрдә яшәүче абыйсына кунакка килгәч, андагы тормыш та бала карашыннан чыгып бәян ителә. Аның Мансур абыйсы әйтмешли, шәһәр шәһәр инде, авыл түгел. Монда алдашу да, бозыклык та күбрәк, чөнки... шәһәрдә кеше күбрәк. «Күп» арасында кеме генә юк шәһәрнең! Кайберсенең имәнеч гамәлен күргәч, Айдарның Акбалык белән хушлашу сүзләрен кабатларлык: «Кеше булып

тууым өчен мин гаепле түгел бит, Акбалык. Мин гаепле түгел!»

Кеше кем ул, дигән аптыраулы сорауга «Бер өйдә жиде кеше» каһарманнары да жавап эзли. Бигрәк тә—әфганнарга каршы мәгънәсез сугышта катнашкан Егор бу хакта еш уйлана. Кешеме соң бу, диярлекләрне байтак очраткан шул ул. «Кеше бөҗәк түгел ул. Әмма безне бөҗәккә дә санамадылар. Суегыз, диделәр, суйдык. Яндырыгыз, диделәр, яндырдык. Приказ. Үтермәсән, үзенне үтерәләр. Үзеннекеләр үк атып үтерә.»

«Ачык капка» китабы «Минем әтине сугышта үтерделәр» дигән повесть белән ябыла. Китап башындагы әсәрдә милиция хезмәткәре Шәүкәтне чеченнар жирендә яралы хәлендә калдырып аерылышкан идек, соңгысында взвод командиры лейтенант Айдар Рәхимовның шул ук Чечня сугышында гомере өзелүгә шаһит булдык. Балаларга багышланган... сугыш китабы! Нишли бу әдип, нишлибез без, кешеләр? Сугышларсыз тора алмыйбызмы соң әллә? Балаларның уеннарына кадәр сугыш та сугыш бит. «Ачык капка» повесте каһарманнарының бар мавыкканы «военный» кино әнә. Анысы—безнең балачак. Туксан яшьлек Мөбарәкша бабайның («Минем әтине сугышта үтерделәр») туксан еллык тормыш тәжрибәсеннән чыгып әйткән сүзләре безнең балалык чорына да, бүгенге балаларга да кагыла. «Бу урыс патшаларын әйтәм. Гомер буе кеше суеп тәм таптылар. Акчаны сугышка тыгып бетерәләр». Әйе, күенечебезгә күрә, сугышлар арасында гына яшәп алгандай итәбез без. Шуна күрә ни тормышыбызның бөтәйгәне, ни кешечә яшәү өметебезнең акланганы, ни чыраебызның яктырганы, ни бер генә буынга да бәхетле балачак килгәне юк. Чөнки сугышлы илдән бәрәкәт кача. Чечняда сугышып, партизан чечен малае кулыннан һәлак булган взвод командиры Рәхимовка китап авторы бер дә юктан гына Айдар исеме бирмәгән: «Акбалык»та күнеле жәрәхәтләнгән, хыялын жуйган Айдарның дәвамы ул. Хактыр ки, балачак хыялын жуйганнарның гомере мәгънәсез уза. Балаларның балалык хокукын да саклый белмибез. «Авызга су кабып яшәгәнгә шушы көнгә калдык түгелме соң?» ди Рәшит Бәшәрнең туксан яшьлек Мөбарәкшасы. Елдан-ел балалар аз туа һәм елдан-елга ятим балалар арта торган мондый аңлаешсыз ил дә була ала икән. Ил-көнендә Ибәтләр, капитан Дохиннар, майор Убойкиннар сүзе өстен йөргәч соң...

«Ачык капка» китабындагыдай күп әсәрләре өчен Рәшит Бәшәргә Татарстан Язучылар берлегенең Абдулла Алиш исемендәге бүләге бирелде, ә бит Абдулла Алиш—сугышта һәлак булган балалар язучысы...

**Рафыйк ШӘРӘФИЕВ**


## «Казан утлары» архивыннан



*Сулдан уңга: Шәриф Камал, Кави Нәҗми, Фәйзулла Туишев. Үткән гасырның 40 нчы еллары.*



*Дөньякүләм мәшһүр композитор София Гобәйдуллина.*



*Бөек максат безнең—Азатлык! Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов. 1989 ел.*



*Татарстан делегациясе композитор Фәрит Яруллин кабере янында. Сулдан уңга—Марат Әхмәтов, Наилә Яруллина, Мирсәет Яруллин, Флера Әхмәтова, Чулпан Бәхтиярова, Рашат Низамиев, Рафаэль Билалов. Белоруссия. Витебск өлкәсе. 1985 ел.*



*Шәйхи Маннур 75 яшьлек юбилее көнендә үзбәк каләмдәшләре бүләк иткән киемдә. 1980 ел.*



*Айдар Хәлим (сулдан уңга), журналист Дамир Рәфыйков (Оренбург) һәм Фәүзия Бәйрәмова Бөтендөнья татар Конгрессы көннәрендә. Казан. 2002 ел.*

*Сажидә Сөләйманованың тууына 80 ел*

# ҖЫРЛАНМАГАН ҖЫРЛАР НИ СӨЙЛИЛӘР?

«Ач, шигърият, серләренне, тылсымлы сүзләр өйрәт!» Кайчандыр, шигърияткә тартыла башлагандамы, хәтергә кереп калган иде бу юллар. Әле ул чакта кем язганлыгын белү дә бик үк мөһим саналмагандыр... Ниндидер табигый булмаган дөнья белән очрашасы килү кулга шигырь китаплары алдыргандыр... Серле, бик серле бит ул шигърият дөньясы! Күнеләндә шигырь уты кабынып, шигърият бакчасына аяк басарга теләгән кайсы гына җан иясе тылсымлы сүзләре белән шигърият капкасының ачылуын, бөтен барлыгы белән үзенең әлеге дөньяда калуын теләми икән!

Әйе, болай итеп, шигъриятне зурлап, олуг шигърияткә чын йөрәктән табынганнар гына әйтә ала. Табына һәм анда кала алганнар гына...

Сажидә Сөләйманованың әлеге канатлы сүзләре аша, аның шигъриятенә, серле күңел дөньясына үтеп керергә теләп өстәлемдә яткан китаплары арасыннан үзе исән чакта, үз куллары белән төзеп, үзе нәшриятка тапшырган, көтү ләззәтен, инде китап булып дөньяга килгәч баласы туган ана шатлыгын кичергәндәй шатлык бирә алган «Кызыл каурыйлар»ны кулыма алам. Укый барам, укыган саен соклануым арта бара. Кайчандыр, әлеге шигырьләрне шигырь яратучы укучы буларак кына укыган булсам, бүген исә бөтенләй башка яктан, башка яссылыктан, каләмдәшем буларак та аны үземә ача барам. Никадәр бай, тирән иҗат! Никадәр моң, наз аларда! Гади генә тоелган шигырьләрендә дә олы мәгънә ята. Лирика—аның шигъриятенең асылы. Әйе, Сажидә Сөләйманова иҗатының сере, биеклеге совет чорында бер көйгә, бер мотивкарак салынган татар шигъриятенә җылылык өстәүдә, лирика жанрын яңа төсмерләр белән баета алуда. Һәр китабы—«Кыр казлары» (1963), «Бәхетне үзем табам» (1966), «Фал китабы» (1974) һ. б. шигърият сөючеләрнең күңел сердәшенә әйләнә. (Рухын яд итеп гаиләсе, «Рухият» нәшрияты бастырып чыгарган «Тормыш, исәнме!» (1998) җыентыгы да зур бүләк, истәлек.) Илгә, көнгә, яшәешкә мәхәббәт белән сугарылган әлеге шигырьләрдән яктылык, нур бөркелә. Күңеле төшенке вакытта язылганнарында да, үзенә «тибеп» алганнарга, тәнкыйтьләүчеләргә дә кинә тоту, ачу саклау юк.

*Без майданга чыктык,*
*һәр көрәштә*
*бар бер гадәт-йола:*
*баш ярырга мөмкин җиргә орып,*
*аяк чалу тыела.*

*...............................*
*Минем йөрәк,*
*йөрәк капланмаган—*
*тик йөрәккә сукма.*

Әйе, нәрсәдер әйтергә телисең, тәнкыйтьлисең килә икән—әйт, тик фикерең генә дөрес һәм ул чын күңелдән, яхшылык теләп булсын, йөрәкне генә яралау булмасын. Аз булдымы шәхесне анламыйча, барлы-юклы белеме (дөресрәге белемсезлеге) яхшыны—начардан, талантлыны—талантсыздан аера белмичә каш ясыйм дип күз чыгаручылар? Аз булдымы кулына каләм алып әсәр яза, сәхнәдә образ, яки картина тудыра алмаслык итеп сындырылган талантларыбыз?.. С. Сөләйманова да әлеге шигыре аша тәнкыйтьчеләргә әнә шул фаҗигаләрне искәртергә теләмиме?!

*Ә бөркеткә һәрчак ук төбәлә.*
*Очып төшә кызыл каурыйлар...*

Кызганыч, Сажидә Сөләйманованы әдәби кичәләрдә генә булса да күреп, шигырьләрен үзе укуында ишетеп калулар насыйп булмады. Беренче шигырь китабы—минем туган елымда—1963 елда чыккан, шушы ук елны Язучылар берлегенә кабул ителә. Үлгән елы исә—минем Казанга килгән елымда—1980 елда.

Күпмедер бер яшькә җитеп иҗат эшенә керешкән кешеләр турында «соңлабрак

килде» дигән нindидер бик үк дөрес булмаган фикер яшәп килә. Бу фикерне С. Сөләйманова иҗаты турында сүз әйткәндә дә кулланучылар бар. Нәрсәгә сонарган соң ул? Аның вакыты, бәлки, нәкъ менә шул вакыттыр? Көнелендә гомер буе тупланып, җыелып килгәнен ул, бәлки, нәкъ менә хәзер әйтеп бирергә теләгәндер? Адәм баласының, бигрәк тә хатын-кызның эчке дөньясы, табигате аның бит яшияши баеый, тулылана бара, күргән-кичергәннәр аша... Хатын да—син, Ана да—син, хезмәткәр дә—син, шагыйрә дә—син... Көйсезен—көйләгәндә, җөйсезен җөйләгәндә күпме шигырь юллары кәгазьгә төшә алмыйча да каладыр...

*Язмышларны күңел күзе аша*
*уткәрергә—*
*Шигърияткә килә хатыннар.*

Үзара әңгәмәләшкәндә, әдәби кулуарларда синен иҗатына бәһа биреп ни генә әйтсәләр дә, әйткән—югала, язган гына кала. Әле дә ярый сагынганда укып юаныр өчен язма истәлекләр саклана.

Кемнен генә язмасын укып карама, һәркайсында шагыйрә иҗатына зур бәһа, соклану, ярату...

«Синен үзең кебек тыйнак, сөйкемле, кешелекле шигырьләренне мин чын күңелдән яратам һәм хөрмәт итәм». (Ә. Еники).

«Без синен әдәбиятка килүенне сокланып, шатланып каршы алган идек. Татар поэзиясенен Анна Ахматовасы булачак бу, дип сөенгән идек. Әле дә шулай уйлыйбыз.» (Х. Туфан).

«Сажидә Сөләйманова биеклеге ул ир-ат шагыйрьләр дә әйтергә курыккан чынлыкны әйтә белүдә». (М. Әгъләмов).

Тик нигәдер Сажидә Сөләйманова үзенең «Шагыйрә» дип исемләнгән шигырендә аксакал белән бәхәскә керепме, әллә үз алдына уйланып кынамы: «Ахматова түгел мин, бүтән»,—дип белдерә. Юк, һич кенә дә үзен ким яки артык итеп күрсәтәсе килүдән түгелдер, ә бәлки «Зиләйлүк», «Тәфтиләү»ләрне тынлап, көйләп үскән кызның җырларында халкыбыз моңы, әрнүләре, халык авыз иҗаты аһәннәре булуын гына искәртәсе килүдәндер.

*Җан—*
*кешедә бәһаләнмәс байлык.*
*Мал—*
*азмыдыр анда кан да кайгы...*
*Дан—*
*янәшә күпме ялагайлык—*

болар халкыбызның мәкаль-әйтемнәре белән янәшә куярлык юллар түгелмени! Билгеле инде, Башкортстанда туып үскән кызның күңеленә башкорт далаларының киңлеге дә, кыя-тауларының мәгърурлыгы дә тәэсир итми калмагандыр. Күңел киңлеге—далалардан булса, горурлыгы—таулардан күчкәндер.

«Җир-су», «Җырланмаган җырлар»... «Сузган ике кулым» поэмасын укыганда шагыйрәнең поэма жанрын да тирән аңлап иҗат итә алуына игътибар итәсең. Үзәктә—Ана белән Бала. Бу тема күп шагыйрә хатын-кызларның бәгырь түрендә булса да, автор аны аерым бер фәлсәфи югарылыкка, шәхес тәрбияләү югарылыгына күтәрә алган.

*Кеше—сәнгать,*
*Иҗат ителәдер*
*Сизелгәндә йөрәк катында.*

Житмешенче еллар уртасында яратып җырланган, яратып тыңланган «Гүзәлия җыры»н, «Саубуллашу вальсы»н, «Урсал тауда»ны җыр-моң яратучыларыбыз әле дә хәтерли булыр. Укытучы, радиотапшырулар мөхәррире, Әлмәт әдәбият берләшмәсе җитәкчесе булып эшләгән шагыйрә яшь талантларга, бигрәк тә хатын-кыз шагыйрәләрнең иҗатына, аларны үстерүгә дә вакыт таба, уңышларына чын күңелдән сөенә торган була.

Әйе, Сажидә Сөләйманова—әдибә. Ул әдәбиятның бөтен жанрларын да ярата, үз итә. Әйтер идем, әсәрләре аның үзен дә яраталар, аңа танылу алып киләләр. Өстенә ишелеп килгән кара кайгыдан да ул сыгылып төшми, ашыга-ашыга, төгәлләп калырга тырышып «Гөлбадран» повестен яза башлый. Әйтергә генә җиңел... Фәлән хәтле гомерең калганын белә торып яшәү, иҗат итү турында уйлар өчен күпме көч, сабырлык, ныклык кирәк! Әле чирнең дә нindie бит! Менә-менә каләм туктап калыр сыман. Гомер өчен, яза башлаган әсәр, җырланмаган җырлар өчен көрәш бара... Һәр авазы серле шагыйрә исә гомер озынлыгының ни белән үлчәнүен аңлап иҗат иткән, яшәгән... һәм яши.

**Гөлзадә БӘЙРӘМОВА**

---

*Безнең календарь*

## Демьян Фәтхинең тууына 100 ел

Демьян Фәтхи иҗатының башлангыч чоры илдә булган кискен үзгәрешләр вакытына туры килә. Әсәрләренең төп темасы да—Октябрь революциясе алып килгән яңа тормышка, искелек белән яңалык көрәшендәге җиңүләргә дан җырлау. Демьян Фәтхи (Касыйм Фәтхетдин улы Фәтхетдинов) 1906 елның 10 октябрендә элекке Самара губернасы (хәзерге—Ульяновск өлкәсе, Чардаклы районы) Татар Колмаеры авылында крестьян гаиләсендә туа. Самара шәһәрендә педагогия техникумында, Казанда (1926) Татрабфакта укый. Шул елларда беренче җыентыклары нәшер ителә.

Демьян Фәтхи иҗатына Һ. Такташ, Х. Туфан, рус шагыйрьләреннән Демьян Бедный шигырьләре (әдәби псевдонимы да аннан алынган) зур йогынты ясый.

Гражданнар сугышы батырлары, халыкның үткәндәге авыр тормышы, халыклар дуслыгы темасына багышланган «Алтай әкияте», «Сабирҗан», «Тальян», «Бояр урманында» һәм колхозлашу проблемаларын күтәргән «Ызансыз кырлар» аның иҗатының төп әсәрләре.

Шагыйрь күңеле туктаусыз эзләнүдә. Утызынчы ел урталарында ул Ерак Көнчыгышка китә. Гади эшче булып эшләү белән берлектә иҗат эшен дә читкә куймый. Алтын рудникларында эшләүче татарлар тормышын, революция алып килгән үзгәрешләрне Себер табигате фонында сурәтләп «Алтын тайга» трагедиясеннән (1939-1940) поэмасын иҗат итә. Әлеге әсәр аңа танылу алып килгән әсәрләренең берсе булып тора.

Туган якларны сагыну, җирсү—читтә йөргән адәм баласының күбесенә хас сыйфат. Бу хис бигрәк тә иҗат кешеләренең күңел түрендә. Демьян Фәтхи дә Татарстанның Зеленодол шәһәренә кайтып урнаша. Ләкин Бөек Ватан сугышы башлану шагыйрьгә туган җирләрдә озак юанырга ирек бирми, ул 1941 елны фронтка китә, берничә тапкыр яралана, 1943 елны Кантемирова (Воронеж өлкәсе) янындагы каты бәрелеш вакытында солдат-шагыйрь батырларча һәлак була.

Якты дөньяда нибары утыз җиде ел яшәп калган шагыйрь татар әдәбиятына әнә шундый матур әсәрләр, якты истәлекләр калдыра.

# БАРАСЫ ЮЛЛАР ОЗЫН

Хәзерге татар прозасы турында сүз чыкканда еш кына канәгатьсезлек төсмерләре өстенлек ала: янәсе, безнең шигърият югары кимәлдә, драматургия үсештә, ә менә чәчмә әсәрләр... Әйе, соңгы дистә елда прозабызның умыртка баганасы булырдай әдәбият аксакаллары бакыйлыкка күчте. Алардан соң ниндидер бушлык хасил булгандыр, табигый. Әмма мондый дәгъвалар Еникиләр, Гыйләҗевләр исән чакта да, хәтта аларның үз авызларыннан да ишетелгәли иде.

Сүз дә юк, әдәбиятның егәрен, тирәнлеген проза әсәрләре билгели. Шуңа күрә прозаның мөмкин кадәр көчлерәк булуын теләвебез —гадәти хәл. Әдәбиятны (бу очракта иң беренче нәүбәттә мин прозаны күздә тотам) тоташ бер диңгез дип күзалласак, аның су кимәлен кушылдык дәрьялар тота. Ягъни хәзерге татар прозасы дигәндә дә күңелгә аерым исемнәр килә. Ә алар күп була алмый...

Һич шикләнмичә әйтергә мөмкин — Нәбирә Гыйматдинова исеме шулар арасында. Әлбәттә без, бер казанда кайнаган кешеләр буларак, кайчагында үзара бәя бирешкәндә, аратаны югарырак та күтәргәлибез. Шуңа күрә бу җәһәттән укучы фикере генә төп билгеләмә була аладыр. Нәбирә — бәхетле язучы, татар әдипләре арасында бүген ул иң күп укыла торганы, дисәм дә, мөгаен, ялгышмамдыр.

Әдәбиятта беренче адымнарыннан ук Нәбирәнең иҗатын күзәтеп киләм. Гаҗәп тә түгел — студент елларыннан ук безнең гомер гел янәшә үтә икән. Дөресен әйтим, иң башта мин аны яшь шагыйрә дип белә идем. Моның бер нәни генә сәбәбе дә бар. Сиксәненче елдамы икән, университетның «Әллүки» әдәби берләшмәсе яшь шагыйрьләр арасында ярыш үткәрде. Дәрәҗәле жюри да чакырылган иде: тулай торакка «Казан утлары» егетләре — Р. Гаташ, М. Галиев, М. Вәлиев, Р. Мөхәммәдиев, С. Шәмсиләр килде. Шунда тал чыбыгыдай нечкә мишәр кызы очына-очына шигырь сөйләде. Шигырьләр, билгеле, ул яшьтәге һәрбер кызныкы шикелле, мәхәббәт сагышына төренгән иде. «Кем бу?» — дип сорадым мин ачкан авызымны да ябарга онытып. «Нәбирә!— диде Газинур Морат. — Бик талантлы кыз. Тормыш тәҗрибәсе белән килгән...»



*Язучыларның 64 нче Халыкара конгрессы көннәре. Уңнан беренче — Н. Гыйматдинова. Шотландия, 1997 ел.*

Газинур юкка гына мондый бәяне бирмәгәндер. Ул чакларда төрле җыелышларда булсын, әдәби мәкаләләрдә булсын, язучының тормыш тәҗрибәсенә нык игътибар ителә иде. Ягъни каләм әһеле, халык арасында әвәрә килеп, әдәбият мәйданына аяк басса, аның язганнары да халыкчан була, дигән фикер үткәрелә иде. Бу җәһәттән, әлбәттә, Нәбирә безнең кебек мәктәп партасыннан университет эскәмиясенә күчкән «яшел»ләрдән аерылып тора иде. Ул яшьтән үк үз күнен үзе күрергә дип «каләшләр каласы» Ивановога чыгып киткән, маляр кызның, Аяз Гыйләҗев әйтмешли, комбинезонына ябышкан ак буяу тамчылары да җуелып бетмәгән иде.

Ләкин кайбер өлкәннәрнең өметләрен акламады бугай ул. Аның соцреализмга хас булганча эшчеләр темасын яктыртырга тырышуы беренче әсәрләрендә үк сизелми иде.

Тулай торакта Нәбирәнең ялкынланып шигырь укуы юкка гына бик еш исемә төшми. Менә хәзер—ул заманнан бирле чирек гасыр узгач—Нәбирә прозасының нәкъ менә шигърияттән үсеп чыгуын, теленең шигъри сүз белән өртелүен яхшы аңлыйсың. Җиде еллар элгәре күренекле шигырь белгече, фән докторы Хәлиф Курбатов та моңа игътибар иткән икән: «Нәбирә Гыйматдинова повестьларының идея-эчтәлек ягына килсәң дә, төзелеш-композицион үзенчәлекләренә карасаң да—чын-чыннан поэзия. Бу автор — хәзерге татар әдәбиятында поэтик прозаның зур остасы».

Нәбирә иҗатының төп үзенчәлеген бик төгәл тотып алган мәрхүм галимебез. Бүген безнең әдәбиятны схематик каһарманнар дыңгычлап тутырылган, очеркка охшаш язмалар басып китте. Болар арасында Нәбирәнең әсәрләре үзләренең җанлы теле, мавыктыргыч сюжеты, символларга бай булуы белән бөтенләй бүтән яссылыкта игътибарны җәлеп итә.

Ул гына да түгел, әлеге серле иҗат без моңарчы күнеккән, инде классик мирасыбыз дип саналган әсәрләрдән дә нык аерыла. Шунысы кызык: әлеге аерымлык, әлеге үзгәлек аның беренче тәҗрибәләреннән үк сизелгән икән. Моннан утыз ике ел элек «Идел» альманахы өчен язылган әчке рецензиясендә (ул берничә ел элек «Мәдәни җомга» гәҗитендә дөнья күрде) Аяз Гыйләҗев болай ди: «Нәбирә повестьлары күңелгә килгәннәр дә, ашыгып-ашыгып дәфтәргә түгелгәннәр... Ә прозаны акыл, гамь белән дәфтәргә тезеп куярга кирәк. Нәбирәгә хисләр комачаулый, ул ашкынып-ашкынып китә дә, гади тормыш законнарын бөтенләй санламый башлый. Тормышның үз логикасы бар, эчке закончалыгы бар, алар берникадәрле авторның тезгенен тотып торалар, һәр әсәрнең үз агымы, үз логикасы булу өстенә, ул тормыш логикасын да бозарга тиеш түгел».

Мин биредә Аяз ага хаксыз булып чыкты, дип әйтергә җиенмыйм. Хикмәт шунда—чын иҗат алдан сызылган бернинди схемаларга, тиеш-тиеш түгеллекләргә буйсынмый. А. Гыйләҗев чын реалист язучы иде, һәм шул күзлектән үзенең таләпләрен дә куйган. Ә Нәбирәнең иҗат алымы бөтенләй бүтән: ул, чыннан да, гадәти тормыш логикасын бозып, үз әдәби-эстетик мантыйгын кора. Әлеге мантыйк күп очракта безне ныграк ышандыра да. Юкка гына бер акыл иясе поэзияне гадәти мантыйкны җимереп яңа мантыйк кору, дип билгеләмәгәндер.

Нәбирәнең иҗаты турында сөйләшеп утырганда Зөлфәт аның иҗатын Габриэль Маркесныкына охшаткан иде. Ул, мөгаен, Маркесның мифологиягә таянуын, аның да әсәрләрендә Вакыт төшенчәсенең бик шартлы булуын күздә тоткандыр. Ничек кенә булмасын, күренекле шагыйребезнең әлеге чагыштыруы Нәбирә иҗатына бөтенләй бүтән ноктадан карарга, өйрәнергә җирлек бирә.

Чөнки Нәбирәнең бәяннары турында сүз чыкса, еш кына өстән-өстән генә әйтелгән бәяләмәләргә тап буласың. Янәсе, ул сихерчеләр, җен-пәриләр белән мавыга, җәмгыятьтә хатын-кызның урынын купайтырга тырыша.

Хәлбуки, әлеге иҗат шактый катлаулы, аның әсәрләрендә беренче күзгә ташланган катламнан соң тирәндәрәк бүтән катламнар, бүтән агымнар бар.

Шул катламнарга кагылырга җөрьәт иткәнче, иң әүвәл тирә-юнебезгә, татар тормышына күз салыйк әле. Уйлап баксаң, үткән гасырда татар хәяте коточкыч үзгәрешләргә дучар булып, хәтта безнең буын күз алдында ышанмастай әверелешләр кичерде. Мең еллар дәвамында халкыбызның рухын саклаган терәүләр сынды, без бөтенләй үз йөзебезне җуйдык түгелме соң? Без хәтта Намус дигән сүзне кулланырга кыенсына башладык. Әдәп-инсаф, низам, итагать кебек төшенчәләр тормышта ирешәсе уңышларга киртә сыман күзаллана хәзер. Иблис телевизор әрҗәсенә кереп, түребезгә менеп урнашты. Хыянәт, зина, ришвәтчелек, эчкечелек, күтләклек гөнаһ булып саналмый инде. Котылу юлы кайда? Тамырлардамы? Язучы шул тамырларны барларга мәҗбүр. Бөтенләй кипмәгәнме алар, әбелхәят суы сугарамы әле аларны? Менә ни өчен Нәбирәнең әсәрләрендә Вакыт төшенчәсе бик шартлы, менә ни өчен ул борынгы мифларга, символларга мөрәҗәгать итә. Зур язучы буларак, ул һәрдаим, һәр әсәрендә безгә Афәт ябырылуын искәртә, ачыргаланып котылу юлын эзли.

Ләкин Афәтнең дә тамырлары соңгы берничә дистә елны гына колачламыйча, шактый тирәнгә барып тоташа икән ләбаса. Урман карты Шәңкәле кайчандыр

Шәнгәрәй мулла булган да, болганчык елларда аны дошманнары тереләй җиргә күмгәннәр, ә хатыны белән баласын суга агызганнар («Китәм, димә»). Мулланы Бүре кабердән йолып ала. Бик борынгы төрки риваятьне хәтерләтмиме соң бу? Бөтен нәселен кырып бетергәч, аяк-куллары чабылган малайны дошманнары, үләр әле, дип ташлап калдыралар. Аны Ашина-бүре килеп коткара, аннары ана балалар да табып бирә — төрки халык янадан күтәрелеп китә. Димәк, үләбез, бетәбез, дигәндә дә Бүре кыяфәтендә Өмет кала икән. Шуна да Бүре образы Нәбирәнен шактый әсәрендә пәйда була да бугай...

Тарих чоңгылларыннан исән-имин үтеп, милләт буларак үз йөзенне җуймау һәр көн туктаусыз көрәш, көчәнеш таләп итә. Шул көчнең чыганагы нидә? Хатын-кызда! Нәбирәнең һәр әсәрендә хатын-кызнын алгы планга чыгуы, минемчә, шунын белән бәйле. Монысы да безнең борынгы риваятьләрдән, әкиятләрдән килә. Хатын-кыз йорттагы учакны саклап, ана утын өстәүче генә түгел, яугирләре йә кырылып, йә хатыншага әйләнеп беткәндә, көрәш кылычын үз кулына алып юлбашчыга әверелүче дә...

Безне элек бөтендөньяда урнашачак коммунизм рәхәтлеге белән алдасалар, бүген глобализм җимешләре белән кызыктыралар. Ләкин без без булып калыр өчен гореф-гадәтләребезне югалтмаска, ил-җирдән аерылмаска кирәк икәнлеген сәнгатьчә итеп Нәбирә кебек язучылар гына әйтә ала. Инде кабилән манкортка, зомбига әверелгәндә дә, Афәт белән күзгә-күз калганда да, Котылу юлы бар — ул синең Табигатең. Мәчет манарасын кисәргә килгән кызыл Гыйниятне үз кулы белән атып үтергән Хәбир мулла урманга, андагы Тоба дигән чокырга китеп котыла («Икебезгә дә авыр»). Тоба авылдан ерак та түгел, авылдашлары да мулланың кайда икәнен белә. Тик анда беркемнең дә кулы җитми. Соңгы чиктә татар сыена торган урыннар Нәбирәнең бүтән әсәрләрендә дә бар. Урман («Утарда», «Китәм, димә»), Сазлык («Күкчәчәк»)... Соңгысы Күкчәчәкне авыр чакта сыйдырса да, үзен дөнья тоткасы санап йөргән ире Лотфулла анда гаип була...

Мондый символлар белән эш итүе, әлбәттә, авторның туган җиргә, Табигатькә булган ышануы белән бәйле. Ул гына да түгел, әлеге кырыс, дәһшәтле җир йөзендә үзең булып, тамырларыннан аерылмаган килеш калыр өчен күңелеңдә син генә сыена алырлык үз дөньяң сакланырга тиешлегенә ишарә дә.

Нәбирә Гыйматдинова әсәрләренең теле турында да берничә сүз әйтәсе килә. Ул тасвир чараларын шактый саран куллана, психологизм гонсырлары белән дә артык мавыкмый. Каһарманнарының холыкларын, характерларын ул диалоглар аша ача. Укучыны һәрдаим киеренкелектә тотар өчен бу, күрәсең, иң отышлы юлдыр.

Шуна күрә инсценировкалар язганда аның әсәрләренә еш мөрәҗәгать итәләр. Мәсәлән, «Сихерче» бәянына нигезләнеп эшләнгән спектакль К. Тинчурин исемендәге театрда уңыш белән барды. Хәзер ул Уфаның «Нур» театры сәхнәсеннән төшми. Әле күптән түгел генә К. Тинчурин исемендәге театрда Нәбирәнең янә бер әсәре буенча «Бер тамчы ярату» спектакле куелды. Ә 2003 елда Г. Камал исемендәге академия театрында үткәрелгән «Яңа татар пьесасы» ярышында аның «Ут күбәләге» әсәре буенча язылган инсценировка җиңүче дип табылды. Бу табигый да, чөнки тел белгече профессор Флера апа Сафиуллина әйткәнчә: «андагы геройларның сөйләм үзенчәлекләре, уртак сөйләмдәге гыйбарәләр, диалекталь лексиканың чама белән генә кертелүе, әсәрдә һәм җөмләдә урынлы кулланылган фразеологик берәмлекләр һәм канатлы сүзләр Нәбирәнең телен лабораториядә өйрәнерлек итә».

Бик сирәк язучыларны гына кабат-кабат укырга мөмкин. Әлбәттә, моның өчен җан-рух тәңгәллеге дә, фикердәшлек тә кирәктер. Нәбирә Гыйматдинова минем өчен шундый язучылар арасында. Күңел төшенке чакларда аның китабын кулыма алам, таныш каһарманнар хыял дөньямда янә яши башлый, кайберләре мина нәкъ туган ягымдагы шивәдә эндәшә. Алар — җанлы, алар тере. Язучы өчен шуннан да зуррак бәхет юк. Ә иң мөһиме — Нәбирәнең әсәрләре җанда көйрәгән Өметне сүндерми.

Безнең бергә барасы юллар озын булыр әле, иншалла. Гомер кыска, юллар озын...

**Ркаил ЗӘЙДУЛЛА**

## Марсель Зариповка 75 яшь

Шагыйрьләр туганда ук шагыйрь булып туа диләр. Ә публицист, очерклар язучы булыр өчен туып-үсеп, илһамны Ходайдан көтеп яту гына җитми, моның өчен тормыш тәҗрибәсе, бик күп һөнәрләрне белү, иҗади сәяхәтләрдә туктаусыз йөрү кирәк. Марсель Зарипов—нәкъ менә шундый кеше. Ул коеп куйган публицист!



Сарман районының Янурыс авылында туып, унбиш яшеннән Петровка спирт заводына гади эшкә урнаша. Армиядә дингезче булып дүрт ел хезмәт итә, аннан кайткач, Әлмәткә килеп «Татнефть» берләшмәсендә электромонтер була.

Һәм, ниһаять, 1959 елдан Әлмәтнең «Знамя труда» газетасы хезмәткәре. 1966 елдан ул инде «Советская Россия» газетасының Татарстандагы махсус хәбәрчесе, нефть районнары тормышына иҗатын бәйли. Юлга чыкканда олы язучыларыбыз аны үзләреннән калдырмый.

М. Зариповның рус һәм татар телләрендә дистәдән артык китабы чыкты. Ул шулай ук Ә. Еники, Н. Фәттах, Г. Ахунов, В. Нуруллин әсәрләрен русчага тәрҗемә итте.

Хөкүмәтебез аның эшчәнлеген күп кенә мактаулы исемнәр, иҗади премияләр белән бәяләде: ул Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның һәм Россиянең атказанган Мәдәният хезмәткәре.

Язучы дустыбыз Марсель Зарипов бүген дә сафта, каләме үткер, сүзе—туры. Без аңа алга таба да иҗади уңышлар һәм сау-таза озын-озак гомер телибез.

*Алхәбәр*

**Кем ул артист? Актерлар нинди уй-гамьнәр дөньясында яши? Сәхнә артистларына режиссер белән уртак тел табу җиңелме, үз-үзеңне раслау өчен нинди сыйфатларга ия булу кирәк...**

**Кыскасы, әлеге тема һәм аңа кагылышлы сораулар безнең матбугатта сирәк яктыртыла диярлек. Юкса тамашачы күбрәк артистларның алкыш һәм чәчәкләргә күмелгән ягын гына күрә. Ә менә тормышта, чынбарлыкта артист кеше ничек уйлый, яши,ниләр кичерә?**

**Хөрмәтле укучыбыз! Әнә шундый күп кенә сорауларга җавапны сез Камал театрының танылган артисты, сәхнәдә күп рольләрне иҗат иткән Әзһәр Шакировның «Язмыштан узмыш» дигән язмасыннан табарсыз. Ул журналыбызның алдагы саннарында басылып чыгачак.**



Лилия
Закирова

*Татарстанның Буа районы, Кайбыч авылында туып-үскән Лилия беренче хикәяләрен мәктәптә укыган елларында яза башлый. Алар «Татарстан яшьләре», «Сабантуй» газеталарында, «Идел», «Ялкын» журналларында басыла. Бүген Лилия КДУның татар факультетында укый.*

# ШАЯН ХИКӘЯЛӘР

### Көндәлек

—Мин синең кебек чагымда өйдәге барлык эшләрне дә үзем эшли идем,—дип орышты Хәлимә апа күзләрен бер ноктага төбәп, берни булмагандай сагыз чәйнәп торучы кызы Алияне.—Әни эштән кайткан вакытка өйне җыештырып, ашарга пешереп куя идем. Ә син...

—Син бит бәләкәй чагында авылда яшәгәнсең,—диде кыз күз карашын кыяр-кыймас кына әнисенә күчереп.—Ә авыл балалары эшчән була. Дәү әни шулай дип әйтте. Сез Казанга күчеп килгәнгә мин гаепле түгел бит инде!

—Шәһәрдә эш беткәнме әллә? Мин бит сиңа җир казырга кушмыйм. Идәндә аунап яткан китапларыңны рәткә китер әнә! Тәртип бозып йөрергә булдырасың бит. Үстердек кызны! Бишенче класска житеп, әйтмәсәң, ашаган савытын да юып куя белми! Ничек яшәрсең син киләчәктә? Һичьюгы кеше арасында үзеңне тәртиплерәк тотсаң икән!

—Мин гаепле түгел,—диде Алия еларга житешеп.—Сумкамны Раилгә аттым мин. Ә ул, җүнсез, иелеп калды. Кем уйлаган аны тәрәзәгә барып тияр дип!

—Кыз кеше малайлар белән сугышып йөрми!

—Дәрес буе чәчтән тартып утырса дамы? Вакытында акылга утыртмасаң, башыңа менеп атлана ул җүнсезләр.

—Нишләп директорга да шулай димәдең?

—Аннары әләкче дип көлеп йөрсеннәрме? Юк инде, мин үзем дә бик шәп алам үчне.

—Ярар алайса, кайткач әтиеңә аңлатып карарсың.

—Әни-и-и...

—Марш бүлмәңә! Мин кергәндә тәртип булсын!

Алия теләр-теләмәс кенә бүлмәсенә атлады. Әни сүзенә каршы килеп булмый шул. Тыңламый гына кара, шундук жил-давыллар кубачак. Әллә кайчан эшләгән һәм эшләнәчәк гөнаһларыңны эзләп табачак. Житмәсә,

бүген директорга чакырттылар үзен. Тәрәзә пыяласын янасына алыштырырга куштылар. Әтисенен генә кәефсез чагы туры килмәсен. Көннәр буе урам чырае күрмичә китап укып ятуын да бик мөмкин...

Тәртип дигән әйбер чыннан да мактанырлык түгел икән шул. Тикмәгә генә дәрес әзерләргә утыргач китап-дәфтәрләрен яртышар сәгать эзләми Алия. Әнә, бүген иртән таба алмый аптыраган «Математика» да бер читтә аунап ята. Кыз китап шкафларын тәртипкә китерергә кереште. Үзенең китапларын барлап чыккач, залдагы киштәне дә җыештырырга булды. «Буш вакытларында азрак китаплар караштырыр идең хет»,—ди бит әтисе орышканда. Хәзер барысын да актарып чыгачак Алия. Тышлыкларындагы рәсемнәре дә дәреслекнекеннән матуррак бугай...

Чехов, Тукай әсәрләре арасында әллә нинди детективлар, мәхәббәт романнары, тагын әллә ниләр бар икән монда. Әтисе юкка гына «кызыклы» китап дип йөртми икән. Рәсемле китапларны актара торгач, Алия шкафның иң аскы бүлегендә яткан тузанланып беткән бер дәфтәргә тап булды. «Көндәлек» дип язылган иде аның тышына. Ә эчендә бернинди билге-фәлән дә күренми. Вәт әкәмәт! Тукта, тукта, «Гарипова Хәлимә» дип язылган түгелме соң? «5 «в» сыйныфы укучысы...» «Үземнең серләремне бары синең белән генә бүлешәм, көндәлегем» дип тә өстәгән. Кы-зык!.. Нинди яшерен серләре булды икән әнисенен?..

«...Бүген математикадан «2»ле алдым. Мисал чишә алмаган өчен түгел (әти әйтмешли, башым шәп эшли минем), партадашым Җәмилнең урындыгына келәй агызган өчен. Мескенкәй, җавап бирәм дип кулын күтәргән иде, урындыктан кымшана да алмый. Шулчак, түзеп тора алмыйча, көлеп җибәрдем. Шул кирәк аңа! Дәрес буе чәчемнән тартып утырмасын иде.»

«...Икенче көн өйдә ятам. Карга күкәйләре карарга менгән җирдән агач башыннан егылып төштем. Әби әйтә: «Малайларга ияреп йөргәч шулай була ул, кыз кеше үзен әдәпле тотарга тиеш»,—ди. Үзем дә беләм, тик Җәмил: «Әйдә, кызык күрсәтәм»,—дигәч, каршы килмәдем инде...»

Тәк-тә-ә-к... Кызык, һаман ниндидер Җәмил... әтинең исемен ник бер телгә алсын! Алия, сулыш та алмый, көндәлекнең алгы битенә күчте.

«...Бүген тагын әни орышты. «Өйне җыештырмыйча көне буе урамда йөрисең»,—ди. Кичә ялгыш төшереп ваткан ваза өчен дә эләкте. Көндәлектәге «2»ле өчен дә. Азрак акылга утырырсың дип бүлмәмә бикләп куйды. Мин дә аптырап тормадым, урындык куеп, форточканы ачтым да, чыгып сыздым. Бүген без Җәмил белән ташу карарга барырга сөйләштек бит. Шундый вакытта тыныч кына өйдә утырып була димени...»

Шулчак бүлмәгә әнисе килеп керде.

Кызының йотлыгып-йотлыгып нидер укып утыруын күреп, эченнән генә шатланып куйды.

—Нинди китап укыйсың, кызым?—диде ул баягыдан күпкә йомшаграк тавыш белән.

—Кызык китап, әни, бик кызык. Бер бик тәртипле кызның тормышы турында. Исеме дә нәкъ синеке кебек.

Хәлимә апа кызының кулында үзенең балачак ядкярен танып алып, агарынып китте.

—Хәзер үк урынына куй! Кем рөхсәт итте сиңа аны укырга?

—Үзегез бит, өйдәге китапханәне укып чыккан бул, дидегез. Теләгегезне үти башладым менә.

—Хәзер үк бир! Кайткач, әтиең белән сөйләшерсең.

—Куям, әни, куям. Әти белән сөйләшер сүзләр дә күп монда. Сер булмаса әйт әле, кем ул Җәмил?

Хәлимә апа дәфтәрне кызы кулыннан тартып алды да, жавап биреп тормый гына бүлмәдән чыгып китте. Алия, әнисе юклыктан файдаланып, ачык калган ишектән урамга атылды. Бүген төнгә чаклы Раил белән уйнаса да, әтисенең бу турыда берни белмәячәген күнеле белән сизенә иде кызчык.

## Оясында ни күрсә...

Мин бер күрүдә үк кемнен кем икәнен чамалыйм. Тышкы кыяфәтен генә түгел, нәрсә белән уйнарга, нинди тәмлүшкәләр ашарга яратканын, хәтта әти-әнисенең кем булып эшләвен дә әйтеп бирә алам. Чынлап! Ялганласам җиде яшемә кадәр мәктәп чырае күрмим!

Менә безнең балалар бакчасын гына алыйк. Елның теләсә кайсы вакытында борын асты ялтырап торган яшь ярымлык Раилдән алып икенче елга укырга керергә тиешле Рәсимгә кадәр әтисе йә әнисенә охшаган.

Кайчан карама, авызын жамаяк кадәрле ачып үкерүче Камилә ашханәгә барыр вакыт житүгә сикереп тора да, мышкылдавыннан туктап, иң беренче булып йөгерә. Тикмәгә түгел. Кеше күрмәгәндә башкаларның кәнфитләрен үзенә шудыру өчен. Шулай булмыйни, экономист Мөнирә апа кызы ич ул! Дөрес булса, авыл халкының байтагының хезмәт хакыннан үзенә өлеш чыгара ди Мөнирә апа.

Адвокат Рифкать абыйның малае Рамил дә тач атасы инде. Малайларның тәпәләшүен күреп алса, шунда ук йөгереп килә. Башта кемнең ничегрәк тукмавын күзәтеп тора. Аннары көчлерәк күренгәненә: «Шулай кирәк! Көчлерәк сыла! Икенче якын килерлек булмасын!»,—дип көч биреп тора. Тәрбияче апа килеп чыга калса: «Рәмис гаепле түгел, ул үзе беренче башлады»,—дип жинүче малайны яклый башлый.

Сәлимәгә аз гына кагылып киттенме, әтинең машина сигнализациясе кебек чиный башлый. Әнисе опера жырчысы аның. Бәлки ул да репетицияләрен бала чагыннан ук башлаган булгандыр...

Пешекче Рәзинә апа кызы Энженең авызы бер вакытта да буш тормый. Әле печенье ашый, әле конфет суыра. Әнисенең зарплатасын тоткарласалар, ипи катысы булса да кимереп йөри. Инде алгы тешләре тәмам череп бетсә дә, бу гадәтеннән биздерә алучы табылмады әле.

Күптән түгел Маркел исемле яңа малайны китерделәр. Көннәр буе уенчык автоматын кыстырып, каш астыннан гына бөтенесен күзәтеп йөри. Монысының әтисе кем икән инде тагын?.. И, Ходаем, үзең сакла!..

Менә шулай. Кызлар әниләрен кабатлап, малайлар әтиләренә охшарга тырышып үсәләр. Бер мин генә андый түгел. Ни әти, ни әни кебек кыланмыйм. Әтиең кем булып эшли соң, дисезме? Журналист ул. Тегеләрнең әти-әниләреннән интервью алып, халыктан ишеткән гайбәткә үзе күргәннәрне дә укмаштырып мәкаләләр язып маташа.

Ярый, минем турыда соңрак сөйләшербез. Теге яңа малай, автоматын терәп, никтер минем янга килә. Әнекәй генәм!.. Теге, әти газетада язып чыккан рэкетер малае түгелме соң бу?! Яхшы чакта тизрәк сызыйм әле мин моннан...

## Чулпан Зариф



Чулпан Әфрәим кызы Четин (Чулпан Зариф, Чулпан Зарипова-Четин) 1969 елда Арча районы Субаш-Аты авылында укытучылар гаиләсендә туа. 1975 елда гаиләсе Арчага күчеп килү сәбәпле, урта мәктәпне Арчада тәмамлый. Мәктәптә укыган елларда район газетасы каршындагы «Тукай якташы» исемле әдәбият-сәнгать түгәрәгенә йөри. Шигырьләре матбугатта күренә башлый.

1987 елда Казан университетының филология факультетына укырга керә, 1988 елда Казан педагогика институтының рус филологиясе факультетына күчә һәм аны 1992 елда уңышлы тәмамлап, татар әдәбияты кафедрасында аспирантурага калдырыла. Студент елларыннан бирле Сәгыйть Рәмиев иҗатын үз итеп, тирәнтен өйрәнә башлый. Аспирантурага кергәч тә шушы юнәлештә эшләвен дәвам итә. 1995 елда «Сәгыйть Рәмиев иҗатында Көнчыгыш һәм Европа эстетикасы контекстында демонизм проблемасы» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. 1995-2002 елларда Казан дәүләт педагогика университетының татар филологиясе факультетында татар халык авыз иҗаты, XX гасыр башы татар әдәбияты һәм борынгы шәрык әдәбияты дигән предметлар укыта.

Аспирантурада укыган һәм Казан дәүләт педагогика университетында эшләгән елларда Республикада чыга торган газета- журналларда шигырьләре һәм мәкаләләре басылып чыга, Бөтенроссия һәм халыкара конференцияләрдә катнаша. Татар әдәбияты кафедрасы каршында оештырылган «Илһам» иҗат оешмасын житәкли. Радио һәм телевидениедә оештырылган әдәби тапшыруларда катнаша.Үзлегеннән төрек телен өйрәнә. 1999 елда татар әдәбияты кафедрасында (КГПИ) доцент дигән фәнни исемгә лаек була.

Соңгы елларда Төркиядә яши, Мугла шәһәре университетында төрки телләр һәм әдәбиятлар кафедрасында төрек телендә татар халык авыз иҗаты, татар әдәбияты, татар теле, рус теле предметлары укыта. Тюркология белән бәйле күп кенә халыкара конференцияләрдә катнаша. Татар халык авыз иҗаты һәм татар әдәбияты белән бәйле актуаль темаларга татар, рус һәм төрек телләрендә мәкаләләре дөнья күрде.

2003 елда рус телендә «Проблема демонизма в творчестве С. Рамиева в контексте восточно-европейской эстетики» («Мастер-Лайн») исемле монографиясе һәм «Кояшка юл тота кәрваным» («Матбугат йорты») исемле шигырь жыентыгы дөнья күрде. 2005 елда С. Рәмиевнең тууына 125 ел тулу уңаеннан «Яңалиф» нәшриятында С. Рәмиев турында замандашлары калдырган истәлекләр, шагыйрьнең совет чорында басылмаган шигырьләре һәм аңа атап язылган шигырьләр, авторның С. Рәмиевнең кызы белән язышкан хатлары, матбугатта элек чыкмаган фотосурәтләр урнаштырылган «Уйласам уй, сызлый күңелем, Сызлый жан...» исемле китабы басылып чыкты. 2006 елда Истанбулда төрекчә-алманча-русча сөйләшү китабы дөнья күрде (З. Бингөл белән берлектә). Төрек телендә «Татар халкының гореф-гадәтләре» исемле китап әзерләнде (Әнкарада «Яңа Авразия» нәшриятына басылу өчен кабул ителде). Татар халык дастаннарын төрек теленә тәрҗемә итеп, аларны фәнни яктан тикшерү проектына катнаша. Интернетта басылып килгән «Татар-информ» хәбәр агентлыгына Төркия һәм Төркиядә яшәүче татарлар белән бәйле хәбәрләр яза.

Соңгы елларда гыйлемгә өстенлек бирсә дә, шигырьләр язуын да дәвам итә.

Быел Язучылар берлеге идарәсе Четин Чулпан Әфрәим кызын Татарстан Язучылар оешмасына әгъза итеп кабул итте.

# *ЖУРНАЛГА ЯЗЫЛУ ДӘВАМ ИТӘ*

*Хөрмәтле укучыларыбыз!*

*2007 елның беренче яртысы өчен вакытлы матбугатка язылу дәвам итә. «Казан утлары»ның индексы—**73210**, Татарстанда ярты елга язылу бәясе **162 сум**.*

*Журналга язылуны җиңеләйтү максатыннан быел да абонемент үрнәген тәкъдим итәбез. Шушы квитанцияне кисеп алып, анда үзегезнең тулы адресыгыз, исем—фамилиягез һәм язылырга теләгән айларны күрсәтеп, үзегез яшәгән җирдәге элемтә бүлегенә тапшырырга кирәк.*

*Казанлылар журналга «Горпечать» киоскларында языла алалар. Бу очракта журналны да шуннан барып аласы була. Фатирыгызда почта әрҗәсе бик үк ышанычлы булмаса, сезгә моннан да кулай ысул юк.*

*«Казан утлары»на язылырга онытмагыз!*

Ф.СП-1

Управление почтовой связи
"Татарстан Почтасы"

**АБОНЕМЕНТ на** ~~газету~~ журнал **73210** (индекс издания)

***Казан утлары***
(наименование издания)

Количество комплектов:

на **2007** год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, имя, отчество)

---

**ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА**

| ПВ | место | литер |
|---|---|---|

на ~~газету~~ журнал **73210** (индекс издания)

***Казан утлары***
(наименование издания)

| | | | |
|---|---|---|---|
| Стоимость | подписки | ____ руб. ____ коп. | Количество комплектов |
| | переадресовки | ____ руб. ____ коп. | |

на **2007** год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, имя, отчество)

## 30 НЧЫ АВГУСТ – ТАРИХИ БӘЙРӘМ КӨНЕ

***

Август аенда быел да Татарстаныбыз олы бәйрәм рухы белән яшәде: аның һәр районы һәм шәһәре Республика көнен билгеләп үтте. 1990 елның 30 августында кабул ителгән дәүләт суверенитеты турындагы Декларация Татарстанның Россия төбәкләре арасында аерым урын алып торуын ассызыклады. Аның белән дөнья күләмендә исәпләшә башладылар. Икътисадый кризис елларында да республикабыз сыгылып төшмәде — һәр тармак үзенең үсешен туктатмады.

Әлбәттә, бәйрәмнең иң зур тантаналары башкалабыз Казанда үтте. Ат узышлары буенча Дөнья кубогының финалы, Татарстан Президенты кубогына автомобиль узышлары, Ярминкә мәйданында танылган сәнгать һәм спорт осталары катнашында зур тамаша... Һәр стадион һәм парк төнгә кадәр гөрләп торды.

Республикабызның башка шәһәрләрендә дә Республика көненә багышланган тантаналар узды. Әйтик, Зеленодолда Республика һәм Шәһәр көненә багышланган бәйрәм чаралары «Авангард» стадионында спорт ярышлары белән башланып китте. Чаллыда Республика көненә багышланган бәйрәм концертлары шәһәр мәйданчыкларында атна буе барды.

Алабуга исә берьюлы өч бәйрәмне - Республика, Шәһәр көнен һәм Нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәрләре көнен билгеләп үтте. Бәйрәм чаралары шәһәр мәйданында үзешчәннәр концерты белән башланды. Биредә шулай ук «Туган як риваятьләре» дигән театрлаштырылган тамаша булды. Алабугалылар Татарстанның атказанган артисты Хәния Фәрхи концертын тамаша кылды.

Түбәнкамалылар Республика көне белән бергә шәһәрнең 40 еллыгын бәйрәм итте. Бәйрәм тантаналары яна социаль объектларны ачудан башланды. Халык иҗаты йорты янында концерт, төрле бәйгеләр булды. Әтиәниләр һәм нәниләрне шәһәр мэры Олег Власов сәламләде. Кичен үзәк сәхнәдә Россия эстрадасы йолдызы Лайма Вайкуле һәм Татарстанның танылган сәнгать эшлеклеләре түбәнкамалыларның күнелен ачты.

***

Президент Минтимер Шәймиев «Пирамида»да Республика көне уңаеннан, тантаналы төстә танылган шәхесләребезне кабул итте. Сәясәт, әдәбият, мәдәният, фән, икътисад һәм башка өлкәләрдә югары дәрәҗәләргә ирешүчеләр катнашында мондый бәйрәм тантанасы быел беренче тапкыр уздырылды.

Президент тантанада Республика көне котлавын җиткерде. Ул чыгышында 16 ел элек Суверенитет турындагы Декларация кабул ителгәннән соң республика ирешкән уңышлар турында сөйләде, узган елда башкалабызның 1000 еллыгы дөнья күләмендә билгеләп үтелүен искә алды. «Декларация кабул итү җитди адым булды. Яңа Россиядә Татарстанның урынын билгеләде. Шушы елларда Татарстанның милли һәм динара дуслыгы өчен күп эшләнде. Җәмгыять аңында татар халкының үткәненә һәм бүгенгесенә карата объектив унай караш формалашты. Моның кадерен белергә тиешбез», — диде Президент.

2006 ел өчен Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен тапшыру бәйрәмнең матур бизәгенә әйләнде. Әлеге бүләккә быел 7 кеше - шагыйрьләр һәм әдипләр Рабит Батулла, Марсель Галиев, Рафаэль Мостафин, Равил Бохараев, композитор Луиза Батыр-Болгари һәм рәссамнар Николай Индюхов белән Фиринат Халиков лаек булган иде.

Президент Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләген лауреатларга шәхсән үзе тапшырды һәм аларны котлап, иҗат уңышлары теләде.

- Югарырак үрләр һәм яңа чорга аяк басу - алда торган максат, - диде Президент, кабул итүгә килгән кунаклар алдында чыгыш ясаганда. - Без озын юл үттек, бу вакыт эчендә шактый үзгәрешләргә дә тарыдык, ул үзгәрешләрнең тәмен дә тойдык. Уртак тырышлыгыбыз нәтиҗәсендә, кайчандыр җинеп булмастай тоелган "каршылыкларны да җинеп, хәл итә ал-мастай мәсьәләләрне дә чиштек...

Башкаладагы бәйрәм тантаналары фейерверк белән тәмамланды.

***

Казан Ратушасында шәһәр мэры Илсур Метшин тантаналы рәвештә «Казанның Мактаулы гражданы» билгеләрен тапшырды.

Әлеге исем Казан Думасы тарафыннан башкаланың үсешенә, Россия һәм дөнья күләмендә аның ролен һәм абруен үстерүгә зур хезмәт өлеше керткән шәхесләргә бирелә. Быел «Казанның Мактаулы гражданы» исеменә җырчы Илһам Шакиров, «Казэнерго» җитештерү берләшмәсе» муниципаль унитар предприятиесе директоры Рәүф Кафиатуллин, «Казгражданпроект» институты» ААЖ генераль директоры Марат Кафиатуллин һәм Россия Президентының Ерак Көнчыгыш Федераль округындагы вәкаләтле вәкиле Камил Исхаков лаек булды.

## ХАЛЫКАРА МӨСЕЛМАН ҖЫЕНЫ

Республика көне алдыннан Казан Ратушасының колонналар залында «Россия-ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеменең икенче халыкара утырышы узды. Бу көнне Татарстан башкаласына гарәп илләре, Төркия мәмләкәте вәкилләре, Россия Федерациясенең Сәүдә-сәнәгать палатасы президенты Евгений Примаков, РФ Президентының Идел буе Федераль округындагы тулы вәкаләтле вәкиле Александр Коновалов, башка рәсми затлар, Россия мөфтиләре шурасы рәисе Равил хәзрәт Гайнетдин, Россия мөселманнары үзәк Диния нәзарәте рәисе Тәлгат Таҗетдин килде һәм чыгышлар ясады. Әлбәттә, җыенда Татарстаннан күпсанлы җитәкчеләр катнашты.

«Россия-Ислам дөньясы» - киңәш органы. Ул Россия белән мөселман илләре һәм ил төбәкләре арасында төрле юнәлештәге хезмәттәшлекне үстерүне максат итеп куя. Төркемнең беренче киңәшмәсе быел март аенда Мәскәүдә узган иде инде.

Казандагы киңәшмәне Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев ачты. Ул дөньяда күпләрне борчыган мәсьәлә - дини яктан аерылуның күтәрелеп чыгуы турында искәртте. «Хәзер үзара мөнәсәбәтләрдә ярыклар барлыкка килде, алар тиз арада упкынга әйләнергә мөмкин. Бергәлек үзендәге кыйммәтләрне башкаларга көч белән тагудан торырга тиеш түгел», - диде Президент. Үзенең чыгышында М. Шәймиев Россиянең, Ислам Конференциясе оешмасында күзәтүче буларак, дөньядагы диннәр арасындагы киеренкелекне бетерергә ярдәм итә алачагын әйтте. Ә Татарстан Исламны үстерүгә дә, Көнбатыш белән Ислам дөньясы арасында хезмәттәшлекне урнаштыруга да үзеннән өлеш кертә алачак, диде ул.

РФ Президентының Идел буе федераль округындагы вәкаләтле вәкиле А. Коновалов форумда катнашучыларга В. Путинның котлавын игълан итте. Шулай ук Ислам Конференциясе оешмасының генераль сәркатибе Әкмәлетдин Ихсаноглының котлавы да укылды. Әлеге котлауда Татарстан һәм аның Президентының Россия белән Ислам дөньясы арасындагы мөнәсәбәтләрдә зур роль уйнавы турында әйтелә.

Россия сәүдә-сәнәгать палатасы президенты академик Евгений Примаков һәм Россия Мөфтиләр шурасы рәисе Равил хәзрәт Гайнетдин бүгенге дөньядагы террорлык актлары белән Ислам дине арасында берниндн уртаклык булмауны ассызыклады.

Утырышта Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, Премьер-министр урынбасары — мәдәният министры З. Вәлиева, башка рәсми кешеләр катнашты.

## КАЗАН — КҮПЛӘР ӨЧЕН БАШКАЛА

Республика көне алдыннан Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев Казан Кремлендәге рәсми резиденциясендә Дәүләт Эрмитажының Халыкара консультатив советы утырышында катнашу өчен башкалабызга килгән дөньяның иң зур музейлары җитәкчеләрен кабул итте.

Очрашуда Британия музее директоры, Халыкара консультатив совет рәисе Нейл Мак-Грегор, Дәүләт Эрмитажы директоры Михаил Пиотровский һ. б. катнашты.

Татарстан Президенты, дөнья музейлары җитәкчеләрен сәламләп, хезмәтегез бөтен кешелек казанышлары белән танышу мөмкинлеге ачуга юнәлдерелгән, дип билгеләп үтте. «Хәзер без, мөмкинлегебезгә карап, тарихи ядкәрләрне торгызу белән бик җитди шөгыльләнәбез, музей эшенә игътибарны күбрәк юнәлтергә тырышабыз», — дип ассызыклады Минтимер Шәймиев.

Очрашудан соң Минтимер Шәймиев һәм Михаил Пиотровский журналистлар сорауларына җавап бирде. «Казанда сезнең Эрмитаж бар, һәм без, биредә Петербург Эрмитажында булганнарның барысы да булачак, дип вәгъдә иттек. Бу юлы без сезгә һәрвакыт Эрмитажда җыелып килә торган Консультатив советны «алып киллек». Казан белән, ә ул, һичшиксез, өченче башкала булып тора, хезмәттәшлегебезне үстерүнең чираттагы этабы бу», — дип басым ясап әйтте М. Пиотровский.

## УНИВЕРСИАДА БЕЗДӘ УЗАРМЫ?

Казан Кремлендә, Президент Минтимер Шәймиев катнашында, 2011 елда XXVI Бөтендөнья җәйге универсиаданы үткәрү урыны итеп Казанны билгеләүгә кагылышлы киңәшмә булды.

Билгеле булганча, Татарстан 2011 елда XXVI җәйге универсиаданы Казанда уздыру өчен Халыкара студентлар спорт берлегенә гариза тапшырды. Гариза инглиз һәм француз телләрендә, буклет һәм 10 минутлык фильм рәвешендә җибәрелгән. Россиядән тыш, Универсиада-2011не үткәрүгә Испаниянең — Мурсия, Тайваньның — Ка-

ошинь, Кытайның — Шенжень һәм Польшаның Познань шәһәрләре теләк белдергән. Мәгълүм булганча, Бөтендөнья универсиадасы — мөһимлеге һәм дәрәҗәсе буенча, Олимпия уеннарыннан кала, икенче урында торучы халыкара спорт чарасы булып исәпләнә.

Минтимер Шәймиев Татарстан горурлана алырлык казанышларның Бөтендөнья универсиадасын Казанда уздыру өчен җирлек тудыруын һәм моңа башлыча барлык шартларның да булуын ассызыклап үтте. «Без универсиада үткәрүгә дәгъва кылуыбыз белән дөрес адымга бардык, ятып калганчы, «атып» калырга кирәк. Билгеле, моңа алыну үзе зур ихтыяр көче, теләк һәм ышаныч таләп итә. Җиңүгә дәгъва кылучылар сафына нигә әле безгә дә басмаска һәм шундый зур күләмдәге вакыйга урыны өчен ахыргача көрәшмәскә?» — диде ул. Россия Физик тәрбия һәм спорт буенча федераль агентлыгының физик тәрбия идарәсе башлыгы Станислав Бирюков, төп җитди көндәш итеп Испаниянең Мурсия шәһәрен атады. Аның сүзләренә караганда, Испаниянең Европа Берлегенә керүе дә зур өстенлек булып санала икән. Виза таләп ителмәү дә катнашучылар өчен унай шарт булып тора.

### ТАТАР ЯШЬЛӘРЕ ТАТАРСТАНДА

Биектау районының «Байтик» савыктыру лагеренда Татар яшьләре көннәре булып узды. Бу чарада Волгоградтан, Самара, Оренбур, Пенза, Иваново һ. б. өлкәләрдән, шулай ук Башкортстаннан, Мордовия, Латвия һәм Казакъстаннан 150 кеше катнашты.

Татар яшьләре көннәре инде 16 ел үткәрелеп килә. Форум кысаларында яшьләр проблемаларын үзәккә алган «түгәрәк өстәл»ләр узды, Россия төбәкләрендә һәм якын чит илләрдә яшьләр сәясәтен тормышка ашыру буенча тупланган тәҗрибә өйрәнелде. Яшь буынның милли үзаңын үстерү мәсьәләләренә зур игътибар бирелде. Татар яшьләре көннәрендә катнашучылар Тукайның туган җире — Кырлайда булды, 30 августта Республика көне бәйрәмен тамаша кылды.

### ТАТАР КИНОСТУДИЯСЕ ХАКЫНДА

Президент Минтимер Шәймиев «Пирамида» мәдәни-күңел ачу комплексында РФ Президенты каршындагы мәдәният Советы президиумы әгъзасы, Россия мәдәният фонды рәисе, Россия Кинематографиячеләр берлеге рәисе, танылган кинорежиссер Никита Михалков белән очрашты. Очрашуда Премьер-министр урынбасары - мәдәният министры Зилә Вәлиева катнашты.

Очрашу тәмамланганнан соң, журналистларга биргән интервьюсында Н. Михалков болай диде: «Бөтенләй диярлек үз киносыз калган Идел буенда киностудия төзү бик кирәк. Илдә күтәрелгән кинематографик шау-шу шартларында Казанга фильм төшерергә Россиянең күп кенә төбәкләреннән килачәкләр. Биредә татар милли фильмнары да төшерелер дип ышанам. Үз вакытында грузин, үзбәк кинематографиячеләренең ана телләрендәге сокландыргыч картиналары русчага тәрҗемә ителеп, бердәм совет мәдәнияте казанышына әверелә иде. Бүген исә нәкъ менә шулай итеп татар киносы төшерелергә, тора-бара ул бөтен Россия халкы өчен аңлаешлыга әйләнергә тиеш. Бары тик чын милли кыйммәт кенә чын мәгънәсендә интернациональ булырга сәләтле».

З. Вәлиева бу җәһәттән Казанда киностудия төзү өчен бөтен иҗади мөмкинлекләрнең булуын билгеләп үтте: талантлы сценарий авторлары, югары белемле режиссерлар да җитәрлек бездә, тулы метражлы нәфис фильмнар («Күктау», «Зөләйха»), документаль фильмнар төшерү тәҗрибәсе дә бар. Проблема бары тик проектны финанслауда, кыйбатлы җиһазлар сатып алуда гына. Республикада күпләп театрлар эшләгән бүгенге чорда сәнгатьнең иң заманча формасы булган киноны да гамәлгә кую кирәклеген искәртте З. Вәлиева. Мәдәният министрлыгы бер квартал эчендә киностудия төзү концепциясен эшләргә, аның белән Россия Кинематографиячеләр берлеген таныштырырга һәм шуннан соң Татарстан Президенты каравына кертергә тиеш.

### МУЗЕЙГА КАЙТКАН ТАРИХ

ТР Милли музеенда «Татарстанның борынгы тарихы» дип исемләнгән даими экспозиция эшли башлады.

Экспозицияне ачу тантанасында, башкалабызның мәртәбәле кунаклары белән бергә, Россия Дәүләт эрмитажы директоры Михаил Пиотровский, Британия музее директоры Нил Мак-Грегор, музейлар буенча Франциядәге Халыкара үзәкнең генераль директоры Мунир Бушенаки, Лувр музее директоры Анри Луаретт һәм башка шәхесләр катнашты.

Концепциянең авторы — Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты хезмәткәре Дмитрий Бугров. Иҗат төркеме: ТР Милли музееның генераль директоры, тарих фәннәре кандидаты Гөлчәчәк Нәҗипова, аның урынбасары Светлана Измайлова, археология бүлеге мөдире, тарих фәннәре докторы Константин Руденко һәм археология бүлегенең фәнни хезмәткәре Ольга Бражник. Милли музейның тарихи экспозициясен торгызу буенча фәнни җитәкче - тарих фәннәре докторы Индус Таһиров.

Яна экспозициядә 400 гасырдан артык дәверне гәүдәләндергән археология һәйкәлләре урын алган. Экспозициянең үзенчәлеге — палеолит дәвереннән алып, тимер гасырының башлангыч чорына кадәр кешелек үсешенең гомуми тенденцияләрен бо-

рыңгы кешеләрнең көнкүреш әйберләре аша яктырту. Җәмгыять үсешен күрсәтү өчен, экспозициядә «Кеше һәм табигать», «Әйберләр дөньясында», «Йорт һәм тышкы дөнья» кебек кешенең тирә-як белән мөнәсәбәтен чагылдырган темалар сайлап алынган. «Төрки каганлыгы һәм Идел Болгарының башлангыч чоры» экспозициясе исә биредә үзенә бер бүлек тәшкил итә.

## «ЯҢА ГАСЫР» ЯҢАЧА ЭШЛИ

21 августтан «Яңа гасыр» радиосы яңа тапшырулар челтәренә күчте. Шул уңайдан бүген «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясендә «түгәрәк өстәл» утырышы узды. Анда «Яңа гасыр» генераль директорының радио- тапшырулар буенча урынбасары Тәлгат Сабитов, "Яңа гасыр" радиосының баш мөхәррире Илнур Фәйзрахманов, яңалыклар бүлеге мөхәррирләре, даими тыңлаучылар катнашты.

Тәлгат Сабитов әйтүенчә, радио тулысынча диярлек татар телендә сөйләүгә күчәчәк. Рус телендә исә бары тик яңалыклар һәм берничә тапшыру гына калачак. «Яңа гасыр»да иртәнге тапшырулар тулысы белән үзгәрәчәк, ул «Шаулы иртә» дигән исем астында узачак. Илнур Фәйзрахманов әйтүенчә, иртәнге якта тыңлаучыларга «җиңел» тапшырулар тәкъдим ителәчәк. Ягъни, уен-көлке, соңгы яңалыклар, кызыклы мәгълүмат, төрле шәхесләр, гади тыңлаучылар белән күңелле аралашулар булачак.

Иң озын, ягъни бер сәгатьлек «Безнең мөнбәр» дигән тапшыру җомга көнне эфирга чыгачак. Яңалыклар исә ярты сәгать саен татар һәм рус телләрендә аралаштырып биреләчәк.

Киләчәктә шимбә-якшәмбе көннәрендә театр архивларында булган татар спектакльләрен дә бирү күздә тотыла.

## БАТЫРЛАР ОНЫТЫЛМЫЙ

25 август — җәлилчеләрне искә алу көнендә ТР Милли музеенда каһарман-шагыйрьнең тууына 100 ел тулуга багышланган күчмә күргәзмә ачылды.

Билгеле булганча, бу ел җәлилчеләр - Фуат Сәйфелмөлеков, Абдулла Батталов, Зиннәт Хәсәнов һәм Сәлим Бохаровларның да юбилей елы. Аларның тууына 90 ел тула.

Күргәзмә М. Җәлилнең иҗатын һәм тормыш юлын чагылдыра, аның иҗатташ дуслары, Моабит төрмәсендәге фикердәшләре белән таныштыра. Экспозициядә ТР Милли музеенда, ТР Милли архивында, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының кулъязмалар архивында сакланган күп кенә уникаль документлар һәм фотолар урын алган. Алар арасында Париж архивында табылган Г. Кормашка кагылышлы документ беренче тапкыр күрсәтелә.

## СӘЙДӘШНЕ САГЫНУ БӘЙРӘМЕ

Югары Ослан районының Кызыл Байрак авылында бөек композитор Салих Сәйдәшев истәлегенә багышланган традицион сәнгать бәйрәме булды. Тантанада Г. Камал исемендәге академия театры артистлары, танылган язучылар, композиторлар, музыкантлар, Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе артистлары катнашты. Алар театральләшкән тамаша ярдәмендә Салих Сәйдәшев тормышын яктырттылар, шулай ук композитор көйләрендә уйнала торган «Казан сөлгесе», «Зәңгәр шәл», һ. б. спектакльләрдән өзекләр күрсәттеләр, аның җырларын яңгыраттылар. Сәйдәшкә багышланган бу бәйрәм инде җиденче тапкыр үткәрелә.

## «ГАЛИЯ» МӘДРӘСӘСЕНӘ — 100 ЕЛ

Уфадагы данлы «Галия» мәдрәсәсенең 100 еллык юбилее быел октябрь аенда югары дәрәҗәдә билгеләп үтеләчәк.

Башкортстан Республикасы Премьер-министры Рафаэль Байдәүләтов имзалаган Карарга ярашлы рәвештә, юбилейны үткәрү программалары кысаларында, «Инкыйлабка кадәр булган дини белем бирү учакларының халыкны мәгърифәти агартудагы роле» дигән фәнни-гамәли конференция үткәреләчәк, республика радиосы һәм телевидениесе тарафыннан тематик тапшырулар әзерләнәчәк. «Галия» мәдрәсәсенең эшчәнлегенә, аны тәмамлап чыгучыларга багышланган күргәзмәләр оештырылачак.

Бөтен Шәрык дөньясына танылган «Галия» мәдрәсәсе 1906 елның 10 октябрендә рәсми рәвештә ачыла. Әлеге мәдрәсәнең дини һәм дөньяви белем бирүче югары уку йорты буларак барлыкка килүе күренекле мәгърифәтче, дин һәм җәмәгать эшлеклесе Зыяэддин Камалетдинов (Зыя Камали) эшчәнлегенә бәйле. «Галия» мәдрәсәсенең әле дә сакланган өч катлы бинасы, нигездә, татар сәүдәгәре С. Назыйров һәм морзабикә С. Янтурина акчаларына салынган була. Мәдрәсәнең уку программасында, ислам диненең тарихы һәм фәлсәфәсе, Коръән тәфсире һәм башка дини предметлар белән беррәттән, психология, педагогика, дидактика фәннәре булган; гарәп, төрек, төрки телләре һәм язмалары өйрәтелгән. Язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов мәдрәсәдә татар теле һәм әдәбияты буенча дәресләр биргән.

«Галия» мәдрәсәсен тәмамлаучылар арасында Шәехзадә Бабич, Сәйфи Кудаш, Солтан Габәши, Мәҗит Гафури, Хәсән Туфан кебек төрки-татар дөньясында танылган шәхесләр бар.

## ШАГЫЙРЬ ПРЕМИЯСЕ

Татарстанның Балык Бистәсе районы — республикабыздагы әдәбият һәм сәнгать тор-

мышында шактый мәртәбәле талантияләре белән танылу алган як. Татарстан Язучылар берлегендә генә дә аннан чыккан ике дистәгә якын әдип санала. Кайбер галимнәр һәм әдәбият белгечләре раславынча, мәшһүр шагыйрь Кол Гали нәкъ менә әлеге җирдәге борынгы болгар шәһәре Кашанда дөньяга килгән, шунда яшәгән булган. Балык Бистәсе халкы үзенең Идрис Хәлфә, М. Укмаси, М. Гали, З. Бәширова, С. Шәкүров, К. Сибгатуллин кебек сүз осталары истәлеген дә күңелләрендә кадерләп саклый. Иҗатларына илһам алган туган якларына күренекле язучылар Р. Фәйзуллин, В. Нуруллин, Р. Әхмәтҗанов, Ә. Гаффар, М. Шиһапов һәм башкалар еш кайталар, якташлары белән әледән-әле очрашып торалар.

Төбәкнең мәдәни тормышында яшь һәм башлап язучыларга халык шагыйре Равил Фәйзуллинның шәхсән үз премиясен бирү матур бер традициягә әйләнеп бара. Быел июль аенда әлеге премиягә ун кеше, шул исәптән, яшь авторлар Алинә Бикмуллина, Ләйсән Фәтхетдинова һәм Юлия Чебышева лаек булды. Бүләк ияләрен танылган язучы, профессор Т. Галиуллин, шагыйрь Ә. Гадел, халык рәссамы А. Абзгильдин, төбәктәге җәмәгать вәкилләре кайнар котлады һәм киләчәк иҗатларында яңа уңышлар теләде.

### БАРДАДА ГАЗЕТА БӘЙРӘМЕ

Пермь краеның Барда районында чыгып килүче «Таң» газетасы үзенең 75 еллыгын билгеләп үтте. Шул уңайдан бирегә «Милли матбугат: тарих, тәҗрибә, перспективалар» дигән төбәкара фәнни-гамәли конференция, Барда мәдәният йортында зур бәйрәм кичәсе булды.

Кунаклар арасында Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Журналистлар берлеге рәисе Р. Ратникова, Пермь крае Законнар чыгару җыены Рәисе Н. Девяткин, РФ Дәүләт Думасы депутаты Ю. Медведев, галим һәм язучы Р. Ягъфәров, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, җырчы һәм композитор М. Имашев, композитор, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Л. Батыр-Болгари, «Мәдәни җомга» газетасының бүлек мөдире Н. Сәйяр, һәм Башкортстан вәкилләре бар иде.

Соныннан кунаклар Барда районы Танып авылының 450 еллык юбилей бәйрәмендә катнашты.

### «ҖИДЕГӘН ЧИШМӘ» БАЛКЫП ТОРАЧАК

Мәдәният министрлыгының декоратив-гамәли сәнгать буенча комиссиясендә Сара Садыйкованың тууына 100 ел тулу уңаеннан куелачак һәйкәлнең макетын тикшереп раслау булды. Макеттан күренгәнчә, һәйкәл үзенчәлекле бер композиция тәшкил итә, һәм ул «Җидегән чишмә» дип атала. Макет-композициянең авторлары — күренекле сынчы Рада Нигъмәтуллина, аның кызлары Белла Рогожина һәм Марина Нигъмәтуллина.

Һәйкәл макеты һәм «Җидегән чишмә» композициясе буенча фикер алышуда Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, шагыйрь Разил Вәлиев, Мәдәният министрлыгының бүлек мөдире Розалия Нургалиева (хәзер ул Татарстан дәүләт сынлы сәнгать музее директоры), Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры директоры Шамил Закиров, Сара Садыйкова иҗтимагый фонды рәисе Әзһәр Хөсәенов, рәссамнар Игорь Башмаков, Мәхмүт Гасыймов һ. б. катнашты. Һәйкәлнең архитектура композициясе буенча фикер алышуда катнашучылар аны бертавыштан унай бәяләде.

Сара Садыйковага багышланган «Җидегән чишмә» исемле архитектура композициясе Казанның Юнысовлар мәйданында, Г. Тукайның әдәби музее янында урнаштырылачак.

***

2006 елның 3 сентябрендә күренекле галим, тарих фәннәре докторы, журналыбызның даими авторы **Әмирханов Равил Госман улы** 60 яшендә вафат булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Казан флоты. Н. Хаҗиәхмәтов рәсеме.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Алмаз Гыймадиев**.

# Яңа китаплар




Хөсәен Фәезханов: **тарихи-документаль җыентык** («Шәхесләребез» сериясе). —Казан: «Җыен» нәшр., 2006. —704 б. Тиражы—2000 данә.

Бу җыентыкта XIX гасыр татар галиме Хөсәен Фәезхановның фәнни хезмәтләре тупланды. Алар матбугатта беренче мәртәбә тулы рәвештә нәшер ителә.

Фәезхановның татар мәдрәсәләрен реформалаштыруга һәм татарларда мәгариф тарихына багышланган «Ислахы мәдарис», «Рисалә» әсәрләре, «Казан тарихы», «Касыйм ханлыгы» һәм Болгар дәүләте дәверендәге утызга якын борынгы эпитафик истәлекләрне—кабер ташларындагы язуларны тасвирлауга багышланган тарихи кыйммәткә ия хезмәтләре фән әһелләре өчен дә, киң катлау укучыларга да кызыклы булыр. Китапта шулай ук Фәезхановның остазы Ш. Мәрҗанигә һ. б. шәхесләргә язган хатлары, әһәмиятле архив документлары, галимнең тормышына һәм эшчәнлегенә багышланган мәкаләләр, библиографик мәгълүматлар бергә тупланган.

Китапның төзүче-авторы—Раиф Мәрданов, фәнни мөхәррире—Миркасыйм Госманов.




Әхәт Сафиуллин. **Җиденче буын: юмористик һәм сатирик хикәяләр.** —Казан: «Рухият» нәшр. 2006. —392 б. Тиражы—1000 данә.

Әхәт Сафиуллин—гомеренең төп өлешен төзелеш эшенә багышлаган кеше. Шул ук вакытта ул язучы буларак та укучыларга яхшы таныш. 50 нче еллар ахырында ук яза башласа да, аның иҗаты соңгы дистә елларда танылу алды, 80 нче еллардан башлап бүгенге көнгә кадәр бер-бер артлы унлап китабы дөнья күрде («Язларында ялгыз йөрсән», «Онытылган вәгъдә», «Сер бирмәдек», «Туган як җилләре», «И гомер, гомер...» һәм башкалар.

«Җиденче буын»—авторның чагыштырмача иң күләмле китабы. Бу китапка төрле елларда язылган җылы юмор, чәнечкеле тел, усал сатира белән сурәтләнгән хикәяләр, монологлар, памфлет һәм фельетоннар тупланган.

Китапның мөхәррире—Р. Миннуллин, рәссамы—Р. Хәсәншин.



Алмаз Гыймадиев

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)